*Р.А.Юсупов*

# Туган тел һәм мәгърифәт

# *Родной язык и образование*

Казань
"Слово"
2020

ББК 72
УДК 001
Ю91

Редактор – *Д.М.Юсупова*

**Юсупов Р.А.**

Ю91 Туган тел һәм мәгърифәт. Родной язык и образование. – Казань: Изд-во “Слово”, 2020. – 272 с.

Академик Рүзәл Юсуповның бу китабында татар телен куллану, саклап үстерү һәм өйрәтү-укытудагы проблемалар, бурычлар бәян ителә.

В данной книге академика Рузаля Юсупова излагаются проблемы, задачи употребления, сохранения, развития и преподавания татарского языка.

ISBN 978-5-98356-369-8

© Р.А. Юсупов, 2020
© Оригинал-макет ООО “Слово”, 2020

# ТЕЛНЕ САКЛАУ ҺӘМ ҮСТЕРҮ
# СОХРАНЕНИЕ И РАЗВИТИЕ ЯЗЫКА

## ТЕЛ ӨЛКӘСЕНДӘГЕ МӨҺИМ БУРЫЧЛАР

Татарстан парламентының тел мәсьәләсендәге соңгы карары нигезендә укучыларны татарчага өйрәтүне нәтиҗәлерәк итеп оештыруны, безнең фикеребезчә, татар телен факультатив рәвештә һәм атнасына ике сәгать күләмендә генә укытырга дигән күрсәтмә нинди уку йортларына һәм укучыларның кайсы контингентына карый дигән сорауны ачыклаудан башларга кирәк. Бу турыда Дәүләт Советының карарында ачык итеп әйтелмәгән. Монда шуны да искәртү мөһим: соңгы айларда мәгълүмат чараларында һәм төрле аудиторияләрдә татар телен өйрәтү хакында барган кызу фикер алышуларда бу телне уку йортларының кайсы төрендә һәм нинди милләт укучыларына укыту турында тәгаенләп әйтелгән сүз булмады. Хәлбуки, бу проблеманы шулай гомумән генә карау мәсьәләне барлык укучыларның һәм аларның ата-аналарының мәнфәгатьләрен, шулай ук республика халыкларының рухи-мәдәни үсеше перспективаларын исәпкә алып, объектив хәл итәргә мөмкинлек бирми.

Укучыларны татар теленә өйрәтү эшен оештыру мәсьәләләре, һичшиксез, республикадагы гомуми белем бирү уку йортларының төп ике төре – мәктәп, гимназия, лицейларның татар телендә укытыла торганнары һәм рус телендә укытыла торганнары булуын исәпкә алып гамәлгә ашырылырга тиеш. Аларда татар телен укыту бер үлчәм, бер үрнәк буенча һәм бертөрле нәтиҗәләр белән башкарыла алмый, һәм, әлбәттә, республика парламентының, үзәк хакимият органнары күрсәтмәсен үтәп, дәррәү килеп, мәсьәләне тикшереп тә тормыйча кабул ителгән туган телне факультатив нигездә атнасына ике сәгатьтән арттырмыйча гына укытырга дигән карары һич кенә дә татар мәктәпләренә карата булырга тиеш түгел. Милли мәктәптә туган тел укытуны ике сәгать белән чикләү бу мәктәп укучыларын һәм аларның ата-аналарын мыскыл итү булыр иде.

Татар мәктәпләренең статусы, Россиядәге башка милли уку йортларыныкы кебек үк, кагылгысыз: ул Россия Федерациясе

Конституциясе һәм Россиянең Мәгариф турындагы законы белән беркетелгән. РФ Конституциясенең 68нче статьясы *“**барлык халыкларның да туган телләрен саклау, аларны өйрәнү һәм үстерү өчен шартлар булдыру хокукын гарантияли**”*. РФнең Мәгариф турындагы законы исә ***“Россия Федерациясе гражданнарының төп гомуми белемне аларның туган телләрендә алу хокукын раслый”*** (6нчы статья). Димәк, республика укыту теле укучыларның ата-аналары теләгенә карап билгеләнгән санда милли уку йортлары булдырырга тулы хокуклы, һәм аның гражданнары дәүләт тарафыннан ***“кирәкле күләмдә тиешле мәгариф учреждениеләре, класслар, группалар белән тәэмин ителүгә һәм аларның гамәлдә булуы өчен шартлар тудырылуына”*** исәп тота алалар (РФнең мәгариф турындагы законының 6нчы статьясы, 2нче пункты).

Татарстандагы милли уку йортларының уңышлы эшләвенә ирешү өчен, Мәгариф һәм фән министрлыгының дәүләт мәгариф стандартларындагы федераль һәм милли-региональ компонентларның, шулай ук мәгариф учреждениесе компонентының нисбәтен ачык һәм катгый итеп билгеләве бик әһәмиятле. Бу мәсьәлә хәзерге вакытта, Россия Федерациясенең Мәгариф һәм фән министрлыгы, мәгариф турындагы законны бозып, дәүләт стандартларыннан региональ компонентны юкка чыгарып, хәтта Россия Федерациясе халыкларының һәм этносларының туган телләре, әдәбиятлары, тарихлары буенча уку программаларын, дәреслекләрен төзү һәм чыгару хокукын да үзләренә алган чакта аеруча актуаль. Үзәк хакимиятнең чиксез тоталитаризм, үзәкләштерү һәм вертикальлек стиле белән эш итүе шушы була түгелме инде?! Россиядәге уннарча халыкларның телләрен, әдәбиятларын, тарихларын укытуны оештыру мәсьәләләренең бары тик федераль мәгариф министрлыгы тарафыннан гына хәл ителүе аек акыллы кешенең башына сыярлык күренешме соң? Бу халыкларны кимсетү, аларның законлы мәнфәгатьләре белән исәпләшмәү була түгелме соң?!

Бу хурлыклы хәлдән котылып, федераль һәм республика министрлыкларының дәүләт мәгариф стандартлары белән бәйләнешле вазыйфаларын үзара бүлешү тәртибен үзгәртергә, төгәлрәк итеп әйткәндә, дәүләт стандартларындагы милли-региональ компонентны торгызып, аны республика мәгариф министрлыкларына бирер вакыт җитте. Туган телләрне, әдәбиятларны һәм җирле тарихны өйрәнүгә бирелә торган вакытны билгеләү, бу предметларның структурасын һәм эчтәлеген төзү белән рес-

публика мәгариф һәм фән министрлыгы мөстәкыйль рәвештә шөгыльләнергә тиеш. Татарстанның мәгариф һәм фән министры, дәүләт күләмендәге җитди эшләрне башкарган зур тәҗрибәле кеше буларак, республика җитәкчелеге ярдәме белән, мәктәптә татар халкының теленә, мәдәниятенә һәм тарихына караган дисциплиналарны укытуны оештыруда, элекке заманнарда булганча, элементар мөстәкыйльлеккә ирешер дип ышанасы килә. Бу уңайдан Россия Федерациясенең мәгариф турындагы законының 6нчы статьясы белән таныштырып китү урынлы булыр: ***"Дәүләт телләрен укыту мәсьәләләре шул республикаларның законнары нигезендә гамәлгә ашырыла".***

Татар телендә гомуми белем бирә торган уку йортларының эшләве законлы күренеш булуы турындагы мәсьәләне көн тәртибенә кую шуның өчен бик әһәмиятле һәм актуаль: хәзерге вакытта төрле объектив һәм субъектив сәбәпләр аркасында республикабыздагы татар мәктәпләре, гимназия һәм лицейларының эшләве өчен мөмкинлекләр көннән-көн кими бара. Татарстаннан читтәге андый уку йортларының хәлен сөйләп тә торырлык түгел инде. Бу күренешнең сәбәпләре ниләрдән гыйбарәт соң?

Беренчедән, соңгы елларда татар мәктәпләре мондый схема белән башкарыла торган оптимизация аркасында нык кимеде: аз санлы балалар укыган татар уку йортын рус мәктәбенә кушып куялар да, элекке татар мәктәбе укучыларын русча укыта башлыйлар.

Икенчедән, Мәскәү әмере белән милли мәктәпләрдә чыгарылыш имтиханнарын рус телендә тапшыру һәм абитуриентларны шул билгеләре буенча югары уку йортына кабул итү тәртибе кертелү аркасында, татар мәктәпләрендә русча укуга күчә баралар.

Өченчедән, хакимиятнең милли мәктәпләргә салкын караштa торуы ата-аналарның балаларын укырга татар мәктәпләренә бирү теләкләрен бетерә.

Әгәр моннан соң да шундый хәл дәвам итсә, Татарстан хакимияте, рус мәктәпләрендә татар телен укытудагы кебек, бу күренешкә битараф булса, күп тә үтми, татар мәктәпләренең юкка чыгуы көне дә килеп җитәргә мөмкин. Бу исә татар әдәби теле кулланылыштан чыгып, тиздән татар мәдәниятенең һәм шуның белән бергә татарларның үзләренең дә алдынгы милләт буларак яшәүдән туктавына китерәчәк дигән сүз.

Республика җитәкчеләре, татар халкына мондый куркыныч янавын күреп, тыныч кына карап тора алмаслар һәм, моны булдырмас өчен, тиешле чаралар күрерләр дип өметләник.

Бу уңайдан Татарстанның мәгариф һәм фән министрлыгы җитәкчеләре алдында нинди мөһим бурычлар тора соң?

Хәзерге вакытта Татарстан дәүләтенең һәм гражданнарының иң әһәмиятле, хәлиткеч бурычы ул – татарча уку йортларын саклап калу һәм арттыру. Бу төп бурычны гамәлгә ашыру мондый проблемаларны хәл итү белән бәйләнгән.

Беренчедән, тиз арада оптимизация сылтавы белән татар мәктәпләрен киметүне, дөресрәге, ябуны туктатырга кирәк. Ул мәктәпләрне укучылар саны дәүләт нормативларына туры килмәгәндә дә саклап калу зарур. Мондый очракларда, бу мәктәпләрне эшләтү өчен, дәүләтнекеннән тыш финанслау чыганакларыннан: төрле фондлардан, предприятие-оешмаларның, зур материаль байлыкларга ия булган кешеләрнең инвестицияләреннән, ярдәмнәреннән, хәтта чит ил фондларыннан да файдалану урынлы булыр. Чит илләрдә, мәсәлән, Финляндиядә, балаларны туган телләренә класста хәтта ике-өч кенә бала булганда да өйрәтүләрен үрнәк итеп алырга кирәк. Монда шуны истә тоту зарур: татар мәктәпләрен саклап калу һәм аларның санын арттыру бигрәк тә авыллар өчен әһәмиятле, чөнки мәктәп ул – мәгърифәт, мәдәният үзәге, һәм татар теле, культурасы, нигездә, татар авыллары аркасында сакланып килә.

Икенчедән, дәүләткә, бөтен көчен салып, татар мәктәпләренең материаль базасын ныгытырга, аларны иң яхшы укытучылар белән тәэмин итү чараларын күрергә, шулай ук татар телендә укытыла торган абруйлы яңа мәктәпләр булдыру юлларын табарга, бу максатларда миллиардлаган, күп миллионлаган долларга ия булган хәлле кешеләрнең капиталларын җәлеп итәргә кирәк.

Өченчедән, республика Президентының, парламентының, шулай ук Татарстаннан сайланган Дәүләт Думасы депутатларының мөмкинлекләрен бергә туплап һәм үз хокукларыннан файдаланып, башка республикаларның җитәкчеләре, депутатлары белән бер фикергә килеп, руслардан башка халыкларның барысы өчен дә хурлыклы күренешне – милли уку йортларында укучылардан чыгарылыш имтиханнарын рус телендә тапшырту тәртибеннән котылуга ирешергә кирәк. Югыйсә, башка сыймаслык хәл бит бу: 11 ел буена туган телләрендә укыган яшьләр чыгарылыш имтиханнарын баш-

ка телдә тапшырсыннар! Үзәк хакимият әһелләре ничек итеп мондый карарга килгәннәр икән һәм республика җитәкчеләре, ниләр уйлап, бу акылга сыймаслык хәлгә риза булдылар икән?! Мондый хәлнең хәтта кайберәүләр бик рәхәтләнеп тәнкыйтьләгән Сталин заманында да булганы юк иде.

Дүртенчедән, республиканың мәгариф һәм фән министрлыгының иң беренче бурычларыннан берсе, бөтен чараларны кулланып, татар мәктәпләрендә укыту эшенең структурасын һәм эчтәлеген камилләштерү, шулай ук барлык дисциплиналарны да укытуның сыйфатын күтәрү булырга тиеш. Шул ук вакытта бу мәктәпләрдә укучыларны туган телгә, рус һәм инглиз телләренә өйрәтүне игътибар үзәгендә тоту зарур. Татар мәктәпләре һәръяктан да иң яхшылардан булырга тиеш.

Бишенчедән, хәзерге вакытта татарларның күбесендә үзләренең телләренә, культураларына карата патриотлык рухы җитәрлек булмавын истә тотып, республика җитәкчелегенә халыкның төрле катлауларында, бигрәк тә яшь буында, лаеклы кешеләр була белү, үз халкыңны зурлау, аның үткәне һәм хәзергесе белән горурлану сыйфатлары тәрбияләү ихтыяҗын гамәлгә ашыру турында уйларга кирәк. Моның өчен уңайлы җирлек бар: татарлар – борынгы күркәм тарихлы, алдынгы культуралы, хезмәт сөючән, максатчан, игелекле традицияләре, гореф-гадәтләре һәм башка төрле уңай сыйфатлары булган халык. Татар милләтеннән бөтен дөньяга танылган күп санлы мәшһүр галимнәр, мәдәният хезмәткәрләре, сәнгать эшлеклеләре, спорт осталары, зур хәрби начальниклар, сугыш һәм хезмәт батырлары бар. Аларның һәркайсы – югары үрнәк һәм горурлык хисләре уятырлык шәхес. Мәгълүмат чараларыннан кирәгенчә оста файдаланып, аларны халыкка мәгълүм итәргә кирәк. Бу эш татар халкында милли горурлык хисләре тәрбияләүдә, милли рухны күтәрүдә нәтиҗәле чара булыр һәм ахыргы исәптә татарларда үзләренең тарихы, мәдәнияте белән кызыксыну, туган теленә мәхәббәт уятыр иде.

Татар телен саклау һәм үстерүнең нигезе уңышлы эшли торган татар мәктәпләре булса, татарларның үз халкының алга баруына, прогрессына хезмәт итә алырлык яшь буынын тәрбияләү өчен шактый нык резерв ул – республикабыздагы укучыларының яртысы чамасын татар балалары һәм яшьләре тәшкил иткән рус мәктәпләре. Әгәр дә республиканың башкарма органнары, беренче чиратта мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан республикасы

халыкларының телләре турындагы закон кабул ителгәннән соң узган чирек гасырда рус мәктәпләрендә татар теле укытуны тиешле дәрәҗәдә оештыра алган булсалар, республикабыз үзенә уңышлы хезмәт итә һәм татар халкының рухи культурасы үсешенә лаеклы өлеш кертә алырлык йөзләрчә мең яшь егет һәм кызларга ия булган булыр иде.

Юк шул! Килеп чыкмады. Мәгариф органнары мәктәпләрдә татар һәм рус телләрен тигез күләмдә укыту турында закон бар, укытучылар эшлиләр, мәктәпләр дәреслекләр белән тәэмин ителгән, димәк, балалар укыйлар һәм татар теленнән тиешле белем алалар дип уйлап, тынычлап йөргәннәр, күрәсең. Татар теле укытучылары гомумән алганда канәгатьләнерлек эшләмәделәр, тиешле коммуникатив метод белән укытмадылар, ялгыш методика буенча төзелгән дәреслекләр укучыларга бу предметтан кирәкле белем алырга мөмкинлек бирмәде. Нәтиҗәдә рус мәктәпләрендә укучылар, шул исәптән татар балалары да, атнага кимендә дүртәр-бишәр сәгать татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә утырып, унбер ел буена бу телдә иркен һәм дөрес итеп сөйләргә, язарга өйрәнеп чыга алмадылар.

Укытучыларның да, мәгариф җитәкчеләренең дә күп еллар шулай формаль эшләп килүләренең нәтиҗәләре билгеле инде: республика парламенты, татар халкының язмышын хәл итүгә зур йогынты ясый торган бу мәсьәлә буенча фикер алышып та тормыйча, берничә законны бозып, моннан ары мәктәпләрдә татар телен факультатив рәвештә атнасына ике сәгать кенә укытырга дигән карар кабул итеп куйды. Парламентарийлар бик нык ашыгудан, бу карарны кабул иткәнче, заманында шушы ук парламент тарафыннан кабул ителгән телләр турында законның бу мәсьәләгә кагылышлы статьясын тикшереп хәл итәргә кирәклеген дә онытып җибәргәннәр. Парадоксаль хәл килеп чыкты: әле дә гамәлдә булган закон буенча татар һәм рус телләре, барлык башка предметлар кебек үк уку планына кертелеп, тигез күләмдә укытылырга тиеш булса, парламентның соңгы карары буенча татар теле укучыларның, ата-аналарның ихтыяры белән (факультатив нигездә), атнасына ике сәгать кенә укытылырга тиеш.

Җитди сорау туа: кайсы документка таянып эш итәргә – телләр турындагы законгамы, әллә РТ Дәүләт Советының соңгы карарынамы? Логика буенча закон беренче урында торырга тиеш, әлбәттә. Ләкин Татарстандагы рус мәктәпләре татар теленә өйрәтүне

парламентның шушы карары буенча гамәлгә ашыра башладылар инде. Әмма шулай да телләр турындагы законның әле гамәлдә булуын (аны гамәлдән чыгару өчен ашыгырга кирәкми дә) истә тотып һәм соңгы вакытта тел проблемасының саклануын, шулай ук ата-аналарның теләкләрен һәм Мәскәүдән килгән күрсәтмәләрне исәпкә алып, телләр турындагы законга кайбер үзгәрешләр кертү хәерле булыр иде. Бу үзгәрешләр, безнең фикеребезчә, шушы төп максатны күздә тотып башкарылырга тиеш: рус мәктәпләрендә укыган татар балалары, туган телләрен яхшы итеп үзләштереп, соңыннан югары һәм урта махсус уку йортларында тиешле белгечлек алып, республиканы, аның халыкларын, милли культураларын алга җибәрү эшендә игелекле хезмәт итәрлек кыйммәтле кадрлар булсыннар.

Бу максатка ирешү өчен, Татарстанның мәгариф һәм фән министрлыгыннан рус мәктәпләрендә татар теле укытуны оештыру системасын нык уйлап, тәҗрибәле белгечләр белән киңәшләшеп төзү таләп ителә. Бу эштә класслардагы укучыларның төрле милләттән булуы берникадәр кыенлык китереп чыгарачак. Ләкин бу хәл ителмәслек проблема түгел: татар теле дәресләре вакытында классны, укучыларның татар телен белү-белмәүләре дәрәҗәсен исәпкә алып, ике төркемгә бүләргә туры киләчәк. Төркемнәрнең берсендә телне бөтенләй белмәүчеләр, ягъни башлап өйрәнүчеләр булса, икенчесендә телне бераз гына булса да белгән балалар булыр дип фараз ителә. Тик монда бер нәрсәне истә тоту мөһим: балаларны төркемнәргә бүлгәндә, итагатьлелек саклап, бик уйлап, акыл белән эш итәргә кирәк булачак. Бүлү, нигездә, рус һәм татар балалары буенча булса да, бу эш аларның туу таныклыкларындагы рәсми мәгълүматларга карап кына хәл ителә алмый: татарча бөтенләй белмәгән татар балалары да үзләренең теләге буенча беренче, ягъни башлап өйрәнүчеләр төркеменә кертелсен. Монда көчләү булырга тиеш түгел. Әмма бу мәсьәләдә укытучыдан шундый бер игелекле гамәл таләп ителә: ул зур әдәплелек белән, педагогик осталыгын кулланып, үз телләрен бераз гына булса да белгән балаларны  икенче, дәвам итеп өйрәнүчеләр төркеменә кертсен иде, чөнки татар балаларына, бөтен көчне туплап, туган телләрен өйрәтү – изге бурыч.

Рус мәктәпләрендә укучыларны татар теленә ике төркемгә бүлеп өйрәтү ихтыяҗы менә нәрсәләр белән аңлатыла.

Телне белү мәсьәләсе буенча бер-берберсеннән нык аерылып торган балаларны (бөтенләй белмәгәннәрне һәм бераз гына булса да белгәннәрне), бергә утыртып, бертөрле методика белән нәтиҗәле укытып булмый: һәркайсының үзенчәлекләрен, мөмкинлекләрен исәпкә алып, төрле методлар кулланып эшләргә кирәк. Беренче – башлап өйрәнүче төркем укучыларыннан телне аның лексикасының һәм грамматикасының минималь дәрәҗәсен генә үзләштереп, иркен аралашырлык, сөйләшерлек итеп кенә белү таләп ителсә, икенче баскыч укучылары өчен – өйрәнелә торган телне югарырак дәрәҗәдә белү максат итеп куела. Чөнки бу төркемне, нигездә, татар укучылары тәшкил иткәнлектән, аларның туган телләрен әйбәт белүе мәгъкуль. Балаларын үз телләренә өйрәтү – һәр халык, һәр этнос вәкилләренең гражданлык бурычы.

Татарстан республикасының дәүләт телләре турындагы законында да, балаларын туган телләренә өйрәтү һәр ата-ананың иң әһәмиятле бурычы дип язылган.

Әле әйтеп киткән төркемнәр өчен татар телен өйрәтүнең мәҗбүри яки ихтыяри (факультатив) булуы төрлечә: нигездә рус һәм башка милләт балаларыннан торган башлангыч төркемнәрдә бу предметны укыту ата-аналар теләге буенча (парламент кушканча) башкарылса, икенче – дәвам итеп өйрәнүчеләр төркемендә татар телен укыту факультатив була алмый, чөнки ул бу төркемдәге укучыларның туган теле. Ихтыярилык (факультативлык) статусы туган телләрдән башка телләргә генә карый. Бу мәсьәләдә Президент В.В.Путинның мондый сүзләренә таянырга кирәк: ***“Үзеңнең туган телең булмаган телне көчләп өйрәтергә дә, шул ук вакытта рус телен укытуның дәрәҗәсен һәм вакытын киметергә дә ярамый”.***

Безнең республикада, бөтен Россиядәге кебек үк, рус телен өйрәтүнең проблемалары юк, аны күп һәм яхшы итеп укыталар. Туган телләрне өйрәтү эшендә исә хәлләр яхшыдан түгел. Татар телен яңа кертелгән система буенча атнасына ике сәгать кенә һәм факультатив рәвештә укытканда, татар балалары туган телләрен яхшы итеп өйрәнерләр дип әйтү кыен. Шуңа күрә Татарстан республикасының телләр турындагы законына рус мәктәпләрендә татар балалары өчен туган тел дәресләре башка предмет дәресләре белән беррәттән расписаниегә кертеп укытылырга тиеш дигән үзгәреш кертергә кирәк. Балалар мәктәптә туган телләрен кирәкле күләмдә һәм нәтиҗәле итеп өйрәнсен. Бу аларның конституцион

хокуклары. Һәм дәүләт, бу хокукны гамәлгә ашыру өчен, кирәкле шартлар булдырырга тиеш.

Укучыларны – татарларны да, башка миллəт балаларын да – татар теленә нәтиҗәле итеп өйрәтүнең нигезе барлык мәктәпләрдә дә ата-аналарга татар телен укытуның кирәклеге, әһәмияте турында аңлату эшен оста башкаруда һәм гомумән уку процессын акыл белән, рациональ итеп оештыруда.

## ТЕЛЕБЕЗНЕ САКЛАП КАЛА АЛЫРБЫЗМЫ ИКӘН?

Беренче карашка бу сорау сәер тоелырга мөмкин: янәсе, ничек инде без телебезне югалтыйк, ди. Аңа нинди куркыныч яный? Әле бит, шөкер, мәктәпләрдә татар телен укыталар, бу телдә китаплар бастырыла, газета-журналлар чыга, радио-телевидение тапшырулары эшләнә, спектакльләр куела... Димәк, телебез хәвеф-хәтәрсез яши булып чыга.

Мәсьәләгә читтән караганда, соңгы елларда татар телен кысрыклау, аны укытуны чикләү, кулланылышындагы тәртипсезлек, кимчелекләрне, ата-аналарның балаларын татарча укытуга мөнәсәбәтен һәм башка җитди проблемаларны исәпкә алмаганда, телебез өчен борчылмаска да мөмкин кебек. Бигрәк тә рәсми кешеләр, хакимият вәкилләре телебезнең язмышы хакында тәнкыйть сүзләре ишетергә теләмәс. Тормышның уңай якларын гына күреп яшәргә иялəнгән һәм шулай булырга тиеш дип санаган кешеләр яшәешебездәге җитешсезлекләрне күрергә һәм ишетергә яратмыйлар. Кимчелекләрне танысаң, моның өчен кемнәргәдер җавап бирергә туры килергә мөмкин бит. Әмма халыкның “Чирен яшергән – үлгән” дигән тапкыр сүзе бар. Җитешсезлекләрне күрмәмешкә салынып йөрсәң, алар, күбәя барып, зур кыенлыклар, күңелсезлекләр китереп чыгарырга мөмкин. Безнең тормышта еш кына шулай була да. Туган телебезнең хәзерге хәле, язмышы, аны өйрәнү-өйрәтү, саклау, аннан акыл белән, дөрес файдалану һәм башка мәсьәләләрдә ваемсыз булып, кыенлыкларны күрмәскә тырышып яшәсәк, бу мәсьәләгә караган проблемалар да көннән-көн арта барып, туган телебез авыр һәм хәтта фаҗигале хәлдә калырга мөмкин. Шунлыктан без телебезнең бүгенге хәленә, андагы үзгәрешләргә игътибар белән карап, объектив анализ һәм нәтиҗәләр ясап, тиешле чаралар күреп торырга тиеш. Тел, үзенең

ияләре булган кешеләр аны кадерләп саклаганда гына, аларга бөтен куәте, матурлыгы белән игелекле хәзмәт күрсәтә ала.

Менә шушы кереш сүздән соң, телебезнең бүгенге халәтенә кагылышлы проблемалар, дөресрәге, аның язмышы хакында кайбер фикерләребезне әйтеп китик.

Борынгы дәүләтле, югары культуралы, миллионлап исәпләнгән татар халкының зур үсешкә ия, камил теленә нинди куркыныч яный, нәтиҗәле кулланылышына, уңышлы үсешенә нәрсәләр комачаулый соң?

Беренчедән, аны балаларга өйрәтү, укыту системасы какшый һәм таркала бару. Үзәк хакимиятнең “тырышлыгы” белән, республика җитәкчеләренең, депутатларның милли мәгариф, мәдәният мәсьәләләренә тиешле игътибар күрсәтмәүләре, ата-аналарның күбесенең балаларының туган телләрен белмәүләренә, аны начар өйрәнүләренә битараф булулары, мәгариф органнарының, мәктәп җитәкчеләренең, туган тел укытучыларының татар телен укыту мәсьәләләре белән нәтиҗәле шөгыльләнмәүләре аркасында, соңгы чирек гасырда татар телен укытуның сыйфаты һәм нәтиҗәлелеге түбәнәйде, ә узган елдан алып, бу эш һәлакәткә дучар була язды. Татар телен өйрәтүгә бу уку елыннан атнасына икешәр сәгать кенә вакыт бирелү һәм татар теле дәресләрен ата-аналар теләге булганда гына үткәрү тәртибе кертелү һәм башка төрле кырыс яңалыклар балаларны туган телләрендә тәрбияләү мөмкинлекләрен нык чикләүгә һәм бетерә баруга китерә.

Мәгълүм булганча, соңгы ун елда гына да дистәләрчә татар мәктәпләре ябылды. Бүгенге көндә эшләп килгәннәре дә русча укытуга күчерелә бара.

Мәскәүнең руслардан башка халыкларның туган телләрен өйрәнүгә һәм үстерүгә куйган киртәләре болар белән генә чикләнми. Мәсәлән, бер бик зарарлы яңалык: татар теле дәреслекләрен бары тик Мәскәү лицензиясе белән һәм моның өчен Татарстан үзәккә зур суммада акча күчергәндә генә бастырып чыгарырга мөмкин. Шуның аркасында хәзер мәктәпләрне татар теленнән яңа дәреслекләр белән тәэмин итү проблемасы килеп чыккан. Ихтимал, телебезне яшь буынга өйрәтү мөмкинлекләрен чикләү өчен тагын нindидер башка төрле киртәләр дә корып маташалардыр әле.

Шуны искәртеп китү зарур: соңгы елларда татар телен өйрәтүне һәм татарча укытуны чикләүгә юнәлтелгән гамәлләр Россия һәм Татарстан Конституцияләренә, шулай ук туган телләрне өйрәтүгә-

өйрәнүгә ирек бирүне күздә тоткан башка законнарга каршы килә: милләтләр үсеше өчен хәлиткеч законнар тупас бозыла.

Әмма нинди генә кыенлыклар тудырмасыннар, халыкларның туган телләрендә аралашу, балаларын үз телләрендә тәрбияләү хокукын беркем дә бетерә алмый, туган телдә сөйләү-сөйләшүне, балаларны шул телдә өйрәтүне беркем дә тыя алмый.

Хәзер, бу уку елыннан калмыйча, мәгариф органнары, мәктәпләр, ата-аналар, бердәм рәвештә рөхсәт ителгән атнасына ике-өч сәгать тел-әдәбият дәресләреннән мөмкин булганча нәтиҗәле файдаланып, балаларына туган телләреннән белем бирүне оештырырга тиешләр. Югыйсә, рус мәктәпләрендә татар телен укытудагы булдыксызлык кебек, бу ике-өч сәгать вакытны да, әрәм-шәрәм итеп бетереп, нәтиҗәсез уздырырга мөмкин.

Җитәрлек белеме булган педагог тырышып эшләгәндә укучыны 9 ел буена атнасына икешәр сәгать укытып та, татарча дөрес, иркен, матур итеп сөйләргә һәм язарга өйрәтә алырга тиештер, ләбаса.

Татар теленең сыйфатына да җитди зыян килә. Бу хәл хәзер мәгълүмат чараларында, радио-телевидение тапшыруларында телебезнең бик нык бозылуыннан гыйбарәт. Күп санлы тупас хаталар, көннәк-көн арта барып, телебезнең табигый төзелешен, лексик, фразеологик, грамматик, фонетик системасын какшата, вата, җимерә баралар.

Телебезне саклауда комачау тудыра торган бер җитди проблема барлыгына күз йомып калырга һич кенә дә ярамый. Бу соңгы елларда шактый күп ата-аналарның балаларын укытырга татар мәктәпләренә бирергә һәм татар теле дәресләренә йөртергә теләмәүләре. Мәсьәләгә объектив карасаң, татар ата-анасының баласын туган телен укытырга теләмәве – татар телен бетерүгә китерә торган иң зур куркыныч, татар халкы өстенә ябырылып килгән афәт. Балалар мәктәптә әдәби телне үзләштермәсәләр, татар әдәби теле бетүгә йөз тотачак, аның киләчәге булмаячак.

Димәк, бу уңайдан Татарстан җитәкчеләре, тел, әдәбият, сәнгать, мәгариф өлкәләрендә хезмәт итүчеләр, иҗат итүчеләр, татар халкының күренекле шәхесләре, зыялылары чаң сугарга, педагог, психолог, социологлар һәм башка төрле белгечләр бу гаҗәп катлаулы һәм четерекле проблеманы хәл итү юлларын эзләп табарга тиеш.

Әлеге мәсьәләне административ чаралар күрү, тыю, мәҗбүр итү ысулы белән хәл итеп булмый: баласын нинди телдә тәрбияләү, укыту, аңа кайсы телне өйрәтү – ата-ананың иреге. Димәк, чара бер генә – аны туган телеңне белү, аны балаңа да өйрәтү изге гамәл, һәркемнең гражданлык, милли бурычы икәнлеген ата-анага педагогик такт, әдәп белән аңлату, туган телең бетсә, халкың да, милләтең дә яшәүдән туктаячагына инандыру.

Татар ата-аналарына балаларын татар мәктәбенә укырга бирергә һәм татар теле дәресләренә йөртергә күндерү гамәле аларда гомумән халкыңа, туган телеңә уңай, хөрмәтле караш тәрбияләү сәясәте белән үрелеп барырга тиеш. Әйтергә кирәк, мондый изге хисләр безнең милләттәшләрнең күбесендә җитәрлектер дип әйтеп булмый әле. Мәгълүм ки, мондый сыйфатлардан башка чын милләтпәрвәр булу мөмкин түгел, әлбәттә.

Шунлыктан безнең милли хисле педагогларыбыз, идеология өчен җаваплы кешеләребез алдында торган бик җаваплы бер бурыч ул – халыкта, бигрәк тә яшьләрдә милли горурлык, милләтеңнең лаеклы улы, кызы булу хисләре тәрбияләү. Бу халкыбызны алдынгы милләт буларак саклауның бик әһәмиятле чарасы. Борынгы тарихлы, дәүләтле, югары культуралы татар халкының тормышның бөтен өлкәләрендә дә – мәдәният, әдәбият, сәнгатьтә, спортта һәм башка төрле тармакларында күп меңләгән күренекле вәкилләре, бөек шәхесләре, сугышта һәм хезмәт фронтында тиңдәшсез батырлыклар күрсәткән күркәм уллары һәм кызлары бар. Менә шулар үрнәгендә яшь буында милли горурлык, лаеклы халык вәкилләре булу сыйфатлары тәрбияләргә кирәк тә инде.

Милләттәшләребезне – олысын да, кечесен дә – милли горурлыкка ия булырга күнектерү гамәлләрен дәүләт органнары тарафыннан бөтен җәмәгатьчелекне катнаштырып һәрьяклы тәрбия программасы кысаларында башкарылырга тиеш.

Безгә мөмкин булганча тизрәк, буыннан-буынга күчеп килеп, күпчелек татар кешеләренең күңел түрендә яткан бер авыр хистән – руслар алдында үзеңне түбәнсетеп күрү хисеннән арынырга кирәк. Татар халкына күп йөз еллар патша режимында, империячел милли сәясәт үткәрелгән дәүләттә яшәү аркасында руслар алдында үзләрен икенче дәрәҗәдәге кешеләр итеп карау, рус халкын исә башка барлык халыклардан өстенрәк итеп күрү психологиясе сеңдерелеп килгән. Шуннан “бөек рус халкы”, “бөек рус теле” һ.б.

төшенчәләр кулланылышка кергән. Бик үкенечле хәл: рус халкын өстен кую сәясәте хәзер, безнең көннәрдә яңадан көчәя бара. Демократиягә каршы килә торган мондый карашның Россиядә яшәүче халыкларның туган телләренә зур зыяны тиде һәм тия инде. Әле моннан бер ел гына элек Россия җитәкчеләренең “рус телен барлык халыклар да белергә тиеш, ә милли телләрне өйрәнү ирекле эш, мәктәпләрдә аларны укыту атнасына 2-3 сәгатьтән артмаска тиеш” дигән күрсәтмәсе аркасында безнең татар телен укытуның вакыты нык киметелде. Шуңа өстәп, башка төрле чикләүләр дә кертелде.

Бүгенге көндә күп татар ата-аналарының һәм башка кайбер кешеләрнең дә, рус теленә өстенлек биреп, үзләренең туган телләренә илтифатсыз каравы да Россиядә гомер-гомергә үткәрелеп килгән әнә шул милләтләрнең ирекле үсүен тоткарлап килгән сәясәтнең нәтиҗәсе һәм чагылышы.

Әле әйтелгәннәр татарларны русларга каршы кую булып аңлашылмасын. Бу акылсызлык булыр иде. Татарлар элек электән башка халыклар белән аңлашып, якыннан аралашып, тату яшәгән һәм яши. Безнең республикада барлык милләт кешеләре дә рус телен яхшы белә. Бу уңай күренеш, әлбәттә.

Бурыч – рус теле белән бергә үз телеңне дә яхшы белү. Бездә укучылар татар, рус һәм инглиз телләрен югары дәрәҗәдә үзләштерә торган мәктәпләр булырга тиеш.

Хәзерге катлаулы шартларда хөкүмәт милли мәсьәләләрне, беренче чиратта татар телен укыту, аны, бозмыйча, дөрес куллану мәсьәләләрен уңышлы хәл итүне һәм, тиешле чаралар күреп, туган телебезне саклау вазыйфаларын үтәүне иң әһәмиятле бурычларыннан итеп санасын иде.

## СУМЕЕМ ЛИ СОХРАНИТЬ СВОЙ РОДНОЙ ЯЗЫК?

На первый взгляд такой вопрос сегодня может показаться несколько наивным. Обязательно найдутся такие, которые будут возражать: почему возникло у этого автора сомнение в перспективе жизнеспособности нашего родного языка, и что угрожает его функционированию? И они перечислят аргументы: в учебных заведениях преподается татарский язык, на этом языке сегодня издаются книги, выпускаются газеты и журналы, делаются радио и телепе-

редачи, ставятся спектакли и т.д. И будут утверждать, что ситуация с татарским языком вполне благополучная.

Так будет казаться, если к рассмотрению этого важнейшего вопроса подходить поверхностно, без глубокого анализа событий, произошедших в последние годы и происходящих поныне, в связи с функционированием, обучением и развитием татарского языка.

Разумеется, будут пытаться расписывать ситуацию с татарским языком лишь в радужном свете те, кто по своему положению, по служебному долгу, кто-то, может, и по своей наивности склонен видеть во всем только позитив.

Но, как известно, жизнь состоит не только из положительных моментов. И небо над татарским языком сегодня не совсем безоблачное, как полагают некоторые. В употреблении, в качественном состоянии, обучении и перспективах развития его в настоящее время имеются серьезные проблемы, которые изо дня в день становятся все ощутимее.

Наступило время со всей серьезностью относиться к положению с татарским языком, всесторонне анализировать сегодняшнее его состояние, объективно оценивая имеющиеся немалые трудности для его успешного функционирования как одного из развитых литературных языков и принять безотлагательные меры, чтобы остановить падение престижа этого языка и потерю его весомого значения в сохранении и развитии татарского народа как цивилизованной нации.

Попытаемся вкратце изложить объективные и субъективные трудности на пути функционирования татарского языка и факторы, представляющие реальную угрозу для его сохранения.

Во-первых, что самое главное – за последние годы по инициативе центральных и при попустительстве местных властей сумели-таки подорвать устоявшуюся, проверенную временем систему преподавания в учебных заведениях татарского языка. Не оказывалось со стороны руководящих органов образования должного внимания организации обучения учащихся татарскому языку в общеобразовательных школах, отсутствовал контроль за эффективностью работы преподавателей родного языка, а также за качеством знаний обучающихся по данному предмету. В результате учащиеся русскоязычных школ, около половины которых составляют дети татар, потратив на изучение татарского языка в течение десятилетия тысячи часов времени, расставались со своим учебным заведением по

сути так и по-настоящему не выучив этот язык, который по закону о языках они по окончании школы должны были знать хорошо.

В том, что два года тому назад начались волнения вокруг преподавания татарского языка, в результате которых по инициативе Президента России и с одобрения парламента республики время на изучение татарского языка в школах было сокращено до двух-трех часов в неделю, причем только с согласия родителей учащихся, в значительной степени повинны сами учителя татарского языка и органы образования: первые работали спустя рукава и безрезультатно, вторые не организовали и не руководили должным образом процессом обучения татарскому языку.

Таким образом, в изучении татарского языка возник коллапс, задача срочного выхода из которого предстояло и предстоит сейчас перед органами образования и преподавателями татарского языка.

Ясно, что никакие сложности и никакие препятствия не должны остановить процесс обучения родному языку татар и отказаться от реализации задачи организации преподавания татарского языка не имел и не имеет права никто. Поэтому и после резких перемен в системе обучения этому языку предстоит заниматься выполнением задач, связанных с изучением языка коренного населения татар Республики Татарстан. Но приходится эту задачу решать уже в более сложных условиях, чем это было раньше. Мысли о том, как надо организовать и проводить обучение татарскому языку изложены в статье "Стиль работы придется изменить", помещенной в этом же сборнике, поэтому не будем останавливаться здесь на этом вопросе.

Однако считаем необходимым в этой связи обратить внимание на одно обстоятельство. У автора этой книги имеется сомнение в том, что не все учителя татарского языка и не все ответственные работники органов образования извлекли уроки и сделали соответствующие выводы из произошедших недавно потрясений с преподаванием татарского языка и, по имеющимся у нас сведениям, кое-где снова стало проявляться прохладное отношение к организации обучения этому языку. Поступают сообщения, что в некоторых школах не все часы, отведенные для татарского языка, используются по назначению, не везде имеются учебники по родному языку, где-то не хватает учителей по данному предмету и т.д.

Надо полагать, что неурядиц подобного характера существует немало, и их будет гораздо больше, если не проявится достаточно

серьезное отношение к преподаванию татарского языка со стороны соответствующих органов образования, руководителей учебных заведений и, разумеется, самих учителей родного языка.

Дальнейшая судьба татарского языка будет решаться в значительной степени именно с этого года в зависимости от того, насколько результативно Министерство образования республики, районные, городские органы образования в этом учебном году – после перехода к обучению татарскому языку в значительно меньшем объеме, чем это было раньше, и лишь по желанию родителей, сумеют организовать и проводить занятия по данному предмету.

Впредь добиваться успехов в этом важнейшем деле смогут лишь лучшие учителя татарского языка, хорошо владеющие знаниями по своему предмету, современной методикой проведения занятий, педагогическим мастерством.

Как ни может показаться парадоксально и как бы ни было досадно об этом заявлять, в последние годы у определенной части татарского населения возникло не одобрительное, вернее сказать, отрицательное отношение к изучению татарского языка, и проявляется нежелание занимать своих детей изучением родного татарского языка.

Такое негативное отношение у определенной, если не значительной, части татар к своему родному языку сегодня представляет главную опасность для сохранения и развития татарского языка. Это феномен XXI века, феномен – угроза для развития наций. Отказ цивилизованного, воспитанного на национальных традициях человека от обучения своего ребенка родному языку выглядит не иначе как нонсенс.

Это явление требует глубокого анализа психологов, педагогов, социологов и других компетентных специалистов и своей объективной оценки и соответствующих выводов.

Попытаемся объяснить нежелание отдельных родителей-татар обучить своих детей родному языку так, как это представляется нам.

Причин такого негативного отношения родителей к родному языку  несколько. Чтобы их правильно, объективно определить, надо быть осведомленным в истории татарского народа, знать его сегодняшнее социальное положение и современную политическую обстановку в стране.

Татары, как известно, жили в царской России, где для нерусских народов не было условий для свободного развития и проявления своей национальной идентичности. Имперская колониальная политика в течение многих веков воспитала поколения нерусских народов в покорности, внушая им чувства приниженности, второсортности, по сравнению с русскими, во всем: и в интеллектуальной сущности в развитии языка, культуры, искусства, образования и т.д. Нельзя сказать, что царизму удавалось все народы постоянно удерживать в интеллектуально-психологическом унижении и воспитать в них рабскую психологию. Отдельные яркие личности из разных народов, вырываясь из-под гнета, становились людьми со своей гражданской позицией и, получая соответствующее образование, осваивая передовую культуру, занимали достойное положение в обществе. Но таких было немного, и в целом в психологии нерусских народов, в том числе татар, веками насаждалось чувство своего униженного, притесненного состояния.

Идея превосходящего положения русских, по сравнению с другими народами, поддерживалась и в советское время: понятия "великий русский народ", "великий русский язык" и т.д. впитывались всем нерусским людям с малых лет и укреплялись в их сознании на всю жизнь.

В последние годы гегемония русского народа, всего того, что связано с ним снова интенсивно культивируется. Она, поддерживаемая руководством России, становится основой официальной государственной политики. Это проявляется во всей духовной жизни, к примеру, не правомерное распоряжение Москвы о том, что лишь русский язык объявляется государственным и обязательным для изучения всеми, а языки других народов считаются не обязательными для их изучения в учебных заведениях и только по желанию родителей учащихся обучение их может осуществляться не более двух-трех часов в неделю.

При этом по указанию центра уже несколько лет действует в школах система сдачи выпускных государственных экзаменов (ЕГЭ) всеми, в том числе учащимися национальных школ, лишь на русском языке и обязательно по русскому языку и по русской литературе, причем в объеме программы русскоязычных школ.

В этом четко проглядывает ущемление прав и сокращение возможностей нерусских молодых людей для успешного продолжения обучения в высшей школе и получения достойной профессии.

Анализ социально-политического положения в стране и национальной политики государства, проводимой в последние годы, ясно показывает, что курс взят на приоритетное развитие всех сфер жизни русского народа, а развитие национальных культур обречено на финансирование государством, как всегда, по остаточному принципу.

Все эти и другие факторы не могут не повлиять на умы представителей нерусских народов. Отсюда и складывается настроение нерусских родителей отдавать предпочтение изучению русского языка даже тогда, когда имеется возможность выбора своего родного языка. В данном случае они, не задумываясь о своем гражданском долге обучать своих детей родному языку, руководствуются лишь прагматическими интересами, видя свой родительский долг в создании достойных условий для того, чтобы их дети могли получать лучшее образование на русском языке.

Пренебрежение определенной части татар, особенно молодежи, к своему родному языку проявляется не только в изучении татарского языка, но и во всех других сферах жизни, где присутствует татарский язык. В городах, в том числе и в Казани, не менее половины жителей которых составляют татары, на улицах, в общественных местах редко встретишь людей, говорящих на татарском языке. А много ли татарского населения, особенно молодых, читают литературу, газеты и журналы, смотрят и слушают телевизионные и радиопередачи на татарском языке? Очень немного!

Благо бы, если во всех татарских семьях общение между их членами происходило на родном языке. Ан нет! Далеко не во всех татарских семьях языком общения является родной язык членов семьи. Потому что многие из татар даже среднего и старшего поколения теперь плохо знают или совсем не знают своего родного языка. Такова наша горькая действительность. Однако это не их вина, а наша общая беда.

Из нашего текста об озабоченности незнание определенной части татар  своего родного языка и нежелание изучить его у читателя может сложиться мнение, что предметом нашей заботы является лишь положение с разговорным языком. Разумеется, мы не сторонники такого узкого понимания языка. Нас прежде всего должно беспокоить состояние татарского литературного языка. Как известно, вся наша духовная жизнь, богатейшее литературное наследие зиждется на развитом, совершенном литературном языке,

который имеет многовековую историю. Когда мы речь ведем о сохранении и развитии родного языка, в первую очередь подразумеваем его литературную форму.

Правомерно выражая озабоченность тем, что в настоящее время сокращается количество татарских школ, численность изучающих в учебных заведениях свой родной язык, падает интерес ко всему, что связано с татарским языком, мы должны прежде всего беспокоиться о судьбе татарского литературного языка, ибо прогресс народа, его успешное функционирование как развитой нации основываются на его богатом литературном языке.

Если в связи с серьезными проблемами в татарском языке, наблюдающимися в последние годы, можно говорить в целом как о количественных потерях в родном языке, то многочисленные грубые нарушения, имеющие место в употреблении литературного языка, можно было назвать как большой ущерб качеству языка.

В целом в использовании татарского языка в разговорной и литературной речи уже в течение ряда десятилетий говорящими и пишущими допускается удивительная халатность, невнимательность и языковая безграмотность.

Мне волею судьбы приходится заниматься изучением качества языка средств массовой информации на татарском языке уже более полувека. За этот период я проанализировал язык многих тысяч номеров различных газет, журналов, отдельных книг, а также многих радио и телепередач, и на основании накопленных материалов мною опубликованы десятки монографии, учебников и сотни статей о качестве употребления татарского языка в средствах массовой информации и других материалах.

Главный неутешительный вывод этой кропотливой работы таков: язык наш употребляется с грубейшими нарушениями правильных литературных норм в огромном количестве. Особенно много таких нарушений наблюдается в материалах перевода с русского языка. При этом количество их из года в год, изо дня в день увеличивается.

Характер языковых ошибок, причины их возникновения, пути их устранения изложены в многочисленных трудах автора этой статьи и других. Однако журналистов, предпринимающих попытку устранить хоть небольшое количество из нарастающего потока ошибок, не заметно.

Главная опасность все более засоряющих литературный язык ошибок заключается в том, что многие из них, грубо нарушая естественные нормы татарского языка, приводят к постепенному разрушению его лексико-грамматической, фонетической структуры, неуклонно подтачивают основы его естественной природы, заполняя язык искусственными, не свойственными для него образованиями.

В искажении и порче языка особенно усердствуют журналисты малоформатных (в основном негосударственных) газет. Им свойственно употребление слов в не своих значениях, использование вышедших из употребления устаревших арабо-персидских заимствований, увлечение созданием без необходимости новых слов, грубо нарушающих естественные правила образования слов и т.д. Такие и другие искажения языка не редкость и для республиканских (государственных) газет.

Очень много языковых ошибок в радио и телепередачах. В них нарушаются и лексико-фразеологические, и грамматические литературные нормы, и фонетическое построение речи (интонация, ударение, произношение звуков и т.д.). Корявая, неправильная речь выступающих и ведущих на татарском языке в радио и телепередачах становится обычным явлением.

Говоря о грубых нарушениях в языке средств массовой информации, нельзя не упомянуть о таких странных нововведениях в малоформатных газетах *“Мәхәббәт”, “Юлдаш”, “Ирек мәйданы”* и т.д., как использование в средствах массовой информации разговорного языка со многими просторечными выражениями. При этом журналисты этих газет сознательно практикуют использование просторечия вместо литературного языка, мотивируя свое совершенно неправомерное изобретение тем, что газеты, издающиеся не на литературном, а на разговорном, просторечном языке, будут более привлекательными для читателей. Вот такие злоключения происходят теперь в татароязычной печати и такие дикие эксперименты проводят с нашим древним, богатейшим, высокоразвитым татарским языком, на котором в течение столетий создавались шедевры художественной и научной литературы.

Не ставя целью подробно анализировать причины создавшегося тревожного положения с татарским языком, назовем лишь наиболее существенные.

Главная из них, по нашему убеждению, заключается в основном в существовавшей в течение столетий практике ущемления прав нерусских народов и отсутствии достаточных условий для свободного развития национальных языков, культур, образования и т.д.

Вторая серьезная причина – в установившейся в последние годы в государственной политике, направленной на сокращение возможностей для получения нерусскими детьми образования на родном языке, а также для изучения в учебных заведениях своего родного языка.

Третья причина – отсутствие системы высшего образования на родном языке.

Одна из причин заключается в преподавании татарского языка в учебных заведениях не на достаточно качественном уровне.

Всемерному снижение качества языка средств массовой информации содействует также отсутствие контроля и требовательности к журналистам за правильность их языка со стороны соответствующих ответственных лиц.

Серьезной причиной падения престижа татарского языка и культуры родной речи является то, что задача сохранения и развития татарского языка не стала одной из первостепенных и важнейших в деятельности органов власти республики.

Цель данной заметки заключается в том, чтобы, заострив внимание на серьезности создавшейся ситуации с употреблением, изучением татарского языка, падением его значимости, а также усилением пренебрежительного отношения к нему со стороны некоторых его носителей, указать на необходимость принять неотложные меры, направленные на оздоровление обстановки с татарским языком, и, по специальной государственной программе, всем ответственным и заинтересованным лицам интенсивно и эффективно заниматься реализацией задач по сохранению и развитию родного языка многомиллионной татарской нации.

# МЕЖДУНАРОДНЫЙ ДЕНЬ РОДНОГО ЯЗЫКА

Ежегодно весь прогрессивный мир будет отмечать Международный день родного языка, объявленный всемирной организацией ЮНЕСКО. В последние годы в нашей республике также стали проводить различные мероприятия, посвященные этой дате. Будем надеяться, что в этом году этот день будут отмечать более широко и с пользой для развития родных языков народов, проживающих в Татарстане.

Объявление ЮНЕСКО Международного дня родного языка было вызвано серьезной озабоченностью создавшимся тревожным положением с родными языками ряда малочисленных народов, населяющих нашу планету. Потеря же даже одного языка – это по сути потеря целого народа, этноса, это серьезное нарушение этнической экологии мира.

Цель установления этой памятной даты и заключается в том, чтобы обратить внимание государств, общественности на необходимость принятия неотложных мер по устранению и предупреждению факторов, приводимых к серьезным нарушениям естественной природы любого языка, пусть даже самого малочисленного народа и тем самым к его потере.

Что касается языков народов, проживающих в нашей республике, также имеются сложности, и немалые, в их употреблении и развитии. На первый взгляд, язык самого многочисленного в России народа – русский язык успешно функционирует и ему, казалось бы, ничто не должно угрожать в отношении сохранения его естественного состояния, правильности, чистоты. Однако, если присмотреться повнимательнее к его нынешнему положению, проанализировать его качество исходя из строгих литературных норм, то не трудно заметить имеющиеся в его употреблении серьезные проблемы.

Проблемы эти заключаются в нарушениях общепринятых в языке норм, правил в разговорной речи отдельных людей (а их немало), в речи участников радио и телепередач, персонажей кинофильмов, а также в многочисленных рекламных текстах, в различных объявлениях, вывесках и т.д.

Вопрос о культуре речи – вопрос серьезный, сложный, требующий особого разговора, и я здесь не намерен на нем останавливаться подробно. Скажу лишь, что культура речи – важная часть общей культуры человека, и обеспечение ее высокого уровня зависит

от ряда факторов, прежде всего от воспитания в семье и в учебных заведениях. Заметим лишь, что за последние лет двадцать уровень воспитательной работы в целом в стране значительно упал. Приходится ли удивляться имеющим место в речи подростков нарушениям литературных норм русского языка, когда их речь нередко пестрит сквернословием. Впрочем, им есть с кого брать пример в этом отношении: многие из взрослых нисколько не чураются высказываться и при женщинах, и при детях матерщинным языком. Удивительно то, что сквернословие в русском языке в определенной степени все более становится даже нормой. Легко убедиться в этом, если прислушаться к речи персонажей кинофильмов, а иногда и в выступлениях официальных лиц.

Я не перестаю удивляться все большему засилию английского языка у нас и в Казани, в столице Татарстана. Посмотрите на это бесчисленное множество реклам, вывесок, всевозможных надписей на улицах, в магазинах, других общественных местах на английском языке. Зачем надо было чуть ли не за три года до универсиады делать объявления на метро, троллейбусах, автобусах на английском языке!? Знать английский язык надо, его следует изучать, но не заменять же им русский язык! Где гордость русского народа, зачем так жестоко расправляться с некогда великим, могучим русским языком!?

С татарским языком проблем гораздо больше. И я с вашего разрешения, уважаемые читатели газеты, на них остановлюсь подробнее.

Нарушений литературных норм в татарском языке – как в устной речи его носителей, так и в письменной – на сегодня много, и их с каждым днем становится больше. Особую тревогу вызывают серьезные нарушения, имеющиеся в языке средств массовой информаций – газет и журналов, радио и телевизионных передач. В своих выступлениях в татароязычной печати я свое утверждение об этом доказываю на анализе многочисленных примеров искажения литературного языка, здесь же, поскольку газета русскоязычная, я, разумеется, не стану обременять читателей примерами. Скажу лишь, что ошибки, имеющиеся в современном татарском языке, не безобидные: они наносят урон не только лексике, но и даже структуре языка, нарушают его специфические особенности, без которых язык теряет свое естественное состояние.

Причин продолжающегося снижения качества татарского языка в последние годы несколько. Я назову лишь некоторые из них.

Первая заключается в том, что в перестроечный период (начиная с 90-х годов прошлого столетия) уровень образования в России в целом, гуманитарного в частности, неуклонно снижается, ибо внимание государства к этой важнейшей сфере жизнедеятельности ослабевает. Это и низкий уровень заработной платы учителей, это и отсутствие других необходимых условий для их успешной работы, это и понижение требовательности за качество знаний как к самим преподавателям, так и к обучающимся.

Вызывает большую тревогу уровень знаний татарского языка особенно у той части детей-татар, которые обучаются в русскоязычных школах. С обучением детей-татар в этих школах своему родному языку создалась драматическая ситуация. Они, изучая этот язык в течение всех одиннадцати лет, причем тратя на это большое количество времени, не овладевают им в совершенстве. Причина в неправильной организации обучения, в неправильной методике преподавания и составления учебников.

Почему же так произошло?

Более четверти века тому назад в связи с принятием Верховным Советом республики закона о языках народов Республики Татарстан, возникла необходимость изучения в школах с русским языком обучения татарского языка, выделяя на это большое время. Для реализации этой задачи срочно потребовалось значительное количество учителей татарского языка, умеющих вести этот предмет в иноязычной аудитории. Поскольку учителей татарского языка, специализировавшихся для обучения татарскому языку в русскоязычной аудитории, не было, к преподаванию были привлечены и учителя, не имеющие опыта этой работы, порою даже не филологи.

Не было учебников, и учебных пособий по обучению татарскому языку русскоязычных учащихся по новой программе. Пришлось в срочном порядке издавать учебники татарского языка для русскоязычных школ, взяв за основу учебники по родному языку для татарских школ. И это изначально было неправильно. Вследствие этого учебники оказались очень сложными, непонятными для русскоязычных учащихся, то есть они совершенно не были рассчитаны на изучающих язык вновь. Надо было с самого начала обучать русскоязычных учащихся, в том числе и детей-татар, татарскому языку как иностранному языку, то есть по методике преподавания иностранных языков.

Учитывая многочисленные жалобы родителей, как русских, так и татар, Министерство образования республики предпринимало определенные попытки для исправления положения. Но серьезных изменений в обучении татарскому языку в русских школах так и не произошло. Нужны коренные изменения в этой области. Закон о языках в области образования не выполняется. Многие тысячи детей-татар лишены возможности овладевать своим родным языком в совершенстве – научиться свободно, правильно говорить и писать на литературном языке. Русские же учащиеся, обучаясь татарскому языку в течение более чем 10 лет, должны также уметь хотя бы свободно общаться на этом языке – на языке коренной национальности республики, как это происходит обычно в цивилизованных демократических государствах.

Я, в свое время исполняя обязанности вице-президента Академии наук Татарстана по гуманитарным вопросам, будучи преисполненным желания каким-то образом содействовать повышению эффективности обучения татарскому языку русскоязычных учащихся, подробно изучив все учебники по татарскому языку для русских школ, побывав на уроках по данному предмету, побеседовав с учителями татарского языка и с родителями, проводил научно-практическую конференцию, посвященную данной проблеме, приняв резолюцию с конкретными предложениями по улучшению дела, неоднократно выступал в газетах, журналах с рекомендациями, однако какой-либо реакции на все это со стороны официальных органов не почувствовал, и дело, как уже сказал, с мертвой точки не движется.

Пользуясь случаем, считаю целесообразным еще раз озвучить некоторые из своих предложений, на мой взгляд, важных для изменения положения с преподаванием татарского языка детям, обучающимся в русскоязычных школах.

Во-первых, Министерство образования и науки нашей республики должно определить одной из своих первостепенных задач организацию качественного обучения татарскому языку учащихся всех школ, в особенности русскоязычных. В целях успешной реализации этой важнейшей задачи в аппарате Министерства должен быть штат заместителя министра по вопросам обучения на нерусских языках и по преподаванию татарского и других нерусских языков.

Во-вторых, в преподавании татарского языка в русскоязычных школах необходимо осуществить кардинальные изменения, полно-

стью переведя обучение данному языку на рельсы методики обучения как иностранному языку. Учебные программы, учебники и учебные пособия следует также полностью перестроить на основе методики обучения татарскому языку как иностранному, которая предполагает прежде всего коммуникативные методы изучения языка. А пока еще существующая система обучения татарскому языку в русскоязычной школе зиждется в основном на заучивании грамматических правил, определений, выполнении множества грамматических заданий, одним словом, изучении без знания самого языка, без освоения необходимого уровня лексики и без приобретения навыков построения речи и т.д.

В-третьих, необходимо установить иную систему организации создания новых учебников и учебных пособий, что заключается, на наш взгляд, в следующем.

Министерство образования создает из опытных, компетентных специалистов-ученых и преподавателей татарского языка экспертную комиссию по определению качества функционирующих учебников с тем, чтобы установить уровень соответствия их современным требованиям эффективного обучения. Заключение данной экспертной комиссии с соответствующими рекомендациями должны лечь в основу написания новых учебников.

Далее Министерство создает коллектив квалифицированных авторов из числа известных специалистов-ученых, а также лучших учителей татарского языка и литературы, имеющих достаточный опыт преподавательской деятельности, а также навыки научно-методической работы.

По существующей практике, учебники пишут, как правило, ученые-работники вузов и школьные учителя, совмещая эту деятельность со своей основной работой, то есть за счет своего личного времени, отдыха, следовательно, сильно перегружая себя. И это, разумеется, на качестве учебников не сказывается положительно. Создание учебников – дело сложное, нелегкое, требующее больших усилий и времени. Учитывая это, я считаю целесообразным ввести в практику предоставление авторам учебников творческого отпуска на время их написания, разумеется, соответствующим образом стимулируя работу материально. Такая система давала бы возможность авторам работать над учебниками целенаправленно, обстоятельно и качественно.

Как уже было сказано в татарских газетно-журнальных материалах, радио-телепередачах, нередко и в учебниках и даже в художественных произведениях, не говоря уже о всевозможных рекламных текстах, вывесках и т.д., имеется немало нарушений норм литературного языка. Следует заметить, что многие из них представляют собой неудачные, корявые кальки из русского языка, которые проникают в татарский язык и оседают в нем надолго, во-первых, из-за недостаточного знания билингвами (носителями двух языков) и татарского и русского языков, во-вторых, благодаря отсутствию у журналистов и других лиц, имеющих дело с пером, навыков перевода, то есть из-за отсутствия у них знаний о принципах, методах, способах перевода с одного языка на другой.

Перевод в жизни нашей республики занимает очень большое место. Особенно много к нему прибегают журналисты. Значительная часть материалов татарских газет (а их сотни в Татарстане) и журналов, радио и телевизионных передач представляют собой переводы с русского языка. Переводят обычно все как им вздумается, полагая, что перевод не требует специальных знаний и что им могут заниматься все, кто более или менее владеет татарским и русским языками.

Между тем, перевод это особая сфера деятельности, требующая, кроме совершенного владения двумя языками, еще и ряда других знаний: принципов, методов и способов перевода, предмета перевода и т.д. И только тот билингв в состоянии выполнять качественные, равноценные (адекватные) переводы, который осведомлен в теории перевода (есть переводческая наука, или наука о переводе) и к тому же имеет достаточный опыт данной работы.

Заметим, что в доперестроечный период у нас в республике вопросам перевода уделялось более серьезное внимание, чем сейчас. При Союзе писателей Татарстана имелась секция переводчиков (возглавлял ее известный переводчик Киям Миннебаев), которая систематически проводила семинары переводчиков, на которых принимали участие известные писатели, а однажды, как мне помнится, участвовал даже композитор Александр Ключарев, выступивший по вопросам перевода песенных текстов. Тогда группу студентов направляли учиться в Литературный институт имени Максима Горького для специализации по переводу.

Организацией и проведением семинаров для переводчиков занимался также Союз журналистов Татарстана, приглашая для

участия в них журналистов газет также из других областей и республик.

Значит, тогда понимали значение перевода и заботились о его качестве. Сейчас все это предано в забвение. И требовательности к качеству переводов не стало. И не случайно, что многочисленные нарушения языка в татарских средств массовой информации – это прежде всего переводческие ошибки.

Накануне Международного дня родного языка с сожалением приходится отмечать, что в последние годы государственная власть России не проявляет заинтересованного отношения к судьбам национальных языков народов, проживающих в Российской Федерации, наоборот, с ее стороны предпринимаются шаги, направленные на постепенное свертывание функционирования и развития этих языков. Это проявлялось, например, в последние годы в издании 309 закона об отмене в средних школах Российской Федерации национальных компонентов, в том числе татарского языка, введение системы сдачи в национальных школах государственных экзаменов на русском языке, введение Положения о приеме в вузы, которое предусматривает сдачу вступительных экзаменов на национальные отделения по русскому языку и литературе, сокращение на селе школ с национальным языком обучения под предлогом их оптимизации и т.д.

Не может не вызвать озабоченности у нерусских народов все чаще повторяющиеся в последнее время утверждения руководителей Российской Федерации о том, что в России якобы имеется одна единая так называемая российская нация, под которой подразумевается, конечно же, русская нация. В унисон этим мерам слышатся голоса представителей центральных властей о желании ликвидировать национальные республики путем превращения их в губернии.

Духом возвеличивания лишь одной русской нации было пропитано последнее послание Президента России В.В.Путина парламенту РФ, такой же дух царит в Стратегии национального развития России и в новом законе об образовании.

Не надо иметь большого ума чтобы понять, что раздувание в последнее время надуманной опасности на территории Татарстана религиозного экстремизма направлено на дестабилизацию обстановки в республике с тем, чтобы помешать прогрессивному развитию народов Татарстана, возможно, не будет ошибкой если

скажем, прежде всего татарского народа, вызывая хаос и смуту среди населения.

Есть много и других факторов, свидетельствующих о том, что кольцо блокады свободного развития нерусских народов все более сжимается.

В этих условиях становится очевидной необходимость, усиливая свою бдительность, проявлять всем нам большую активность по дальнейшему развитию своей культуры, сохранению родного языка, используя любые возможности для обеспечения хорошего знания и взрослым населением, и детьми, и подростками своего родного языка, для создания условий для его изучения всеми.

Для решения этих задач нам следует усилить свою гражданскую позицию и принципиальность, не боясь высказывать свое твердое слово. В вопросах сохранения, обучения и развития родного языка и правительству, и парламенту надобно проявлять большую решительность и принимать более действенные меры. Ведь у нас в республике имеются законы и постановления, призванные обеспечивать выполнение этих благородных задач. Надо лишь добиваться реализации этих законодательных актов. А это дело прежде всего руководства республики.

Говоря о необходимости выступать всем единым фронтом за сохранение и развитие родного языка, нельзя не затронуть один деликатный, но очень важный вопрос, имеющий прямое отношение к данной теме. Это вопрос о степени патриотичности, вернее о безразличии определенной части татарского населения, относительно проявления чувств любви, уважения к своей культуре, к родному языку, к своему народу.

Горькая правда в этом вопросе заключается в том, что некоторые из татар (а таких, к сожалению, немало) считают не очень приемлемыми всякие заявления о необходимости развития всего национального, татарского, с большой предосторожностью или даже с боязнью относятся к самой идее развития национальной культуры, как и в целом самой нации. Это проявляется в том, что некоторые родители не хотят отдавать своих детей в татарские школы, выступают против изучения в школах татарского языка, не выписывают и не читают газеты и журналы, художественную литературу, не слушают и не смотрят радио и телевизионные передачи на татарском языке, не интересуются татарскими спектаклями, не хотят воспитывать своих детей в семье на родном языке и т.д.

Говоря об этом, я не собираюсь строго осуждать этих людей в таком, мягко говоря, в безразличии ко всему своему родному. Причин такого положения много. В целом это результат всей предыдущей национальной политики Советского Союза и успешно продолжающейся в его преемнике России, которая направлена на всяческое возвеличивание лишь одной русской нации в ущерб самобытности всех других наций и народов. Жесткая и жестокая политика СССР была построена таким образом, что в любом стремлении к развитию своего, национального властные структуры готовы были усматривать что-то негативное, запретное, и на радетелей о своем национальном вешали ярлык националиста, что сопровождалось в последующем трагическими событиями для них. Поэтому народ был напуган, жил в постоянном страхе обвинения в национализме, который квалифицировался властями как преступление.

И это чувство боязни, боязливости, крепко осевшее в сердцах миллионов людей прошедшего столетия не стерлось и поныне, как бы по генам передалось и к нынешнему среднему поколению и даже части молодежи. Уже несколько столетий, с момента падения Казанского ханства, Русское правительство огнем и мечом воспитывало у инородцев, в том числе и татар, покорность, внушая им якобы их второсортность.

Во дворе уже давно XXI век, и пора наконец обрести полное духовное раскрепощение, чувствовать себя равноправными со всеми гражданами своей страны и достойными людьми всей планеты. Эту мысль я подчеркиваю потому, что нам, татарам, вместе со своим руководством, то есть совместно с Президентом, парламентом и правительством, впору целенаправленно и эффективно, по специальной программе, заниматься воспитанием и у взрослых, и у молодежи, и детей чувств национальной гордости и патриотизма. Для этого возможности большие, и обстановка вполне благоприятствует.

Что я подразумеваю, говоря о возможностях, вернее, об условиях воспитания национального патриотизма? Это то, что у нас, у татар, богатая история, древняя культура, развитый древний язык, тысячелетняя литература, наш народ – труженик, смелый защитник своей родины. Сколько у нас было и есть выдающихся личностей во всех сферах жизнедеятельности. Еще в древней Волжской Булгарии, родине наших предков, жили и творили известные ученые (в истории они известны), выдающиеся люди из

татар жили и в Казанском ханстве и в последующие века в Русском государстве. Ученым-богословом мирового масштаба, например, был Шигабутдин Марджани, имя которого носит теперешняя мечеть на улице Каюма Насыри. Научные труды Ш.Марджани ныне хранятся в крупных библиотеках Англии, Германии и других стран.

Гордостью татарского народа в настоящее время являются многие крупные ученые, деятели культуры, искусства, выдающиеся спортсмены, военачальники. Это такие, как академики Роальд Сагъдеев, Рашид Сюняев, Роберт Нигматуллин, Камиль Валеев, Эдхам Тенишев, композиторы Салих Сайдашев, Софья Губайдуллина, Фарид Яруллин, солисты мирового балета Рудольф Нуриев, Ирек Мухамедов, актеры театра и кино Чулпан Хаматова, Марат Башаров, Сергей Шакуров, звезды эстрады Альбина Шагимуратова, Дина Гарипова, Эльмира Калимуллина, неоднократные чемпионы мира и олимпиады Алина Кабаева, Лейсан Утяшева, Марат Сафин, Зинатулла Билялетдинов, генералы армии Махмуд Гараев, Рашит Нургалеев. Если продолжить этот список, он будет длинным.

А сколько у нас было Героев Советского Союза и Социалистического Труда! Сотни! Пропорционально они занимают второе место после русских.

Очень многих выдающихся сынов и дочерей татар, расселенных по всему миру, мы еще не знаем.

Вот оно прекрасное поле деятельности для патриотического воспитания детей и молодежи, да и взрослых. Именам и деяниям таких выдающихся личностей следует предать широкую гласность. О них надо подробно рассказывать, их надо широко освещать в средствах массовой информации – в печати, на радио и телевидении, о них надо создавать документальные и художественные произведения, кинофильмы.

Побольше узнавая героические подвиги, великие добрые дела соплеменников, глубоко познавая свой народ, славные страницы его истории, у молодежи и взрослых будут зарождаться чувства законной гордости за свой народ, уважение и любовь к нему, что будет вызывать у них потребность в изучении и знании своего родного языка, своей культуры, литературы и искусства.

Разумеется, при написании этих строк я осознаю, что писать проще, чем реализовать эти мысли. Не все так просто осуществлять это. Есть бюджет. Есть еще Москва и многое другое.

При выполнении серьезных задач, связанных с воспитанием национальной гордости кто-то из представителей местных властей, наверняка, будет оглядываться в сторону Москвы: что скажут там, не обвинят ли нас в сказанном выше национализме? Кто-то, возможно, и из самой Москвы будет напоминать об этом. Но я глубоко убежден, что в этом деле опасаться кого-то не следует. Показ достижений своего народа, освещение деяний выдающихся соплеменников – это вовсе не нарушение законов, тем более не преступление. Сохранение и приумножение духовного богатства своего народа через демонстрацию его достойных представителей – это гуманный акт, законное действие. Это гражданский долг каждого человека.

Действия, направленные на сохранение и процветание национальной культуры, языка и других атрибутов духовной жизни того или иного народа ничего общего не имеет с так называемым пресловутым национализмом. Такие действия могут стать отрицательными лишь тогда, когда они наносят урон другому народу. Подлинная цивилизация, настоящий демократизм подразумевают свободное развитие всех наций и народов, их культур и языков.

Что касается татар, то они веками живут в дружбе и тесном сотрудничестве с русскими и другими народами. Нет причины для раздора и ссоры между ними. Страна у нас огромная и республика просторная, земли и места всем хватит. Никаких притеснений никого и кем-либо!

Святой долг представителей каждого народа, каждого гражданина – сделать все возможное для сохранения и развития своего народа, своей культуры, своего языка.

Серьезная задача Республики Татарстан на духовном поприще – воспитывать и обучать молодежь высоконравственную, эрудированную, владеющую тремя языками – родным, русским и английским.

Родной язык – это язык матери (ана теле – у татар). Он для каждого дорог, как родители, как своя Родина, родная земля. Без родного языка нет народа и нации. Так будем же беречь его и заботиться о нем.

# СОХРАНЕНИЕ РОДНОГО ЯЗЫКА – ДОЛГ КАЖДОГО

В результате принятия закона и правительственной программы о языках народов Татарстана в республике был предпринят ряд серьезных мер по сохранению и развитию татарского языка: усилилось внимание к преподаванию родного языка, увеличился объем средств массовой информации на татарском языке, отношение к нему как со стороны руководства республики, так и со стороны самого населения стало более позитивным.

Однако утверждать, что в настоящее время с проблемой сохранения и развития татарского языка все благополучно, не приходится.

На сегодняшний день существуют две серьезные проблемы, связанные с состоянием и перспективой татарского литературного языка. Первая из них связана с функционально-стилистическими особенностями, то есть какой процент татарского населения владеет своим родным языком и как активно использует его в своей жизни. Вторая проблема заключается в том, каково качество употребления татарского языка его носителями, то есть каков уровень культуры их речи.

Что касается степени употребительности татарского языка, то количество татар, в совершенстве владеющих своим родным языком и свободно общающихся на нем, в последние годы больше не стало. Наоборот, оно, кажется, имеет тенденцию к постепенному сокращению. Это связано, во-первых, с тем, что численность татарского населения, проживающего на селе, в связи с процессом урбанизации, все более уменьшается. Между тем, как известно, сохранение и развитие татарского языка, прежде всего, обусловливается стабильной жизнью сельского татарского населения.

Во-вторых, современным татарам, проживающим в городах совместно с представителями других национальностей, свойственно на производстве, в общественных местах, на транспорте разговаривать на русском языке. К тому же, если взрослое татарское население дома общается, как правило, на своем родном языке, то значительная часть татарских юношей и девушек, а также детей даже в семье в своем общении все больше пользуется русским языком.

Для выросшей в городе татарской молодежи языком общения в учебных заведениях является тоже, в основном, русский язык.

Такова современная языковая картина татар.

Языковая политика, как и в целом национальная политика, а также национальные отношения – это очень тонкая, деликатная область. Здесь нельзя решать вопросы принудительно, администрированием. Нужен взвешенный, разумный подход. В этом деле, как и в других, должны проявляться выражение воли и демократические принципы. Нельзя силой заставлять людей говорить лишь на их родном языке.

Современному обществу требуются люди, владеющие как их родным, так и русским и английским языками. Однако, бесспорно то, что представители всех народов, в том числе, разумеется, и татары, должны как можно лучше знать свой родной язык и уметь свободно общаться на нем, хотя бы дома, в своих семьях. Это главное условие для выживания нации и народа.

Сохранение и развитие языка – важнейшее политическое дело государственного, мирового масштаба. Ибо каждый язык, независимо от того, кому он принадлежит – или многочисленной нации, или малочисленному народу, этносу – это драгоценный клад, созданный тем или иным народом. Если язык функционирует, то живет и народ, который им пользуется, если исчезает язык, то не становится и самого народа.

Различные языки и вместе с ними национальные культуры логично сравнивать с лесной поляной, состоящей из множества разнообразных цветов, образующих вместе красочный ковер. С потерей этих цветов будет пропадать и красота ковра. Так же и с языками: с потерей каждого из многочисленных языков обществу, культуре народов будет нанесен непоправимый урон. Сохранение и развитие родного языка требуют глубоко продуманной, многосторонней работы, которая должна осуществляться по специальной государственной программе.

Изложим некоторые из задач, составляющих данную программу.

Важнейшим условием для прогресса татарского народа, развития его языка, культуры является воспитание у населения, в особенности у детей и молодежи, чувств национальной гордости и патриотизма.

Быть патриотом – это значит любить свою страну, свою Родину, дорожить ею. Однако патриотизм для татар не ограничивается лишь этим. Для того, чтобы у них присутствовало желание знать

и сохранять родной язык, свою культуру, совершенствовать и развивать их, обогащать духовные ценности, необходимо иметь в себе такие качества, как любовь к своему народу, родному краю, его природе, уважение к своей истории, возвеличивание и почитание великих людей, личностей, гордость ими.

Воспитание у молодежи патриотизма и национальной гордости на сегодня представляет самую важную и вместе с тем самую сложную задачу. И ее можно решать лишь комплексом глубоко продуманных, серьезных задач, проводимых государством, правительством республики.

Во-первых, необходимо знакомить молодежь, как среднее и старшее поколение, в доступной и увлекательной форме с богатой историей татарского народа. История татар восходит к древним временам, и она достаточно полно насыщена яркими страницами, примерами самоотверженности и героизма, событиями, способными пробудить чувства патриотизма и гордости за свой народ.

В этих целях прежде всего Министерству образования республики следует в ближайшее время критически пересмотреть учебники истории татар и народов Татарстана и там, где это необходимо, переиздавать их с учетом требований к ним максимальной объективности. В то же время необходимо активно издавать популярные книги, освещающие различные периоды жизни татарского народа.

Во-вторых, важнейшим средством в воспитании у людей чувства национальной гордости является пропаганда великих сынов и дочерей, крупных личностей татарского народа. Справедливости ради следует заметить, что есть очень много выдающихся лиц из татар, которые не могут не вызывать не только у молодых, но и у старшего поколения чувства законной гордости за свой народ.

Задача заключается в том, чтобы достойно показывать всех выдающихся татар, волею судьбы разбросанных по всему свету. О них следует написать книги, освещать их жизнь и дела в печати, создавать о них радио и телепередачи, кинофильмы.

Воспитание патриотизма и национальной гордости остро необходимо для всего татарского народа. И реализации это цели должны служить все соответствующие органы под руководством правительства – в первую очередь печать, радио-телевидение, министерство образования, учреждения культуры, учебные заведения, книжные издательства.

Одним из условий сохранения и развития татарского языка является совершенствование, улучшение системы обучения родному языку.

Следует признаться, что проблем, связанных с преподаванием татарского языка, еще немало. Это особенно касается обучения детей, плохо знающих свой родной язык или совершенно не владеющих им. Не секрет, что имеется немало упреков по поводу преподавания татарского языка со стороны родителей детей, обучающихся в школах с русским языком обучения или в русских классах смешанных школ. Оставляет желать гораздо лучшего знания татарского языка детей, посещающих уроки родного языка в таких школах и классах в течение всего периода обучения. Странно, но факт: дети овладевают английским языком быстрее и лучше, чем своим родным. Тут есть, о чем задуматься.

То, что дети, обучающиеся в городских школах, слабо владеют своим родным татарским языком, и что нередко не хватает серьезного отношения и внимания к обучению их родному языку, объясняется следующими обстоятельствами.

Первое – это дефицит в патриотизме, национальной гордости, о чем было сказано выше.

Второе – недостаточно высокий уровень преподавания родного языка.

Третье – отсутствие совершенной методики обучения татарскому языку детей, не общающихся в семье на их родном языке.

Все эти факторы взаимосвязаны и взаимообусловлены. И все они основываются на одном главном обстоятельстве: отношение к обучению татарскому языку как ко второстепенному делу и отсутствие у людей, занимающихся этим делом, необходимой ответственности и требовательности к себе и другим.

Корни отсутствия должного внимания и ответственного отношения к преподаванию татарского языка уходят далеко. Обучение детей-татар, занимающихся в русских школах, родному языку в течение нескольких десятилетий осуществлялось формально. Учащиеся-татары, посещая уроки родного языка, до окончания школы так и не могли выучить этот язык в совершенстве. Ибо в организации и проведении уроков татарского языка имели место серьезные недостатки: преподавание нередко велось не специалистами, были проблемы, связанные с качеством учебников и методикой обуче-

ния, не хватало наглядных пособий и технических средств, были и другие неурядицы.

Между тем обучение детей-татар своему родному языку в русскоязычных школах представляет собой значительную возможность для сохранения татарского языка, так как количество школ с русским языком обучения и численность обучающихся в них детей-татар в Республике Татарстан значительно.

Упомянутые выше и не отмеченные здесь другие сложности в сохранении, обучении и развитии татарского языка в конечном счете создают не всегда благополучную атмосферу вокруг татарского языка. Не случайно, что редко встретишь говорящих на своем родном языке татар в общественных местах, на транспорте и на улицах городов Татарстана, хотя в них большую часть жителей составляют татары. Не случайно также и то, что большая часть детей и подростков-татар, проживающих в городах, общается дома не на своем родном языке.

Сохранение и развитие родного языка подразумевает не только расширение его функций и увеличение численности населения, говорящего на нем, но и обеспечение его качественного уровня, соблюдение носителями языка его литературных норм, то есть поддержание культуры речи.

Современные татары в преобладающем своем большинстве двуязычны. Многие из них уже несколько десятилетий, наряду со своим родным языком, довольно хорошо владеют русским языком и свободно общаются на нем. Роль русского языка в жизни татар, как и других народов Российской Федерации, приобретает все большее значение.

Если владение татарами русским языком, с одной стороны, создает больше условий для их успешной жизнедеятельности, то, с другой, возлагает на них и ответственность за правильное пользование обоими языками.

Эта ответственность обусловлена тем, что носитель двух языков (билингв), если в совершенстве не владеет обоими языками и не имеет филологических знаний о соотношении языков, отдельные лексические единицы, грамматические формы русского языка ошибочно (механически) переносит в татарский язык, в результате чего особенности, правила, нормы родного языка, свойственные лишь ему, искажаются, нарушается его естественная природа.

Именно по этой схеме двуязычные обладатели пера нередко занимаются автоматическим переносом в татарский язык невостребованных им слов, выражений, морфологических и синтаксических форм русского языка, противоречащих нормам родного языка. Данное явление более всего наблюдается в средствах массовой информации, и оно приобретает все большее распространение.

Разумеется, нельзя полагать, что все нарушения норм татарского языка происходят лишь вследствие неправильного перевода с русского языка. Часть их является результатом прежде всего несовершенного знания журналистами и другими билингвами родного татарского языка, а также их невнимательного, халатного отношения к языку, слову вообще.

Языковые ошибки, распространяясь и увеличиваясь количественно, приводят к подрыву естественной природы языка, постепенно расшатывают его основу, структуру. Если этот процесс будет продолжаться беспрепятственно, то язык со временем может потерять свою самобытность и стать каким-то искусственным, суррогатным, то есть окончательно потерять свое соответствующее оригинальное качество.

В свете сказанного возникает серьезная задача для всех – журналистов и писателей, ученых, преподавателей и для всего населения – встать в защиту правильности, чистоты родного языка.

Какие же имеются пути и средства для соблюдения норм культуры речи, для поддержания чистоты и правильности родного языка?

Одним из главных средств является улучшение качества преподавания татарского языка в учебных заведениях различного уровня, для чего прежде всего необходимо повышать ответственность преподавателей, а также требовательность к обучающимся за их знания.

Следует ввести в учебные планы общеобразовательных школ, специальных средних и высших учебных заведений такие предметы, как основы культуры речи, теория и практика перевода, и соответствующие специальные курсы.

Необходимо в печати, на радио и телевидении пропагандировать культуру речи, открывая для этого специальные рубрики, проводить популярные занятия по привитию населению правильных литературных норм современного татарского языка.

Перед Татарским книжным издательством стоит задача издания книг по культуре речи и теории и практике перевода.

Необходимо резко повысить ответственность журналистов, ученых и всех тех, кто владеет мастерством пера, за сохранение чистоты и правильности языка, соблюдение норм литературного языка. Обладание культурой родной речи, правильными литературными нормами языка – это неразрывная часть общей культуры человека. И поэтому борьба за чистоту родного языка, культуру речи – священный долг каждого, кто любит свой родной язык, свою культуру, свой народ и дорожит ими.

# СӨЙЛӘМ КУЛЬТУРАСЫ
# КУЛЬТУРА РЕЧИ

## МАТБУГАТ ҺӘМ ТУГАН ТЕЛ

Хәзер татар телен, бигрәк тә әдәби телне, саклау һәм үстерү өчен, шартлар көннән-көн кыенлаша: соңгы бер-ике дистә елда милли мәктәпләрнең саны нык кимеде һәм булганнарында да туган телне укытуның сәгатьләре бик аз калды. Димәк, ана телен өйрәнү һәм аны куллану дәрәҗәсе кискен түбәнәя бара. Шуңа бәйле рәвештә татар әдәбиятын укучыларның сафлары да күзгә күренеп сирәгәя. Бу, телебездән файдаланучыларның мәйданы да тарая, һәм татар теленең яшәешенә куркыныч яный дигән сүз.

Әлбәттә, халык туган теленең бетүенә йөз тотуы белән килешеп тормас, Татарстанның хакимият ияләре дә туган телебезнең, мәдәниятнең һәм милләтнең киләчәгенә һәрвакыт битараф булмаслар. Ләкин вакыт уза, һәм әлегә дәүләт, телебезне саклап калу өчен, тиешле дәрәҗәдә җитди чаралар күрергә ашыкмый. Республикабызда шушындый хәләт хөкем сөргәндә, туган телебезне аның сафлыгын, дөреслеген югалтмыйча саклау өчен ниләр эшләргә, нинди чаралар күрергә мөмкин икән соң ? Бу сорау барыннан да бигрәк көндәлек эшләре туган тел белән бәйләнгән һөнәр ияләренә карый. Мондый һөнәр ияләренең иң бәрәкәтлеләре, иң куәтлеләре – журналистлар.

Бүгенге көндә телебезне яшәтү дигән тарихи миссия беренче чиратта газета-журналлар әзерләп чыгаручы каләм ияләре журналистларга йөкләнә. Республикабызда һәм аз гына булса да чит өлкәләрдә дә атнага бер яки берничә тапкыр меңнәрчә тиражлар белән чыгып бара торган дистәләрчә газета һәм журналлар, халыкның рухи ихтыяҗын канәгатьләндереп, аның карамагына туган телебездә әзерләнгән бихисап күп санлы язмалар тәкъдим итеп торалар. Матбугат – халыкның дөрес әдәби туган телен өйрәнүенә һәм куллануына ярдәм итеп торырга тиешле бик әһәмиятле чара.

Һәм бүгенге көндә безнең журналистларның изге бурычы – матбугатны саф, матур, чын татар әдәби телендә әзерләп укучы-

га җиткерү. Матбугатның табигый дөрес татар телендә чыгып баруы – телебезнең саклануы өчен иң нәтиҗәле, иң мөһим шарт. Без бу язмабызда матбугатка куелган шушы югары таләп җирлегендә бүгенге газеталар теленең торышы, сыйфаты, андагы проблемалар хакында һәм шул уңайдан татар журналистлары алдында торган бурычлар турында әңгәмә корырбыз.

Күп санлы газета-журналларда халык яратып укый торган үтемле, тәэсирле телдә язылган материаллар аз түгел, шулай ук республика шәһәр һәм районнарында чыгып килгән матбугатны әзерләүчеләр арасында телне яхшы белгән, тәҗрибәле, сәләтле журналистлар да бар.

Халыкның рухи тормышында әһәмиятле роль уйнаган журналистларның фидакарь хезмәтләренә югары бәя биреп, без татарча газета-журналларның бүгенге көндә туган телне саклау өлкәсендәге роленә аеруча зур игътибар итәргә кирәк дигән фикердә торабыз. Хәзерге шартларда милли матбугатка куелган иң мөһим таләпләрнең берсе шул: аның теле үрнәк әдәби тел булырга тиеш. Безнең газеталарның җәмгыятьтә тоткан урынын билгеләгәндә аларның эчтәлеге, тематикасы белән бер үк вакытта телләренең сыйфаты, әле әйтелгән үрнәк тел таләбенә җавап бирә алу-алмауларын да исәпкә алу зарур.

Мин, дистәләрчә еллар буена татар матбугатын даими рәвештә укып, аның турында йөзләрчә мәкаләләр, дистәләрчә китаплар язган кеше буларк, татарча газета-журналларның теленә карата мөнәсәбәтемне белдерерлек нигезем һәм моңа хакым бардыр дип уйлыйм. Менә шушы кереш сүздән соң, безнең бүгенге газеталарыбызның теле һәм андагы проблемалар хакында кайбер фикерләребезне бәян итәрбез.

Әйтелгәнчә, чагыштырмача канәгатьләндерерлек телдә чыга торган газеталар, шактый дөрес, үтемле телдә язылган материаллар булуга карамастан (алар барысы да шулай булырга тиеш, гомумән алганда безнең хәзерге татарча газеталарыбызның телендә проблемалар күп. Алар, йомгаклап әйткәндә, нигездә, шуннан гыйбарәт: бүгенге газеталарда телне бозып куллану киң таралган, гадәти күренешкә әверелә бара. Телне бозу төшенчәсе күп төрле мәгънәләргә ия. Монда аерым сүзләрне, тәгъбирләрне үзләренә хас булмаган, ят мәгънәдә куллану да, татар телендәге яңа лексик берәмлекләр ясалышы кагыйдәләре бозылып ясалган сүзләр һәм әйтелмәләр дә, урынсыз, кирәксезгә чит тел алынмалары, халыкка

аңлашылмый торган искергән сүзләр куллану да, туган телнең бай сүзлеге мөмкинлекләреннән, аның синонимнары хәзинәсеннән, лаеклы грамматик формаларыннан тулы файдалана белмәү, телнең табигый синтаксик төзелешен, тәртибен, кагыйдәләрен (нормаларын) бозу һәм башка тискәре күренешләр керә.

Матбугаттагы иҗтимагый-сәяси, фәнни-техник эчтәлекле материалларның, төрле хәбәр-белдерүләрнең теле көннән-көн җанлы, табигый сөйләм теленнән аермалы, үзенә күрә бертөрле коры, “казенный”, ясалма-калька теле була бара. Бу кырыс фикеребез буш сүз генә булып калмасын өчен, без аны реаль фактлар, конкрет мисаллар белән растарга тырышырбыз, шул ук вакытта бүгенге матбугат телендә киң таралган, күп санлы тупас ялгышларның барлыкка килү сәбәпләрен ачыклап, алардан арыну һәм аларны моннан соң булдырмау чараларын да тәкъдим итәрбез.

Татарча матбугат теленең шулай торган саен ныграк бозыла, коры, бизәксез, “казенный” телгә әверелә баруының төп сәбәбе журналистларның, күп материалларны русчадан тәрҗемә итеп алганда, тәрҗемә эшенең принцип-методларын белмәгәнлектән, рус теленә генә хас сүз, тәгъбир, җөмлә өлгеләрен механик рәвештә татар теленә күчереп куюларында. Тәрҗемә, нигездә, алар тарафыннан сүзгә-сүз, хәрефкә-хәреф (калькалаштыру) ысулы белән башкарыла. Болай тәрҗемә итү, мәгълүм булганча, икенче телдә оригиналның эчтәлеген, мәгънәсен төгәл белдерергә дә комачаулый һәм тәрҗемә теленең табигый төзелешен бозуга да китерә.

Безнең татар һәм рус телләре белән эш итүче, гадәттә, икенчесеннән беренчесенә тәрҗемә итү белән шөгыльләнүче каләм ияләребез бу эштәге иң әһәмиятле, хәлиткеч принципны исәпкә алмыйлар: бер телдәге текстны, сөйләмне икенче телгә күчергәндә оригиналның эчтәлеге, мәгънәсе мөмкин булганча төгәл белдерелергә тиеш, шул ук вакытта тәрҗемә теле дөрес, табигый тел буларак сакланырга тиеш. Бу принцип оригиналның җөмләсенә (кайчакта аннан да киңрәк контекстка), сүзтезмәсенә (тәгъбиренә, гыйбарәсенә) салынган мәгънәне тәрҗемә теле чаралары ярдәмендә белдерү юлы белән гамәлгә ашырыла. Татар матбугатында хезмәт итүчеләр исә, нигездә, оригиналның һәр сүзен тәрҗемә телендәге аерым сүз ярдәмендә тәгъбир итү ысулы белән эшлиләр. Шуның өстенә, тәрҗемә телендә оригинал сүзенә тәңгәллек, гадәттә, ул сүзнең киң контексттагы (тексттагы, җөмләдәге, әйтелмәдәге) мәгънәсен белдерерлек итеп түгел, бәлки аның иң күп тарал-

ган, ике тел сүзлекләрендә теркәлгән, төп мәгънәсен белдерерлек итеп кенә билгеләнә. Бу тәрҗемә теленең хасиятен, табигый үзенчәлекләрен бозуга китерә. Матбугатта рус теленең һәр сүзен татар теленә һәр очракта да аерым сүз белән һәм аның, кагыйдә буларак, төп тәңгәллеге ярдәмендә генә тәрҗемә итү аркасында барлыкка килгән ялгышлар күп санлы һәм күп төрле. Сүзгә-сүз һәм төп тәңгәлләкләр белән генә тәрҗемә итү барыннан да бигрәк татар теле сүзләренең сөйләмдә үзара табигый бәйләнешкә керү нормаларын (кагыйдәләрен) бозуга китерә, чөнки төп мәгънәләре белән тәңгәл ике тел сүзләре сөйләмдә башка тәңгәл сүзләр ярдәмендә үзара мәгънәви (семантик) бәйләнешкә керү үзенчәлекләре буенча бер очракта бер-берсенә туры килсәләр (бердәй булсалар), икенче очракта – туры килмиләр (бер-берсеннән аерылалар). Мәсәлән, татар телендәге **птица, лететь** сүзләре һәм аларның татар телендәге тәңгәллекләре **кош** һәм **очу** сүзләре ике телдә дә, үзара мәгънәле бәйләнешкә кереп, табигый сүзтезмә (җөмлә) тәшкил итәләр: **птица летает – кош оча**. Шул ук вакытта рус телендәге **человек** һәм **лететь** сүзләре, үзара бәйләнешкә кереп, мәгънәле берәмлек тәшкил итсә (мәсәлән, "Р.Н.Миңнеханов полетел в Москву" җөмләсендә), аларның татар телендәге тәңгәллекләре **кеше** һәм **оча**, үзара бәйләнешкә кереп, табигый сөйләм берәмлеге тәшкил итә алмый: **кеше оча** (мәсәлән, "премьер-министр Кытайга оча") дип әйтеп булмый. Русчадан тәрҗемә итеп эшләүче журналистларның (аларның барысына да диярлек күпмедер дәрәҗәдә тәрҗемә итәргә туры килә) телендәге күп ялгышлар нәкъ менә шушы ике телдәге тәңгәл сүзләрнең мәгънәле бәйләнешкә керү үзенчәлекләрен исәпкә алмаулары, тәгаенләп әйткәндә, татар һәм рус телләрендәге тәңгәл сүзләрнең семантик бәйләнешләрендәге гомуми һәм аермалы сыйфатларын белеп эш итмәүләре, рус телендәге сүзләр бәйләнеше өлгеләрен татар теленә механик рәвештә күчереп куюлары аркасында килеп чыга.

Газеталарда сүзләрнең сөйләмдә үзара табигый семантик бәйләнешләре бозылып төзелгән әйтелмәләр (сүзтезмәләр) меңнәрчә исәпләнә. Аеруча гыйбрәтлеләрен – татар теле өчен бигрәк тә ят, сәер, котсыз, ямьсезләрен – укучылар игътибарына да тәкъдим итәргә булдык.

Рус теленең **рост, развитие** сүзләрен һәр очракта да ялгыш **үсү** сүзе белән тәрҗемә итү нәтиҗәсендә барлыкка китерелгән "гарип" сүзтезмәләр (тәгъбирләр):

Хезмәттәшлек үсә (дөресе – хезмәттәшлек киңәя, җәелә, ныгый һ.б.; элемтәләр үсә (элемтәләр киңәя, ныгый һ.б. кирәк); акча күләме үсә (...арта кирәк); температура үсә (күтәрелә); тарифлар үсә (күтәрелә, арта); мөнәсәбәтләр үсә (...ныгый кирәк); канәгатьсезлек үсә (көчәя); вакыйгалар үсә (куера, кискенләшә); Россиядән качарга теләүчеләр саны үсә (арта); бәяләр үсә (арта, күтәрелә); ризасызлык үсә (көчәя, арта); киеренкелек үсә (көчәя, арта); авыру үсә (көчәя); хәл үсә (киеренкеләнә, катлаулана); куркыныч үсә (арта); республика законнарын үстер (чыгару, камилләштерү һ.б.); төзү тармаклары үскән субъект (алга киткән субъект); сәнәгать комплексын үстерү (ныгыту, җәелдерү); караклык темпы 5,5 тапкыр үскән (арткан, күтәрелгән); акча суммасы үсә (арта); хәләл тормыш рәвешен үстерү (гадел яшәүне алга җибәрү, алга сөрү); авыллар үссен өчен (алга барсын, яхшы яшәсен өчен); тормыш дәрәҗәсе үскән (күтәрелгән, тормыш яхшырган); картлык пенсиясе үскән (арткан) һ.б.

**Глубокий (ая, ое)** сүзен һәрчак төп мәгънәсендәге **тирән** сүзе белән тәрҗемә итү аркасында барлыкка килеп, газета-журналларда гына түгел, радио-телевидениедә дә һәм башка урыннарда да еш кулланыла торган гайре табигый (табигый булмаган) гыйбарәләр:

Тирән ихтирам (дөресе – нык (бик) ихтирам итү, зур, олы ихтирам һ.б.); тирән мәхәббәт (көчле мәхәббәт, нык ярату һ.б.); тирән кайгы (зур кайгы, кара кайгы); тирән борчу (зур борчу); фәнне тирән белгән укытучылар (фәнне яхшы белгән укытучылар); тирәнтен ялгыша (нык ялгыша); тирән рәхмәт (зур рәхмәт); тирән тәэсир (көчле тәэсир); тирән кызыксыну (нык кызыксыну); тирән үзләштерү (нык, яхшы, төптән үзләштерү); тирән игътибар (зур игътибар); тирән ышаныч (нык ышану, зур ышаныч); тирән дуслык (нык, көчле дуслык); тирән канәгатьләнү (нык, зур канәгатьләнү); тирән уйлану (ныклап уйлану, җитди уйлану); тирән үзгәреш (зур үзгәреш); тирән ачу (зур ачу); тирән аңлау (яхшы, төптән аңлау) һ.б.

Рус телендәге **крупный (ая, ое)** һәм татар телендәге **эре** сүзе мәгънәләре белән бер-берсенә өлешчә генә туры киләләр: бер үк төрле зур кисәкләрдән торган (киресе **вак**), шулай ук данәләп исәпләнә торган әйберләр (эре күкәй, эре суган, алма һ.б.). Рус телендә татарча **эре** мәгънәсендәге күп сүзләр **большой (ая, ое)** сүзе ярдәмендә белдерелә. Ләкин үзара мөнәсәбәттәге телләрнең специфик (берсенә генә хас) үзенчәлекләрен белеп бетермәгән каләм ияләре, **крупный** сүзен, контексттагы (сөйләмдәге) конкрет

мәгънәсенә төшенеп тормыйча, һәр очракта да **эре** дип тәрҗемә итәләр һәм нәтиҗәдә тупас ялгышлар ясыйлар. Мисаллар: эре шәһәрләр (дөресе – зур шәһәрләр); эре предприятиеләр (зур предприятиеләр); эре җитәкче (зур...); эре районнар; эре халыклар (күп санлы халыклар); алдагы мисалларның барысында да **эре** урынында **зур** сүзе кулланылырга тиеш: эре завод, эре ширкәт, эре комплекс, эре аквапарк, эре фәнни үзәк, эре оешма, эре дәүләт, эре ил һ.б.

**Предупредить**, мәгънәсеә карап, татар теленә төрле сүзләр белән тәрҗемә ителергә тиеш: а) ниндидер ярамаган, хәтәр, зарарлы эш (күренеш) булуы турында кешеләргә алдан әйтеп, хәбәр итеп куйганда **кисәтү** сүзе белән (мәсәлән, баланы шырпы белән уйнарга ярамаганлыгы турында кисәтү); б) ниндидер тискәре, зарарлы күренешне, хәлне булдырмас, өчен тиешле чаралар күрү мәгънәсендә **булдырмау, булдырмый калу, саклану** сүзләре белән. Ләкин ике тел ияләре еш кына бу хакта белмиләр һәм **предупредить**ны һәр очракта да **кисәтү** дип тәрҗемә итәләр. Нәтиҗә, әлбәттә, тискәре була: татар теленең дөрес сөйләм нормалары тупас бозыла. Мәсәлән: “Максат – сәламәтлеккә зыян салуны кисәтү” (дөресе – “... зыян китермәү, зыян китерүдән саклану); “Астманы ничек кисәтергә?” (“Астманы ничек булдырмаска?” яки “Астмадан ничек сакланырга?”); “Җир җиләге кан тамыры-йөрәк авыруларын кисәтә” (дөресе – “...авыруларын булдырмаска ярдәм итә” яки “...авыруларыннан саклый”);

Туберкулезга каршы кисәтү чаралары (дөресе – Туберкулезга каршы көрәш чаралары); Авыруны дәвалауга караганда, кисәтү җиңелрәк (дөресе – Авыруны дәвалауга караганда, аннан саклану җиңелрәк); ...халыкның наркотикларга ияләшүен кисәтү буенча комплекслы программа (...халыкны наркотикларга ияләштермәүнең комплекслы программасы); Табигый һәм техноген һәлакәтләрне кисәтү буенча эшне оештыру (Табигать һәм техноген һәлакәтләреннән саклану (яки котылу) эшен оештыру); Җиләк куакларының өшүләрен кисәтү (Җиләк куакларын өшүдән саклау).

Соңгы ике-өч елда безнең журналистлар телне куллану өлкәсендә аеруча зур новаторлык күрсәтүгә күнегеп киттеләр. Тик ул новаторлыклары үзләрен канәгатьләдерү һәм шатландыру өчен генә булса инде, югыйсә аның халык өчен, матбугат укучыларга һич кенә дә кирәге юктыр, чөнки алар чын татарча түгел, тиеш-

ле мәгънәне аңлаешлы итеп белдерә дә алмыйлар. Менә аларның кайберләре.

Рус теленең **звучать, озвучить (озвучивать)** сүзләрен тәрҗемә итә белмәүдән килеп чыккан **яңгырау, яңгырату** ярдәмендә ясалган тузга язмаган әйтелмә-сүзтезмәләр: *анда яңгыраган мәгълүматларга караганда...; шелтәләр дә яңгырады; теләкләр дә яңгырады; ...саннар коллегия утырышында яңгырады; сораулар да яңгырады; ...дәресендә яңгыраткан идеяләр; фикерләр яңгырады; чынбарлыкны яңгыратты; бу санны яңгыратты.* Бу әйтелмәләрдәге төшенчәләрнең берсе дә яңгырый торган нәрсәләр түгел, ләбаса, ул тәгъбирләрне алардагы **яңгырады** сүзен тиешле сүзләр белән алыштырып, чын татарча итеп әйтү бер дә авыр түгел: *шелтәләр белдерелә (ясала); теләкләр белдерелә(әйтелә); саннар китерелә; сораулар бирелә; идеяләр белдерелә, әйтелә; фикерләр белдерелә; тәкъдимнәр ясала.*

Русчадагы **сократить (сокращать)** сүзен һәр урында да ялгыш **кыскарту** дип тәрҗемә итү аркасында *татар теле сәгатьләрен киметтеләр яки азайттылар, татар мәктәпләрен киметтеләр яки яптылар, хезмәт хакын киметтеләр, чиновниклар санын киметтеләр* һ.б.ш дип әйтәсе урында *татар теле сәгатьләрен, мәктәпләрен, хезмәт хакын, чиновниклар санын кыскарттылар* һ.б. дип язалар һәм сөйлиләр.

Бүгенге матбугат битләрендә **живой** сүзеннән уйлап тормыйча гына тәрҗемә ителгән **тере** сүзе белән төзелгән сәер әйтелмәләр дә шактый күп күренә: *тере традиция, тере могҗизалар, тере тавыш, тере акча, тере чәчәкләр, тере тәгълимат, моңның тере гәүдәләнеше һ.б.*

**Текә (круто, крутой)** сүзе белән ясалган гыйбарәләр дә татар телен бозуга җитди өлеш кертәләр: *текә егетләр, текә почта бүлекчәсе, ...ярышта текә исем өчен 63 әби көч сынашкан* һ.б.

Рус теленнән механик рәвештә, ягъни уйлап тормыйча гына калькалаштырып алынган мондый тупас, шыксыз тәгъбирләр татар телен нык бозалар, пычраталар, аның табигый төзелешен какшаталар: *үз өстем(ң,н)дә эшләү, кул белән тудырылган гүзәллек, кошлар җырлаудан туктамый, тыйнак кына утыручы радио бинасы, яңгыраган җан ачысы,бөртекле сөйләшү, кыргый табигать, кыргый пляж, иреннәре неп-нечкә, чагыштыруны яңгыратабыз, аяклары калын, күп шалтыратулар кабул итә, укучылар өстендә нык эшләргә кирәк, сәламәт яшәү рәвеше алып бару, 100 яшьлек*

*мәчет, тәнкыйть күзлегеннән чыгып карау, нечкә иреннәрен кысып, бер төркем... хаҗ кылырга очты, сине начальникка сорыйлар, киң танылу ала, яшь кызларга үреп салган чәчләр бара, кочегар булып эшләдем, күмер йоттым, һава торышы... аязачак, матур сөйләмгә зур басым ясарга уйладык, авылларыбыз картаймасын, тәрәзә тирли, чи сөтне эчмәгез, төен пункт, вулкан эшләп тора, калын гәүдәле, нечкә тема, иң-иңнәр* һәм башка, һәм башка шулай татар сүзләре белән русча язу һәм сөйләү күренешләре (мисалларның уңай вариантлары бу юллар авторының “Матбугат һәм эфир теле” дигән китабында бирелгән).

Безнең матбугатта шулай ук рус теленең һәр сүзен татар теленә аерым сүз белән һәм, гадәттә, аның төп мәгънәсендәге тәңгәллеге ярдәмендә тәрҗемә итүгә бәйләнешле киң таралган ялгышларның бер төре сүзгә-сүз, хәрефкә-хәреф күчерү ысулы белән эш итү аркасында, сүзләрнең сөйләмдә (текстта) мәгънәви (семантик) бәйләнешен булдыруда катнашкан бәйләү чараларын дөрес билгели белмәү өлкәсенә карый. Яңа гына карап узган сүзләрнең семантик (мәгънәви) бәйләнешендәге кебек, үзара мөнәсәбәттәге татар һәм рус телләре сүзләренең сөйләмдәге бәйләнешен төзүдә катнашып, бәйләү ролен башкарган ике тел грамматик чаралары, төп мәгънәләрендә тәңгәллек буларак бер очракта бердәй вазифа үтиләр, икенче очракта аларның вазифалары бер-берсеннән аерыла. Бу күренеш төрле телләрдәге бердәй лексик мәгънәле сүзләрнең сөйләмдә үзара специфик үзенчәлекләренә ия булулары белән аңлатыла. Ул үзенчәлекләрне белү – ике тел белән эш итүчеләр (тәрҗемә итүчеләр) бер тел чараларын икенче телдә белдергәндә, оригинал теле сыйфатларын механик рәвештә тәрҗемә теленә күчереп куеп, аның табигый төзелеше кагыйдәләрен, тәртибен (нормаларын) бозудан саклау өчен катгый шарт. Ике телдәге бердәй мәгънәле сүзләрнең сөйләмдәге бәйләнеше чараларының специфик үзенчәлекләрен исәпкә алмау тәрҗемә телендәге күп санлы тупас ялгышларга китерә. Хәзер без бу күренешне мисаллар җирлегендә карап китәрбез.

...татар милләтенең киләчәге турында фикерләре белән уртаклашты; Мәрьям Мөхәммәтгәрәева... хатирәләре белән бик теләп уртаклашты; Хәсән Сарьян, Нурихан Фәттахлар... үз тәҗрибәләре белән уртаклаша иде; Алар истәлекләр белән уртаклашты; максат-хыяллар белән уртаклашу.

Данил Салихов ... уйлары белән бүлеште; Театрның яңалыклары белән ... бүлештеләр; Флора Низамова җылы хатирәләре белән бүлеште; Без сезнең шушы тәҗрибәгез белән бүлешүегезне теләр идек; Без аннан осталык серләре белән бүлешүен сорадык (мондый мисалларның исемлеген дәвам иттерергә мөмкин).

Бу мисаллардан каләм ияләренең күбесенең, татар теле җөмләләрен төзегәндә сүзләрне үзара бәйләү чараларын куллануга караган элементар грамматика кагыйдәләрен белмичә, рус теле синтаксисы өлгеләреннән файдаланулары күренә. Татар телендә гомуми семантикалы **бүлешү, уртаклашу** объект мәгънәсендәге сүзләрне үзләренә төшем һәм баш килешләре кушымчалары ярдәмендә ияртәләр һәм субьектны белдерә торган сүзгә **белән** бәйлеге ярдәмендә бәйләнәләр: мал бүлешү; малны туганың белән бүлешү; фикер уртаклашу; дусларың белән бер әһәмиятле фикерне уртаклашу. Журналистның грамматика китапларын укып торырга вакыты булмаса, ул татар теленең аңлатмалы сүзлегенә генә күз салса да ярар иде: анда **бүлешү, уртаклашу** сүзләре мисаллар белән ачык итеп аңлатып бирелгән. Югарыда күрсәтелгән тискәре мисаллардагы *тәҗрибә белән уртаклашу, серләре белән бүлешү* әйтелмәләре ялгыш **делиться (поделиться) опытом** дигән рус теле гыйбарәсенең творительный падеждагы **опытом** сүзенең татарча калькасы (*копать лопатой – көрәк белән казу*) үрнәгендә ясалган.

Сөйләмдә сүзләрнең үзара бәйләнеше чаралары, нигездә, рус теле формалары үрнәгендә ялгыш кулланылып, татар теленең табигый төзелеше, телне тел итеп саклый торган үзенчәлекләре бозылуы татарча мәгълүмат чараларында шулкадәр күп таралган һәм көннән-көн арта бара: хәтта язма һәм сөйләмә телебездәге тупас калька-ялгышларның шушы бер төре мисалында гына да бөтен укымышлы татарлар, тиешле дәүләт органнары, чаң сугып, ашыгыч чаралар күрмәсә, телебезнең хасияте, асылы бозылып, ул күпмедер вакыттан ниндидер бер корама-катыш, ясалма телгә әверелергә мөмкин дигән нәтиҗә ясарга була.

“Матбугат һәм эфир теле” дигән китапта гына да мәгълүмат чараларында ялгыш кулланылган 400гә якын бәйләү чарасы теркәлгән. Аларның күбесе, язма телнең башка жанрларында да таралып, сөйләм теленә дә кереп урнаша бара. Хәзер инде, мәсәлән, чын татарча *станокта эшләү, өстәл янында, табында утыру, партада, компьютер алдында утыру, гармун уйнау, скрипка уйнау,*

*Мәскәү янындагы (тирәсендәге) сугышлар* кебек әйтелмәләр урынына русчадан ялгыш калькалаштырып ясалган формалар (*станок артында эшләү, өстәл артында, парта артында, компьютер артында утыру, гармунда, скрипкада уйнау, Мәскәү астындагы сугышлар*) телебездәге гадәти күренешкә әверелә баралар.

Фикеребезне куәтләү ихтыяҗыннан әле әйтелгән төр ялгышларның һәм аларның дөрес вариантларының кечкенә генә таблицасын урнаштырырга булдык.

| **Ялгышлар** | **Төзәтелгән вариантлары** |
|---|---|
| *Тәҗрибәмнән чыгып* әйтә алам. | *Тәҗрибәмә таянып* әйтә алам. |
| ...диңгезнең *матурлыгы белән соклану* мөмкинлеге бар | ...диңгезнең *матурлыгына соклану* мөмкинлеге бар |
| Парижга *белем артыннан* килгән. | Парижга *белем алырга дип барган.* |
| *Ни булды синең белән?* | *Ни булды сиңа?* |
| Хатын-кыз полигамиясе гадәти *күренеш булып әверелгән...* | Хатын-кыз полигамиясе гадәти *күренешкә әверелгән...* |
| Иртүк торып, *чәчәк артыннан йөгерә* | Иртүк торып, *чәчәк алырга йөгерә* |
| Алия Фәйзуллина *скрипкада уйный.* | Алия Фәйзуллина *скрипка уйный.* |
| *Нәрсә белән ашаталар* аларны? | *Нәрсә ашаталар* аларга? |
| Елан... Андрейның уң *кулына чага* | *Елан Андрейның уң кулын чага* |
| Медицина *техникасын файдалана* | Медицина *техникасыннан файдалана.* |
| “Безнең гәҗит” һәр *кеше турында кайгырта.* | “Безнең гәҗит” һәр *кешене кайгырта.* |
| Мөхәммәт Мәһдиев белән *бер парта артында утырып* укый. | Мөхәммәт Мәһдиев белән *бер партада утырып* укый. |
| Ул – минем *җитәкчелегем астында эшләгән* иң сәләтле фәнни хезмәткәр. | Ул – минем *җитәкчелегемдә эшләгән* иң сәләтле фәнни хезмәткәр. |
| *Көнчыгыш телләрне өйрәнү* институтында укучылар | *Көнчыгыш телләрен өйрәнү* институтында укучылар |
| Студентлар белән түгәрәк *өстәл артында* очрашу. | Студентлар белән түгәрәк *өстәл янында* очрашу. |
| Ул ябык *ишекләр артында узды* | Ул ябык ишекле *бүлмәдә узды* |
| Төркиягә *фольклор коллектив белән* барып | Төркиягә *фольклор коллективы белән* барып |

| | |
|---|---|
| ...идарә компанияләре эшчәнлеген ныклы *күзәтү астында тотарга* кирәк. | ...идарә компанияләре эшен нык *күзәтеп торырга* кирәк. |
| Яшь чакта *гармунда уйный* торган идем. | Яшь чакта *гармун уйный* торган идем. |
| КФУның *Яр Чаллы* институты студенты... | КФУның *Яр Чаллысы* институты студенты... |
| Респондентларның 3 проценты *аның белән соклана* | Респондентларның 3 проценты *аңа соклана* |
| *Һава белән сулаганда* 60 метрга кадәр төшеп эшләп була. | *Һава сулаганда* 60 метрга кадәр төшеп эшләп була. |
| *Яшьләр турында таныштыра* башласаң... | *Яшьләр белән таныштыра* башласаң... |
| Эсседә суык *су белән коену* организмда стресс китереп чыгара. | Эсседә суык *суда коену* организмда стресс китереп чыгара. |
| Эш *тәҗрибәсе белән* мәктәп укытучылары белән дә *бүлешә.* | Эш *тәҗрибәсен* мәктәп укытучылары белән дә бүлешә |
| Аларның Пушкин *иҗаты белән* хәбәрдар булу ихтималы... | Аларның Пушкин *иҗатыннан* хәбәрдар булуы ихтималы... |
| Төрле *авыруларга дәва* эзләп килә. | Төрле *авырулардан дәва* эзләп килә. |
| Аны *радио буенча башкаралар.* | Аны *радиодан башкаралар.* |
| Милли мәсьәләләр *буенча шөгыльләнүче* бүлекләр. | Милли мәсьәләләр *белән шөгыльләнүче* бүлекләр. |
| *Аның артыннан* башкалар да *иярәләр.* | *Аңа* башкалар да *иярә.* |
| Беренче мәртәбә *микрофон артына утыруым* иде. | Беренче мәртәбә *микрофон каршына (алдына) утыруым* иде. |
| Эшнең үтәлешен *контроль астында тотарга* кирәк. | Эшнең үтәлешен *контрольдә тотарга* кирәк. |
| *Иҗаты артыннан* күзәтәм. | *Иҗатын күзәтеп барам (күзәтәм).* |
| *Эшче һөнәрләрнең абруен* күтәрергә кирәк. | *Эшче һөнәрләренең абруен* күтәрергә кирәк. |
| Илшат Әминов шушы *проблема өстендә эшли.* | Илшат Әминов шушы *проблема белән шөгыльләнә (проблеманы хәл итә).* |
| *Чаңгыда шуарга* бармакчы идек | *Чаңгы шуарга* бармакчы идек |

| | |
|---|---|
| Хәзерге балалар *урыс теллегә* әйләнә. | Хәзерге балалар *рус телендә сөйләшә торганга әверелә (сөйләшә торган булалар).* |
| Башка төрле *ризыкларны да авыз итәргә була.* | Башка төрле *ризыклардан да авыз итәргә (ризыкларны да ашап карарга) була.* |
| *Фән өлкәсенә кызыксыну.* | *Фән өлкәсе белән кызыксыну.* |
| *Руль артындагы хатын-кызны* яманламыйк. | *Машина йөртүче хатын-кызны* яманламыйк. |
| *Урыс телле үзәк каналларда* | *Рус телендә эшләүче үзәк каналларда* |
| Минем әнием теләсә нинди *көй астында йоклап китәргә* мөмкин. | Минем әнием теләсә нинди *көйгә дә йоклап китәргә* мөмкин. |
| "*Рус телле балаларга* – татар теле һәм әдәбияты" | "*Рус телендә сөйләшүче балаларга* – татар теле һәм әдәбияты" |
| *Бу турыда* журналистлар *кызыксынган.* | *Моның белән* журналистлар *кызыксынган.* |
| *Фашизм өстеннән* җиңү. | *Фашизмны җ*иңү. |
| Күпме генә *көлмәделәр аның өстеннән* | Күпме генә *көлмәделәр аннан* |
| *Диссертация өстендә эшләү.* | *Диссертация язу.* |
| Башка мәчетләр инде *байтактан* кавказлылар *йогынтысы астында.* | Башка мәчетләр инде *шактый вакытлар* кавказлылар *йогынтысында.* |
| Һәр төркем үз *девизы астында эшләде.* | Һәр төркем үз *девизы белән эшләде.* |
| Җирле *каналлар куркыныч астында.* | Җирле *каналларга куркыныч яный.* |
| Ул башка илләрнең *тәэсире астында калмады...* | Ул башка илләрнең *тәэсирендә калмады...* |
| Аларның рус *изүе астына* элеккәннән соңгы аяныч хәлләре... | Аларның рус *изүенә* эләккәннән соңгы аяныч хәлләре... |
| Рим – ачык *һава астындагы музей* ул. | Рим – ачык *һавадагы музей* ул. |
| ...халыкара аэропортын үз *кул астында тоткан.* | ...халыкара аэропортын үз *кулында тоткан.* |
| Бүресыманнар – *аяклары биек булган ерткычлар.* | Бүресыманнар – озын *аяклы ерткычлар.* |

| | |
|---|---|
| Кая инде ул хәзер *шикәрле чәй эчүләр.* | Кая инде ул хәзер *шикәр белән чәй эчүләр.* |
| Мин *моның белән риза түгел.* | Мин *моңа риза түгел.* |
| Россия халкы *тормыш хәле белән нык борчыла.* | Россия халкы *тормыш хәленә нык борчыла.* |
| *Ремонт белән соңга калу.* | *Ремонтны соңга калдыру (ремонт соңа калу).* |
| *Аның сүзе эше белән аерылмый.* | *Аның сүзе эшеннән аерылмый.* |
| *Йомыркалар белән ящиклар.* | *Йомыркалар салынган ящиклар.* |
| *Экспертизалар белән нәрсә булды?* | *Экспертизаларга нәрсә булды?* |
| Спектакль *18 сәгатьтә башлана.* | Спектакль *сәгать 6 да башлана.* |
| “Шәфкать” телемарофоны кичке *5 сәгатьтә башлана.* | “Шәфкать” телемарофоны кичке *сәгать 5тә башлана.* |
| *...аяклары өчен кайнар ванна ясагыз.* | *...аякларыгызга кайнар ванна ясагыз.* |
| *Киемнәр өчен кыстыргыч.* | *Кием кыстыргычы.* |
| *Кул өчен крем.* | *Кул кремы.* |
| *Аякны, кулны операция аша кисеп алу.* | *Аякны, кулны операция ясап кисеп алу.* |
| *Елмаю аша сөйлиләр.* | *Елмаеп сөйлиләр.* |
| *Җылыту аша* микроорганизмнардан *арындыру.* | *Җылыту юлы белән (җылытып)* микроорганизмнардан *арындыру.* |
| *Баскыч аша күтәрелеп,* люктан *эчкә үтәләр.* | *Баскычтан менеп (күтәрелеп),* люктан *эчкә керәләр.* |
| Агулы гөмбәне *сабы аша белергә була.* | Агулы гөмбәне *сабыннан (сабына карап) белергә була.* |
| ...бер солдат безнең *ишеккә шакый.* | ...бер солдат безнең *ишекне шакый.* |

## МАТБУГАТ ТЕЛЕНЕҢ ЛЕКСИКАСЫНДАГЫ ПРОБЛЕМАЛАР

Хәзерге татарча мәгълүмат чараларына, шул исәптән матбугат теленә, ялгыш мәгънәдәге һәм табигый сүз ясалышы кагыйдәләре бозып ясалган, чит телдән кирәксезгә кабул ителгән һәм искергән сүзләрнең күпләп кулланылуы аркасында шактый нык зыян килә. Моның сәбәбе каләм ияләренең күбесенең, беренчедән, татар телен тиешле дәрәҗәдә белмәве, икенчедән, тәрҗемә принципларыннан һәм методларыннан хәбәрдар булмаганлыктан, рус теленең

специфик үзенчәлекләрен, формаларын ялгыш татар теленә калькалаштырып алу белән мавыгуларында. Шуңа тагын күп журналистларның төп эш кораллары телләренә зур җаваплылык һәм таләпчәнлек белән карамаулары өстәлә. Бүгенге журналист үзенең төп бурычы вакытында тиешле материалны әзерләп бирү генә дип саный, үзе иҗат иткән язмасы теленең югары сыйфатлы булырга тиешлеге турында борчылмый, хәер, аннан моны таләп тә итмиләр. Нәтиҗәдә бүгенге матбугат битләрендә һәртөрле тупас тел ялгышлары тулып ята.

Шундый кырыс хөкем сүзләре җирлегендә газеталар теленең сүзлек составына караган проблемаларга анализ ясап карыйк.

Беренчедән, сүзләрне аларның үзләренә хас булмаган, башка төрле, ят мәгънәләрдә куллану күренеше тарала бара.

Соңгы вакытларда журналистлар кирәксә-кирәкмәсә, урынлы-урынсыз, дөресме-юкмы икәнлеген исәпкә алмыйча, **җирлек** сүзен куллана башладылар. Ләкин ул татар теленең аңлатмалы сүзлегендә теркәлгән үз мәгънәләрендә кулланылмый. **Җирлек** – 1) *җир булу сыйфаты, туфракның уңдырышлылыгы; 2) үсеп утырган яки басып торган әйбер астындагы җир; 3) башка төсләр, бизәкләр аерылып торган төп, нигез төс, фон; 4) нәрсәнең дә булса барлыкка килүендә нигез, чыганак; 5) нинди дә булса бер эш, вакыйга өчен кирәкле шартлар, мөмкинлекләр.* Хәзер абруйлы булып саналган бер республика газетасының соңгы саннарыннан алынган мисалларга күз салыйк: Авыл җирлекләрендә балалар саны кимүе; Авыл җирлекләрендә ...укытучылар берничә фән укыта; Авыл җирлегендәге кешене... яклау җитми; Җирлеккә җиде авыл керә; ...Олы Мәңгәр авыл җирлеге башлыгы... Бу һәм башка күп санлы шундый сүзтезмәләрдәге **җирлек җир, авыл** мәгънәсендә кулланыла. Бу урында бер нәрсәне искәртеп китү мөһим. Соңгы берничә елда, рус телендәге **поселение** дип йөртелә торган берничә авылны берләштергән зур авылны, авыл хуҗалыгын татарча **җирлек** дип атый башладылар. Ни өчен җирлек ул? Ни өчен авыллар берләшмәсе, авыл хуҗалыгы, утар һәм башка шундыйрак сүз (исем) түгел? Кемнең башына килде икән **поселение**не **җирлек** дип атау?

Кайсыдыр еллардан башлап, берничә буын татар кешеләре иркен кулланып килгән **союз** (Советлар Союзы, язучылар союзы һ.б.) сүзен **берлек** сүзе белән алмаштырдылар. Кирәк булдымы икән

һәм кемгә кирәк булды икән бу яңалык? Үзен аклыймы икән бу үзгәреш? Моңа уңай җавап бирү кыен һәм мөмкин дә түгелдер.

Татар теленең аңлатмалы сүзлегендә **берлек**нең өч төрле мәгънәсе күрсәтелгән: 1) бер сумлык акча; 2) грамматикадагы термин (берлек һәм күплек категорияләре); 3) бердәмлек, оешканлык, тыгыз, ныклы бәйләнеш. **Журналистлар союзы** һәм башка шундый союзлар атамаларындагы **союз – берләшмә** мәгънәсендәге сүз. Шулай булгач, халыкка бик мәгълүм **союз**ны аның мәгънәсен дөрес белдерми торган **берлек** сүзе белән алмаштыру кирәкле гамәл булдымы икән?

“Шушы кошлар… җырлый-җырлый, кош балалары үстерделәр. Сыерчык җырларын тыңлап, без дә үстек”. Шулай итеп, безнең каләм ияләре сайрар кошларны да җырлата башладылар инде!

“Биектән егылганда, бала күп төрле **җәрәхәтләр** ала. Аның баш миенә, умырткалыгына, эчке органнарына зыян килә”. Текстның эчтәлегеннән күренгәнчә, сүз **җәрәхәтләнү** (**җәрәхәт** ул – **тәндәге яра**) турында түгел, **имгәнү** турында бара, димәк, “*бала бик нык имгәнә*” дип әйтергә кирәк иде.

Рус телендәге **ценность** сүзен ялгыш **кыйммәт** дип тәрҗемә итү аркасында матбугат телендә *рухи кыйммәтләр, гаилә кыйммәтләре, тормыш кыйммәте* кебек тәгъбирләр киң таралды. **Кыйммәт** ул – *зур, югары бәяле* дигән сүз, ә **ценность** – *бәя, хак, әһәмият, байлык, хәзинә.* Димәк, *рухи кыйммәтләр* түгел, *рухи хәзинәләр, гаилә кыйммәте – гаиләнең әһәмияте, роле* һ.б. *Тормыш кыйммәте – тормышның (яшәүнең) әһәмияте, мәгънәсе, уңай, мөһим яклары һ.б.* (контекстка карап тиешле сүз сайлап алына).

**Спрос, просить** сүзләрен ялгыш **сорау** дип тәрҗемә итү аркасында, бу сүзне үзенә хас булмаган мәгънәләрдә куллану очраклары күп. Мәсәлән: “*Яз салкын килсә дә, үсентеләргә **сорау** зур*” (дөресе – ...үсентеләргә **ихтыяҗ** зур); “*...сорау булганда тәкъдим итүче табыла*” (...ихтыяҗ булганда ...); “*Аны* (әлбәне – *Р.Ю.*) *әзерләү сабырлыкның нindиен генә сорый әле!”* Чын татарча: “*Аны әзерләү өчен зур сабырлык кирәк (...сабырлык таләп итәлә яки Аны әзерләү өчен нинди генә сабырлык (түземлек) кирәк әле!”* һ.б.

“Изге сәфәргә чыгучылар иң элек Мәскәүгә, аннан Дубайга очты”. Татарча яхшы белгән кеше болай сөйләмәс, “Изге сәфәр кылучылар башта Мәскәүгә, аннары Дубайга киттеләр” дип әйтер.

Рус телендәге **призвать (призывать)** сүзенең төрле мәгънәләре татар телендә **чакыру, өндәү, кушу, тәкъдим итү,**

**теләк белдерү, боеру, хәрби хезмәткә алу** һәм башка кайбер сүзләр белән белдерелә. Ләкин ике тел белән эш итүчеләр, гадәттә, төрле синонимнарның тиешлесен сайлап (эзләп) тормыйлар, башларына беренче килгәннән (төп тәңгәллеге **чакыру** сүзеннән) генә файдаланалар. Мәсәлән: "Министр берләшергә чакыра" (Министр берләшергә өнди, куша, кирәк, ди һ.б.); "Егетләрне армиягә чакыралар" (дөресе – "...армиягә алалар"); "А.Песошин эшне кызулатырга чакырды" (**кушты, кирәк диде** һ.б.).

Хәзерге матбугат хезмәткәрләренең сүзләрне бөтенләй нигезсез, көтелмәгән, гадәти булмаган мәгънәләрдә куллана башлаулары нык гаҗәпләндерә. Андый сүзләр шактый. Менә берничәсе: *"Оештыру комитеты рекорд куйганын җиткергәч, Булат бер мәлгә аптырап кала"; "Альтекст" фирмасы фаҗигада зыян күрүчеләргә ярдәм итәчәген җиткерде"; "Бу хакта ...Ирина Нижельская җиткерде".* Җөмләләрдән күренгәнчә, сүз аларда кемнәрнеңдер кемнәргәдер нәрсәдер турында хәбәр итүе, яңалык әйтүе турында бара, димәк җөмләләрдәге **җиткерү (җиткергәч, җиткерде) әйтү, хәбәр итү** кебек сүзләр белән алмаштырылырга тиеш.

Соңгы көннәрдә генә "...республикада 300 **каланча** төзелгән һәм 2330 чакрым суүткәргеч челтәре салынган" дигән хәбәр басылган иде. Каян чыккан икән бу каланчалар безнең заманда дип гаҗәпләнер идең, тик текстан монда сүз су башнялары турында барганлыгы аңлашыла. Текст авторы су башняларын каланчалар дип атаган. Чын каланчалар – тирә-юньне күзәтү өчен тар һәм биек итеп эшләнгән баскычлы корылмалар безнең авыл хуҗалыкларына моннан ярты гасыр элек үк хезмәт итүдән туктадылар инде. Аларны татарлар һәрвакыт **каланча** дип йөрттеләр, әмма хәзер су башнясы берничек тә каланчага әверелә алмас, шулай булгач, аны русча исеме белән **башня** дип атарга кирәк булыр.

"Көмеш туйга **бәһасез бүләк**" (мәкалә исеме); "**Бәһасез шәхесләребез** язмышы аркылы... горурланып яшәргә"; "безнең икътисад өчен **бәһасез ресурс**". Бу җөмләләрдәге **бәһасез** сүзен укучы ничек, нәрсә дип аңлый торгандыр: текстның эчтәлегенә караганда ул русчадагы **бесценный** сүзеннән хәрефкә-хәреф тәрҗемә итеп ясалган һәм **бик кыйммәтле** дигән мәгънәне аңлатырга тиеш булса кирәк. Ләкин ул **бәһасе юк**, димәк, **бер тиенгә тормаслык** дип аңлашыла. Уйламыйча, телгә җиңел карап, русча сүзләрне әйләндереп барып кына эш итү шундый башваткычлар китереп чыгара шул.

Безнең телдә русчадан калькалаштырып ясалган һәм каләм ияләре тарафыннан мәгънәсенә төшенмичә генә кулланыла торган сүзләрнең берсе – **кызганычка каршы.** Ул рус телендәге **к сожалению** дигән кереш сүзнең хәрефкә-хәреф тәрҗемәсе. **Кызганычка каршы** – составындагы ике сүз үзара табигый бәйләнештә тормаган әйтелмә – оригиналдагы мәгънәне төгәл белдерми. Ул мәгънәне **аяныч, үкенеч(ле)** сүзләре тулырак белдерә. Шуның өстенә, ул әйтелмә, гадәттә, текстның эчтәлеген төзүдә җитди роль уйнамый: аны күп очракларда төшереп калдырсаң да, сөйләмгә сизелерлек зыян килми. **К сожалению** мәгънәсе кирәк дип табылган очракта татар телендә аны белдерерлек башка – тел өчен кулайрак, табигыйрак чаралар да бар, аларны куллана белергә генә кирәк. Мәсәлән, рус телендәге “к сожалению, забыл” дигән әйтелмәнең мәгънәсен безнең телдә “онытканмын шул, гөнаһ шомлыгы, онытканмын бит!” кебегрәк тәгъбирләр белән белдерергә мөмкин.

| **Ялгыш мәгънәдә кулланылган сүзләр белән төзелгән тәгъбирләр** | **Төзәтелгән вариантлары** |
|---|---|
| Музей – *бәһасез хәзинә оясы.* | Музей – *чиксез кыйммәтле хәзинә урыны.* |
| ...туганнарыбызның ике тутый кошы бар иде. Кеша белән Геша: *берсе – ир, икенчесе – хатын.* | ...туганнарыбызның ике тутый кошы бар иде. Кеша белән Геша: *берсе – ата, икенчесе – ана.* |
| уен коралында уйный белмәгән балаларга *искәрмәләр ясала.* | уен коралында уйный белмәгән балаларга *ташламалар ясала.* |
| Тәрәзәдән *очып чыкмасын* (мәкалә исеме – *Р.Ю.*) | Тәрәзәдән *егылып төшмәсен.* |
| *Алдагы ел* белән чагыштырганда былтыр түрәләрнең кереме берничә тапкыр арткан. | *Элекке ел* белән чагыштырганда... |
| Өлкәннәрнең аның яныннан ашыга-кабалана узып китүләреннән үз эченә *йомыла башлый.* | *...үз эченә бикләнә башлый.* |

| | |
|---|---|
| Башкаланың бер генә *комлыгында* да су коенырга ярамый. | Башкаланың бер генә *пляжында да* су коенырга ярамый. |
| Роспотебнадзор *комлыкларны* тикшергәннән соң шундый нәтиҗәгә килгән. | Роспотебнадзор *пляжларны* тикшергәннән соң шундый нәтиҗәгә килгән. |
| *Русиянең саклану министры* | *Россиянең оборона министры...* |
| Арча читекләрен Германиягә *чакырдылар.* | Арча читекләрен Германиягә *соратып алганнар.* |
| Җиңүчеләрнең исемнәре бүген *фаш ителәчәк.* | Җиңүчеләрнең исемнәре бүген *игълан ителәчәк.* |
| Сафин Илдарның мәкерле *хәрәкәтләре* барып чыкмый. | Сафин Илдарның мәкерле *эшләре* барып чыкмый. |
| кан *агышы* тулысынча торгызылды. | кан *йөреше* тулысынча торгызылды. |
| бик *нечкәләп* сорашты. | бик *җентекләп* сорашты. |
| Иң яхшы *бозлыклар,* һәм аларда күмәкләшеп шууны оештыру. | Иң яхшы *шугалаклар (яки катоклар),* һәм аларда күмәкләшеп шууны оештыру. |
| Икенче *төркемгә* караган инвалид. | Икенче *группа* инвалиды. |
| Дәүләт *бүләге иясе.* | Дәүләт *премиясе лауреаты.* |
| “Кәҗәләргә йоклау өчен аерым *киштә* булдыру зарур”. | “Кәҗәләргә... аерым *урын* булдыру зарур”. |
| “*Уфада хәрәкәт итүче* татар иҗтимагый оешмаларының күпчелеге...” | “*Уфадагы* татар иҗтимагый оешмаларының күпчелеге...” |
| “Камай урамында тимер-томыр *ноктасы* ачып җибәргән”. | “Камай урамында тимер-томыр (металл) *кибете (алу-сату урыны*) ачып җибәргән”. |
| Халыкара *сораулар* буенча ректор киңәшчесе . | Халыкара *мәсьәләләр* буенча ректор киңәшчесе. |
| “Аның әнисе –*рус*, әтисе –латыш”. | “Аның әнисе – *рус хатыны (марҗа)*, әтисе – латыш”. |
| Узган *йөзлекнең* 90нчы елларында. | Узган *гасырның* 90нчы елларында. |
| Аны (имбирны – *Р.Ю.*) ашказаны һәм эчәк юллары *какшаганда* файдаланалар. | *Аннан* ашказаны һәм эчәк юллары *бозылганда (авыртканда*) файдаланалар. |
| “Барысы да яхшы, әмма *йомшарырга* ярамый”. | “Барысы да яхшы, әмма *тынычланырга* ярамый”. |

| | |
|---|---|
| халыкның *кереме* 7 процентка *кыскарганын* искәртте. | ...*кереме* 7 процентка *кимегәнен* (яки *азайганын)* искәртте. |
| ...*симез хәрефләр белән* “Редактор” дип язып куелган. | ...*калын хәрефләр белән* “Редактор” дип язып куелган. |
| Чикләүләр, аерым рәсмиләрнең *финанс хисапларын туңдыру...* | ...*финанс хисапларын туктатып тору...* |
| Тарихчы Нурулла Гариф... Россиянең Төркиягә каршы *чикләүләрен хөкем итте.* | ...*чикләүләрен тәнкыйтьләп чыкты.* |
| ИГИЛ* террорчылары... Триумфаль *гөмбәзне (арка) җимерде.* | ...*Триумфаль арканы (капканы) җимергән.* |
| Башка *нәмзатла*р Казанда Тукай бүләге өчен *тупса* артыннан *тупса* таптап йөргән чакта... | ...*бусага артыннан бусага таптап йөргән чакта...* |
| ”Сверлийцы” спектаклен карадым... Ләкин *ул мине борчымый.* | ...ләкин *ул мине дулкынландырмый* яки *ул миңа тәэсир итми.* |
| Кайбер балалар бакчаларында *черегән ашамлыкларның* булуы фаш ителгән. | Кайбер балалар бакчаларында *бозылган ашамлыкларның* булуы фаш ителгән. |
| гаскәр артыннан *хәрәкәтләнеп*, яралыларга ярдәм күрсәтә. | гаскәр артыннан *барып*, яралыларга ярдәм күрсәтә |
| Помеев... Россиянең *шымчылык* хезмәтенә зыян салды. | Помеев... Россиянең *яшерен агентлык* хезмәтенә зыян салды. |
| Халык үз *бөеген* зурлады. | Халык *күренекле улын* зурлады. |
| 22 миллион кеше *хәерчелекнең соңгы чигенә* җиткән. | 22 миллион кеше *ярлылыкның соңгы чигенә* җиткән. |
| Кышын *һава торышы* гел *үзгәреп торучан.* | Кышын *көннәр* гел *үзгәреп торучан.* |
| Шәһәрдә *машина асрау* авырлаша бара. | Шәһәрдә *машина тоту* авырая бара. |
| Тик ул да *больницада яралардан һәлак була.* | Тик ул да *больницада яралардан үлә.* |
| ...382 депутатның барысы да *канунны* хуплаган. | ...382 депутатның барысы да *законны* хуплаган. |

---

ИГИЛ – Россиядә тыелган террорчылык оешмасы.

| | |
|---|---|
| *Укол салдырырга* кеше таба алмыйча аптырады. | *Укол кадатырга* (яки *ясатырга*) кеше таба алмыйча аптырады. |
| *Зарлы* телефон ни сөйли? *Гозер* телефоны ни сөйли? | *Теләк-гозер* телефоны ни сөйли? |
| Рафыйк абыйның (Миңнекәев) куйган *хезмәтенең бәясе юк.* | Рафыйк абыйның (Миңнекәев) *хезмәте бик зур бәяләрлек.* |
| Миндә әлеге фоторәсемне *киндергә күчерү* теләге туды. | Миндә әлеге фоторәсемне *киндер тукымага күчерү* теләге туды. |
| сугышның *дәресләрен онытырга* хакыбыз юк. | сугышның *сабакларын онытырга* хакыбыз юк. |
| ...Илсур Метшин *метрода хәрәкәт итте.* | ...Илсур Метшин *метрода йөрде.* |
| Мин Олег Кудряшовта *шөгыльләндем* | Мин Олег Кудряшовта укыдым, *өйрәндем* |
| Моңа ... Илдар Халиков та *басым ясады.* | Моңа ... Илдар Халиков та *ныклап (каты итеп, кискен итеп) әйтте.* |
| ...Боинг-737” самолеты *мәтәлеп төште.* | ...Боинг-737” самолеты *егылып (ватылып) төшкән.* |
| Буаз сыерлар өчен *тудыру* бүлеге яхшылап ремонтланган. | Буаз сыерлар өчен *бозаулау* бүлеге яхшылап ремонтланган. |
| Бәла *мәдәниятсезлектән* килә. | Бәла *тәрбиясезлектән (яки культурасызлыктан)* килә. |
| *Газлаштыру* өлкәсендә башкарган эшләребез *сөенерлек.* | *Газ кертү (үткәрү)* өлкәсендә башкарган эшләребез *сөендерерлек.* |
| *Тере чәчәк* бүләк итү. | *Чәчәк* бүләк итү. |
| Бу тема беркайчан да *картаймый.* | Бу тема беркайчан да *искерми.* |
| Ул... президент институтын булдыруның *чишмә башында торды.* | Ул...президент институтын булдыруны *башлап йөрде.* |
| Альбина Шаһиморатова...Бакуга *оча.* | Альбина Шаһиморатова... Бакуга *китә (бара*). |

Татар матбугатында яңа сүзләр ясап куллану гадәткә кереп бара. Әгәр дә алар табигый сүз ясалышы кагыйдәләре буенча ясалып, тиешле мәгънәне ачык, төгәл итеп белдерсәләр, моннан зыян

булмас иде. Ләкин аларның күбесенә карата болай дип әйтеп булмый. Киресенчә, алар, нигездә, уңышсыз, ялгыш ясалган лексик берәмлекләрне тәшкил итәләр һәм туган телне бозуга, чүпләүгә генә китерәләр.

Хәзер шундый уңышсыз ясалган, аңлашылмый торган гайре табигый берничә сүзне анализлап, кайберләрен исемлек рәвешендә күрсәтеп китәрбез.

Газета-журналларда һәм тел белән эш ителгән башка өлкәләрдә кулланыла торган **ассызыклау** сүзен алып карыйк. Бу **подчеркнуть** сүзенең хәрефкә-хәреф тәрҗемәсе. Ләкин ул татар телендәге сүз ясалышы кагыйдәсенә (нормасына) туры килми һәм аның мәгънәсен дә аңларлык түгел. **Сызык** сүзенә **-ла** кушымчасы ялганып, яңа мәгънәле сүз ясап булмый: **сызыкла(у)** дигән сүз юк һәм була да алмый. Аны хәрефкә-хәреф тәрҗемә итәргә күнеккән каләм ияләре, кайчандыр *подчеркнуть* мәгънәсен чын татарча итеп белдерә алмаганлыктан гаҗиз булып, шундый гарип сүз төзеп куйган булганнар, һәм хәзерге журналистлар, аның уңышлымы-юкмы, дөресме-түгелме икәнлегенә төшенеп тормыйча гына иркен кулланалар (алай эшләү инде гадәткә кергән).

Мәсьәләгә җитдирәк карасаң, татар телендә **подчеркнуть**ның нәрсәгә дә булса игътибар юнәлтеп, аның әһәмиятен аерып күрсәтү мәгънәсен белдерерлек чаралар бар, аларны эзләп таба белергә генә кирәк. Аннары тагын шунысы бар: русча язучылар *подчеркнуть* сүзен күп очракта котылгысыз кирәкле сүз буларак түгел, *сказал, отметил* сүзләренең синонимы ролендә генә кулланалар. Шунлыктан, аның мәгънәсен бирү өчен, күбесенчә “ассызыклап” торасы юк, бәлки **әйтте, дип әйтте, диде, сөйләде** кебек сүзләр генә куллану да җитә. Мәсәлән:

“Фәрит Мөхәммәтшин аның тәҗрибәле булуын *ассызыклады*” (...тәҗрибәле булуына *игътибарын юнәлтте*); “Бу бик җитди сан, дип *ассызыклады* Тимур әфәнде” (... *дип әйтте* Тимур әфәнде); “Минтимер Шәймиев аның төп сыйфатларын *ассызыклады”* (...сыйфатларын *санап чыкты* яки *әйтеп китте, әйтте).*

**Ассызыклау** кебек язмышлы сүзләрнең берсе – **дәүләтчелек. Государственность**ны калькалаштырып төзелгән бу сүз, матбугат телендә актив кулланылса да, татар теленең сүз ясалышы кагыйдәләренә туры да килми, һәм аның мәгънәсен дә кире русчага тәрҗемә итеп карасаң гына чамалап була. Безнең телдә **дәүләтчелек**нең нигезен тәшкил иткән *дәүләтче* дигән сүз юк,

димәк, булмаган сүзгә кушымча ялгап, яңа сүз ясау да мөмкин түгел. *Дәүләт төзелеше, дәүләт оешмасы* мәгънәсендәге *государственность* (государственный строй, государственная организация) асылда *дәүләт* дигән сүз. Димәк, аны күп урында шулай, татар кешесе аңларлык итеп, **дәүләт** дип кенә атарга була. Мәгънәсен бөтен төгәллеге белән белдерү ихтыяҗы булганда, *дәүләт төзелеше* дияргә мөмкин. Мәсәлән: "Безнең илнең күп халыклары совет власте чорында милли дәүләтләрен булдыруга яки дәүләт төзелешенә ирештеләр". "Гали Акыш – татар халкының дәүләтчелеген торгызуда ярдәм итәргә тырышкан олуг зат". Җөмләне "....дәүләтен торгызуда ярдәм итәргә тырышкан олуг зат" дип төзесәң, мәгънә дә аңлаешлы һәм дөрес итеп белдереләчәк, татар теле дә бозылмаячак.

**Деятельность**ның уңышсыз калькасы булса да, хәзер **эш, гамәл, хезмәт** сүзләре урынында хаксыз еш кулланыла торган **эшчәнлек** сүзе бар. **Эшчән – хезмәт сөючән, тырыш** дигән сыйфат мәгънәсендәге сүз (эшчән кеше). Шуңа **-лек** кушымчасы ялганып ясалган **эшчәнлек** – *эшчән, тырыш, уңган* сыйфатына ия булу мәгънәсендәге абстракт исем. Ләкин ул, ниндидер сәбәпләр аркасында, матбугат телендә бик популяр булып китеп, хәзер кирәксәкирәкмәсә, әйтелгәнчә, **эш, гамәл, хезмәт** урынында бик күп кулланыла: "Галимнәр эшчәнлеге турында күпләр белми" (дөресе – "Галимнәр эше турында..."); "Эшчәнлегебезне өч юнәлештә алып барабыз..." (Эшебезне өч юнәлештә алып барабыз); "2018 ел эшчәнлегенә йомгак ясау" (2018 елдагы эшкә йомгак ясау) һ.б.

Журналистлар – яңа сүз кулланырга маһир халык. Бу гомумән алганда начар сыйфат түгел. Ләкин алар еш кына, теге яки бу яңалыкның файдалымы юкмы, урынлымы-юкмы, ул дөрес сүзмеюкмы икәнлеген уйлап тормыйча, хәтта ул ялгыш сүз булса да, аны бик тиз кулланылышка кертеп җибәрәләр (Монда русларның "Дурной пример заразителен" дигән гыйбарәсе искә төшә). Шундый ялгыш, сәер сүзләрнең берсе – **иң-иң(нәр).** Ул, тексттан (сөйләмнән) аңлашылганча, **иң яхшы, иң уңган** һ.б. сыйфатларга ия затларны белдерә: "Ф.Мөхәммәтшин иң-иңнәргә дәүләт бүләкләре тапшырды"; "Бу залда иң-иңнәр утыра". *Безнең телдә иң-иң сыйфатның югары дәрәҗәсен белдерә торган кисәкчә сүз һәм аны исем ролендә йөртүнең бернинди дә хаҗәте юк.*

Рус теленнән букваль (хәрефкә-хәреф) тәрҗемә итү кайчакта чамасыз дәрәҗәгә җитә: татар теленә оригиналның грамма-

тик формаларын күчереп кую белән шөгыльләнә башлыйлар һәм нәтиҗәдә туган телнең табигый төзелешен бозуга керешәләр. Болай эшләү инде гафу ителерлек нәрсә түгел. Соңгы вакытларда бу хәл рус телендәге иркәләү-кечерәйтү суффиксларының функцияләрен (вазифаларын) татар теле исемнәренә тагуда ачык чагылыш таба. Рус сүзләрендәге иркәләү-кечерәйтү мәгънәсен аларның татар телендәге тәңгәллекләренә **-чык-чек** кушымчасын ялгап белдерү гадәткә керә бара. Менә бу мисалларга игътибар итик:

“**Кызчык**ның мәктәптә кияргә формасы юк”; “Минем өчен син һәрвакыт нәни **кызчыг**ым булып калырсың”; “**Кызчыклар** курчакларга киемнәрне үзләре тегә”. Хәзер матбугатта күп очрый торган *кызчыклар* дөрес кулланылмый, әлбәттә. **Кызчык** татар теле өчен хас түгел.

**Правнук (правнучка)** мәгънәсен белдерү өчен ясалган **оныкчык** сүзен куллануны да аклап булмый. Аны оныкның баласы, кызы, улы дип әйтеп була һәм шулай әйтергә кирәк тә. Мәсәлән, “Камилә әби кызы, ике оныгы һәм оныкчыклары янында” дигән җөмләне, саф татарча итеп, болай төзергә кирәк: “Камилә әби кызы, ике оныгы һәм аларның (оныкларының) балалары янында”.

Инде хәзер кайберәүләр өчен газеталарда **шәһәрчек, хикәячек, китапчык, мәйданчык** кебек сүзләрне куллану да (хәлбуки, бу ялгыш гамәл булса да) гаҗәп күренеш булып саналмый. “А.Хәбибуллин... Балашиха шәһәрчегендә яши”; “...нәтиҗәләрен китапчык итеп бастырып чыгарырга уйлыйбыз”; “11 хикәячек бу санда басылып та чыкты”; “...халыкара мәйданчыкта... кирәкле мәсьәләләр буенча фикер алыштык”.

Хәзерге татар телен начар белгән һәм тәрҗемә итә белмәгән журналистларның “новаторлыгы” аркасында телебездә **икетуган, туганнан туган** дигән сәер атамалар барлыкка килде: “Котдус абый – Чыңгыз Айтматовның әнисе Нәгыймә апа белән ике туган”; “Насыйбуллина Флераның ике туган сеңлесе Яруллина Асия...”; “Кызның ике туган апасы белән элемтәгә кердек”; “Туганнан туган апамны табарга булышты”; “Әтиемнең туганнан туган энесе Гаяз Семеновны җәзалап үтерделәр”. Кемнәр була икән соң бу икетуган, туганнан туган кешеләр? Газета укучы кемнәр дип аңларга тиеш икән аларны? Аларны саф татарча һәм халык аңларлык итеп әйтергә (язарга) мөмкиндер бит! Әлбәттә, мөмкин. Моның өчен тик телне яхшы белергә һәм тырышыбрак эшләргә генә кирәк.

| Ялгыш ясалган сүзләр белән төзелгән тәгъбирләр | Төзәтелгән вариантлары |
|---|---|
| ...мәгълүматлар Белоруссиянең рәсми саннары белән **чагышмый** | ... рәсми саннарына туры килми |
| Моравиянең **идән асты** оешмалары | Моравиянең яшерен оешмалары |
| Кремль **сүзчесе** ...хәбәр итеп өлгерде | Кремльнең пресс-секретаре (?) хәбәр итеп өлгергән |
| хезмәттәшлек турында килешүләр **имзаланды** | ...килешүләргә имза куелды |
| Район өчен ят **кәсепчелек** | ...ят кәсеп |
| **Сөючеләр** фида кылды | Игелеклеләр (игелекле кешеләр) фида кылды |
| Авыл хуҗалыгы **билгеләнешендәге** җир | Авыл хуҗалыгы карамагындагы (?) җир |
| Йөрәк **җиткелексезлеге** | Йөрәкнең тулы көченә эшләмәве (әкрен эшләве, хәлсезләнүе) |
| ...**йөрәге токткан** | ...йөрәк өянәге булган |
| Оборона министрлыгы мәгълүматларына **сылтама белән** “Интерфакс” хәбәр итә | ...мәгълүматларына таянып “Интерфакс” хәбәр итә |
| ...нинди законнарга **сылтама ясыйсыз**? | ...нинди законнарга таянасыз? |
| **Әңгәмәләшүгә**...В.Протасов та кушыла | Әңгәмәгә ...кушыла |
| Ләбиб Лерон М.Шәймиев белән очрашып **әңгәмәләште** | … очрашып сөйләште (әңгәмә ясады) |
| ...дип **җаваплады** хуҗабикә | ...дип җавап бирде хуҗабикә |
| Яз җиткәч, сулау **авырлаша** | ...сулау авырая |
| **Азыклата** ярдәм күрсәтә алалар | Азык белән ярдәм күрсәтә алалар |
| Эстетик казанышларны **шәкелләштерү** | Эстетик казанышларны формалаштыру |
| ...шул чакта **уйламады микән**? | ...уйламадымы икән? |
| Иҗади эшләр **агымдагы елның** ноябренә кадәр кабул ителә | Иҗади эшләр бу елның ноябренә кадәр кабул ителә |
| **чәчһәвас** | парикмахер |
| **Сөтчелек** фермалары | (Савым) сыер фермалары |
| **Газлаштыру** эшләре | Газ кертү (үткәрү) эшләре |
| Чира исемле **жираф ханым** (?!) ана булырга җыена. | Чира исемле ана жираф балаларга җыена. |

| | |
|---|---|
| Мәскәү **армейчылары** иптәшләрчә матчын үткәрделәр. | Мәскәү армиячеләре хәрбиләре командасы иптәшләрчә матч үткәрделәр. |
| Компьютерларны **татарлаштыручы** программалар. | Компьютерларны татарчалаштыручы (татарчага күчерүче) программалар. |
| ...төрле **савымчылар** | ...сыер савучылар |
| Татар дөньясында **танылулы** ул Радик Нуретдин. | Татарлар арасында *билгеле кеше* ул Радик Нуретдин. |
| ... **сарыкчылык** *фермасын* бетергәч бушап, тынып калды. | ... *сарык фермасын* бетергәч, бушап, тынып калды. |
| 900е – **хезмәтләндерүче** | *Тугыз йөзе – хезмәт күрсәтүче...* |
| Клаус Шиллинг әсирләрне бизгәк белән **йогышландырган.** | Клаус Шиллинг әсирләргә бизгәк *йоктырган.* |
| ***Кулчатырыңны*** алырга онытма. | *Зонтыңны (зонтигыңны)* алырга онытма. |
| **Боралакка** юл ачык. | *Вертолетка* юл ачык. |
| 41 яшьлек ирнең **кул чуклары** зыян күргән. | 41 яшьлек ирнең *кул бармаклары* зәгыйфьләнгән (вар.: *бармакларына зыян кил*гән). |
| Ул **чыганакчылык гыйлеме** белән махсус шөгыльләнә башлый. | Ул язма *чыганаклар белән махсус* шөгыльләнә башлый (Ул язма чыганакларны махсус өйрәнә башлый һ.б.). |
| Кыйммәтле ювелир **бизәнгечләрен** урлаганнар. | Кыйммәтле ювелир *бизәнү әйберләрен* урлаганнар. |
| ...төзелеш **рөхсәтнамәсе** кирәк. | ... төзелеш *лицензиясе* кирәк. |
| ... төнгә кадәр **санак** каршында утыра. | ... төнгә кадәр (төн җиткәнче) *компьютер* каршында утыра. |
| Узган елда *дуңгызчылык* фермасы төзелде. | Узган елда *дуңгыз* фермасы төзелде. |
| ...Нәфыйга Вәлиева да *пешекче* серләрен яхшылап үзләштергән. | ...Нәфыйга Вәлиева да *аш-су әзерләүнең* серләрен яхшылап үзләштергән. |
| Ярый әле **сыемдагы** абсорбентка ут капмаган. | Ярый әле *цистернадагы* (*махсус зур савыттагы*) абсорбентка ут капмаган. |

| | |
|---|---|
| Җыентыкка Татарстан **көйязарларының** иң затлы иҗат җимешләре генә кертелгән. | Җыентыкка Татарстан *композиторларының* иң затлы иҗат җимешләре генә кертелгән. |
| Йөзегезгә карагач, **ярымай** күренә. | Йөзегез *ай* кебек балкый (вариант: йөзегездән ай нуры сирпелә...). |
| Биюләре **уткабызгычлы...** | Биюләре *дәртле...* |
| Газпром"ның ***кыз предприятиесе*** – "Газпром трансгаз... Казан" җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте... | Газпром"ның *булендек предприятиесе* – Газпром трансгаз җаваплылыгы чикләнгән Казан җәмгыяте... |
| Татарча-русча-инглизчә **сөйләүлек** чыгачак. | Татарча-русча-инглизчә *сөйләшү китабы* чыгачак. |
| Үрдәкләр дә **бибиләде**. | Үрдәкләр дә *бәби (бала) чыгарды.* |
| Ник дәүләтсез иттең мине ***бүгенгемдә?*** | Ник дәүләтсез иттең мине *бүген*?. |
| Корбан бәйрәменә сарыклар сатам. ***Аяклата*** һәм суеп. | Корбан бәйрәменә сарыклар сатам. *Тере килеш* һәм суеп. |
| ...өченче урынга исә Бурж-Хәлифә **күктерәр йорты** куелган. | ...өченче урынга исә Бурж-Хәлифә *небоскребы* (бик биек йорты) куелган. |
| ...800 түрә һәм **түрәчек** акча үзләштерүдә тотыла | ... 800 түрә һәм *чиновник* (?) акча үзләштерүдә тотыла. |
| ...юлларда **тайгыч** | ... юлларда *тайгак* |
| Сүриягә **ихтыярилар** туплау вакытлыча тукталганчыга кадәр ... | Сириягә *иреклеләр* туплау вакытлыча тукталганчыга кадәр ... |
| Мөхәммәт Мәһдиевнең **истәлекханәсе** ачылуга да 10 ел үтеп киткән. | Мөхәммәт Мәһдиевнең *музее* ачылуга да 10 ел үтеп киткән. |
| Арцебарскийның тормыш юлын **нечкәләсәң..**. | Арцебарскийның *тормыш юлы белән якыннан танышсаң*, аның чыннан да... |
| ...акционерлык җәмгыятенең **калай бөгүчесе** Галиев Анатолий... | ...акционерлык җәмгыятенең *калайчысы (*яки *калай остасы)* Галиев Анатолий... |

Бүгенге татарча газета-журналларда аңлаешлы хәзерге заман сүзе була торып, халыкка аңлашылмый торган борынгы иске татар сүзләрен куллануны дөрес гамәл дип санап булмый, әлбәттә. Хәлбуки, кайбер журналистлар яңалык артыннан куып, шундый

архаик сүзләрдән файдалану белән мавыгалар. Мисаллар: "Үзеңне ни рәвешле тотышыңа читтәнрәк **багу** кызык икән" (хәзерге телдәгечә: Үзеңне ни рәвешле тотышыңны читтән **карап тору** кызык икән); "Бөек Ватан сугышында фашистлар белән тиңдәшсез **орыш** 1418 көн барды" (хәзергечә: "...тиңдәшсез **сугыш** 1418 көн барды"). Газета битләрендә **белем алу** урынына **белем өстәү, дежур тору** урынына **кизү тор**у дип, **карак**ны **угры**, армиядәге подразделениене (**отрядны) чирү**, **соң**ны **соңра, авыл**ны **сала** дип язу күренешләренә тап буласың. Казан **Кремл**ен кайберәүләр ни өчен Казан **Кирмән**е дип атауларын аңлап булмый. **Мәрәкә** (ит мәрәкәсе), **кимәл** (эстафетаны тиешле кимәлдә...тапшыра), ...вакытларны шул **өслүптә** сурәтләргә тырыштык. Бу фразалардагы **мәрәкә, кимәл, өслүп** сүзләрен газета укучылар аңлыйлармы икән?

Иске әдәби телдә кулланылып, хәзерге татарлар теленнән күптән чыккан, халыкка аңлашылмый торган гарәп һәм фарсы сүзләреннән бүгенге матбугат телендә файдалануны да дөрес гамәл дип әйтеп булмый. Болай эшләүгә бернинди ихтыяҗ да, нигез дә юк. Газета-журнал теле барлык халыкка аңлаешлы, популяр булырга тиеш. Ул искергән гарәп-фарсы алынмалары урынын инде күптән татар теленең үз сүзләре, интернациональ сүзләр алган һәм, алар телнең үз чаралары кебек үзләштерелгән. Хәзерге матбугатта кирәксезгә кулланылган берничә гарәп һәм фарсы сүзен карап китик: Конституция **мәхкәмәсе** (Конституция суды); ярышларның **баш хөкемдары** (ярышларның баш судьясы); .... мине **горбәткә** чыгарып җибәрде (... **чит җиргә чыгарып җибәрде** кирәк); әмма тоткынлыкта **калебләре** сынмаган (...рухлары сынмаган яки ...төшенкелеккә бирелмәгәннәр); ...**маддәләре** буенча җинаять эшләре кузгатылган (...статьялары буенча...); ...үзе **истирах** кылган оҗмах почмагы бит ул (...рәхәт кылган яки рәхәтләнеп ял иткән оҗмах почмагы бит ул); монда (институтта – *Р.Ю.*) өч меңгә якын **шәкерт** укый, аларга дүрт йөзләп **мөгаллим** белем бирә (монда өч меңгә якын укучы (студент) укый, аларга дүрт йөзләп укытучы белем бирә); үзләренең **низамнәмәләре** нигезендә (**уставлары** нигезендә); журнал редакциясе **шурасы** (журнал редакциясе советы); **каһвә**не кайчан эчәргә? (**кофе**ны кайчан эчәргә?); **мантыйкый фикер** йөртү бик кирәк иде (**логик фикер** йөртү...); сәяси **шигарьләр** артына яшеренеп (сәяси **лозунглар**га яшеренеп); сезгә булган мөнәсәбәттән **мәмнүн** булдыгызмы? (...мөнәсәбәттән

канәгать калдыгызмы? яки ...мөнәсәбәт күңелегезгә хуш килдеме?); ...әсәрләрнең **мәүзуг** төрлелеген тәэмин итә (...тема, проблема, сюжет төрлелеген тәэмин итә); баш мие **фалиҗы** (баш мие параличы); Октябрь **инкыйлабы** (Октябрь революциясе); **басмаханә** (типография); **сәркатип** (секретарь); **сәнәгать** (промышленность).

Кайбер журналистларның тел белән үзләренчә, белдеклеләнеп, тел фәне кагыйдәләрен исәпкә алмыйча эш итүләре кирәксезгә, ягъни кулланылыштагы әдәби тел сүзе була торып, диалекталь (билгеле бер урында яшәүчеләр теленә генә хас) сүзләр куллануларында да күренә. Хәзерге матбугат хезмәткәрләре, мәсәлән, **арзан, арзанлы, арзанаю** сүзләрен онытып баралар булса кирәк, алар урынына **очсыз, очсызлы, очсызлану** сүзләрен куллану гадәткә кереп бара: "Монда бит бөтен әйбер **очсыз**") дөресе – "...бөтен әйбер **арзан**"); Карабодай **очсызланган** (Карабодай **арзанайган)**.

Кайсыдыр каләм ияләренә **былчырак (пычрак)** сүзе ошамый: аны **саз** сүзе белән алмаштыралар: "Ник һаман да кешеләр саз ерып йөри?" ("...былчырак ерып йөри" кирәк, сазны ерып йөреп булмый: анда батасың!).

**Качу, тиз генә китеп бару** урынына **таю, кинәт** урынына **кисәк, төп** урынына **төпкел** (күңел төпкелләре), **кармалау** урынына **кабалау** ("Фермерның янчыгын кабалаучылар кимеми"), **икән** урынына **микән** ("Нигә аларны эфирга чыгармыйлар микән?") кебек диалектизмнар куллану хәлләре булып тора газета битләрендә. Кайберәүләрнең тау ягы сөйләшенә хас **бармалы, кайтмалы** формалы сүзләр кулланып язулары да әдәби тел кануннарына туры килми. Матбугат билгеле бер район өчен генә түгел, бөтен татар халкы өчен бит, шулай булгач, аның теле дә һәркем аңларлык булырга тиештер, ләбаса.

Газета журналистларының, телне куллануга җавапсыз карап, аны бозулары кирәксезгә рус сүзләреннән файдалануларында да чагылыш таба. Тел фәнендәге кагыйдә буенча кулланылышка алынма сүзләр тиешле төшенчәне, мәгънәне белдерергә туган телнең үз чаралары булмаган очракта гына кабул ителергә тиеш. Әмма газета чыгаручыларның кайберләре бу кагыйдәне яки бөтенләй исендә тотмый, яки белми: татар теленең үз сүзе булганда рус алынмасын кулланып яза. Мәсәлән:

"Җәлил **подпольега** соңрак килгән" (татарчасы – "Җәлил яшерен оешмага соңрак кергән"); "Россия сырны... 10 тапкыр кимрәк

**импортлаган**" ("Россия сырны... чит илдән 10 тапкыр кимрәк **алган**"); "Нинди кухняны үз итәсең?" (Нинди ризыкларны (ашларны), кайсы милләт ризыкларын (ашларын) үз итәсең, яратасың?); "Владимир Путин кытай кухнясын ярата икән" (...кытай ризыкларын, ашларын ярата икән); "Әти-әниләрнең күбесе, форма алганда, **ретрога** өстенлек бирә" (...элекке фасоннарга (киемнәргә) өстенлек бирә); "Алар... **наив** рәвештә үзләрен дүртенче хакимият дип санадылар" (...Алар... самимилек (беркатлылык) белән үзләрен... санадылар); "...балалар **травмалары** 40 процентка кадәр арткан" (...балаларның имгәнүләре 40 процентка арткан); "Экология **катастрофасы**" (экология һәлакате); "...немецларга плен төшә" (...әсирлеккә эләгә); "Хатирә әбинең иске өен күргәч, **шок булды**" (...өнсез калдым яки шаккаттым); "Россия икътисады яңа **шок халәте** көтәчәк" (...тагын бер тетрәнү кичерәчәк) һ.б.

Татар теле гыйлемендә хөкем сөргән рус алынма сүзләренең әйтелеше һәм язылышына караган кагыйдә буенча, узган гасырның 20-30нчы елларыннан, ягъни хәзерге татар теле формалашып, нормага салынып беткән чордан соң татар теленә рус алынмалары һәм интернациональ сүзләр, нигездә, чыганак телдәге әйтелеш һәм язылыш формасы белән, димәк, үзгәртелмичә үзләштереләләр. Бу хәзерге киң таралган татар-рус икетеллелеге халәтенә туры килә: татарлар рус телен яхшы белгән чорда рус алынма сүзләрен әйтелеш һәм язылышларын үзгәртеп куллану ихтыяҗы калмый. Әмма хәзерге журналистлар арасында рус теле алынма сүзләренең әйтелеш һәм язылышын татарның үзенчәлекле авазлары (хәрефләре) белән үзгәртсәң, алар татарның үз сүзләре кебек булачак дип фикер йөртүчеләр бар, күрәсең: кайбер алынма сүзләрне үзләренең язмаларында яңадан "татарчалаштыру" белән шөгыльләнәләр. Хәзерге икетеллелек чорында мондый эш үзен акламый, әлбәттә. Берничә мисал: **тауар** (товар), **керәчен лампасы** (керосин лампасы); **нимес** (немец); **җәгърәфия** (география); **урыс теле** (рус теле); **сәвит халкы** (совет халкы); **кампитр** (компьютер); **крәстиән** (крестьян); **пәлтә** (пальто); **кәчтүм** (костюм); **кәтлит** (котлет); **кәнфит** (конфет); **йогырт** (йогурт); **фәйләсүф** (философ); **тупыйк** (тупик); **тупыл** (тополь) һ.б.

Матбугат теле дөрес, үтемле, тәэсирле булсын өчен, анда сүзләрнең стиль үзенчәлекләренең исәпкә алынуы да әһәмиятле. Сүзләрнең, лексик мәгънәләреннән тыш, стилистик мәгънә төсмерләре дә була, һәм сөйләмнең камиллегенә, эчтәлекнең

төгәллегенә ирешүдә шуларны да белеп эш итү мөһим. Безнең газета материалларында кайчакта тел кулланылышының бу ягына игътибар җитеп бетми. Һәркайсыбызга бик мәгълүм **чәчәк** һәм **чәчкә** сүзләрен алып карыйк. Болар төп мәгънәләре белән бер үк сүзләр. Әмма кулланылыш үзенчәлекләре буенча бер-берсеннән берникадәр аерылалар: **чәчәк** телебезнең барлык стильләрендә дә кулланыла торган гомуми кулланылышлы сүз, **чәчкә** исә, нигездә, гади сөйләмдә, шигърияттә кулланыла, ләкин аны рәсми стильдә, иҗтимагый-сәяси, фәнни-техник эчтәлекле материалларда куллану урынлы булмый. Димәк, дәүләт, хөкүмәт органы – республика газетасындагы җитди эчтәлекле хәбәрдә "Казан **чәчкәләргә** күмелә, **чәчкә савытлары** арта" дип язуны хуплап булмый (дөресе – Казан чәчәкләргә күмелә, чәчәк савытлары арта).

"Штраф **чәпәячәкләр** (газетадагы хәбәр исеме). Бу контекстта **чәпи** (гади сөйләм сүзе) һич кенә дә урынлы түгел.

"**Күчсезләргә** ярдәм итү" (**хәлсезләргә** ярдәм итү кирәктер); "10 минуттан артыграк басып тору җилкәнең **кирәген бирергә** мөмкин" (**кирәген бирү** дөрес кулланылмый, **зыян китерә, эштән чыгара** һ.б.ш. кирәк); "**Карт арысланның китүе"** (Нурсолтан Назарбаев турында болай әйтү – зур тупаслык); "Татарстан мәктәпләреннән татар телен **куып чыгарырга** җыенган..." (**телне куып чыгару** дип әйтү килешми: кысрыклап чыгару дисәң, дөресрәк булыр) һ.б.

Стиль мәсьәләсе турындагы сүз уңаеннан сөйләмнең табигый агышына, интонациясенә зыян китерә торган "артык" сүзләр турында да әйтеп китү мәгъкуль.

Телнең гомумән алганда артык сүзләре булмый. Шулай да кайбер очракларда һәм кайбер урыннарда сүзне кирәксез, артык куллану күренеше бар һәм хәтта күп дип әйтергә була. Бу бигрәк тә газета укыганда күзгә ташлана. Еш кына нигә кирәк булды икән инде монда бу сүз дип гаҗәпләнергә туры килә.

"Артык" сүзләрнең иң күп һәм иң мәгънәсез кулланылганнары – **булып тора** һәм **булган**. "...республика Россиядә иң алга киткән төбәкләрнең берсе **булып тора**" , "Ул регби буенча Латвия командасының баш тренеры **булып тора**". Нигә кирәге бар бу җөмләләрдә **булып тора**ларның?

"Халкыбызга хас **булган** сабыр холык, түземлелек", "Татар теле өчен хас **булган** авазларны дөрес итеп әйтергә өйрәтү", Безнең

өчен мөһим **булган** бу вакыйга", "Рус милләтеннән **булган** кыз (рус кызы дисәң, аның кайсы милләттән булуы аңлашылмыймы икәнни?). Бу җөмләләрдә **булып тора** һәм **булган** сүзләренең һич кенә дә кирәк түгеллеге көн кебек ачык.

**Шул вакыт эчендә** рәвешендәге гыйбарәләр күп очрый: Алардагы **эчендә** бик кирәкме, **шул вакытта** гына дисәң, җитмиме икән?

"...**туган телгә карата мәхәббәте** көннән-көн үсә бара аның" (...**туган телне яратуы** көннән-көн арта бара аның булса, татарча дөресрәк булыр).

"Россия пенсия фондының Татарстан буенча **бүлекчәсе**" тәгъбирен "...Татарстан **бүлеге**" дисәң, татарча табигыйрак булыр иде.

"Артык" сүзләрнең күбесе рус теле сүзләрен ялгыш хәрефкә-хәреф тәрҗемә итү аркасында барлыкка килә. Мәсәлән, **булып тора – является** сүзенең, **карата – по отношению** тәгъбиренең калькалары. Урынсыз кулланылган кереш сүзләр дә – русчадан букваль тәрҗемәләр. Мәсәлән: "Бездә гигантомания – киң таралган күренеш. Гигант, әмма, гафу итегез, импотент" (Монда **простите**ның калькасы **гафу итегез**нең ни кирәге бар?).

"Ул заманнардан соң, **кем әйтмешли,** күпме сулар акты..." (Кем әйтмешли (**как говорится** калькасы) нигә кирәк булды икән?).

"...үлемсез әсәрләр тудыру – зур батырлык, әйтергә яраса, феноменаль күренеш" (**әйтергә яраса** – артык).

"...11 кешене елан чаккан. Аерым алганда, шундый очраклар Әлмәт... Югары Осланда теркәлгән" (**аерым алганда** нигә?).

"**Нәрсә-нәрсә**, татар матбугаты болай да тышауланган инде" (русчадагы **что-что**ның калькасы нәрсә-нәрсә бу урында бөтенләй кирәксез).

"Артык" сүзләр һәм тәгъбирләр сөйләмгә күп очракта каләм ияләренең җитди уйлап эш итмәүләре нәтиҗәсендә килеп керә. Мәсәлән: "655 гектар мәйданда үсә торган көзге бодайны суктырырга керешкән". *655 гектар көзге бодай* дисәң, дөресрәк була түгелме соң?

"...хезмәт хакы түләнелми торган ялга җибәрелгән" (**түләүсез ялга** җибәрелгән дип әйтү әйбәтрәк булыр иде).

"хезмәттәшлекне алга таба үстерү фразасында **алга таба** артыктыр, үстерү артка таба булмый бит инде.

“күз яшьләрен эчкә йота-йота” фразасында **эчкә** сүзе артык.

“пособие күләме 10 мең сумга кадәр җитәчәк” (**кадәр** – артык сүз).

“...бу шикләр эреп юкка чыккан” (**эреп** нигә кирәк монда?).

“хезмәт хакы нибары 5 процентка гына күтәрелә” (**гына** булгач **нибары**ның кирәге калмыйдыр).

“Шул елны тәмамлаган чыгарылыш укучылары очрашырга җыена” (**чыгарылыш** сүзе нигә?).

Безнең телдә **туу турындагы таныклык** сүзе бар. Бу атаманың **турындагы** сүзе рус теленең **о** предлогын букваль тәрҗемә итү аркасында барлыкка килгән: саф татарча – **туу таныклыгы**. Матбугат теленең лексика өлкәсенә караган проблемалары фразеологизмнар дип аталган күчерелмә мәгънәле, образлы тәгъбирләрне куллануда да чагылыш табалар. Бу өлкәдәге сәер күренешләр дә, күбрәк рус теле чараларын дөрес тәрҗемә итә белмәү аркасында килеп чыгалар. Тәгаен итеп әйткәндә, рус фразеологизмнарын еш кына хәрефкә-хәреф тәрҗемә итү аркасында татар теле өчен табигый булмаган, кытыршы, гарип гыйбарәләр барлыкка килә. Матбугатта очрый торган русчадан калькалаштырып алынган берничә фразеологик берәмлекне карап китик.

“***Күсәк белән оҗмахка кумыйлар” – “В рай дубиной не загоняют”*** фразеологизмының хәрефкә-хәреф тәрҗемәсе – татар теле өчен табигый әйтем түгел.

“Нәбирә Гыйматдинова әсәрләре **бер тын белән** укыла”. **На одном дыхании** фразеологизмының калькасы **бер тын белән** оригинал мәгънәсен белдерми, татарча аның адекват тәңгәллеге килеп чыкмаган. Аны – **берутыруда укып чыгыла, тын да алмыйча укыла, әсәрләрен онытылып укыйсың** кебегрәк итеп төзергә кирәк иде.

**“Кул очы белән эшләмәдем**” әйтеме дә татарча дөрес түгел: **кул очы белән эшләү** дип әйтелми.

**“Ак көнләшү белән көнләшү”** дә уңышлы төзелмәгән, татарлар өчен көнләшүнең агы да, карасы да булмый. Көнләшү ул – татарларда тискәре күренеш. Русларның **белая зависть** мәгънәсен татарча күбрәк **кызыгу** сүзе белдерә, башка чаралар да бардыр.

Русчадан калька **бармак аша карау** фразеологиясен да уңышлы ясалган дип әйтеп булмый.

Матбугат телендә күптән кулланылып килгән **мәсьәләне кабыргасы белән кую** тәгъбирен “мәсьәләне кискен итеп кую яки

җитди итеп кую" рәвешендә куллану максатка ярашлы булыр иде.

"**Кәгазьсез син бөҗәк кенә**" ("Без бумажки ты букашка"ның букваль тәрҗемәсе) тәгъбирен "Кәгазьсез беркая да бара алмыйсың", "Кәгазьсез берни дә эшләп булмый" кебегрәк итеп төзергә кирәк иде.

**"Сез үз тәлинкәгездә түгел идегез"** ("Вы были не в своей тарелке"ның сүзгә-сүз, хәрефкә-хәреф тәрҗемәсе) шулай ук оригинал мәгънәсен дә белдерми, һәм анда татар фразеологизмының рухы да сакланмаган.

Язма телдә дә, сөйләм телендә дә киң таралган "**Бәйрәм белән! Яңа ел белән!"** кебек тәгъбирләр – шулай ук русчадан уңышсыз калькалар.

Алар чын татарча "Бәйрәм котлы булсын! Яңа ел (бәйрәм) мөбарәк булсын! Бәйрәм белән котлыйм (тәбриклим)!" рәвешендә булырга тиешләр.

Мисаллардан күренгәнчә, рус теле фразеологизмнары татарчага һәрвакытта да образлы тотрыклы берәмлекләр белән тәрҗемә ителмиләр. Журналистлар моны исләрендә тотсыннар иде.

Матбугат телендә географик исемнәрне (топонимика исемнәрен) куллануга караган төгәлсезлекләр хөкем сөрә. Бу мәсьәләдә төп проблема шунда: кайбер журналистлар, мондый исемнәр мөмкин булганча күбрәк татарча язылышлы һәм әйтелешле булсын дигән изге ният белән эш итеп, кайчакта арттырып җибәрәләр, ягъни инде татар телендә күптән русча формада үзләштерелгән география исемнәрен татарчалаштыру белән шөгыльләнәләр. Бу, беренчедән, андый ялгызлык исемнәрен халык аңламаслык хәлгә китерә, икенчедән, топонимика исемнәрен элекке, искергән формаларына кире кайтару хәзерге актив икетеллелек чорының табигатенә туры килми, әдәби телне, шул исәптән матбугат телен, халыкның җанлы сөйләм теленнән аерыла баруына этәрә. Россия халыкларында географик исемнәрне бердәм аралашу теле рус телендә куллану гомуми күренешкә әверелеп бара. Шушындый халәттә, татар матбугатында гына топонимика исемнәрен, башка барлык халыклар телләрендәгедән зур аермалы әйтелешле һәм язылышлы итәрнә омтылу үзен акламас.

Россиядәге Свердловск, Оренбург, Ижевск, Ярославль, Астрахань, Саратов, Ульяновск шәһәрләре исемнәре бөтен СССР халкы, шул исәптән татарлар, тарафыннан гомуми әйтелеш һәм язылыш

формаларында, ягъни рус телендәгечә кулланылып килделәр. Соңгы елларда, кайсыдыр каләм ияләре ихтыяры белән, аларның бик күптәннән, татарларның күпчелеге рус теленең үзенчәлекле авазларын әйтә белмәгәнлектән татарчалаштырып үзләштергән формаларын кире кайтара башладылар: **Свердловскины Свердлау, Оренбургны Орынбур, Ырымбур, Ижевскины Ижау, Ярославльне Ярыслау, Астраханьны Әстерхан (Әчтерхан), Саратовны Сарытау, Ульяновскины Ульян** дип куллана башладылар. Кайберәүләр **Петербургны Питырбур, Варшаваны Варшау, Алма-Атаны Алматы, Бакуны Бакы, Кабардино-Балкарияне Кабарты Балкар, Грузияне Гөрҗестан, Германияне Алмания** дип атыйлар. Халык кимендә бер гасыр әйтеп, язып ияләнгән ул шәһәр һәм ил исемнәрен кем ничек тели шулай үзгәртүнең кемгә кирәге бар икән. Бу бит үзенә күрә зур буталчыклык кертә торган башбаштаклык. Рәсми әдәби газета телендә алар элеккечә, рус телендәге бердәм формаларында кулланылырга тиешләр. Матур әдәбият стилендә, халыкның җанлы сөйләмендә алар татарчалаштырылган вариантларында кулланылырга мөмкин, әлбәттә. Мәсәлән, күп кеше Улъяновскины Ульян дип гадиләштереп, җиңеләйтеп сөйли. Сөйләсеннәр, әмма инде Саратовны Сарытау дип, Ижевскины Ижау дип сөйләүчеләр күп булмастыр, мөгаен. Һәрхәлдә әдәби тел нормалары һәр татар кешесе өчен бердәм (бертөрле) булырга тиеш.

Башбаштаклык көнчыгыш илләре, шәһәрләре исемнәрен куллануда да бар. **Ливанны Лүбнән дип, Палестинаны Фәләстыйн, Пакистанны Пакъстан, Сирияне Сүрия, Дамаскны Димәшкъ, Әзербәйҗанны Әзәри** дип язу очраклары бар. Бу мәсьәләдә дә ничек булса булсын, татарча гына булсын дигән принцип белән эш итүчеләр күренә. Гарәп-фарсы исемнәрен уйлап, тикшереп тормыйча, татарчага күчерү дөрес булмый. Әгәр дә аларның чыганак формасын тәгаен белмәсәң, русча формасында куллану хәерлерәк. Мисал өчен, гарәп телендәге Юсеф сүзен кайберәүләр, татар киеме кидертеп, Йосып итеп куярга тели. Алай булмый шул: Йосып Юсеф түгел инде ул. Сүз уңаенда: бер журналист мәгълүм **Юсупов сараен** (Дворец Юсупова) **Йосыпов сарае** дип язган: бу тарихи чынбарлыкны бозу була. Дөресе – Юсупов сарае.

Европаны Аурупа дип, Евроазияне Ауразия дип үзгәртеп атау да бүгенге көн таләпләренә җавап бирми.

Казандагы **Дербышки** бистәсен **Дәрвишләр** бистәсе дип атауның дөреслеге шикле: Дербышки белән дәрвишләрнең уртаклыгы юктыр.

Казанның метро станцияләренең берсен татарча **Кәҗә бистәсе** дип атау да уйлап эшләнгән гамәл түгел.

Ниһаять, безнең топонимика исемнәренә караган бер зур хата – **Яр Чаллы.** Татарча белгән кеше килешер: Яр Чаллы дип әйтү дөрес түгел, чын татарча – **Яр Чаллысы**. Уңайлылык өчен ул шәһәрне **Чаллы** дип кенә атарга кирәк. Аяныч: исемнәр кушуга, гомумән тел мәсьәләләренә караган мәсьәләләрне чиновниклар филолог галимнәр белән киңәшләшеп хәл итсәләр, нәтиҗәләр уңайлырак булыр иде. Шулай эшләмәгәнгә күрә, туган телебезне куллану мәсьәләләрендә тупас ялгышлар тулып ята.

Дөрес сөйләмгә ирешү, фәнни итеп әйткәндә, сөйләм культурасын саклау өчен, фигыль сүз төркеменә кергән сүзләрне дөрес куллану әһәмиятле. Хәлбуки, безнең бүгенге телебездә, шул исәптән матбугат телендә дә, бу мәсьәләдә проблемалар шактый күп. Телнең бу бик мөһим сүзләреннән тулы һәм дөрес файдаланырга мәктәпләрдә дә, һөнәри уку йортларында да нәтиҗәле итеп өйрәтмиләр булса кирәк.

Журналистлар эшенә килгәндә, аларга университетта телебезнең бу бай сүзлек катламын куллану дәресләре үткәрелмидер һәм вуздан соң белгечләрнең үзлекләреннән өйрәнү гадәте дә юктыр.

Хикмәт шунда: татар теле фигыльләренең күп төрле формалары бар, һәм аларның, һәркайсының, төп лексик-грамматик мәгънәләреннән тыш, төрле мәгънә төсмерләре бар. Үткән заман хикәя фигыльләренең генә дә **барды, барган, бара иде, барган иде, барган була (булган) бара торган иде, бара торган була (булган), барганым бар, барганы(м,ң) бар иде** формалары кулланыла.

Журналистлар менә шушы үткән заман хикәя фигыльләрен һәм сыйфат фигыльләрне кулланганда күп ялгышлар җибәрәләр. Алар күп төрле, шуңа күрә монда, барысын да сөйләп тормыйча, бер-икесен – аеруча киң таралганнарын гына әйтеп китик.

**-ды-де (-ты-те)** кушымчалы билгеле үткән заман хикәя фигыльләре эш-хәлне (процессны) язучы, сөйләүче үзе күргән очракта кулланыла: “Мин кичә театрга бардым”.

**-ган-гән (-кан-кән)** кушымчалы билгесез үткән заман хикәя фигыльләре процессны сөйләүче (язучы), үзе күрмичә, баш-

ка кешедән ишетеп, укып, радио-телевидениедән ишетеп-күреп сөйләгәндә кулланыла: “Кичә Мәскәүдә боз яуган”.

Әмма каләм ияләре, гадәттә, барлык очракларда да диярлек **-ды-де (-ты-те)** кушымчалы үткән заман хикәя фигыльләреннән генә файдаланалар: “Әби патша татарларга... таш мәчетләр салырга **рөхсәт бирде**” (**рөхсәт биргән** кирәк); Америка астронавтлары берничә тапкыр айга менеп **төштеләр** (...айга менеп **төшкәннәр** булырга тиеш).

Фигыльләрнең мондый кызыклы һәм четерекле үзенчәлеге дә бар: процесс гамәлгә ашырылганда сөйләүче (язучы) үзе булып та, ул аны сизми калса, процесс субъектның ихтыярыннан башка гамәлгә ашырылса, фигыльләрнең **-ган-гән (-кан-кән)** кушымчалы төрләре кулланыла. Ләкин моны күп кеше белми. Республика газетасындагы бер мәкаләнең исеме “**Утырттым да оныттым диярлек булмасын”.** Бу җөмләдә фигыль **онытканмын** формасында булырга тиеш.

Татар теленең аналитик фигыль формалары процесс башкарылуның күп төрле дәрәҗәләре: дәвамлылык, кинәтлек, әкренлек һәм башка төрле мәгънәләрен белдерә алалар. Бу үзенчәлекләрне белеп куллану сөйләмне җанлырак, бизәклерәк итәргә мөмкинлек бирә. Ләкин практикада бу бай мөмкинлекләр тулы файдаланылмый. Мәсәлән, бу җөмләнең фигыльләре дөрес кулланылмаган: “Эшмәкәр, әледән-әле авылга кайтып, якташларының хәлләрен белешә, һәркемгә булыша” (“...хәлләрен белешеп, һәркемгә булышып тора” кирәк) : **тора** ярдәмче сүзе белән ясалган фигыльләр дәвамлылыкны белдерәләр (белешеп, булышып тора).

**Иде** ярдәмче сүзе белән ясалган аналитик фигыльләр дә сөйләүче (язучы) процессның башкарылуын үзе күргәнлекне белдерә. Әмма бу кагыйдә дә еш кына үтәлми: “... бу Усениново авылын Карамзин да искә алган иде” (дөресе – “...Карамзин да искә алган булган”).

Матбугат материалларында телнең бозылуы *сыйфат фигыльләр* дип атала торган сүзләрне куллануда да ачык күренә: монда да, телдән файдалануның башка өлкәләрендәге кебек, элементар хаталар хөкем сөрә. Фикеребезне кайбер мисалларны анализлау җирлегендә расларга тырышып карыйк (мисаллар бер газетаның соңгы саннарыннан гына алынды).

“Россиядә ел башыннан **үлүчеләр** саны 32 мең кешегә кимегән”.

Монда сүз үлеп ятучылар турында түгел, үлгән кешеләр турында бара бит, шулай булгач, **үлүчеләр саны** дип әйтү ялгыш, **үлгәннәр** яки **үлгән кешеләр саны** дияргә кирәк.

“Кайчандыр иң артта **баручы** районда нинди үзгәрешләр бар?”. “Кайчандыр иң артта **барган** районда...” дип әйтелергә тиеш татарча.

“Беренче турдан **узучылар** редакциягә әңгәмәгә чакырыла” (Беренче турдан **узганнар...**).

Мондый мисаллар газеталарда йөзләрчә, меңнәрчә. Димәк, журналистларның күбесе (**-учы-үче** формалы) хәзерге заман сыйфат фигыле белән **-ган-гән (-кан-кән)** кушымчалы үткән заман сыйфат фигыльләренең аермасын белмиләр: һәрвакыт **-учы-үче** формалы фигыльләрне генә кулланалар.

Татар теленең **-ган-гән (-кан-кән)** кушымчалы сыйфат фигыльләренең мәгънәләре күп төрле. Мәсәлән, алар предметның билгесен үткәндә булган процесс аша гына белдереп калмыйлар, бәлки даими булып торган эш-хәл аша да белдерәләр. “Чылтырап **аккан** чишмәгә суга дип барган идем”, дип җырлый халык, **агучы** чишмәгә түгел, хәлбуки, “чишмә хәзер дә ага”. “Безнең районга **кергән** авыллар” дип әйтелә чын татарча, бүгенге көн турында сөйләгәндә дә (**керүче** авыллар түгел). Хәзер инде “һәлак **булучыларга** һәйкәл ачылды” дип сөйләү һәм язу гадәти күренешкә әверелеп бара (дөресе – “һәлак **булганнарга** яки **булган** кешеләргә...”).

Ниһаять, газета-журналлар телендәге проблемаларга караган тагын бер мәсьәлә ул – җөмләдәге сүз тәртибе. Мәгълүм булганча, сүзләр сөйләмдә билгеле бер тәртиптә урнашалар: һәр сүзнең үз урыны бар. Каләм иясе, сүз остасы, сөйләм камил булсын өчен, язганда һәм сөйләгәндә сүзләрнең урнашу тәртибен сакларга тиеш. Ул тәртип бозылса, сөйләм дә ямьсезләнә, кытыршылана, мәгънә дә тоныклана, бозыла. Менә бер җөмләне укып карыйк: “**Зәп-зәңгәр, озык кара керфекләр** белән каймаланган нур чәчеп торган күзләр дисеңме... – бар да килешле”. Бу җөмләдә **зәп-зәңгәр** сүзе ялгыш урынга куелган булу аркасында сөйләмдәге фикерне аңлау кыенлаша: **зәп-зәңгәр, күзләргә** караганлыктан, шул сүз алдыннан куелырга тиеш, ә ул җөмләнең башында ук куелган. Җөмлә “Озын кара керфекләр белән каймаланган, нур чәчеп торган **зәп-зәңгәр күзләр** дисеңме...” рәвешендә булырга тиеш. Бу җөмләдә шулай ук, сүзләр дөрес урнаштырылмау аркасында, җитди мәгънә ялгышы

килеп чыккан: “Донецк халык республикасы вәкилләре **40 тапкыр ут ачмау килешүен бозды**”. “**Ут ачмау килешүен 40 тапкыр бозды**” дип әйтәсе урында “40 тапкыр ут ачмау килешүен бозды” булып чыккан.

Сүз тәртибе ялгышларының иң күбесе шуннан гыйбарәт: җөмләдә логика буенча хосусый төшенчәне белдерә торган сүзләр гомуми төшенчәне белдергән сүзләрдән соң куеласы урында, киресенчә, алардан алда куелалар. Мисаллар: “...намуслы хезмәте өчен “Бөгелмә аэропорты” җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры ...медале белән бүләкләнде”. Дөресе – “...җаваплылыгы чикләнгән җәмгыять “Бөгелмә аэропорты” директоры ...бүләкләнде”.

Менә бу гыйбрәтле җөмләне тикшереп карыйк: **“Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының кырык бишенче утырышын 2019 елның 14 февралендә 10 сәгатьтә Татарстан Республикасы Дәүләт Советының утырышлар залында чакырырга”**.

Монда берничә тупас хата бар.

Беренчедән, **бишенче чакырылыш** җөмлә башында түгел, Дәүләт Советы алдыннан куелырга тиеш.

Икенчедән, бер җөмләдә **Татарстан Республикасы Дәүләт Советы,** бертөрле нигезле **чакырылыш** һәм **чакырырга**, **утырышын** һәм **утырышлар** сүзләре кабатлана (бу стилистик кытыршылык).

Өченчедән, **утырышны чакыру** сүзтезмәсендәге сүзләрнең үзара семантик бәйләнеше табигый түгел: **утырышны чакыру** дип әйтелми.

Дүртенчедән, **10 сәгатьтә** дип әйтү дөрес түгел: саф татарча – сәгать 10 да.

Бишенчедән, татар телендә (рус телендә дә) кабул ителгән орфография кагыйдәләре буенча, тезмә ялгызлык исемнәренең беренче сүзләре генә баш хәреф белән язылырга тиеш: “Татарстан республикасы”, “Дәүләт советы”.

Алтынчыдан, Татарстан республикасы Дәүләт советы сүзләрен кабатламас өчен, аларның икенчесен **парламент** сүзе белән алмаштырырга кирәк.

Әйтелгәннәрне исәпкә алып, җөмләне болай үзгәртеп төзесәк, ул язу өчен дә, уку өчен дә бераз җиңеләер иде һәм тел кануннарына да күбрәк туры килер иде:

“**Татарстан республикасының бишенче чакырылыш Дәүләт советының кырык бишенче утырышын (сессиясен**

**түгелмени? –** *Р.Ю.*) **2019 елның 14нче февралендә сәгать 10да утырышлар залында үткәрергә".**

Сүз тәртибенә караган тагын бер ялгыш: безнең каләм ияләре аныклаулы мөнәсәбәттәге ике сүздән торган сүзтезмәләрдә, рус теленә ияреп, ялгыш аныклаучы компонентны аныкланмыштан соң куялар: "**Галим-тюрколог** Әхмәт Зәки Вәлиди хезмәтләре...". Дөресе – "Т**юрколог-галим** ...Вәлиди хезмәтләре". Чагыштыру өчен: **Гали-итекче** түгел, **итекче Гали**, **галим-телче** түгел, **телче галим.**

Сүз тәртибенә караган бер гасыр диярлек дәвам иткән тупас ялгыш – сәгать исәбенәйтү. Безнең журналистлар, шулай ук русча сүз тәртибенә ияреп, чын татарча итеп, **сәгать 10, унынчы 25 минут, ун тулырга 5 минут** рәвешендә язасы, әйтәсе урында **10 сәгать, 9 сәгать 15 минут** һ.б. өлгесен кулланалар.

Сүзебезне йомгаклап әйткәндә шул: бүгенге матбугат язмаларында туган телебезне тупас бозып куллану күренешләре зур урын алып тора.

Чаң сугып, ашыгыч рәвештә тиешле чаралар күрелмәсә, татар матбугаты теле тагын да ныграк корама-калька теленә әверелә баруын дәвам иттерәчәк.

## ТЕЛЕБЕЗ ҮЗЕБЕЗЧӘ БУЛСЫН

Безнең телебез – халык тарафыннан күп гасырлар буена иҗат ителеп, камилләштерелеп барлыкка килгән чиксез кыйммәтле рухи хәзинәбез. Ул алдынгы мәдәниятле, югары цивилизацияле татар милләтенең беренче билгесе, аны милләт буларак саклап тора торган калканы. Туган тел ул – ата-анабыз, туып-үскән җиребез кебек үк кадерле нәрсә. Шуңа күрә үз телен яхшы итеп өйрәнү, камил белү һәм аны дөрес куллану – шушы милләт кешесе булып саналган һәркемнең изге бурычы. Ана телен хөрмәт иткән, аның табигый халәтен саклап, бозмыйча, дөрес кулланган кешене генә чын мәгънәсендә тәрбияле, югары культуралы зат итеп санарга мөмкин.

Телне белү, куллану дәрәҗәсе төрлечә була. Аны гаиләдә, якын кешеләрең белән генә аралашырлык, базар, кибет кебек урыннарда аңлашырлык итеп кенә белүне гади сөйләм теленә ия булу диләр. Шулай ук акыл хезмәте башкарыла торган җирләрдә, әдәбиятта,

сәнгатьтә, мәгариф, фән өлкәләрендә, матбугатта кулланыла торган тел дә бар. Телнең бу төре әдәби тел дип атала, һәм аңа ия булу анның катлаулырак үзенчәлекләрен, күбрәк сүз байлыгын үзләштерүне таләп итә. Тиешле дәрәҗәдәге укымышлы, яхшы тәрбияле кеше, гадәттә, телнең менә шушы әдәби дип йөртелә торган формасын белә һәм шуннан иркен файдалана. Телне яхшы итеп белү турында сөйләгәндә, нигездә, әдәби телгә ия булу күздә тотыла.

Туган телнең әдәби формасын камил белү һәм шул телнең барлык табигый үзенчәлекләреннән, сүзлек байлыгыннан тулы файдаланып кулланганда гына халыкның бу тылсымлы, бөек хәзинәсен саклап үстерергә мөмкин. Әдәби тел, аны ныклап үзләштереп, дөрес итеп кулланганда гына, татар халкын алдынгы милләт буларак саклау һәм алга җибәрү хезмәтен үти алачак. Димәк, ана телен балаларга гаиләдә өйрәтеп, башлангыч сыйныфларда укыту җитә дигән сафсата сатуларны җитди сүз итеп кабул итәргә ярамый, мондый белдерүләр милләтне саклау һәм прогресска илтүгә ярдәм итми генә түгел, киресенчә, аны тоткарлый.

Бүгенге көндә яшәүче үз милләтен кадерләгән, милли җанлы горур татар кешесенең изге бурычы – туган телен белү, белмәгәненең яки начар белгәненең – өйрәнү һәм үз телендә иркен аралашу. Максат – үз телеңне ипи-тозлык, ярым-йорты гына белү түгел, бәлки камил, матур, бай  әдәби телне үзләштерү һәм мең еллык тарихлы татар әдәбияты белән танышу, шулай ук үзеңне татар телендәге газета-журналларны укырга, радио-телевидение тапшыруларын тыңларга, карарга күнектерү. Ата-аналарның гражданлык бурычы – балаларын гаиләдә үз телләрендә сөйләшергә гадәтләндерү, татар классларында һәм мәктәпләрендә укыту, рус мәктәпләрендә укыганнарын татар теле дәресләренә йөртү.

Менә шушы шартларны үтәүгә ирешә алсак кына, без бу заманда телебезне, мәдәниятебезне, гореф-гадәтләребезне һәм гомумән милләтебезне саклап кала алачакбыз.

Ләкин телне саклау турында сөйләгәндә ул гади аралашу, аңлашу чарасы буларак кына түгел, бәлки кешеләргә әдәбият, сәнгать әсәрләре иҗат итү өчен, фән, иҗтимагый-сәясәт өлкәләрендә дә хезмәт күрсәтә торган катлаулы төзелешле, камил, нәфис корал буларак күз алдында тотыла. Бу исә тел белән эш итүчеләр, бигрәк тә телне үзләренең көндәлек эш коралы итеп кулланучы  язучылар, журналистлар, укытучылар, галимнәр һәм

башка иҗат, акыл хезмәте кешеләре телнең барлык үзенчәлекләрен яхшы белеп, алардан тулы файдаланырга тиеш дигән сүз.

Бу язмада менә шушы фикер җирлегендә соңгы бер-ике айда дөньяга чыккан татарча матбугат теленең торышы, сыйфаты, бүгенге көн таләпләренә ни дәрәҗәдә җавап бирүе хакында бәян ителер.

Газеталарда күп авторлар язган төрле жанрдагы материаллар басылганлыктан, аларның теленә бертөрле генә бәя бирү кыен. Аларда дөрес, матур тел белән оста язылган мәкаләләр һәм хәбәрләр дә, мактый алырлык түгелләре дә бар. Матур әдәбият стиленә тартым очеркларның һәм публицистик материалларның телендә хилафлык күренешләре булса да бик аз гына. Русчадан тәрҗемә итеп алынган хәбәрләрнең телендә проблемалар күп. Матбугат теле үрнәк әдәби тел булырга тиеш дигән югары таләпне һәм чирен яшергән үлгән дигән мәкальне истә тотып, шулай ук газеталарыбыз халыкның күңеленә хуш килерлек, укучыларны дөрес әдәби телдә тәрбияләргә ярдәм итәрлек булсын дигән изге ният белән, бу язмада, автор карашынча, телебезне бозып, ялгыш куллану күренешләренә анализ ясау, аларның барлыкка килү сәбәпләрен күрсәтү һәм хаталарны төзәтүгә юнәлдерелгән тәкъдимнәр бирү максаты куелды.

Матбугат материалларында хөкем сөргән тел ялгышлары күп төрле. Алар аерым-аерым күрсәтелер. Ялгышларның күбесе өчен уртак сыйфатлар – сүзләрне еш кына дөрес мәгънәдә куллана белмәү, аларның татар теленә генә хас үзенчәлекләрен, мәгънә төсмерләрен исәпкә алмау, сүзләр куллануындагы бертөрлелек, синонимнардан аз файдалану яки бөтенләй файдаланмау, нәтиҗәдә сүзлек хәзинәсенең фәкыйрьләнүе һәм башка кайбер нәрсәләр. Бу күренешләрне анализларга күчкәнче, шуны искәртеп кую урынлы булыр. Газеталардагы, шулай ук радио-телевидение тапшыруларындагы хаталарның күбесенең төп сәбәпләре – татар телен дә, аның белән даими тыгыз бәйләнештә торган рус телен дә бөтен специфик (һәркайсының да үзенә генә хас) үзенчәлекләре белән белеп бетермәү һәм күп очракларда русчадан татарчага дөрес тәрҗемә итә белмәү, төгәлрәк итеп әйткәндә, татар телендә рус сүзенә тәңгәллекне аның сөйләмдәге, тексттагы мәгънәсенә карап билгеләмичә, ике тел сүзлекләрендә теркәлгән, күпчелек очракта билгеле, зиһенгә беренче килгән сүзне генә куллану, ягъни калькалаштырып кына бару.

Нәтиҗәдә матбугат теле торган саен күбрәк калькалар теленә әверелә бара. Бу безнең татар газеталарында иң нык таралган чир.

Кайбер каләм ияләре язмаларының укучыга аңлаешлы булу-булмавы хакында уйланып тормыйлар. Мәсәлән, **обороняться (саклану**) сүзеннән ясалган **оборона**ны **саклану** дип тәрҗемә итә башладылар: *саклану министрлыгы, саклану сәнәгате* һ.б. Ләкин **оборона** ул **саклану** гына түгел, бәлки дошманга каршы тору чаралары, корылмалары да. Тәрҗемә принципларында әйтелгәнчә, кайбер чит тел терминнарын тәрҗемә телендә берничә сүз ярдәмендә (аңлатмалы юл белән) белдерергә туры килгән очракларда, кыскалык, уңайлык өчен, алынма сүздән файдаланырга туры килә. Элекке тәрҗемәчеләр, журналистлар, шушы кагыйдәне исәпкә алып, алынма **оборона** сүзен кулланып килделәр: *оборона министрлыгы, оборона промышленносте* һ.б. Соңгы елларда журналистлар ничек булса булсын, тик үзебезчә генә булсын дигән принцип белән эш итеп, мондый тезмә терминнардагы **оборона**ны **саклау** сүзе белән тәрҗемә итеп куллана башладылар. Ләкин моны уңышлы гамәл дип әйтеп булмастыр, чөнки, газета укучының, мәсәлән, “... яшүсмер килеш **саклану заводы**нда эшләгән” дигән җөмләдәге **саклану заводы**ның нинди предприятие икәнлеген аңлавы бик шикле.

“Көрәшче авыр тән җәрәхәтләре алган һәм больницада **һәлак булган**”. Бу җөмләне укыгач, авторның татар теленең бөтен хасиятләрен белмәве аңлашыла. **Һәлак булу** ул больницада яки өйдә авырып үлү түгел, вакытсыз, фаҗигале үлем, мәсәлән, *сугыш кырында, янгында, суга батып һәлак булды* диләр. Җөмлә “*көрәшче, бик нык имгәнеп, больницада үлгән*” рәвешендә булырга тиеш иде.

Каләм һәм сүз әһелләре еш кына, кайсыдыр сүзне, тәгъбирне кулланганда, аның төгәл мәгънәсенә төшенеп җитмиләр, һәм нәтиҗәдә тәрҗемәдә тупас хаталар китә. Менә бу җөмләләргә игътибар итик:

“Тәкәбберлек исламга **тиң** түгел”; “Ислам динендәге кешеләргә тиң булмаган тәкәбберлек күренеше” (динне һәм ислам динендәге кешеләрне ничек итеп тәкәбберлеккә тиңләштерү турында сөйләргә мөмкин: газета укучы моны нәрсә дип аңларга тиеш икән?!). Монда **тиң** сүзе ялгыш **хас** сүзе урынында кулланылган булса кирәк.

“**Яхшы эшне нигә фаш итмәскә**?!” Бу җөмләне укып, нинди мәгънәсезлек икән бу дип уйлыйсың: яхшы эш фаш ителергә тиеш икән дигән нәтиҗә ясарга туры килә. Автор **игълан итү** сүзен **фаш**

**итү** белән бутаган, күрәсең: “**Яхшы эшне нигә игълан итмәскә (белдермәскә, күрсәтмәскә, хәбәр итмәскә** һ.б.)” дияргә кирәк булгандыр.

Бу җөмлә авторы **исәпкә алу** урынында **искә алу** әйтелмәсен кулланган, хәлбуки, аларның мәгънә аермасы җир белән күк аермасы кебек: “Хәзерге укырга өйрәтү китаплары... телнең фонетик-лексик үзенчәлекләрен никадәр **искә ала**?”

Кайбер матбугат әһелләренең яки бик игътибарсыз булуларына, яки телне начар белүләренә һәм белергә теләмәүләренә нык гаҗәпләнергә туры килә.

“Былтыр “Татнефть” 29,5 млн. тонна нефтьне җир өстенә чыгарган. Алдагы ел белән чагыштырганда, бу 594 мең тоннага күбрәк”. Алдагы ел ул киләсе ел бит, узган елны киләсе ел белән ничек чагыштырасың? “*Элекке ел белән чагыштырганда*” дияргә кирәк бит.

Кайчакта ике тел белән эш итүчеләргә аңлатмалы һәм тәрҗемә сүзлекләренә күз салсалар, сөйләм культурасы (дөрес сөйләм) турындагы мәкаләләрне һәм китапларны укысалар да зыян булмас иде, ләбаса.

Соңгы вакытларда Россиядә “**цифровая экономика**” дигән әйтелмә кулланылышка керде. Татарча аны “**санлы икътисад**” дип тәрҗемә итәләр. Болай эшләү дөресме икән? **Цифр** ул **сан** үзе түгел, бәлки санның билгесе генә. Шулай булгач, аны, алынма буларак, **цифр** дип кулланыргадыр. Югыйсә, менә бу җөмлә аңлашылырмы: “*Санлаштыру, балыкчылык өлкәләрендә дә уртак эшләрне көчәйтәсе бар*”. “**Санлы икътисад**”ка караганда “**цифрлы икътисад”** аңлаешлырак булмасмы икән?

Татар журналистлары элек-электән, һәрхәлдә совет елларында да һәм аннан соңгы чорда да, бик әһәмиятле тәрҗемә итү белеменнән мәхрүм ителеп килделәр. Хикмәт шунда: иң зур күпчелек руслар тәшкил иткән, барлык мөһим информация татарча мәгълүмат чараларына рус телендә ирештерелгәнлектән, милли телләрдә чыгарыла торган газета-журнал һәм радио-телевидение хезмәткәрләре материалларның шактый күп өлешен русчадан тәрҗемә итеп алалар, ягъни аларның күбесе, нигездә, рус теленнән тәрҗемә итү белән шөгыльләнә. Шунлыктан булачак журналистларны әзерләгәндә, аларга тәрҗемә теориясеннән (тәрҗемә фәненнән, тәрҗемә белеменнән) тиешле мәгълүмат бирү шарт. Бүгенге көндә, тәрҗемә итүнең принципларын, метод һәм алымнарын белми то-

рып, журналистлык эшен уңышлы башкару мөмкин түгел. Ләкин, инде искәртеп киткәнчә, безнең республикада, татар журналистларын махсус һәм әйбәт итеп тәрҗемә теориясенә өйрәтү беркайчан да булмады. Матбугат һәм радио-телевидение җитәкчеләре дә, тиешле дәүләт органнары да аларны эш барышында булса да бу һөнәргә өйрәтү яки, үзлекләреннән өйрәнүләрен таләп итү белән шөгыльләнмәделәр. Нәтиҗә күз алдында: дистәләрчә газеталардагы меңнәрчә мәкалә-хәбәрләрдә, берничә радио-телевидение каналларыннан һәр көнне агылып торган тапшыруларда чиксез күп тел хаталары, туган телне бозып куллану күренешләре тулып ята. Һәм аларның күбесенең нигезендә русчадан татарчага механик рәвештә, сүзгә-сүз, хәрефкә-хәреф тәрҗемә итү ята. Болай эшләү исә тәрҗемә итүче кешеләрнең, бер телдәге фикерне, мәгънәне икенче телдә белдергәндә, оригиналның һәр сүзенә тәрҗемә телендә дә бер тәңгәл сүз бар дип, примитив (беркатлы) эш итүенә кайтып кала. Алар барлык телләрдә дә сүзләр күп мәгънәле һәм шунлыктан ике тел сүзләре арасында һәр очрак өчен әзер тәңгәллек (адекват сүз берәмлеге) була алмый, андый тәңгәллек һәр конкрет очракта оригинал сүзенең контексттагы (сөйләмдәге) мәгънәсенә карап кына табып куела дигән бәхәссез хакыйкатьне (аксиоманы) исәпкә алмыйлар.

Менә шулай сүзгә-сүз, хәрефкә-хәреф, механик рәвештә тәрҗемә итү аркасында телебездәге әйтелмәләр, тәгъбирләр, гыйбарәләрне тәшкил иткән сүзләрнең үзара табигый мәгънә бәйләнешенә керү үзенчәлекләре бозыла һәм татар теле өчен ят, ясалма гайре табигый сүзтезмәләр (әйтелмәләр) барлыкка килә. Болар татар телендәге мәгълүмат чараларында иң күп санлы ялгышларны тәшкил итәләр.

Бу фикерне кайбер мисаллар ярдәмендә бәян итик.

**Үсү** сүзе белән бергә килеп ясалган гайре табигый әйтелмәләр бик күп. Бу рус телендәге **расти, развиваться** сүзләрен һәр очракта да **үсү** белән тәрҗемә итү, аның күп санлы синонимнарыннан файдаланмау нәтиҗәсе. **Үсү**нең төп мәгънәсе – *биологик (кеше, хайван, үсемлек һ.б.ш) нәрсәләрнең зураюы, киңәюе, озынаюы, микъдары арту* кебек төшенчәләрне белдерә. Җансыз нәрсәләрнең, предметларның *арта, зурая, күбәя, калка баруы* кебек күренешләрне белдерү өчен, татар теленең башка төрле сүзләре бар, һәм шулар кулланылырга тиеш тә. Әмма журналистлар күп очракта аларны барлап тормыйлар, яраса-ярамаса да **үсү** сүзеннән генә файдаланалар:

“Россиядә халык **канәгатьсезлеге үсә** башлау уңаеннан...” (“...**канәгатьсезлеге арта башлау**...” кирәк); “...Русиядә үлүчеләр **саны үсә**” (дөресе – “... **саны арта**”); “**бәяләр үсә**” (“**бәяләр күтәрелә**”); “һава **температурасы үсә**” (дөресе – “һава **температурасы күтәрелә**”); “Аның республика **законнарын үстерүдәге** роле дә гаять зур булды” (“**закон үстерүе**” бик уңышсыз әйтелмә) һ.б.

Хәзерге журналистлар **телефоннан шалтыраттылар** дип әйтәсе урында, рус теле формасына ияреп , “**шалтыратулар кабул иттек яки кабул итеп алдык” (принимать звонки**дан) дип язалар һәм сөйлиләр.

Мондый сәер, татар теле өчен ят гыйбәрәләр матбугат телендә көннән-көн арта бара. Менә, мәсәлән, соңгы көннәрдә генә **ярышта җинүне ярышны ота** дип әйтә башладылар: “Моңа кадәр беркемнең дә ... барлык зур **ярышларны ота** алганы юк иде әле”.

Безнең татарлар гомер – гомергә **картинаны (рәсемне) ясый** торганнар иде, хәзер инде, рус телендә **писать (написать) картину** әйтелмәсенә ияреп, татарча да **картинаны яза** башладылар: “Полотно Рембрандның XVII гасырда **язган** сериясенә керә икән”.

Шулай ук, “**вести активный образ жизни**” әйтелмәсенә ияреп, “**актив тормыш рәвеше алып бару**” дияп язалар. “**Актив яшәү**” генә дисәң, чын татарча булыр дип куркалар, күрәсең.

Русчадан, уйлап тормыйча гына калькалаштырып, табигатьне дә кыргыйлаштырып куйдылар: “**Бөтен дөнья кыргый табигать фонды**”.

Болайга китсә, “**дикие гуси**”ны **кыргый казлар** дип (дөресе – *кыр казлары*), **дикий лук**ны **кыргый суган** (*кыр суганы* яки *болын суганы* яки *җуа*) һ.б. дип атый башлаулары да ихтимал.

Татар теленең табигый кагыйдәләрен, нормаларын тупас бозып куллану күренешләре матбугатта, радио-телевидениедә һәм кайбер башка материалларда әйтелмәләрне тәшкил иткән сүзләрне бәйләүче грамматик чаралардан дөрес файдалана белмәүдә ачык чагылыш таба. Бу сүзтезмәләрнең компонентларын бәйләү чараларын кулланудагы ялгышлар телнең хосусиятен, үзенә генә хас (специфик) төзелешен, телне тел итеп саклый торган үзенчәлекләрен бозуга китерә.

Бүгенге журналистлар (барысы да түгелдер, әлбәттә) **шөгыльләнү** сүзенең җөмләдәге башка сүзләрне **белән** бәйлеге ярдәмендә ияртүен белмиләр:

“...йөртүчесез автомобильләр **эшләү буенча** шөгыльләнәләр” (дөресе – “...автомобильләр **эшләү белән** шөгыльләнәләр”).

Газетадагы бер мәкаләнең исеме – “**Пәнҗешәмбе очрашалар**”. Моны “*Пәнҗешәмбедә* яки *пәнҗешәмбе көнне очрашалар*” дип аңларга кирәктер инде, шәт.

Шулай ук бер хәбәрнең исеме – “**Мостай ага эшен дәвам итте**”. Бу язуга караганда, моны “**Мостай ага үзенең эшен дәвам иттергән”** дип аңларга була. Чынлыкта исә сүз Мостай Кәрим улы Илгиз Кәримовның әтисенең эшен дәвам иттергәнлеге турында бара. Гаеп журналистта: “**Мостай аганың эшен дәвам иттерде**” дип язарга кирәк иде.

Тел ул – катлаулы, нәзәкатле, шул ук вакытта нәзберек нәрсә. Андагы һәр мөстәкыйль сүзнең һәм хәтта бер-ике аваздан гына торган ярдәмлек сүзнең дә кайда һәм ничек кулланылырга тиешле урыны, кулланылу тәртибе бар. Шунлыктан телебезнең һәр сүзен, һәр авазын яхшы белеп, урынлы куллану таләп ителә. Һәм шуңа күрә рус телендә тәгъбир ителгән мәгънәне, фикерне үзебезнең тел чаралары белән белдергәндә бик сак эш итәргә кирәк. Оригиналның һәр сүзен, һәр грамматик формасын тәрҗемә телендә дә чагылдырырга кирәк дип, туган телнең табигый төзелешенә, үзенә генә хас үзенчәлегенә зыян китерергә ярамый. Тәрҗемә эшенең бу таләбеннән хәбәрдар булмаган кайбер журналистлар, менә шулай эшләп, татар телен бозалар, оригинал формасын икенче телгә бик төгәл күчерәбез дип, ул телнең, ягъни тәрҗемә теленең табигыйлыгына зыян китерәләр, бу тел өчен килешсез, сәер сүзләр ясап кулланалар.

“Славян язуының аталары буларак **хөрмәтләнгән** агай-эне “(Кирилл һәм Мефодий – *Р.Ю.*). Татар телендә **хөрмәтле, хөрмәтләү** сүзләре бар, ләкин **хөрмәтләнгән (уважаемый**ны калькалаштырганнар булса кирәк) дигән сүз юк, **хөрмәтле** яки **хөрмәткә лаек** дип әйтергә кирәк иде.

Телебезне тупас бозып куллану күренешләре күп төрле һәм күп санлы. Милләттәшләребез һәм Татарстан җитәкчеләре алдында торган иң әһәмиятле бурычларның берсе – милли горурлыгыбызны уятып һәм куәтләп, барлык тиешле чараларны күреп, туган телебезне бозмыйча, дөрес, матур итеп куллану, шулай итеп, аны сафлыгын саклап, камилләштерә, баета бару.

## ТӨГӘЛСЕЗЛЕКЛӘР КҮҢЕЛНЕ ҺАМАН ДА БОРЧЫЙ

1964 нче елның 23 маенда "Социалистик Татарстан" газетасы "Төгәлсезлекләр күңелне борчый" дигән мәкаләмне бастырып чыгарган иде. Шушы көннәрдә минем тормышымдагы бу кечкенә генә вакыйгага нәкъ 55 ел булды. Үзенә күрә бер юбилей кебек нәрсә. Ул язмада республикада чыгып килгән газеталарда телебезне кулланудагы ялгышлар бәян ителгән иде. Ярты гасырдан артык вакыт узганнан соң, бу уңайдан газеталарыбызның хәле ничегрәк икән соң, күңелне борчырлык күренешләр беткәнме, әллә һаман да дәвам итәме икән? Турысын әйтик: бүгенге мәгълүмат чараларында – матбугатта һәм радио-телевидениедә телебезне бозып куллану күренешләре бетмәгән түгел, киресенчә, тагын да арткан гына.

Туган телебездән файдаланудагы проблемалар, гомумиләштереп әйткәндә, авторларның, телне кулланудагы ялгышлары аркасында сөйләмнәрендәге (текстларындагы) мәгънә төгәлсезлекләренә һәм татар теле кагыйдәләре (нормалары) бозылуга кайтып кала. Мондый тискәре күренешләр каләм ияләренең эш коралларын тәшкил иткән телне җиренә җиткереп, бөтен үзенчәлекләре белән белмәүләре, вазыйфаларын үтәүгә тиешенчә җаваплы карамыйча һәм ашыгып эшләү нәтиҗәсендә барлыкка килә. Шуның өстенә, хәзер татар журналистларының, күп мәгълүматны рус телендә кабул итеп алып, аннан тәрҗемә итеп файдалануларын һәм тәрҗемә һөнәрен үзләштермәгән булулары аркасында, бу гамәлләрендә дә күп хаталар җибәрүләрен истә тотарга туры килә.

Бүгенге мәгълүмат чаралары телен анализлау шуны күрсәтә: журналистлар, язганда һәм сөйләгәндә, еш кына татар теленең үзенә генә хас (специфик) үзенчәлекләрен, сүзнең бары шушы телгә генә караган хасиятен тәшкил иткән мәгънә төсмерләрен сизмичә, туган тел күренешләреннән механик рәвештә файдаланып, сүзнең күп төрле мәгънәләре арасыннан тиешлесен эзләп тормыйча, аның, нигездә, төп мәгънәсенә генә таянып эш итәләр. Русчадан тәрҗемә иткәндә исә, алар шулай ук, тиешле мәгънәне, фикерне белдерү өчен, бөтен тексттан (сөйләмнән) аңлашылган мәгънәгә игътибар итмичә, рус теле чараларын татарчага турыдан-туры, сүзгә-сүз, хәрефкә-хәреф күчереп, ягъни калькалаштырып алалар. Нәтиҗә, әлбәттә, тискәре булып чыга: тиешле эчтәлек,

мәгънә дә төгәл белдерелми, туган телнең табигый әйтелеш һәм язылыш тәртибе, кагыйдәләре дә бозыла.

Бу фикерне раслардык мисаллар йөзләрчә генә түгел, меңнәрчә. Без монда газеталарның соңгы бер-ике айда чыккан саннарыннан алынганнарының кайберләрен генә күрсәтербез.

“*Каушап һәм туктап калырга хокукыбыз юк*”. Бу җөмләдәге **хокукыбыз** сүзе, беренче карашка дөрес кебек тоелса да, чын татарча түгел: телне яхшы белгән кеше “... **хакыбыз** юк” дип әйтер иде.

“*Хәләл – тормыш рәвеше ул”*. Саф татарча **тормыш рәвеше** дип әйтелми, **яшәү рәвеше** диелә.

“*Хәзерге укырга өйрәтү китаплары ... телнең фонетик-лексик үзенчәлекләрен никадәр искә ала?* Бу җөмлә авторы, **исәпкә алу** урынына **искә алу** сүзен кулланып, тупас хата җибәргән.

“*Көрәшче авыр тән җәрәхәтләре алган һәм больницада һәлак булган”*. Бу җөмләдә өч ялгыш бар. Беренчедән, автор **җәрәхәтләнү** сүзен урынсыз кулланган: **җәрәхәтләнү** – ул **яралану**, көрәшкәндә исә **имгәнү** хәлләре булып тора. Икенчедән, **һәлак булу** сүзе ялгыш кулланылган: һәлак булу – зур бәхетсезлек аркасында, фаҗигале хәлдә, көчләү юлы белән (мәсәлән, сугышта, юл һәлакәтендә) үлү, авырып (өйдәме, больницадамы) вафат булуны үлү диләр; Өченчедән, **җәрәхәт алу – получить травму**ның калькасы, аны бу очракта саф татарча **имгәнү** дип әйтү ятышлырак булыр иде. Димәк, әлеге җөмләне “*Көрәшче, нык имгәнеп, больницада үлгән”* рәвешендә төзү татарча дөресрәк булыр.

“*Төрмә Сан-Франциско шәһәреннән 2,5 чакрым ераклыктагы утрауда урнашкан, ике арада – бозлы су һәм ярсу агым”*. Мондагы **бозлы су** рус телендәге **ледяная вода** әйтелмәсендәге **ледяная** сүзенең мәгънәсен төгәл белдерә белмәү аркасында килеп чыккан: **бозлы** (боз белән катыш) **су**, мәсәлән, язгы ташуда була, ә бу җөмләдә сүз **боз кебек салкын** яки **бик салкын су** турында бара, һәм аны шулай язарга да кирәк иде.

“*Былтыр “Татнефть” 29,5 миллион тонна нефтьне җир өстенә чыгарган. Алдагы ел белән чагыштырганда, бу 594 мең тоннага күбрәк”*. **Алдагы ел** ул – **киләсе ел**, шулай булгач, **былтыргы** (узган) **елны** ничек итеп **киләсе ел** белән чагыштырырга мөмкин? Былтыргыдан элегрәк ел – татарча **өченче ел** (татар телендә кичәгедән элегрәк үткән көн дә **өченче көн** дип әйтелә). Димәк, җөмләне “*Элекке ел (яки өченче ел) белән чагыштырганда...”* дип төзергә кирәк иде.

Каләм ияләренең кайберләре тел белән эш итүгә шулкадәр җиңел карый, хәтта кайчак язган, сөйләгән сүзләренә укучы яки тыңлаучы гына түгел, үзләре дә төшенеп җитми булса кирәк. Менә бу җөмләләргә игътибар итик:

**Сорау, соралу** сүзләре белән төзелгән мәгънәсез, котсыз гыйбарәләр һәм җөмләләр күп кулланыла: *"Сорау булганда, тәкъдим итүче табыла" (*Дөресе – "**Ихтыяҗ** булганда...". *"Әмма анда төзекләндерү эшләре үткәрү сорала"* ("...төзекләндерү эшләре башкару **таләп ителә**, "...төзекләндерә эшләре башкарырга **кирәк**", "...төзекләндерергә кирәк" һәм башкача шулайрак булырга тиеш); *"Атна саен абзыйның зиратына барам – алар барамы, юкмы әле анда – зур сорау астында..."*. Бу җөмләдәге **зур сорау астында** тәгъбирен, русчага тәрҗемә итеп укымасаң (*под большим вопросом*), аңлау мөмкин түгел. Аның мәгънәсен, чын татарча итеп, "**анысы да (монысы да) әле бик шикле**" дигән гыйбарә белән белдерү зарур.

*"КФУ ректоры Илшат Гафуров яңа шартларда яңа татар телен укыту методикасын төзү мәсьәләсен күтәрде"*. Каян килгән соң ул **яңа татар теле** төшенчәсе, кем уйлап чыгарган икән аны? Сүз татар телен яңача укыту методикасы кирәклеге турында барадыр. Шулай икән, аны, кешечә, аңлаешлы итеп язарга кирәктер һәм мөмкиндер, ләбаса.

Телдән төп эш коралы буларак файдаланган кеше һәр тел сүзләренең дә, нигездә, күп мәгънәле икәнлеген һәм шуның өстенә аларның мәгънә төсмерләренә дә ия булуын белергә тиеш. Шул ук вакытта аның бер үк мәгънәнең, урынына карап, төрле сүзләр (синонимнар) белән белдерелүеннән хәбәрдар булып эш итү зарур. Безнең каләм ияләренә күп очракта шулай эшләү җитми. Сүзлек байлыгы тулы файдаланылмый, сүзнең синонимнары тиешенчә кулланылмый. Нәтиҗәдә мәгънә төсмерләре, аның бизәкләре бирелеп җитми, тел ясалма рәвештә фәкыйрьләндерелә. Мәсәлән, русчадан **призвать** сүзен һәр очракта да **чакыру** дип тәрҗемә итәләр. Ә аның мәгънәләрен татарча **өндәү, тәкъдим итү, кушу, кирәк, үтенү** кебек сүзләр белән дә тәгъбир итәргә мөмкин. *"А.Песошин объектларны төзүгә җаваплы затларны эшне кызулатырга чакырды"* җөмләсендә **чакырды** дөрес кулланылмаган, "...җаваплы кешеләргә эшне кызулатырга **кушты**" яки "...кызулатырга **кирәк, диде**" татарча ятышлырак булыр иде. Бу фразадагы **хәерче** сүзен куллану да үзен һич кенә дә акламый: *"Тагын бер хәерче дәүләт –*

*Камбоджаның премьер-министры...”.* **Хәерче** – бик ярлы, бик фәкыйрь кешегә карата кулланыла торган һәм күпмедер дәрәҗәдә кимсетү төсмере белән әйтелә торган сүз, шулай булгач, илгә, дәүләткә карата болай әйтү – әдәпсезлек. Сүзне әйткәнче, бераз гына булса да уйлап карарга һәм **хәерче**нең синонимы **ярлы** сүзе барлыгын да белергә кирәк бит.

Сүз куллануда гомумән уйлап эш итү җитми. Журналистларның кайберләре берәр яңа сүз уйлап чыгарса яки билгеле бер сүзне моңарчы билгеле булмаган мәгънәдә, гайре табигый итеп кулланса, башкалары шуны, уйлап та тормыйча, дәррәү күтәреп алалар, кирәксә-кирәкмәсә, адым саен шуннан файдаланалар. Соңгы вакытларда матбугат битләрендә тулып яткан **яңгырату, кыскарту, тере (акча, тавыш һ.б.) иң-иңнәр, җиткерү, текә** кебек дистәләрчә шаблон сүзләр татар публицистикасы телен һич кенә дә бизәми. Ә “**Юлдаш”, “Мәхәббәт”, “Гаилә”** кебек кечкенә форматлы хосусый газеталар телендә ясалма, кыланчык сүзләр шулкадәр күп, хәтта ул газеталарны аңлавы авыр. Аларны тел кулланудагы хулиганлык күренеше дип кенә санарга мөмкин.

“*Бу хакта ...Ирина Нижельская җиткерде*”. Нәрсәне җиткергән бу ханым? Ни өчен “*Бу хакта (яки моны) ... Ирина Нижельская* ***хәбәр итте (яки әйтте), сөйләде*** *һ.б. түгел?*

“*...ярышта текә исем өчен 63 әби көч сынашкан”.* Нинди була икән ул **текә исем**? Шулай ук нигә кирәк ул татар телендә киң таралган **текә егетләр, тере тавыш, тере акча** һәм башка шундый ходай кушмаган сүзләр, укучылар ничек аңлый икән аларны?! Нинди мөгез чыгарулар бу?!

Татар теле хәзер күбесенчә русчадан ялгыш тәрҗемә итү аркасында нык бозыла. Ялгышлык шуннан гыйбарәт: тәрҗемә белән шөгыльләнүче журналистлар тәрҗемә итүнең төп принцибын – оригиналда белдерелгән эчтәлек, мәгънә, фикер тәрҗемә теле чаралары белән бу телне бозмыйча күчерелергә тиеш дигән принципны саклап эш итмиләр, татар телендә рус сүзенә тәңгәллекне һәрвакытта да, аның контексттагы, сөйләмдәге мәгънәсенә карап түгел, бәлки беренче чиратта иң күп таралган, тәрҗемә сүзлекләрендә теркәлгән һәм төп мәгънәсенә карап билгелиләр. Нәтиҗәдә еш кына оригиналның мәгънәсе дә төгәл белдерелми һәм шуның өстенә тәрҗемә теленең табигый кулланылыш тәртибе, кагыйдәләре дә (нормалары да) бозыла.

Мәгълүмат чараларында  татар теле аеруча тәрҗемә иткәндә рус телендәге сүзләрнең үзара мәгънә ягыннан бәйләнеш үзенчәлеген татар теленә механик рәвештә күчереп кую нәтиҗәсендә бозыла. Моның механизмы шуннан гыйбарәт. Ике телдәге төп мәгънәләре буенча тәңгәл сүзләр сөйләмдә (текстта) үзара мәгънәви бәйләнешкә керү сәләтләре буенча бер очракта бер-берсенә туры киләләр, кайбер очракларда аермалы булалар. Мәсәлән, "*Предупредить ребенка об опасности*" һәм "*Баланы куркыныч турында кисәтү*" җөмләләрендә **предупредить ребенка** һәм **баланы кисәтү** тәңгәллекләре ике телдә дә бертөрле табигый бәйләнешкә керәләр. "*Предупредить болезнь*" әйтелмәсендәге сүзләр үзара табигый бәйләнешкә керсә дә, татарча – "*авыруны кисәтү*" дип әйтү татарча табигый булмый, дөресе – **авыруны булдырмый калу (булдырмау)** яки **авырудан саклану.**

Төрле системалы рус һәм татар телләре арасындагы менә шушы гомумилекне һәм аермалы үзенчәлекне тәрҗемә иткәндә исәпкә алмау аркасында туган телнең грамматик (сүзләр бәйләнеше) кагыйдәләре (нормалары) нык бозыла. Моңа мисалларны бик күп китерергә була. Без берничәсен генә күрсәтү белән чикләнербез.

"*Без алга таба да әлеге юнәлештә хәрәкәт итәчәкбез"* (дөресе – "... шушы юнәлештә **барачакбыз**"); "*Ә бит күпчелек очракта бу афәтне кисәтеп булыр иде*" ("... бу афәттән **котылырга булыр** иде"); "*Инсультны кисәтеп була" (*"Инсульттан **сакланып** була*"); "Узган атнада укучыларыбыздан әнә шундый шалтыратулар кабул итеп алдык" (*"...укучыларыбыз телефоннарыннан яки укучыларыбыздан телефоннан) шундый хәбәрләр алдык"). *"Республика җәмәгатьчелеге авыр югалтуга дучар булды" (*"... зур югалтуга дучар булды"); "*...Дәүләт Советы Рәисе вазыйфаларын биләгән куренекле дәүләт эшлеклесе..." ("*...Дәүләт Советы рәисе вазыйфаларын **башкарган** күренекле дәүләт эшлеклесе..."); "*Автобус ... элеккеге маршруты буенча хәрәкәтләнәчәк" (*"Автобус ... **йөриячәк**").

Телебездәге, бигрәк тә матбугат һәм радио-телевидение телендәге, проблемалар сөйләмдә (текстта) табигый рәвештә, бик күп очрый торган әйтелмәләрдәге сүзләрнең бәйләү чараларын еш кына ялгыш куллану аркасында барлыкка киләләр. Һәм монда да русчадан хәрефкә-хәреф тәрҗемә итү шактый дәрәҗәдә чагылыш таба. Бүгенге телдә аеруча киң таралган татар теле өчен табигый булмаган берничә әйтелмәне анализлыйк.

**Кызыксыну** сүзе белән ясалган гыйбарәләр.

*“Президент илчегә, республикага карата кызыксыну белдергәне өчен, рәхмәт сүзләрен җиткерде”.*

*“Журналист ... ярдәм күрсәтелүе-күрсәтелмәве турында да кызыксынды”.*

*“Телгә кызыксыну уяту өчен булса да килсен иде”.*

Бу җөмләләрдәге **республикага карата кызыксыну, күрсәтелмәве турында кызыксыну, телгә кызыксыну** сүзтезмәләре татарча табигый түгел: **кызыксыну** әйтелмәдәге икенче сүзне үзенә **белән** бәйлеге ярдәмендә ияртә: **республика белән кызыксыну, күрсәтелмәве белән кызыксыну, тел белән кызыксыну.**

“*Станок артына басып та бик мантый алмыйсың”* (дөресе – “**Станокка басып та**...”. Мин кечкенә вакытта “*Бас әле станокка*” дигән җыр бар иде. Ул вакытта татарча дөресрәк сөйләгәннәр: “*Бас әле станок артына*” дип җырламаганнар бит.

Телебезгә рус сүзтезмәләрендәге **за, под, над, на** предлогларын татарчага **арт, аст, өст** бәйлекләре һәм кайбер кушымчалар белән тәрҗемә итү аркасында килеп кергән гарип калькалар хәзер инде иркен кулланылалар. **Парта артында, өстәл артында (хәтта түгәрәк өстәл артында), пианино артында, компьютер артында утыру, руль артында утыру; Мәскәү астындагы сугышлар; китап өстендә эшләү, үз өстен(н)дә эшләү; гармунда уйнау, скрипкада уйнау** кебек тәгъбирләр куллану гадәти күренешкә әверелеп бара. Уйлап карасаң, бу күренеш (бу гына түгел, әлбәттә) татар теленең табигый төзелешен җимерүгә китерә бит. Чын татарча – **партада утыру, өстәл янында, пианино алдында утыру, Мәскәү янындагы (тирәсендәге) сугышлар, китап язу, белемеңне (осталыгыңны) күтәрү (камилләштерү), гармун уйнау, скрипка уйнау** һ.б.

17 май көнне республиканың баш газетасында бер фәннәр докторы белән интервью басылып чыкты. Анда журналист “Хезерге татар **язучыларның** теленә нинди бәя бирергә була?” дип сорый. Ни өчен “Татар **язучыларының** теленә” түгел? Шул ук интервьюда галимнең җавабында “Шигърият җырның нигез булып тора” дигән җөмлә укыйбыз. “Җырның нигез”? Монда хәреф хатасыдыр гына дип уйларга була, әлбәттә. Ләкин мондый үкенечле хаталар күп җыела. Мәктәп укучыларына мондый сочинение өчен яхшы билге куймаслар иде.

Әле күрсәткән мисалдагы ялгышны механик хата дип уйлый алсак та, соңгы елларда дистәләгән газеталардагы йөзләгән

язмаларда кулланылып килгән **эшче һөнәрләр** гыйбарәсендәге бер хәрефтән генә торган, ләкин бик тупас ялгышны очраклы рәвештә генә төшеп калган хәреф хатасы дип санап булмый. Бу рус телендәге **рабочие профессии** атамасын тәрҗемә итә белмәү галәмәте. Дөресе – **эшче һөнәрләре.**

Бер халык шагыйренең җитди газетада басылган "Мөһерле җөмләләре"ннән бу җөмләдә беренче карашка хата юк та кебек, ләкин беренче карашка гына: *"Анда (китапханәдә – Р.Ю.) татар әдәбияты рус һәм башка телләрдә дә тәкъдим ителүе кирәк".* Сүз татар әдәбиятының тәкъдим ителүе турында барадыр. Әмма җөмләнең төзелеше ягыннан хилафлык бар: тартым кушымчасы белән килгән *тәкъдим ителүе* фигыле үзе ияркән *татар әдәбияты* сүзенең иялек килешендә килүен таләп итә, димәк, **татар әдәбиятының тәкъдим ителүе** булырга тиеш иде.

Газеталардагы (аларда гына түгел) күңелне борчырлык тел ялгышларының берсе – **рус телле мәктәп, рус телле әдәбият, рус телле укучылар** рәвешендәге әйтелмәләрнең актив кулланылуы. Болар да рус телендәге **рускоязычный** сүзен хәрефкә-хәреф тәрҗемә итү нәтиҗәсендә барлыкка килгән гыйбарәләр, һәм алар да татар теленең грамматик төзелешен бозып төзелгән сүзтезмәләрне тәшкил итәләр. Саф татарча **рус телле** яки башка теләсә кайсы телле дип әйтеп булмый: ачыклаулы мөнәсәбәттәге әйтелмәләрдә **тел** үзен ияртеп килгән сүз белән тартым кушымчасы ярдәмендә бәйләнә (рус теле, татар теле). Ә әлеге рус сүзе өлгесендә ялгыш ясалган гыйбарәләрне татарча дөрес итеп әйтү мөмкинлекләре җитәрлек: **рус мәктәбе яки рус телендә укыта торган мәктәп, рус телендәге әдәбият, рус телендә укучылар** һ.б.

Грамматикада фигыльләр дип йөртелә торган сүзләр кулланылышындагы проблемалар турында да әйтеп китик.

Фигыльләрне күп очракта дөрес куллана белмәү зур тарихлы һәм җитди тел ялгышларының берсе. Хикмәт шунда: татар теленең фигыль формалары мул, һәм алардан дөрес файдалана белсәң, бу тел иясенә фикерен тулы, камил рәвештә тәгъбир итәргә мөмкинлек бирә. Әмма мәгълүмат чараларын әзерләүчеләр, гадәттә, күп төрле фигыль формаларын белеп бетермәү һәм, нигездә, ашыгып эшләү аркасында фигыль сүзләр байлыгыннан тулы файдаланмыйлар, еш кына аларны ялгыш кулланалар. Нәтиҗәдә телнең морфологик төзелеше бозыла, тел фәкыйрьләндерелә.

Фигыльләрнең матбугатта һәм радио-телевидениедә күп очракта ялгыш кулланыла торган үткән заман хикәя фигыльләре һәм сыйфат фигыльләр дип аталганнары хакында бәян итү зарур.

Мәгълүмат чараларында үткән заман хикәя фигыльләренең **эшләдем, эшләгән, эшләгән иде (була, булган), эшли торган иде (була, булган) эшләгәнем(ң,е) бар** формаларыннан күбесенчә **бардым** (билгеле үткән заман фигыле дип атала) формасы гына кулланыла. Күрәсең, каләм ияләре ул формаларның төрле мәгънә төсмерләре белдерүе һәм алардан урынлы файдалана белергә кирәклек турында уйланып тормыйлар.

Гадәттә тупас хаталар **-ган-гән(-кан-кән)** кушымчалы билгесез үткән заман формасы урынында ялгыш **-ды-де(-ты-те)** кушымчалы билгеле (категорик) үткән заман формасын куллануга карый. Билгеле үткән заман хикәя фигыльләренең төп мәгънәсе – язучы (сөйләүче) үзе күргән эш-хәлне (процессны) белдерү. Мәсәлән, мин үзем күргән очракта яуган яңгыр турында кемгәдер хәбәр иткәндә **яңгыр яуды** дип әйтәм. Әгәр дә мин, берәр бәла-каза турында, үзем күрмичә, кемнәндер ишетеп яки мәгълүмат чараларыннан укып, карап хәбәр итсәм, **фәлән җирдә авария булган** дим. Үзем күрмәгән процесс турында фәлән нәрсә булды дип сөйләсәм, язсам, бу татарча дөрес булмас иде. Ләкин, әйтелгәнчә, мәгълүмат чараларында моны исәпкә алып тормыйлар, һәркайда һәм һәрчак диярлек, моннан меңәр ел элек булган хәлләрне сурәтләгәндә дә, Америка астронавтларының айда йөреп кайтулары турында язганда һәм сөйләгәндә дә **-ды-де (-ты-те)** формалы фигыльләр генә кулланалар.

Сыйфат фигыльләрне куллану өлкәсендә төп проблема авторларның, бу сүз төркеменең хәзерге һәм үткән заман формаларының мәгънә аермаларын белмичә яки моңа игътибар итеп тормыйча, **-ган-гән (-кан-кән)** кушымчалы үткән заман сыйфат фигыльләре урынына да **-учы-үче** кушымчалы хәзерге заман сыйфат фигыльләреннән файдалануларында. Бу исә телебезнең табигый нормаларын җитди бозуга китерә. Берничә мисал:

“*Олуг Мөхәммәд – Казан ханлыгына нигез **салучы** изге зат*” (дөресе – “... нигез **салган** изге зат”.

“*төрле тармакларда хезмәт **куючы** олуг шәхесләр арабыздан китеп барды*” (“.... хезмәт **куйган** (иткән) олы шәхесләр...”).

“*Беренче турдан узучылар редакциягә әңгәмәгә чакырыла*”(ни өчен **узучылар**, алар узганнар бит инде, “*...**узганнар** чакырыла*” булырга тиеш).

Үткән заман сыйфат фигыль формасының тагын бер әһәмиятле вазифасын белү мөһим. Бу аның предметның билгесен даими булып тора торган процесс аша белдерү: "*Чылтырап **аккан** чишмәгә суга дип барган идем" ("Фазыл чишмәсе"* җырыннан*); "Арча районына **кергән** авыллар буйлап йөрибез").* Әмма мәгълүмат чараларында кайчак үткән заман сыйфат фигыльләренең бу вазифасы да исәпкә алынмый.

Телне бөтен үзенчәлекләре, нечкәлекләре һәм "серләре" белән белгәндә генә, аның зур мөмкинлекләреннән, байлыгыннан тулы файдаланырга һәм аларны укучыга (тыңлаучыга) ирештереп була. Ләкин хәзерге журналистлар болай эшли аламы икән? Шикләнергә урын бар. Мәсәлән, менә бу җөмләгә игътибар итик: "*Фазыл мулла ул җимешләрне авыручыларга бушлай бирә торган булган, чөнки ул заманда әле аптекалар юк"*. "Ул заманда **аптекалар юк**" дип әйтү чын татарча түгел, "...**аптекалар булмаган**" диярге кирәк. Татар теле кагыйдәләре буенча үткәндә булган процесс турында хәбәр иткәндә **бар, юк** сүзләре кулланылмый, бәлки **булган, булмаган** дип әйтелә.

Телебезнең фигыльләр өлкәсенә караган тагын бер кызыклы үзенчәлеге шуннан гыйбарәт: үткәндә булган процесста, үзең катнашып та, аны сизми калган, процесс үзеңнең ихтыярыңнан тыш башкарылган очрак турында бәян иткәндә, *фәлән нәрсә эшләдем* формасында түгел, *фәлән нәрсә эшләгәнмен* дип әйтелә, ягъни төп кагыйдә буенча **-ды-де (-ты-те)** кушымчалы билгеле үткән заман фигыле урынында **-ган-гән** (**-кан-кән**) кушымчалы билгесез үткән заман фигыле куланыла. Мәсәлән, йоклар алдыннан, будильник куеп, иртән аның шалтыраганын ишетмичә йоклап калганмын икән, соңыннан бу турыда кемгә дә булса хәбәр иткәндә, "*будильник шалтыраганын **ишетмәдем***" димим, ә **ишетмәгәнмен** дим. Әмма республика газеталарының берсендә эшләүче журналист телебезнең бу үзенчәлеген белми икән, югыйсә ул "*Утырттым да **оныттым**"* дип язмас, бәлки "*Утырттым да **онытканмын**"* дигән булыр иде.

Сүзләрнең сөйләмдә (текстта) тиешле мәгънәне белдерү өчен хезмәт итә торган кушымчаларын дөрес кулланмау телнең табигый төзелешен генә түгел, автор әйтергә теләгән фикерне дә бозарга, аны укучының ялгыш аңлавына да китерергә мөмкин.

Илгиз Кәримовның үзенең әтисе Мостай Кәрим эшен дәвам иттерүе турында басылган кечкенә генә хәбәрнең исеме "*Мостай*

*ага эшен дәвам итте”* дип атала. Һәм бу фразадан Мостай Кәрим үзенең эшен дәвам иткән дип аңларга мөмкин. Ялгыш аңлашу булмасын өчен, җөмләне *“Мостай **аганың** эшен дәвам **иттерә**”* рәвешендә төзергә кирәк.

Фигыльләрне кулланудагы тагын бер күп таралган ялгыш – **дәвам иттерү** урынында **дәвам итте** формасын куллану. Чын татарча – *“Мин эшне дәвам иттерәм”, “Син дәвам иттерәсең”, “Ул дәвам иттерә”, “Тормыш дәвам итә”*. Практикада бу кагыйдә дә сакланмый.

Татар теле фигыльләренең бер әһәмиятле үзенчәлеге шунда: сөйләмдә аларның аналитик төрләре актив кулланыла. Әмма матбугат телендә фигыль сүзләрнең телне бизи торган бу хасиятеннән дә тиешенчә файдаланмыйлар. *“Профсоюз өлкә комитеты район комитеты җитәкчелеген Казанга ... даими рәвештә чакырды”*. Бу җөмләдә **чакырды** фигыле дөрес кулланылмаган: даими рәвештә, димәк, күп мәртәбәләр чакырганда, фигыль **чакырып торды** рәвешендә – аналитик формада булырга тиеш. Телебезнең мондый үзенчәлекләрен белеп, аларны үзеңнең язу һәм сөйләвеңдә куллану өчен, әдәби телне яхшы белергә һәм тел гыйлеменә караган фәнни әдәбияттан, уку дәреслекләреннән дә хәбәрдар булу зарур.

Төп эш коралы тел булган кешедән бу коралын бик яхшы белү таләбе сүзләрнең стилистик кулланылышы дигән нәзәкатьле мәгълүматка ия булуны да күздә тота. Безнең журналистларыбызга бу мәсьәләгә дә игътибар итәргә кирәк. Фикеребезне конкрет мисал белән ачыклыйк. Безнең телдә уртак мәгънәле **ата-ана** һәм **әти-әни** сүзләре бар. Каләм әһелләре, гадәттә аларны бер үк сүзнең төрле вариантлары гына дип белеп, кайсысы кайда кулланылырга тиеш икәнлеген уйлап тормыйлар. Хәлбуки, алар стилистик кулланылышлары буенча нәкъ бер үк төрле түгел. Үзеңнең *әтиең һәм әниең* һәм *икенче затның әти-әнисе* турында саф татарча сөйләгәндә, гадәттә, **әти-әнием** һәм **әти-әниең** дип әйтәләр, өченче затның *әтисе* һәм *әнисе* һәм гомумән *аталар һәм анала*р турында сөйләгәндә, **ата-аналар** диләр. Телнең бу үзенчәлеген матбугат язмаларында да исәпкә алсалар ярар иде. Мәсәлән, *“Моны әти-әниләр, мәктәп, район-шәһәр җитәкчеләренә бергәләп хәл итәргә туры киләчәк”* дигән җөмләдәге *әти-әниләр*не **ата-аналар** дип әйтү татарча дөресрәк булыр иде.

Нурсолтан Назарбаевның үз теләге белән президентлыктан китүе турындагы хәбәрне безнең бер газета *“Карт арысланның*

*китүе”* дигән исем белән бастырды. Каһарман ир-егетләрне сугыштагы батырлыклары турында сөйләгәндә, аларны зурлап, күчерелмә мәгънәдә *арысланнар кебек көрәштеләр* дип әйтү бар. Ләкин тыныч тормышта яшәгән өлкән яшьтәге кешегә карата *карт арыслан* дип әйтү килешәме икән? Минемчә, бу очракта хөрмәтле олы кешене *карт арыслан* белән чагыштыру урынлы түгел.

Каләм ияләре өчен һәр сүзнең кулланылышына җаваплылык хисе тоеп, халыкча әйткәндә, һәр сүзеңне үлчәп сөйләү мөһим. Әмма кайбер авторларда телгә мондый җаваплы караш җитми. Мәсәлән, “*Көмеш туйга **бәһасез** бүләк”* дип язган журналист *бәһасез* сүзенең мәгънәсенә төшендеме икән, укучы моны ничек аңлар дип уйладымы икән?! Юктыр, мөгаен. Югыйсә, ул алай язмас иде. **Бәһасез** ул бәһасе юк, димәк, бер тиенгә дә тормаслык, бик начар дигән сүз бит, көмеш туй ияләренә андый бүләк бирмәсләр бит инде. Бу авторның мондый сәер фразасындагы **бәһасез** сүзе – русның **бесценный** сүзен, мәгънәсен аңламыйча, хәрефкә-хәреф тәрҗемә итеп куллану галәмәте. **Бесценный** ул – бик кыйммәтле, бәя биреп бетергесез дигән сүз.

Телнең дөреслеген, табигыйлыгын саклау, мәгънәне төгәл белдерү өчен сөйләмдә сүзләрнең тиешле тәртиптә урнаштырылуы да мөһим. Безнең мәгълүмат чараларында бу таләп гамәлгә ашырылып җитми. Сүзләрне тиешле урыннарына куймау сөйләмне (текстны) дөрес аңларга комачаулый, аның табигый агымына, яңгырашына зыян китерә, телгә буталчыклык кертә. Бер-ике мисал:

*“Гринпис” табигатьне саклау оешмасы...”.* Дөресе – *“Табигатьне саклау оешмасы “Гринпис”...”.* Болай оешманың шартлы исемен аның аңлатмалы исеменнән алда кую күренеше – киң таралган хата.

*“Шура” битләрендә **галим тарихчы**... мәкаләләр бастыра”.* Табигый сүз тәртибе буенча, **тарихчы галим** булырга тиеш.

Мәгълүмат чаралары теленең кулланылышындагы төгәлсезлекләр, ялгышлар күп төрле һәм күп санлы. Аларны бер мәкалә кысаларында гына сөйләп бетерү мөмкин түгел. Сүзебезне йомгаклап, шуларны игълан итү мәгъкуль булыр:

Соңгы ярты гасырдан артык вакытта матбугатта, шулай ук радио-телевидение тапшыруларында күңелне борчырлык төгәлсезлекләр, татар телен бозу күренешләре кимемәгән, арткан гына. Моның сәбәпләре берничә: мәктәпләрдә укучыларга, журна-

лист буласы студентларга татар теле тиешле дәрәҗәдә өйрәтелми, мәгълүмат чараларын әзерләүчеләр телләрен камилләштерү белән шөгыльләнмиләр, аларга тиешле органнардан һәм җитәкчеләрдән язмалары һәм тапшыруларының теле дөрес, үтемле булсын дигән таләп куелмый. Мәгълүмат чараларының, бигрәк тә тәрҗемә итеп әзерләнгән хәбәрләрнең, иҗтимагый-сәяси эчтәлекле материалларның теле елдан-ел, көннән-көн, җанлы, табигый халәтен ныграк югалтып, үзенә күрә бертөрле рәсми, коры, каль-калаштырылган корама, “казенный” телгә әверелә бара.

Халыкның рухи тормышындагы бик мөһим нәрсә – матбугат һәм радио-телевидение үзенең абруйлыгын теле югары сыйфатлы булганда гына саклый алачак.

## ТУГАН ТЕЛ САФЛЫГЫ

Газетада тиздән Татарстан журналистлар союзының съезды булачагы турында хәбәр урнаштырылды. Шул уңайдан мин татарча мәгълүмат чаралары, ягъни газета-журналлар һәм радио-телевидение теленең һәм шуңа бәйле рәвештә гомумән телебезнең хәзерге хәле хакындагы кайбер фикерләремне укучылар хөкеменә тәкъдим итәргә булдым.

Башта ук кисәтеп куям: журналистлар үпкәләмәсен, минем бу язма гомумән алганда тәнкыйть рухы белән сугарылган. Чөнки хәзер телебезне куллануда тискәре күренешләр күп, һәм алар көннән-көн арта бара. Хәер, газета-журналлардагы мәкаләләрнең, радио-телевидение тапшыруларының барысының да теле канәгатьләнерлек түгел икән дигән фикер тумасын. Дөрес итеп, матур телдә язган һәм сөйләгән журналистлар да бар. Ләкин алар аз, хәтта бик аз. Хәлбуки, яхшылары күп, начарлары аз гына булырга тиеш. Гомумән алданда исә мәсьәләгә объектив караучылар килешер, телебезнең бүгенге торышы, киләчәге уңаеннан чаң сугарга күптән вакыт җитте: мәсьәлә бик җитди.

Чаң сугарлык тискәре күренешләрниләрдән гыйбарәт соң?

Бу сорауга бик кыска гына җавап шул: телебез инде дистәләрчә еллар бозып кулланыла. Күп кешеләр сөйләшкәндә дә, рәсми урыннарда чыгыш ясаганда да, газета-журналларга язганда һәм радио-телевидение тапшыруларында сөйләгәндә дә татар телен ваталар-җимерәләр, тиешле мәгънәне төгәл белдереп, һәр сүзне, тәгъбирне

дөрес, матур итеп, табигый әйтелешен, яңгырашын халык тарафыннан меңнәрчә еллар буена барлыкка китерелгән кагыйдәләрен, тәртибен саклап куллана белмиләр. Сүз телне кулланудагы вак-төяк ялгышлар турында гына бармый, хәзер телне бозулар шул дәрәҗәгә җитә: аның табигый төзелеше, телне тел итеп саклаган лексик-фразеологик, грамматик, фонетик үзенчәлекләре, калыплары какшатыла, таркатыла.

Сөйләгәннәребез буш сүз булып кына калмасын өчен, соңгы вакытларда мәгълүмат чараларындагы меңләгән тел ялгышларының аеруча күп таралганнарын, бигрәк тә гыйбрәтлеләрен генә күрсәтеп, телебезне көннән-көн басып ала барган мондый галәмәтләрнең барлыкка килүенең сәбәпләрен әйтеп, алардан арыну, андый күренешләрне моннан ары булдырмас өчен ниләр эшләргә кирәк икәнлеге хакында әңгәмә корырбыз.

Телебездәге ялгышларның бик күбесе каләм ияләренең, үзләре кулланган сүз һәм әйтелмәләрнең күп төрле мәгънәләргә һәм мәгънә төсмерләренә ия булуларын уйлап тормыйча һәм аларны белеп бетермичә, җиңел генә, өстән-өстән генә эш итүләре аркасында килеп чыга. Мондый хаталар күбесенчә русчадан ялгыш тәрҗемә итү белән дә бәйләнгән була. Кайбер мисаллар.

“Туганнарыбызның ике тутый кошы бар. Кеша белән Геша: **берсе – ир, икенчесе – хатын**” Бу мисал республика газеталарының берсеннән алынды (гомумән бу мәкаләдәге мисалларның күбесе матбугат һәм радио-телеведение материалларыннан). Бу бит шаккаттыргыч хәл: татар журналисты төрле җенестәге кошларны **ир** белән **хатын** дип түгел, **ата** һәм **ана** дип аерып атарга кирәклеген белмәсен (дөресе – “...Кеша белән Геша: берсе – **ата,** икенчесе – **ана**”).

“Диңгездә **кемнәр** яши? – Балыклар!” (телевидение тапшыруыннан). Татарча балык **кем** булмый, **нәрсә** була.

“Кәҗәләргә йоклау өчен аерым **киштә** булдыру зарур”. Безнең кайбер журналистларыбыз кәҗәләрне менә шулай киштәдә йоклата башлаганнар инде!

“Халыкара **сораулар** буенча ректор киңәшчесе”. Бу җөмләнең авторы рус телендәге **вопрос** сүзенең **сорау** гына түгел, бәлки **мәсьәлә** дә икәнлеген белмәгән (дөресе – “Халыкара мәсьәләләр буенча ректор киңәшчесе”).

“...гәүдәң дә **калынайды**, ди”. Гәүдә **калын** булмый, **юан** була! Ялпак нәрсәләргә карата гына **калын** һәм **юка** дип әйтәләр.

“Аның әнисе – **рус**, әтисе – латыш”. Чын татарча – хатын-кыз рус дип әйтелми**, рус хатыны, рус кызы** (яки **маржа**) диләр.

“Президент иртәгә Мәскәүгә **оча**” Бу җөмләдәге **оча –** русчадагы **лететь** (летит, полетит һ.б.) сүзенең калькасы. Татарча кешеләргә карата **очу** сүзе кулланылмый: **бара, кайта, китә** һ.б. сүзләр тиешле транспорт чарасы исеме белән бергә әйтелә: **самолет белән бару, самолетка утырып кайту** һ.б. (“Президент иртәгә (самолет белән) Мәскәүгә бара (китә”).

Хәзер мәгълүмат чаралары телендә аңлашылмый торган, татар теле өчен ят, гайре табигый сүзләр шактый күп очрый. Бу күренешнең сәбәбе каләм ияләренең, беренчедән, тәрҗемә ысулларын белмичә, оригиналның һәр сүзен тәрҗемә телендә аерым сүз белән белдерергә тырышуында, икенчедән, яңа сүзләр уйлап табу белән мавыгып, туган телдәге табигый сүз ясалышы кагыйдәләрен тупас бозуларында. Берничә мисал.

Матбугат телендә шактый күп кулланыла торган **агымдагы (ел** белән бергә килгәндәге) сүзе **текущий (год, ремонт** һ.б.) сүзенә ияреп ясалган (тамыры – *течь- агу*), һәм мәгънәсез лексик берәмлек килеп чыккан: *агымдагы? (су агымындагы*?). Аны күбрәк *текущий год*ның хәрефкә-хәреф (букваль) тәрҗемәсе буларак кулланалар. Баксаң, аның татар теле өчен бөтенләй кирәге дә юк! *Текущий год* ул – *быел* һәм *бу ел.*

Республикабызның иң мәртәбәле дип саналып йөргән газетасыннан бер мисал:

“Суфия апа ***икетуган*** Халидә Сафина белән Казанда очрашкан”. Кем ул ***икетуган***? Ике туган кеше була аламы? Ул атама аны рус телендәге *двоюродный (двоюродная*) сүзеннән калькалаштырып ясалган, әлбәттә, әмма татар телендә мондый сүз юк.

Кайбер журналист-тәрҗемәчеләр рус телендә аерым бер сүз белән белдерелгән мәгънәне татарча, телне бозмыйча, тасвирлау (берничә сүз белән) белдерергә мөмкин булса да, телне җимереп, яңа бер сүз ясап маташалар. Нәтиҗәдә оригинал сүзенең мәгънәсе дөрес тәгъбир ителми, аңлашылмый да, тәрҗемәченең уңышсыз иҗат җимеше – яңа сүз дә чын татар сүзе булып чыкмый. Шундый сүзләрнең тагын берсе – ***правнук (правнучка***) сүзеннән ясалган ***оныкчык.*** Бу татар теле өчен табигый сүз түгел: безнең телдә, зат исемнәренә -*чык-чек* кушымчасы ялгап, кечерәйтелгән мәгънәдәге яңа сүз ясау тәртибе юк (*онык+чык*). Аннан килеп, татар кешесе аны аңламый да: кем ул *правнукмы? правнучкамы*? Формасы һәм

яңгырашы да татарча түгел. Ә бит *правнукны оныкның улы, правнучканы оныкның кызы* дип әйтеп була. *Оныкул* үзе дә русның *внуг*ыннан аз гына үзгәртеп ясалган, һәм аны да улының (кызының) улы яки кызы дип әйтү чын татарча булыр иде.

Мәгълүмат чараларында очрый торган *кызчык* та саф татарча сүз түгел, ул *девочкага (девчонкага*) ияреп ясалган, чын татарчасы – *кечкенә кыз, нәни кыз* яки *кыз* гына.

“Бу хакта ... матбугат үзәгенә **сылтама** белән “Риа Новости” хәбәр итә” дип яза безнең республика газеталарының берсе. Бу җөмләдге ***сылтама*** – русчадагы ***ссылка*** сүзенең ялгыш тәрҗемәсе: татар телендә гомумән мондый исем сүз төркеме юк. Аның мәгънәсен татарча *таяну* сүзе бирә: “Бу хакта ... матбугат үзәгенә *таянып,* “Риа Новости” агентлыгы хәбәр итә” кирәк.

Соңгы вакытларда журналистларның бер “новатор”лыгы **-иң-иң (иң-иңнәр)** сүзе. **Иң яхшы, иң тырыш** кебек сүзләр урынына алар еш кына шушы неологизмны кулланалар. “Бу затлы бүләк **-иң-иңнәргә** бирелергә тиеш” (дөресе – ... **иң лаеклыларга** бирелергә тиеш).

Телебезнең морфология формаларын дөрес кулланмау күренешләре дә күп. Андыйларның киң таралган һәм мәгънәне бозуга, телнең табигый байлыгына зыян китерә торганнарыннан – фигыль формаларын ялгыш куллану. Ялгышлар бигрәк тә үткән заман хикәя фигыльләрне, сыйфат фигыльләрне һәм аналитик формалы фигыль сүзләрен куллана белмәүгә карый.

Язмабызның күләме чикләнгән булу сәбәпле, бүгенге көндә газета-журналларда, радио-телевидение тапшыруларында тулып яткан йөзләрчә, меңнәрчә тел ялгышларын күрсәтеп бетерү мөмкин түгел, әлбәттә. Алар турында мәкалә авторының “Матбугат һәм эфир теле”, “Тәрҗемә мәсьәләләре”, “Вопросы теории и практики перевода” дигән һәм башка дистәләрчә китапларында, шулай ук газеталарда басылган йөзләрчә мәкаләләрендә бик җентекләп язылган. Кызыксынган кешеләр табып укый ала.

Телебезне кулланудагы ялгышларның бик күбесе сүзләрнең үзара мәгънәле (мәгънәви) бәйләнешкә керү үзенчәлекләрен исәпкә алмау аркасында барлыкка килә. Ике тел бедән эш итүчеләр, гадәттә, сөйләмдә сүзнең башка һәртөрле сүз белән бергә килә (мәгънәләре буенча бәйләнешкә керә) алмаганлыгын белмиләр булса кирәк. Мәсәлән, **уңган** сүзе, **кеше** сүзе белән табигый бәйләнешкә кереп, мәгънәле әйтелмә тәшкил итә (**уңган кеше**). Шул ук вакытта ул

**уңган йорт** сүзе белән табигый бәйләнешкә керә алмый: **уңган йорт** дип әйтеп булмый.

Сүзләрнең үзара мәгънәви бәйләнешкә керә алу үзенчәлекләрен исәпкә алу бигрәк тә тәрҗемә процессы өчен әһәмиятле.

Үзара тәңгәл төрле тел сүзләренең сөйләмдә башка сүзләр белән семантик бәйләнешкә керүләренең төп үзенчәлеге шуннан гыйбарәт: ике телдәге тәңгәл сүзләр, үзара бәйләнешкә кереп, мәгънәле әйтелмә (җөмлә) тәшкил итә алу сәләте буенча бер очракта бердәй (бертөрле) булалар, икенче очракта төрле булалар. Мәсәлән, рус телендәге *рыба*, *плавать* сүзләре һәм аларның татар телендәге тәңгәллекләре *балык, йөзү* ике телдә дә, үзара мәгънәле бәйләнешкә кереп, табигый әйтелмә (җөмлә) тәшкил итәләр: *рыба плавает – балык йөзә.* Шул ук вакытта рус телендәге *лодка* һәм *плыть* (*плавать*) сүзләре, үзара бәйләнешкә кереп, мәгънәле берәмлек тәшкил итсә (*лодка плывет*), аларның татар телендәге тәңгәллекләре *көймә* һәм *йөзә*, үзара бәйләнешкә кереп, табигый сөйләм берәмлеге тәшкил итә алмый: татарча *көймә йөзә* дип әйтелми, *көймә килә, китә,бара* диелә.

Бүгенге татарча мәгълүмат чаралары телендәге күпчелек ялгышлар журналистларның менә шушы ике телдәге үзара тәңгәл сүзләрнең сөйләмдә башка сүзләр белән бәйләнешкә керә алу үзенчәлекләре буенча һәр очракта да бердәй булмавын исәпкә алып эш итмәүләре, төгәлрәк итеп әйткәндә, рус сүзләренең бәйләнешкә керү үзенчәлеген татар теленә механик рәвештә күчереп куюлары аркасында килеп чыга.

Сүзләрнең сөйләмдә үзара табигый мәгънә бәйләнешен бозып куллану хәрефкә-хәреф тәрҗемә итүгә, ягъни уйлап тормыйча гына, механик рәвештә эшләүгә нигезләнә. Бу рәвешле эшләүнең технологиясе болай.

Каләм иясе тәрҗемә иткәндә оригинал (рус) сүзенә тәңгәллекне аның сөйләмдә (текстта) гына ачыла торган мәгънәсен исәпкә алып түгел, бәлки иң күп кулланылган, ике тел сүзлекләрендә теркәлгән, башына беренче килгән мәгънәсенә карап кына билгели. Икенче төрле итеп әйткәндә, ул сүзләрнең барлык телләрдә дә күп мәгънәле икәнлеген, димәк, бер телдәге сүзгә икенче телдә һәрвактта да кулланылырлык әзер тәңгәллек булмавы белән исәпләшми. Нәтиҗәдә, безнең мәгълүмат чараларындагыча, татар сүзләре белән русча язу һәм сөйләү килеп чыга.

Соңгы берничә елда журналистларның шулай уйлап тормыйча гына эшләүләре нәтиҗәсендә мәгълүмат чараларында күп кенә сәер шаблон әйтелмәләр барлыкка килде. Мәсәдән: **тере тавыш, тере акча, тере тәгълимат, текә егет, тере гәүдәләнеш; сәламәт яшәү рәвеше алып  бару, актив тормыш алып бару, уку эшчәнлеге алып бару...; сыйфат үсү, чыгымнар үсү, җинаятьчелек үсү...; яңгыраган сораулар, яңгыраган җан ачысы, теләкне яңгырату, чынбарлыкны яңгырату...; үз өстемдә (өстендә, өстеңдә) эшләү, хаталар өстендә эшләү...; җылы (салкын) һава торышы саклану...; тирән мәхәббәт, тирән ихтирам, тирән канәгатьләнү...; бәхетне үз кулларың белән тудыру, документаль повесть тудыру...; тыйнак кульязма,  тыйнак өлеш, тыйнак йорт...; нечкәләп сөйләү, иреннәре нечкә; кыргый пляж, кыргый табигать, кыргый алма...; эре оешма, эре завод, эре ил...; "Башваткыч" тапшыруына 7 яшь, техникумга 75 яшь; тәнкыйть күзлегеннән чыгып бәя бирү; шушы хис мине көне буенча озатып йөрде, тырышлык сыйфатлары... гомере буе озата бара; сине начальникка сорыйлар; тәрәзәләр тирли; автомобиль картая...; хыялый хикәя...**

Татар телен уртача гына булса да белгән кеше килешер: бу мисаллар безнең мәгълүмат чаралары белән эш итүчеләр арасында үзенең төп эш коралы туган телен никадәр түбән дәрәҗәдә белгән, дөресрәге, белмәгән кешеләр эшли. Мондый тузга язмаган гыйбарәләр бүген матбугат битләрендә меңнәрчә.

Күп санлы тел ялгышларының нигезендә яткан тагын бер күренеш ул – сөйләмдәге үзара мәгънә бәйләнешендә сүзләрне бәйләүче грамматик чараларны дөрес кулланмау. Мондый ялгышлар шулай ук, нигездә, русчадан тәрҗемә материаллары теленә хас. Һәм алар да  – ике тел белән эш итүчеләрнең ул телләрнең үзенчәлекләрен җитәрлек дәрәҗәдә белмәүләре һәм тәрҗемә итү теориясеннән хәбәрдар булмаулары нәтиҗәсе.

Кайбер мисаллар:

"Нәрсә белән ашаталар аларны?".  Бу җөмләдәге **нәрсә**  – рус телендәге **чем** сүзенең хәрефкә-хәреф тәрҗемәсе, һәм бу бик тупас ялгыш: татарча – "**Нәрсә ашаталар**?".

"**Ни булды синең белән**?". Бу шулай ук русчадан калька һәм тупас хата ("*Что случилось с тобой*?") – Чын татарча – "**Нәрсә булды сиңа**?".

“Алар истәлекләр белән уртаклашты”. Татарча “Истәлекләр белән уртаклашмыйлар”, бәлки кемнәрдер истәлекләрен уртаклашалар.

“... **яңгырлы көн астында үтә**”. **Көн астында** түгел, **көндә үтә.**

“Әдәби әсәрләргә кызыксыну уяту”. **Кызыксыну** сөйләмдә үзара бәйләнештәге икенче сүзне үзенә **белән** бәйлеге ярдәмендә ияртә (дөресе – “*әдәби әсәрләр белән кызыксыну*”).

“Алар **үз йортлары белән** торалар” (“Они живут со своим домом “ дигән җөмләнең калькасы). Киң таралган һәм тупас хата. Чын татарча “үз йорты белән тору” дип әйтелми, гадәттә **үз йортында** кемнәр беләндер торалар.

“Студентлар белән **түгәрәк өстәл артында** очрашу” (“встретиться за круглым столом” калькасы. Мәгънәсезлек килеп чыга бит: өстәл түгәрәк булгач, аның арты буламы соң?

“**Контроль астында тоту**” (“держать под контролем” фразасының калькасы). Дөресе – “**контрольдә тоту”.**

Соңгы вакытларда татар теленә хәтта рус теленең синтаксик калыпларын күчерә башладылар. Мәсәлән, “Ак барс” банкка барып кредит алдык” (татарча – “Ак барс” банкына...); “Эшче һөнәрләр елы” (дөресе – эшче һөнәрләре елы); “Габдулла Тукай исемендәге **татар гимназиядә**...” (татарча “... **татар гимназиясендә**); “Поликлиникалар **шимбә** эшләрме?” (дөресе – “...**шимбә көнне** яки **шимбәдә** эшләрме?”); “**рус тел белеме**” – **рус теле белеме** булырга тиеш. Бу мәгълүмат чараларыннан алынган мисаллар (андыйлар газеталарда йөзләрчә һәм меңнәрчә) бүгенге көндә татар теленең гаять нык бозылуын күрсәтә.

Радио-телевидение теле турында берничә сүз. Эфир тапшыруларында, бигрәк тә телевидениедә, телне шулкадәр бозалар, хәтта аларны карау һәм тыңлаудан гайрәт чигә: авазларны ялгыш әйтәләр (мәсәлән, **һ** урынына **х**: **шәхәр, хәм, хава** һ.б.), калын **к-г** урынына нечкә **к-г** кулланалар, интонацияне, сүз басымын дөрес куймыйлар һ.б. Телевидение тапшыруларында катнашучыларның күбесенең теле адәм көлдерерлек: сүзләрнең яртысы русча, татарчаларын да бозып әйтәләр. Андагы тәртипсезлекне сөйләп һәм язып бетерерлек түгел.

Мәсьәләне мөмкин булганча яхшыртуга, проблемаларны киметүгә ярдәм итү максатыннан кайбер тәкъдимнәребезне әйтеп китик.

Беренчедән, һәркайсыбыз өчен шул мәгълүм булырга тиеш: хәзер газета-журналларда, радио-телевидение тапшыруларында көннән-көн арта барган тупас тел бозылу күренешләренә бик җитди хәл итеп карау зарур. Диалектик материализм өйрәткәнчә, сан үзгәрешләре әкренләп сыйфат үзгәрешләренә әверелә. Телне кулланудагы күп санлы ялгышлар да, арта барып, телебезнең табигый төзелешенә җитди зыян китерергә, аның хасиятен, телне тел итеп саклый торган төп үзенчәлекләрен югалтуга китерергә мөмкин. Һәм нәтиҗәдә камил әдәби телнең, үзенең игелекле вазыйфаларын тиешле дәрәҗәдә сыйфатлы итеп башкару мөмкинлекләреннән мәхрүм булып, ниндидер катнаш, корама телгә әверелү ихтималы бар.

Бу уңайдан шушы хакыйкатьне искә төшерү дә урынлы булыр: сөйләм культурасы ул – гомуми культураның әһәмиятле өлеше. Дөрес, матур сөйләмгә ия булмаган кешене тулы мәгънәсендә зыялы, тәрбияле кеше дип әйтеп булмый.

Бу әйтелгәннәрдән төп нәтиҗә шул: туган телебезнең язмышы өчен җаваплы оешмалар, республика җитәкчеләре, татар теленең сафлыгы, дөреслеге мәсьәләсен игътибар үзәгенә алып, телебезне саклау белән бергә, аның сафлыгын кайгырту бурычларын хәл итү белән дә шөгыльләнсен иде.

Бу бурычлар ниләрдән гыйбарәт соң?

Иң әһәмиятле бурыч – мәктәпләрдә татар телен укытуны контрольдә тотып, аның сыйфатлы, нәтиҗәле итеп башкарылуына ирешү. Телне сыйфатлы итеп укыту исә балаларга туган телләрен яхшы итеп өйрәтүне күздә тота.

Бу мәсьәләдә төп игътибарны менә нәрсәгә юнәлтергә кирәк: моңарчы татар телен укытуда балаларга кагыйдәләр ятлатып, күнегүләр эшләтеп, телнең, нигездә, грамматикасын үзләштерү максаты куела иде. Хәзер укытучыларның төп бурычы телне барыннан да бигрәк практик яктан өйрәтү, ягъни укучыны ана телендә дөрес, иркен, йөгерек итеп сөйләргә һәм тиешле орфография һәм пунктуация кагыйдәләрен саклап язарга өйрәтү булырга тиеш. Туган тел программасында тәрҗемә итүнең төп теоретик нигезләрен һәм тәрҗемә итү күнекмәләрен үзләштерү дә күздә тотылсын иде. Чөнки урта белемгә ия егет һәм кызларга татар теленнән алган белемнәреннән гомерләре буена файдаланырга туры киләчәк, шуңа күрә аларның туган телләрен белүләре тиешле дәрәҗәдә булырга тиеш.

Укучыларга туган телләрен яхшы итеп өйрәтү – иң мөһим бурыч: алар мәктәптән татар телен тиешенчә белеп чыксалар, киләчәктә телнең сафлыгын саклаучыларның төп терәге булачаклар. Мәгариф органнарына бу бурычны үтәү җиңел булмачаячак, әлбәттә. Соңгы елларда хакимият тарафыннан туган телләрне укытуга карашның уңай якка үзгәрмәвен исәпкә алсак, бу эшне уңышлы гамәлгә ашыру өчен объектив кыенлыклар барлыгы ачык күренә. Әмма аларны хәл итми мөмкин түгел.

Бу мәсьәләдә якын арада башкарыласы беренче дәрәҗәдәге бурычлар: татар мәктәпләренең һәм татар теле укучыларының санын арттыруга ирешү, әлегә алар, киресенчә, кими баралар; татар мәктәпләре укытучыларының квалификациясен, педагогик-методик осталыгын күтәрү, мәктәпләрнең материаль базасын ныгыту. Максат – татар мәктәпләрен иң абруйлы уку йортлары итү. Бик әһәмиятле һәм катлаулы эш – ата-аналарның гомумән татар теленә мөнәсәбәтләрен һәм балаларын татарча укытуга карашларын уңай якка үзгәртү. Бу зур тәҗрибәле укытучыларның, күренекле педагог һәм психолог галимнәрнең һәм башка төрле лаеклы белгечләрнең уртак тырышлыгы белән, махсус программа буенча башкарыласы эш.

Матбугат, радио-телевидение иң үтемле, популяр мәгълүмат тарату чарасы гына түгел, бәлки туган телне саклау, аны яшь буынга өйрәтү, дөрес, саф телне укучы, тыңлаучы һәм караучыларга пропагандалау коралы да булырга тиеш. Ул телебезне саклауда, аның кулланылышын киңәйтүдә, дөреслегенә, сафлыгына ирешүдә зур ярдәм дә итә ала. Үзенең теле үрнәк булмаса, телебезгә җитди зыян да китерә ала.

Мәгълүмат чаралары туган телебезнең үзенә бер индикаторы ролен үти: анда гомумән телдәге булган үзгәрешләр, проблемалар ачык күренеп тора. Минем үземә, мәсәлән, республика газеталарындагы үзгәрешләрне инде ярты гасырдан артык өйрәнеп, күзәтеп барырга туры килде. Бу темага 1964 елны “Социалистик Татарстан” газетасында “*Төгәлсезлекләр күңелне борчый*” дигән беренче мәкаләм басылып чыккан иде. Ул төгәлсезлекләр, ягъни газеталардагы тел бозу күренешләре теркәлгән карточкалар белән инде берничә каталог тартмасы тулды. Бу процесс әле дә дәвам итә. Шул да мәгълүм булсын: ул вакытларда телне бозу хәзерге кебек үк түгел иде. Чөнки, 70-80-90 нчы елларда матбугат теленә, гомумән мәдәният тормышына хакимият һәм иҗат союзлары тарафыннан

игътибар зуррак иде. Мисал өчен: язучылар союзының һәм журналистлар союзының һәркайсының тәрҗемәчеләр секцияләре эшләп килде. Алар системалы рәвештә күренекле язучылар, тәҗрибәле журналистлар катнашуында матур әдәбият һәм матбугат материаллары телләренең торышы турында семинарлар уздырдылар. Бервакыт журналистлар союзы Татарстанда һәм башка өлкәләрдә чыга торган татар газеталарының редакторларын, тәрҗемәчеләрен җыеп берничә көнлек семинар үткәргән иде. Анда газета тәрҗемәләренең сыйфаты турында миңа да доклад сөйләргә туры килде.

Мин ул вакытлардагы хәлләрне шуның өчен искә төшерәм: хәзер газеталар, ул еллардагы белән чагыштырганда, күпкә артты, дәүләтнекеләрдән тыш, әллә никадәр хосусый басмалар чыга. Һәм аларда эшләүче журналистларның кайберләре анархия стиле белән эш итә: телне ничек телиләр шулай ботарлап язалар, тел фәне, телнең гасырлар буена формалашкан тәртибе, кагыйдәләре белән исәпләшеп тормыйча, үзбелдеклелек ысулы белән эшлиләр. Кайбер газеталарның (мәсәлән, “Юлдаш”, “Гаилә”, “Мәхәббәт” дигән газеталарның) телен шул дәрәҗәдә бозалар, хәтта аны аңлавы да кыен. Хосусый радио хезмәткәрләре дә тел белән артык үзирекле эш итәргә яраталар.

Хәзер татар журналистларының кайберләре, матбугат халыкка якын булырга тиеш дигән сафсата корып, газеталарны гади сөйләм телендә, “урам телендә” чыгарырга тәкъдим итәләр, кайберләре бу идеяләрен гамәлгә ашырып та маташалар. Телебезне куллануда һич кенә дә анархия булырга тиеш түгел. Бу гаять зур культурасызлык, туган телне гасырлар буена иҗат иткән халкыңа илтифатсызлык. Телне бозарга беркемнең дә хакы юк. Инде кемдер, юньсезлек эшләп, телне бозып куллана икән, аңа карата чара күрелергә, аның бу гамәле туктатылырга тиеш. Бу эш исә рәсми дәүләт органнары вазыйфасына керә.

Безнең хөкүмәтнең, халыкның рухи тормышындагы, мәдәниятендәге хәлләр өчен җаваплы төп органнары, шулай ук мәгълүмат чаралары белән идарә иткән Татмедиа һәм журналистлар союзы, ниһаять, матбугат, радио-телевидение эше белән якыннанрак танышып, газета-журналларның, эфирга таратыла торган тапшыруларның телен анализлап, хөкемнәрен чыгарырга һәм халыкның рухи ихтыяҗларын канәгатьләндерергә бурычлы затларның башбаштаклык кылуларына чик куярга тиеш.

Татарча мәгълүмат чараларының телләре тиешле дәрәҗәдә булсын өчен, татар журналистларын тиз арада заман таләпләренә

җавап бирерлек итеп әзерләү мәсьәләсен хәл итәргә кирәк. Бу мәсьәлә дә республиканың тиешле җитәкчеләренең җитди чаралар күрүен көтеп тора.

Сүзебезне йомгаклап куйыйк.

Хәзер һәркайсыбыздан туган телебезне аның дөреслеген, матурлыгын, камиллеген югалтмыйча саклау, аны яшь буынга һәм өлкәннәргә нәтиҗәле итеп өйрәтү, укыту, татарча мәгълүмат чаралары телен тиешле югарылыкта тоту, ата-аналарның һәм гомумән барлык татар кешеләренең милли рухын, патриотлык хисләрен уяту һәм ныгыту бурычлары һәм башка шундый игелекле гамәлләр кылу таләп ителә. Ул бурычларның гаять әһәмиятле икәнлеген аңлап, телебезне, мәдәниятебезне саклау һәм үстерүгә, халкыбызны, милләтебезне алга җибәрүгә зур ихтыяҗ барлыгына инанып, бу изге максатка ирешү өчен, һәркем кулыннан килерлеген эшләсә, бай тарихлы, югары культуралы, күркәм сыйфатларга ия татар милләте әле озак яшәр дигән өмет баглыйбыз.

## СҮЗЕБЕЗНЕ УЙЛАП СӨЙЛИК!

Бүгенге мәгълүмат чараларында, кайбер кешеләрнең телендә дә, сүзне, уйлап тормыйча, аның чын мәгънәсенә төшенеп җитмичә сөйләү һәм язу күренеше арта бара. Моның нәтиҗәсе мәгълүм: туган телебезнең табигый төзелеше, үзенчәлеге бозыла, матбугат, радио-телевидение материалларының укучыга, тыңлаучыга аңлаешлылык дәрәҗәсе һәм уңай тәэсир итү көче кими.

Мисаллар эзләп ерак барасы юк.

Хәзер газета-журналларда, радио-телевидение тапшыруларында, кайбер китапларда һәм кайбер кешеләрнең сөйләмендә йөзләрчә, меңнәрчә табигый булмаган, ясалма әйтелмәләр, тәгъбирләр, сүзләр кулланыла.

Телебездә бик еш очрый торган *үсү* сүзен һәм аның белән бергә килеп төзелгән әйтелмәләрне (сүзтезмәләрне) алып карыйк. *Хезмәттәшлек үсә, икътисад үсә, Татарстан үсә, шәһәр үсә, штрафлар күләме үсә, сыйфат үсә, көнләшү үсә, авырулар үсә, туристлар саны үсә, бәяләр үсә, киеренкелек үсә, ризасызлык үсә, хәл үсә, омтылыш үсә, куркыныч үсә* һәм тагын әллә нәрсәләр үсә, дип язалар һәм сөйлиләр.

Бу гыйбарәләрдәге сүзләрнең барысы да дип әйтерлек татар теленең үзенеке һәм аерым-аерым алганда аңлаешлы булса да, гомумән әйтелмәләр буларак, алар саф татарча түгел: чын татар кешесе *куркыныч үсә, ризасызлык үсә* һәм башка шулай дип сөйләмәс.

Монда сүзләрнең үзара безнең телгә генә хас, билгеле бер төрле мәгънә бәйләнешләренә керү үзенчәлеге булуын истә тоту зарур. Моны мисаллар ярдәмендә аңлатсак, аңлаешлырак булыр. *Тәмле* һәм *бәлеш* сүзләре сөйләмдә, бер-берсе белән бәйләнешкә кереп, *тәмле бәлеш* дигән табигый, дөрес әйтелмә тәшкил итәләр. Шул ук *тәмле* сүзе, мәсәлән, *йорт* сүзе белән бәйләнешкә кереп, безнең тел өчен табигый гыйбарә төзи алмый: *тәмле йорт*, дип әйтеп булмый: билгеле бер сүзләр, башка ниндидер бер сүзләр белән генә бергә килеп, табигый мәгънәле әйтелмәләр (тәгъбирләр) тәшкил итәләр.

Башка меңнәрчә сүзләр белән дә шул ук хәл: телдәге һәртөрле сүзнең башка теләсә кайсы сүз белән мәгънәви бәйләнешкә керү сәләте (мөмкинлеге) булмый.

Монда тагын бер әһәмиятле нәрсә бар. Төрле телләрдәге төп мәгънәләре белән бердәй сүзләр (тәңгәллекләр) үзара мәгънә бәйләнешенә керү үзенчәлекләре буенча кайбер очракта бер-берсенә туры киләләр, кайбер очракларда исә туры килмиләр. Мәсәлән: *глубокая* һәм *река* сүзләре һәм аларның төп мәгънәләре буенча татарча тәңгәллекләре *тирән* һәм *елга* бу ике телдә дә сөйләмдә үзара бәйләнешкә керү мөмкинлеге буенча бертөрле. Шуның белән бергә *глубокая* һәм *печаль* сүзләре рус теле өчен табигый бәйләнешкә керсәләр, аларның татарча тәңгәллекләре *тирән* һәм *кайгы* андый бәйләнешкә керә алмыйлар: чын татарча *тирән кайгы* дип әйтелми, бәлки *зур кайгы* була.

Ике тел белән эш итүче каләм ияләренә, тәрҗемәчеләргә төрле тел сүзләренең сөйләмдә үзара бәйләнешкә керүендәге бу үзенчәлекне һәрвакыт истә тотып эшләргә кирәк. Хәлбуки, хәзерге телдәге ялгышларның күбесе менә шушы үзенчәлекне исәпкә алмау аркасында килеп чыга.

Әле мисал итеп күрсәткән *үсү* сүзе белән килгән әйтелмәләр шуның өчен татарча дөрес түгел: аларны тәшкил иткән сүзләр ялгыш рус телендәге тәңгәллекләренең гыйбарә төзү өлгеләре буенча бәйләнешкә кертелгән. Рус телендәге *расти, развиться (развиваться)* сүзләренең татарча төп мәгънәсендәге тәңгәллеге *үсү*

булса да, ул төрле мәгънәләрендәге әйтелмәләрдә башка сүзләр белән белдерелә:

*хезмәттәшлек киңәя* (*ныгый, җәелә, арта* һ.б.); *икътисад алга бара (уңышлы бара, икътисадта уңышка ирешелә һ.б.; Татарстан алга бара; шәһәр зурая (матурая, төзекләнә һ.б.); штрафларның күләме арта; сыйфат яхшыра; көнләшү арта (көчәя һ.б.); авырулар арта (күбәя, тарала һ.б.); туристлар саны арта; бәяләр күтәрелә (арта); киеренкелек арта; ризасызлык көчәя; хәл киеренкеләнә; омтылыш ныгый; куркыныч арта.*

Соңгы вакытларда рус телендәге *звучать,озвучивать* сүзләрен ялгыш тәрҗемә итү аркасында *яңгырау, яңгырату* сүзләре белән бәйләнештәге шактый мәгънәсез гыйбарәләр күп кулланыла: *шелтәләр яңгырады* (дөресе – шелтә белдерелде, шелтә сүзләре әйтелде һ..б); *теләкләр яңгырады* (теләкләр белдерелде, әйтелде); *саннар яңгырады* (саннар китерелде һ.б.); *сораулар яңгырады* (сораулар бирелде, әйтелде, җиткерелде һ.б.); *җаваплар яңгырады* (җаваплар бирелде, алынды һ.б.); *идеяләр яңгырады* (идеяләр әйтелде, белдерелде, җиткерелде һ.б.); *фикерләр яңгырады* (фикерләр әйтелде, белдерелде һ.б.); *тәкъдимнәр яңгырады* (тәкъдимнәр ясалды, әйтелде һ.б.).

***Призвать*** сүзен һәр урында да ***чакыру*** дип тәрҗемә итү аркасында барлыкка килгән тупас ялгышлар хөкем сөрә: “Антон Силуанов пенсиягә чыгу яшен арттырырга *чакырды*” (чын татарчасы – “... пенсия яшен арттырырга кирәк, диде” яки “...арттырырга өндәде”); “Севастополь егетләренең солдатка *чакырылмаячагын* да хәбәр итте” (дөресе – “...солдатка яки армиягә алынмаячагын хәбәр итте”); “Ул даруларны смс-хәбәрләр аша рекламалауны тыярга *чакырды*” (дөресе – “...тыярга ***кирәк,*** диде”).

“Ул бөтен Россия мөселманнарына чын ислам *кыйммәтләрен* таратучы рухи үзәккә әверелер”. Бу җөмләдәге “*ислам кыйммәтләрен*” укучы аңлыймы яки нәрсә дип аңлый икән? Татар телендә *кыйммәт* дигән сыйфат сүз төркеме бар ( мәсәлән, азык-төлекнең бәясе *кыйммәт*), ләкин *кыйммәтләр* дигән исем юк. Хәзерге мәгълүмат чараларында кулланыла торган *кыйммәтләр* рус телендәге *ценности* сүзен хәрефкә-хәреф тәрҗемә итеп ясалган калька, әмма ул татарча дөрес түгел. *Ценности*ның мәгънәсе татарча урынына карап, *хәзинә, байлык* һәм башка сүзләр белән белдерелә (мәсәлән, *рухи хәзинәләр*). Әлеге җөмләдәге *ислам кыйммәтләренең* мәгънәсен исә *ислам тәгълиматы* әйтелмәсе белдерә, һәм шуны кулланырга кирәк тә.

Публицистика телен нык боза торган күренешләрнең берсе – рус телендәге *глубокий* сүзен һәр очракта да да *тирән* дип тәрҗемә итү аркасында барлыкка килгән гайре табигый гыйбарәләр: (фәнне) *тирән белү* (чын татарчасы – яхшы белү, төптән белү, нык(лап) белү һ.б.); *тирән бочылу, борчу* (зур борчу, нык бочылу һ.б.); *тирән кайгы* (зур кайгы, кара кайгы һ.б.); *тирәнтен ял*гышу (нык, каты ялгышу); *тирән рәхмәт* (зур рәхмәт); *тирән тәэсир* (көчле тәэсир); *тирән кызыксыну* (нык кызыксыну, бик кызыксыну); *тирән үзләштерү* (нык, яхшы үзләштерү); *тирән ихтирам* (зур, олы ихтирам); *тирән ышаныч* (зур ышаныч, нык ышаныч); *тирән борчылу* (нык борчылу); *тирән дуслык* (нык, көчле дуслык); *тирән канәгатьләнү* (нык, зур канәгатьләнү); *тирән уйлану* (нык-лап, җитди уйлану); *тирән гомумиләштерү (?!); тирән үзгәреш* (зур үзгәреш); *тирән(тен) өйрәнү* (ныклап, җентекләп өйрәнү); *тирән ачу* (зур ачу, нык ачулану һ.б.). Бүгенге телебездә мондый сәер тәгъбирләр күп.

"Татарстанда ... *гаилә* бал кортлары исәпләнә". Менә ул, туган телне яхшы итеп белмичә, рус теленнән "әвештереп" кенә эшләүнең бер гыйбрәтле мисалы. Татарча "фәлән гаилә бал кортлары" димиләр, "фәлән баш умарта (бал кортлары)" диләр.

"*Иртә язда* җирен эшкәртеп...". Нәрсә ул, нинди була ул иртә яз? Безнең телдә *быел яз иртә килде*, дип сөйләү бар, ләкин *иртә яз* дигән әйтелмә юк. Бу русчадагы *ранняя весна*ның хәрефкә-хәреф тәрҗемәсе. Татарча аны *яз башында* диләр.

"...эшләп йөрүчеләрнең пенсияләре кала, әмма алар индексацияләнмәячәк. *Эшләрен калдыралар икән*, булачак." Кемгә һәм ничек калдырырга тиеш икән алар эшләрен?! Бу шулай ук, башны ватмыйча гына, русчадан әйләндереп куеп кына эш итү галәмәте ("если оставят работу" фразасыннан калька). Чын татарчасы – "эшләреннән китәләр, эшләрен ташлыйлар, эшләүләреннән туктыйлар, эшләреннән чыгалар икән" һ.б.

Тел белән уйламыйча, механик рәвештә эш итү укучыда, тыңлаучыда аңлашылмаучылык яки автор әйтергә теләгән фикерне ялгыш аңлау китереп чыгара. "Россиядә яшәүче *һәр бишенче кеше (каждый пятый человек*ның калькасы – *Р.Ю.)* эшен югалтудан курка". Әйтерсең кешеләрне сафка тезеп куйганнар да, шуларның һәр бишенчесе эшен югалтудан курка. Дөресе – "...(һәр) биш кешенең берсе (кешеләрнең биштән берсе)... курка.

"Шушы *бәһасез* байлыгыбызны үстерү өчен... мәгариф әһелләренә игътибарны тагын да арттыру кирәк". Нинди була икән

ул *бәһасез байлык*? *Бәһасез, бәһасе юк*, димәк, бернигә дә тормый торган, бик начар була түгелме соң инде ул! Бу җөмләдәге *бәһасез* сүзе – *бесценный*ның ялгыш тәрҗемәсе булса кирәк. *Бесценный* ул – бик кыйммәтле, бәя биреп бетергесез" дигән сүз. Димәк, телләрне начар белү, тәрҗемә итә белмәү тупас ялгышларга, оригиналның мәгънәсен капма-каршы итүгә китереп җиткерә.

Менә бу җөмләләрнең дә эчтәлеген, мәгънәсен аңлау кыен: "Безнең максат – *уртак санак төрки тел*". Төрки *телләрне компьютерда эшкәртүгә* багышланган... конференция ачылды". Нинди була икән ул – *уртак санак төрки тел?!* Телләрне ничек компьютерда эшкәртеп була икән һәм эшкәртергә кирәкме икән? Сүз монда төрки телләрне компьютерга (компьютер программасына) салу (кертү) турында бара, һәм аны шулай язарга кирәктер дә.

"ИГИЛ* террорчылары... Триумфаль *гөмбәзне* (арка) җимерде". Бу җөмләдән *гөмбәз* белән *арка* бер үк нәрсә дип аңлашыла.

Бу һәм башка мисаллар үзәк республика газеталарыннан. Гөмбәз белән арканы бутап, күрсәтелгән һәм алда күрсәтеләчәк тупас тел ялгышлары белән язу татар матбугатына абруй өстәми, әлбәттә.

Укучылар игътибарына газетадан бер кечкенә генә хәбәр тәкъдим итеп, фикер алышу мәгъкуль булыр.

**Үз өстеңдә эшләп кара**

"*Биеклектән, караңгыдан, йогышлы чирләрдән, танспорттан курку хисе күңелегезгә кереп утырган икән, сез үзегез генә түгел. Мондый тойгы белән күпләр яши*".

Психолог Резеда Мәрданова *фобиянең башы кечкенә яшьтән башланырга мөмкин*, дигән фикердә. "*Бала елый икән, аны бабай килә дип куркыта башлыйлар. Күңелендәге ярсуын баса алмаган бала куркып кала. Еллар узкән саен бу курку калкып чыгарга мөмкин*", – ди ул.

Бу мәгълүматның эчтәлегенә карата да фикерләр бар. Ләкин монысы хәзергә безнең эш түгел. Без аның теле турында фикер йөртик.

Беренчедән, бу информациянең исемен ничек аңларга икән? Ул текстны бөтенләй чагылдырмый да, формасы белән дә татарча дөрес түгел: чын татарча "үз өстеңдә эшләү" дип әйтелми, бу мәгънәсез гыйбарә.

---

ИГИЛ – Россиядә тыелган террорчылык оешмасы.

Икенчедән, баштагы ике җөмлә уңышсыз төзелгән, ул русчадан калька. Аларны татарча болайрак әйтергә кирәк: "*Күңелегезгә биеклектән, караңгыдан, йогышлы чирләрдән (авырулардан) курку хисе сеңгән икән, сез андыйлардан берүзегез генә түгел. Мондый хис күп кешеләрдә була"*.

Өченчедән, чираттагы җөмлә стиль ягыннан кытыршы: "... башы... башлана" дип әйтү килешми: "Психолог Резеда Мәрданова фикеренчә, курку кечкенә яшьтән үк башланырга мөмкин" кебегрәк итеп әйтергә кирәк.

Сөйләмдә сүзләрнең мәгънәви бәйләнешен гамәлгә ашыра торган грамматик чараларны дөрес кулланмау нәтиҗәсендә дә тупас хаталар килеп чыга. Мәсәлән: "Проект мәктәп укучыларында техник *һөнәрләргә кызыксыну уяту* максатында булдырылган" (дөресе – "... һөнәрләр белән кызыксыну..."); "...үзенең *истәлекләре белән уртаклашты*" ("... истәлекләрен уртаклашты" кирәк); "Без күршеләребездән тәҗрибә алышу, белемнәре белән уртаклашу өчен килдек" (дөресе – "Без күршеләребез белән тәҗрибәләрен, белемнәрен уртаклашу өчен килдек"); "*Кайгы-хәсрәтләре турында уртаклашабыз*" (дөресе – "Кайгы-хәсрәтләрен уртаклашабыз"); "Табиблар инде *кыш була торган* грипп, ОРВИ чирләренә каршы чаралар уздыра башлады" ("...кышын була торган" кирәк); "Алар Рөстәм Миңнехановны үз президентлары саныйлар" ("...үз президентлары итеп саныйлар" булырга тиеш); "Кичә *Россия хәрби авиация* Сүриядә ДАИШ урнашкан 9 урынга һөҗүм итте" ("Кичә Россиянең хәрби авиациясе... һөҗүм иткән" кирәк); "*Утын белән яга торган печь"* (татарча – "утын яга торган мич"); "*Татар тел факультеты*" ("татар теле факультеты").

Мәгълүмат чараларының теле барлык укучыларга һәм тыңлаучыларга да аңлаешлы, популяр булырга тиеш. Журналистларның кайберләре бу хакыйкатьне һәрчакта да истә тотып эш итмиләр. Хәлбуки, иҗтимагый-сәяси эчтәлекле, фән һәм техника белән бәйләнешле материалларның, яңалык һәм хәбәрләрнең, тәрҗемә материалларның теле еш кына катлаулы, үзенә бер төрле коры, "казенный" була. Гади генә итеп, саф татарча, халыкча, сөйләм теленә якынрак, җанлы һәм ачык аңлаешлы итеп язарга һәм сөйләргә тырышырга кирәктер. Югарыда күрсәтелгән кебек һәм менә мондый җөмләләр, гыйбарәләр белән язу һәм сөйләү популяр телгә ирешүгә ярдәм итми шул. Менә, мәсәлән, *күзәтү* яки *күзәтеп тору* дип кенә әйтәсе урында *күзәтү астына алу, күрсәтелә* яки *белдерелә (әйтелә)* диясе урында *ассызыклана, бу*

*ел (быел)* урынында *агымдагы ел, гаиләнең матур (әһәмиятле) йолалары яки традицияләре* урынында *гаилә кыйммәтләре, картиналар ясау* урынында *әсәрләр тудыру* дип, *машина йөри* дип әйтәсе урында *машина хәрәкәт итә*, (*самолет белән) Мәскәүгә барам* диясе урында *Мәскәүгә очам* дип сөйләү һәм язуларны, башка шундый штампларны күп күрергә һәм ишетергә туры килә әле.

Телебезнең бай фигыль формаларыннан тулы файдаланылмый, кайберләре исә ялгыш кулланыла. Мәсәлән, бер газетада язылганча, "Мин 1934 елның 5 гыйнварында ... тудым" дип әйтү – телнең иң әһәмиятле һәм мәгълүм кагыйдәләреннән берсен (нормасын) бозу. Туган телен әйбәт белгән татар кешесе һич кенә дә *тудым* димәс, *туганмын* дияр.

*-Ган-гән (-кан-кән)* кушымчалы үткән заман сыйфат фигыльләре барлыгын онытып, алар урынына *-учы-үче* кушымчалы хәзерге заман сыйфат фигыльләрен генә куллану гадәткә керә бара. Нәтиҗәдә телнең табигый үзенчәлекләре һәм тиешле мәгънәне бозыла. Бу үзе бер аерым сөйләшү темасы.

Туган телебез – үзен горурлык белән мин татар милләтеннән, дип санаган һәркем өчен бик кадерле нәрсә. Ана теле ул – халыкның иң әһәмиятле, иң беренче билгесе, асылы. Тел бетсә, аның иясе булган халык та югала. Туган теле ярым-йорты, корамалы булса, бу хәл халыкның алга баруына, цивилизациягә ирешүенә нык комачаулый, башка халыклар арасында дәрәҗәсен төшерә. Ә без, татарлар, лаеклы милләт, һәрвакыт һәм һәръяктан күркәм халык булганбыз, һәм булырбыз да. Моның исә төп шартларыннан берсе – туган телебезне бозмыйча, дөрес куллану, аны кадерләп саклау.

## ТӘРҖЕМӘ ҺӘМ СӨЙЛӘМ КУЛЬТУРАСЫ

Бүгенге көндә сөйләмебездә, матбугат материалларында, радио-телевидение тапшыруларында, фәнни әдәбиятта, эш кәгазьләрендә туган телебездәге дөрес сөйләм нормаларының шактый еш бозылуы, нигездә, безнең хәзер үзенчәлекле заманда – татар-рус икетеллелеге чорында яшәвебез белән бәйле.

Без, Россия дәүләтендә яшәүче татарлар, кечкенәдән үк, үзебезнең туган телебез белән беррәттән, рус теленнән дә файдаланырга дучар ителгән: күпчелекне рус халкы тәшкил иткән күп

милләтле илдә рус телен белми торып, нәтиҗәле, уңышлы яшәү бик кыенга туры килә, дөресрәге, мөмкин дә түгелдер.

Шушы халәттә татар кешесенә, туган телендә теге яки бу фикерне, мәгълүматны бәян иткәндә, тиешле төшенчәне белдергәндә, күп очракта рус теленнән тәрҗемәгә мөрәҗәгать итәргә туры килә, чөнки һәртөрле информация, фән-техника, сәясәт, мәдәният өлкәсендәге яңалыклар безнең илдә башта, кагыйдә буларак, рус телендә ирештерелә. Һәм руслардан башка халыклар, шул исәптән татарлар да, кирәкле мәгълүматны, информацияне рус теленнән тәрҗемә итеп ала. Хәер, монда бу халыкларның турыдан-туры башка илләр белән шактый нык бәйләнешләре барлыгын да исәптән чыгарырга ярамый. Ләкин классик бәйләнеш – безнең илдә рус теле белән башка телләр бәйләнеше – әлегә хәлиткеч рольне уйный.

Димәк, хәзерге шартларда безнең телебез даими рәвештә рус теле белән элемтәдә тора, һәм татар теле иясенә, рус телен дә белеп, ул телдә дә эш итәргә, шуның өстенә, бу ике телне берсеннән икенчесенә тәрҗемә итеп тә кулланырга туры килә.

Сөйләмебездәге – телдән сөйләмебездә дә, язма сөйләмебездә дә – тел ялгышларын анализлаганда, шул нәрсә ачыклана: аларның күбесе, беренчедән, туган телебезне дә, рус телен дә җиренә җиткереп, ягъни камил белмәүдән һәм, икенчедән, аларның берсеннән икенчесенә дөрес тәрҗемә итә алмаудан килеп чыга.

Тәрҗемә процессында төп мәсьәлә шуннан гыйбарәт: бездә ике тел белән эш итүчеләрнең һәркайсы, ике телне дә ярыйсы гына белгәнлектән, тәрҗемә итә беләм дип инанган хәлдә, бу эшкә кыю алына һәм гадәттә теләсә нинди материалны тәрҗемә итеп тә чыга. Моны һәвәскәрләр тәрҗемәсе дип атарга булыр иде. Болай тәрҗемә иткәндә оригинал телендә бәян ителгән эчтәлек тәрҗемә телендә бирелә, һәм ул шактый тулы һәм төгәл дә белдерелергә мөмкин. Ләкин мондый тәрҗемәләрнең теле һәрвакытта да тиешле дәрәҗәдә камил, әдәби яктан дөрес була дип әйтү чынбарлыкка туры килеп бетмәс иде.

Татар теле бүген күп санлы мәгълүмат чаралары материалларын, рәсми документларны, эш кәгазьләрен, фәнни-техник хезмәтләрне махсус филологик белемнәре булмаган һәм ике телне дә камил белмәгән кешеләр тәрҗемә итү аркасында нык бозыла.

Тәрҗемә итүнең үзенең зур практикага нигезләнгән мәгълүм принциплары, алымнары һәм ысуллары, теориясе, фәне бар. Аларны белми торып, югары сыйфатлы тәрҗемәгә ирешү мөмкин түгел: һәвәскәр башкарган тәрҗемә оригиналның мәгънәсен дә бозарга,

тәрҗемә теленең дөреслегенә, табигыйлыгына зыян да китерергә мөмкин.

Тәрҗемә эшенә куела торган төп ике таләп – оригиналның эчтәлеген, мәгънәсен мөмкин булганча төгәл, тулы итеп бирү һәм тәрҗемә теленең дөреслеген саклау. Бу таләпләрнең икесен дә үтәү җиңел эш түгел, ләкин бик тырышканда мөмкин. Әмма русчадан татарчага тәрҗемәләрдә барыннан да бигрәк туган телебез бозыла. Хәер, оригиналның мәгънәсенә зыян китерү хәлләре дә сирәк түгел.

Тәрҗемә иткәндә туган телнең нормалары, дөрес әйтелеше, кулланылышы, фән теле белән әйткәндә, нормалары бозылу күбесенчә оригиналның сүзләрен хәрефкә-хәреф (букваль), уйлап тормыйча гына, әйләндереп кую юлы белән генә тәрҗемә итү аркасында килеп чыга.

Болай хәрефкә-хәреф тәрҗемә итү нидән гыйбарәт соң?

Барлык телләрдә дә сүзләрнең күбесе күп мәгънәле. Шунлыктан ике яки берничә телдәге сүзләр арасында чагыштырмача даими тәңгәллекләрне бары тик аларның төп мәгънәләренә нигезләнеп кенә билгеләп була. Гомумән алганда исә тәрҗемә процессында бер телдәге теге яки бу сүзгә тәңгәллекне һәр конкрет очракта контекстка (сүз сөрешенә) карап кына табарга мөмкин, чөнки бер үк сүз төрле текстта (сөйләмдә) төрле мәгънә белдерә, һәм ул мәгънәләр икенче телдә төрле сүзләр белән белдерелә. Мәсәлән, рус телендәге *горячий,* сүзенең мәгънәләренә татар телендә берничә сүз туры килә: *горячий чай – кайнар чәй, горячий человек – кызу (канлы) кеше, горячее желание – көчле теләк, горячий день – мәшәкатьле көн. Көчле* сүзенең мәгънәләре исә рус телендә, урынына карап, *сильный, мощный, могучий, крепкий, бурный, тяжкий* һ.б. сүзләр белән тәгъбир ителә.

Тәрҗемә иткәндә кайчакта оригинал сүзләренә ике тел сүзлекләрендә теркәлмәгән, бөтенләй көтелмәгән тәңгәллекләр табып куярга туры килә. Әйтик, русча-татарча сүзлектә *богатый* сүзенең төп ике тәңгәллеге бирелгән: *бай, мул*. Ә менә *богатое платье* дигән сүзтезмәнең мәгънәсен татарча биргәндә, *богатое* сүзе *затлы* дип тәрҗемә ителә: *затлы күлмәк.* Шулай ук сүзлектә *робкий* сүзенең русча тәңгәллекләре итеп *кыюсыз, юаш, куркак* сүзләре теркәлгән. *Робкий свет месяца* тәрҗемәсендә исә *робкий*ның тәңгәллеге *тоныкк* булып чыга: *тоныкк ай яктысы. Болезнь повторяется* әйтелмәсендә *повторяться* сүзлектәгечә *кабатлана* түгел,

*яңара: авыру яңара.* Менә тагын бер генә гыйбрәтле мисал: *Я юнкер, а теперь представлен – Юнкер мин, тиздән офицер итәчәкләр* (Л.Толстой) (*представлен – офицер итәчәкләр*). Мондый контекстуаль тәңгәллекләр тәрҗемә практикасында адым саен очрап тора.

Димәк, тәрҗемә эшендәге катгый кагыйдәләрнең берсе шул: оригинал телендәге аерым бер сүзнең тәрҗемә телендә тексттан (сөйләмнән) аерым тәңгәллеге турында сүз дә була алмый: бер телдәге теге яки бу сүзгә дөрес тәңгәллекне контекстта гына (сөйләмдә генә) табып куярга мөмкин.

Әмма русчадан татарчага тәрҗемәләрдәге төп бәла шунда: тәрҗемәдә оригинал сүзенә тәңгәллек еш кына ул сүзнең тәрҗемә телендә иң күп таралганнары, зиһенгә беренче килгәннәре арасыннан гына алып, аның контексттагы, ягъни конкрет мәгънәсен исәпкә алмыйча гына билгеләп куела.

Менә шуңа күрә дә бүгенге көндә безнең матбугат битләрендә, радио-телевидение тапшыруларында, кайбер китапларда татар сүзләре белән русча язу күренешләре тулып ята: *тере тавышка җырлау* (*тере тавыш – живой голос*ның уңышсыз калькасы: чын татарча *тере тавыш* дип әйтеп булмый – *үзе җырлый, турыдан-туры үзе җырлый* кебегрәк итеп әйтергә кирәк); *руль артына утырып килде* (рульнең артына утырмыйлар, алдына утыралар: *машинаны үзе йөртә, машина белән үзе идарә итә* кебегрәк итеп саф татарча әйтергә мөмкин һәм кирәк тә); *эре заводлар, эре җитәкчеләр* (дөресе – *зур заводлар, зур җитәкчеләр*), *...яңгыраган фикерләр* (*белдерелгән фикерләр*), *Мәскәү астындагы сугышлар* (*Мәскәү янындагы (тирәсендәге) сугышлар*), *пианино артында утыру (пианино алдында утыру), станок артында эшләү (станокта эшләү*).

Тәрҗемә итүнең ысулларын, методларын белмәгән һәвәскәр тәрҗемәче, гадәттә, оригинал сүзенең һәрберсе аерым сүз белән тәрҗемә итеlә, ягъни тәрҗемә ителә торган телнең һәр сүзенә тәрҗемә теленең аерым бер сүзе туры килә дигән ялгыш принцип белән эш итә. Һәм шушылай эшләү аркасында телебездә әллә никадәр бәла-казалар килеп чыга.

Тәрҗемә практикасында күбесенчә оригиналның һәр сүзен аерым бер сүз белән генә тәрҗемә итү мөмкин булмый: ул ике сүз белән дә, сүзтезмә белән дә тәрҗемә ителергә мөмкин. Һәм оригинал теленең кайсыдыр бер сүзе аерым гына алганда тәрҗемәдә бирелмәскә дә мөмкин. Принцип: тәрҗемәдә оригиналдагы һәр

сүзнең мәгънәсен аерым-аерым бирү шарт түгел, бәлки сүзтезмә, ә кайчакта берничә җөмлә бергә белдергән фикерне, мәгънәне бирү.

Берничә мисал китерик. Рус телендәге *живые цветы* әйтелмәсен сүзгә-сүз тәрҗемә итү аркасында телебездә кайчак *тере чәчәкләр* әйләнмәсе очрый. Монда *живой* сүзен татарча бирүнең бөтенләй кирәге юк: *чәчәкләр* генә диергә кирәк, чөнки *тере чәчәкләр* дип әйтү татарча дөрес түгел.

Шулай ук *живые деньги* сүзтезмәсен механик рәвештә (буквал) тәрҗемә итеп, телебезгә *тере акчалар* тәгъбирен керттеләр. Бу да тупас хата: монда *тере* сүзенең кирәге юк. Хезмәт хакын акчалата яки әйбер белән түләү тәртибе бар, һәм моны туган телдә кулланырга кирәк тә.

*Доярка* сүзен татарча аерым бер сүз белән белдерү өчен, бервакыт бер журналист *савымчы* сүзен уйлап чыгарган иде. Аның бу гамәле уңышлы булды дип әйтмәс идем мин, чөнки ул татар телендәге  сүз ясалышы тәртибенә туры килми: безнең телдә гомер-гомергә кулланылып килгән *сыер савучы* сүзе бар.

"Халык үз *бөеген* зурлады" (газетадан). Бу да рус теленең аерым бер сүзен бер сүз белән генә тәрҗемә итү галәмәте. *Бөеген зурлау* татарча түгел. *Халык үзенең бөек кешесен (бөек шагыйрен, бөек шәхесен һ.б.) зурлады* кирәк.

Соңгы вакытта *русскоязычная школа*ны рус *телле мәктәп, русскоязычные ученики*ны *рус телле укучылар* дип язу һәм сөйләү гадәткә кереп бара. Бу да *русскоязычный*ны сүзгә-сүз тәрҗемә итү галәмәте. Болай әйтү һич тә татарча түгел: *рус телле* дип әйтеп булмый, *рус телендә укыта торган мәктәп* яки *рус мәктәбе, русча укучылар* яки *рус мәктәбендә укучылар* диергә кирәк.

Русчадан татарчага тәрҗемә материалларында, тәрҗемәчеләрнең оригиналның эчтәлеген аңлап җиткермәүләре, игътибарлыклары җитмәү аркасында, шактый тупас мәгънә хаталары да китә.

Соңгы елларда Казанда үткәрелгән "Сотворение мира" фестивален кайбер газеталар "Тынычлык яратылышы" фестивале дип язып чыкты. Беренчедән, чын татарча *тынычлык яратылу* дип әйтеп булмый. Икенчедән, чынлыкта "Сотворение мира" христиан динендәге *дөнья яратылышы* төшенчәсе белән бәйле әйтелмә.

*Раскулачивать* сүзен республикабызның бер газетасы *кулаклаштыру* дип тәрҗемә итте (*Кулаклаштырылган һәм ... Себергә сөрелгән*). *Кулак дип игълан ителеп ... Себергә сөрелгән* рәвешендәрәк әйтергә кирәктер.

“Тәрәзәләр тонировкалы, кузов *броньланган”* (газетадан). Һич кенә дә *броньланган* түгел, “броня белән капланган яки тышланган” булырга тиеш. Бронь белән броняны бутау егетлек түгел, әлбәттә.

Соңгы елларда кайбер газеталарда Дербышки поселогын Дәрвишләр бистәсе дип йөртә башладылар. Дербышканың дәрвишләр белән бернинди дә уртаклыгы юк, әлбәттә. Дәрвишне русча *дервиш* диләр, ә бу *Дербышка:* аны татарча да шулай кулланырга кирәк.

“Победа”да буаз сыерлар өчен *тудыру бүлеге* яхшылап ремонтланган” (газетадан). Тәрҗемәче *родильное отделениене* шулай механик рәвештә *тудыру бүлеге* дип тәрҗемә иткән. Ләкин монда сүз бала табу турында түгел, бәлки сыерларның бозаулавы турында бара. Шулай булгач, *сыер бозаулау бүлеге* яки *бозаулату бүлеге* дип алырга кирәк иде.

Мондый кызык һәм кызганыч хәлләр меңләп исәпләнә бездәге тәрҗемә практикасында.

Шундыйларның аеруча киң таралганнары татар теленең үткән заман хикәя фигыльләренә һәм сыйфат фигыльләренә карый.

Рус телендә үткән заман хикәя фигыльләренең бары бер генә формасы бар (сделал, пришел, понес). Татар телендә исә мондый фигыльләр күп формалы (барды, барган, бара иде, барган иде, барган булган, бара торган иде, бара торган була, бара торган булган һәм башкалар). Тәрҗемәчеләр, ике телдәге вазыйфалары белән якын бу формаларның нисбәтен белмичә яки моңа игътибар итмичә, рус телендәге бер төрле генә форма тәэсирендә татар телендә күбесенчә *-ды-де (-ты-те)* кушымчалы билгеле үткән заман формасындагы фигыльләрне генә кулланалар. Нәтиҗәдә телебездәге бай фигыль формаларының мәгънә төсмерләре тулы бирелми һәм телебез һәр очракта да бер генә форма куллану аркасында күпмедер дәрәҗәдә фәкыйрьләндерелә. *-ды-де, -ты-те* кушымчалы фигыльләр, кагыйдә буларак, сөйләүче (язучы) үткәндә булган эш-хәлне үзе күргәндә генә кулланыла, процесс турында, үзе күрмичә, башка чыганакларга таянып кына (кешедән, радио-телевидениедән ишетеп, укып хәбәр иткәндә *-ган-гән (-кан-кән)* кушымчалы яки башка формалы фигыльләр кулланылырга тиеш. Әмма тәрҗемә практикасында (кайчак оригинал текстларда да) бу кагыйдә еш кына үтәлми.

-*учы-үче* кушымчалы сыйфат фигыль формаларын куллануга кагылышлы хаталар күп очрый.

Моның сәбәпләренең берсе – үзара тәңгәллекләр булып саналган *-ущ/-ющ, -ащ/-ящ* суффикслы причастиеләр белән *-учы/-үче* кушымчалы сыйфат фигыльләрнең һәр очракта да бертөрле кулланылмавында. Хикмәт шунда: рус телендә причастие төрләре үзләре ачыклап килгән сүзләрнең зат исеме яки предмет исеме булуларына карата битараф, ягъни моңа карап үзгәрмиләр. Татар теленең хәзерге заман сыйфат фигыльләре исә, ачыкланып килгән сүзнең җансыз әйбер исеме яки зат исеме булуына карап, төрле формаларда кулланыла. Хәл фигыль белән *торган* ярдәмче сүзеннән ясалган *(эшли торган)* аналитик формалы хәзерге заман сыйфат фигыль зат исемнәрен дә, предмет исемнәрен дә ачыклап килә алса *(яза торган кеше, яза торган машина), -учы/-үче* кушымчалы сыйфат фигыльләр, гадәттә, зат исемнәренә карата кулланыла. Аны предмет исемнәре белән бәйләнешкә кертү татар теле нормалары буенча дөрес түгел: *череп ятучы такта* диюгә караганда *череп ята торган* яки *череп яткан такта* дип әйтү кулайрак; *безнең авылга йөрүче машина* түгел, *безнең авылга йөри торган машина.* Тәрҗемәчеләрнең кайберләре телебезнең бу үзенчәлеген онытып җибәрә, һәм нәтиҗәдә *өйрәнүче төшенчәләр, хезмәт итүче идеяләр, ерак торучы шәһәр, саклаучы документ, канга бирүче эчке секреция бизләре* кебек тәгъбирләр барлыкка килә. Алардагы *-учы/-үче* кушымчалы сыйфат фигыльләрне *-а/-ә + торган* формасында куллану дөресрәк булыр иде.

*Елга бер* ***килүче*** *ял* ***(килә торган*** *ял* булырга тиеш).

*Волгоград урамы буенча* ***үтүче*** *җылылык үткәргечтә ике тишек-тошык табылган* (дөресе – ***үтә торган*** *җылылык үткәргечтә).*

*Аллоплант – кеше тәне күзәнәкләреннән* ***ясалучы*** *биоматериал* (дөресе – *күзәнәкләреннән* ***ясала торган*** *биоматериал).*

Икенче интерференция хатасы *-ган/-гән, -кан/-кән* кушымчасы белән ясалган үткән заман фигыль формаларының төрле функцияләр башкаруын белмичә, рус телендәге хәзерге заман причастиесенә ияреп, *-ган/-гән, -кан/-кән* формасы урынына ялгыш *-учы/-үче* кушымчалы хәзерге заман сыйфат фигыльләр куллану-дан гыйбарәт.

*-ган/-гән, -кан/-кән* кушымчасы белән ясалган сүзләр үткән заман сыйфат фигыльләр дип аталса да, аларның вазыйфасы предметның билгесен сөйләү вакытына кадәр булган эш-хәл аша белдерү генә түгел. Бу фигыльләрнең бер функциясе – үткәндәге

процесс билгесенең хәзер дә дәвам иткән нәтиҗәсен белдерү. *Безнең биләмәләребезне* ***урап алучы*** *елга шундый сай* фразасында *урап алучы* дөрес түгел, *урап алган* булырга тиеш, *чылтырап агучы чишмә* түгел, *чылтырап аккан чишмә* бит.

Предметның сөйләү вакытына кадәр булган процесс аша белдерелгән билгесен *-учы-үче* кушымчалы сыйфат белән тәгъбир итү – тупас хаталарның берсе. Хәлбуки мондый ялгышлар матбугат телендә еш очрый. Мисаллар:

*Бүген республикабызда 7 меңгә якын сәяси яктан* ***зыян күрүче*** *яши* ( *...зыян күргән кеше яши* кирәк.).

*Ә бит ул (В.В.Радлов) – Россия тюркологиясенә нигез* ***салучыларның*** *берсе, төрки халыкларның телен, тарихын, ...* ***өйрәнүче*** *һәм фәнни хезмәтләр язып* ***калдыручы*** *зур галим* (дөресе – ***нигез салган, ...өйрәнгән һәм ...язып калдырган*** *зур галимнәрнең берсе*).

Тәрҗемәләрдә рус теленең кайбер морфологик формаларын механик рәвештә күчереп кую – калькалаштыру аркасында татар теленең грамматик нормалары бозылу күренешләре бар.

Йөкләтү юнәлеше формасы урынына ялгыш төп юнәлеш формасын кулланалар: Әңгәмәбезне алга таба дәвам итәбез (радио) (дөресе – әңгәмәбезне дәвам иттерәбез).

Рус телендәге кечерәйтү-иркәләү кушымчаларын калькалаштыралар: оныкчык, кызчык, китапчык, шәһәрчек, төнкәй. Болар, әлбәттә, табигый күренеш түгел. Татар теленең андый мәгънәләрне белдерерлек үз чаралары бар.

Кыскасы, русчадан татарчага тәрҗемә итүдә ялгышлар күп. Нәтиҗәдә туган тел нык бозыла. Бу хәлдән котылу өчен, татар телен урта һәм югары уку йортларында яхшырак өйрәтергә кирәк, һәм журналистлар тәрҗемә принципларыннан, метод һәм алымнардан хәбәрдар булырга тиеш.

## НИЧЕК ЯЗСАҢ ДА ЯРЫЙМЫ?

“Гаилә гәҗите” һәм “Юлдаш” газеталарын укып, мине нык гаҗәпләнү катыш зур канәгатьсезлек хисләре биләп алды. Һәр ике газета да гадәти әдәби телдән үзгә, ниндидер бер ясалма, сәер телдә языла икән. Аларда басылган язмаларны укыганда, бу газеталарны чыгаручылар, миллионлаган татар халкының меңнәрчә

еллар буена формалашып, камилләшеп килгән телен санга сукмыйча, үзләре теләгәнчә үзгәртелгән телдә иҗат итәргә дигән карарга килгәннәр икән дип уйлыйсың. Аннары тагын бу газеталарны оештыручы каләм ияләре татар әдәби теле фәненнән, журналистика таләпләреннән хәбәрдар түгел, ахрысы, дигән фикер дә туа.

Мондый кырыс фикерне конкрет мисаллар белән дәлилләргә кирәклекне истә тотып, исемнәре аталган газеталарның теленә берникадәр анализ ясап, үзебезнең карашыбызны белдереп китик.

Беренчедән, газеталарда иң күзгә ташланган нәрсә шул: язмаларда аңлашылмый яки авыр аңлаешлы сүзләр бик күп. Алар килеп чыгышлары һәм төзелешләре буенча газета әһелләре үзләре ясаган һәм күбесенчә уңышсыз ясалган лексик чаралардан, иске әдәби телдә кулланылып, хәзер инде кулланылыштан чыккан гарәп һәм фарсы алынмаларыннан, диалектализм һәм гади сөйләм сүзләреннән гыйбарәт. Андый сүзләр бик күп булганлыктан, аларның бер өлешен генә күрсәтеп китәрбез.

“Юл **вәкыфләрен кыек салым** белән бәйләмәсәң дә ярый”; “Үзәкнең **көндәшлек хезмәте**”; “**Тамгалык җыемы**”; “Китап-**тәкъвимнәргә** язылa аласыз”; “**Азык чытыры**”; “**Мәтбага**: Казан, **Җәмашев зурур, 37**”; “**Ленинтау”; Түбән Чулман; “Яшелчәк”; “Авазә”; Будда рәһибе, Өстенәүкәт; “Зәнҗәбил** тамыры**”; “Элпәле** савыт-саба тәбигый **әчемнәргә** бирешми”; “**Җуганда** йомшак **болытча** гына кулланыгыз”; “**Җылыткычлар** ут кебек кызу иде”; “**Корычатчы** булып күмәк хуҗалыкта калдым”; “**Мәетлек**”; “Хатлар язу өчен **сәрнәмә баглантылар**”; “**Ташыма** салымы түләүдән азат ителәчәк”; “Мәхкәмә **кайтарма акча** түләү турында карар чыгарды”; “**Сазлак** та суны йомшартырга ярдәм итә”; “Мин **рухан**”; “**Күмәк җитәк** килеп керде”; “**Күрсәткедән** аналары ташлап киткән балалар”; “**Күренгечләрне** барлап”; “**Сатмалык** буенда басып торган ханым”; “**Раслыкнамә**”; “Казанның **туптибәрләр такымы”,** “**Йомыкыйлык** чире белән авыручы яшүсмер”; “Зяб бистәсе 18нче **тораклыгы**”; “**Ягулык-утчылык һөнәрияте**”; Казанда **авыруларга бирешмәүчәнлек зәгыйфьлегенә китерүче йогыш** (ВИЧ) булган кешеләр саны буенча куркыныч хәл күзәтелә.

Мондый башваткыч сүзләр һәм җөмләләрдән торган текстларны укучылар ничек кабул итәләр икән һәм аларны аңлап укыйлармы икән?

Телебездә инде дистәләрчә, йөзләрчә еллар кулланылып килгән һәм һәркемгә яхшы аңлаешлы сүзләрне халык аңламаслык,

уңышсыз ясалган сүзләр белән алмаштыруның кемгә һәм нигә кирәге бар икән? "Гаилә гәҗите" һәм "Юлдаш" газеталары эшләгәнчә, таблица сүзен **җәдвәл** (*тапкырлау җәдвәле*) дип, командировканы **эшсәфәр**, лифтны **меңгермәлек** ("*бер эшче меңгермәлек коесына төшеп киткән*"), изоляторны **тотмалык**, пособиене **эшсезлек акчасы**, автомобильне **тимерат,** компьютерны **санак**, ферманы **терлекхәнә**, гостиницаны **юлхәнә**, училище, колледжны **һөнәрхәнә**, саклык банкын **акчахәнә, акчалык** дип үзгәртү һәм башка күп санлы мөгез чыгаруларның телдә буталчыклыкка, аңлашылмаучылыкка китерүе көн кебек ачык.

Әлеге газеталарның журналистлары яңа сүзләр уйлап чыгару белән шулкадәр мавыгалар, хәтта **телефон (шалтыраткыч), нефть (карамай), газ (зәңгәр ягулык), финанс министрлыгы (акча эшләре министрлыгы)** кебек сүзләрне дә "татарчалаштырып" маташалар.

Туган телебезне куллануда башбаштаклык, анархия булырга тиеш түгел: бер генә газета һәм журналны да аны иҗат итүчеләрнең үзләре теләгәнчә үзгәртелгән телдә язарга хаклары юк. Безнең югары дәрәҗәле, бай тарихлы, камил төзелешле әдәби телебез бар, һәм ул бернинди төзәтү, "сипләү"гә мохтаҗ түгел. Барлык газета-журналлар да, радио-телевидение тапшырулары да шушы телдә гамәлгә ашырылырга тиеш. Һәр мәкалә дә, эфир тапшыруы да һәркемгә аңлаешлы дөрес, матур әдәби телдә башкарылырга тиеш.

Үзен журналистикага багышлаган һәрбер каләм иясе, тел ярдәмендә башкарылырга тиешле җитди эшкә керешкәнче, татар әдәби телен, аның бөтен үзенчәлекләрен, кагыйдәләрен, нормаларын, шул исәптән сүзләрне сөйләмдә белеп куллану, дөрес язу тәртибен яхшылап өйрәнергә тиеш. Әдәби телне ярым-йорты гына үзләштергән килеш, нинди дер яңа тел төзү белән шөгыльләнеп маташырга кирәкми.

"Гаилә гәҗите", "Юлдаш" газеталарындагыча, йөзләрчә сүзләрнең орфография сүзлекләрендә теркәлгән, меңләгән язучылар, журналистлар, укытучылар, башка төрле белгечләр дистәләрчә еллар күнеккән язылыш тәртибен бозып, тузга язмаган рәвештә кулланылуын аңлап та, аңлатып та булмый. Гыйбрәт өчен бу газеталарның декабрь аенда чыккан 47, 51 нче саннарындагы текстлардан алынган сүзләрнең язылышына игътибар итик:

**Иркөт** (Иркутск), **Сургыт** (Сургут), **Кәмил** (Камил), **Вәһит** (Вахит), **Әлбирт** (Альберт), **Рәдик** (Радик), **Зәһитева** (Заһитова),

**Җәмашев** (Ямашев), **әдәм** (адәм), **хәстә** (хаста), **мәшәкәт** (мәшәкать), **сәләмәт** (сәламәт), **һәләкәт** (һәлакәт), **бәлә** (бәла), **кәдерли** (кадерли), **ниһәят** (ниһаять), **хәләт** (халәт), **аугуст** (август), **синтәбер** (сентябрь), **наябер** (ноябрь), **дикәбер** (декабрь), **сәләр** (соляр), **кәдәр** (кадәр), **мәглүмәт** (мәгълүмат), **кәбер** (кабер), **иләһи** (илаһи), **шәфкәт** (шәфкать), **йәмле** (ямьле), **җуып алырга** (юып алырга), **тәбигый** (табигый), **кәчтрүл** (кастрюль), **балкашык** (бал кашыгы), **ыстакан** (стакан), **һәләл** (хәләл), **маяниз** (майонез), **кәнсирләнгән әнәнас** (консервланган ананас), **памидур** (помидор), **кәнәфер** (канәфер), **кәбәхәт** (кабәхәт), **хәттә** (хәтта), **идәрә** (идарә), **кәләм** (каләм), **җоклау** (йоклау), **элиминт** (алимент), **мәтди** (матди), **кәнәгатьсезлек** (канәгатьсезлек), **градыс** (градус), **хәйван** (хайван), **гөрәл** (горилла), **хәүфле** (хәвефле), **мәтбага** (матбага), **шәһәдәт** (шәһадәт), **мөләем** (мөлаем), **хәттә** (хәтта), **курткы** (куртка), **хәтирә** (хатирә), **җегет** (егет), **җылый** (елый), **тәләп итү** (таләп итү), **фиркә** (фирка), **кина** (кино), **кила (**кило), **сүрәт** (сурәт), **берәз** (бераз), **җәрәһәт** (җәрәхәт), **җәһит** (яһүд), **Алийә** (Алия), **Илиас** (Илъяс), **җинәят** (җинаять).

Мондый сәер сүзләр исемлеген дәвам иттерергә була. Ләкин күрсәтелгәннәреннән дә җитди нәтиҗәләр ясарга мөмкин.

“Гаилә гәҗите”, “Юлдаш” газеталарын чыгаручылар, татар әдәби телен тупас бозып, халыкка аңлашылмый торган йөзләрчә ясалма лексика кулланып, традицион орфография кагыйдәләре белән исәпләшмичә, меңнәрчә сүзләрне гарипләндереп язып, нинди максатка ирешергә телиләр икән? Бәлки, алар башка журналистлардан ничек булса да аерылып тору, үзләрен өстен кую, оригиналь итеп күрсәтү өчен шулай эшлиләрдер дип уйларга туры килә.

Ничек кенә булмасын, мондый “новаторлык” матбугат ярдәмендә халыкка дөрес, саф, популяр телдә кызыклы, мәгънәле, файдалы информация бирү, яшьләрне, урта буын кешеләрен үрнәк татар теленә өйрәтүгә ярдәм итү бурычларына һич кенә дә җавап бирми.

Йомгаклау сүзе: матбугат органнары өчен җаваплы Татмедиа, Журналистлар союзы һәм башка оешмалар, газета-журналларның хәле белән даими кызыксынып барып, аларның телләренең сыйфатына да игътибар итәрләр, мәгълүмат чараларының эшендә анархия хөкем сөрүгә юл куймаслар дип ышанасы килә.

# АЛЫНМА СҮЗЛӘРНЕ КУЛЛАНУ

Соңгы елларда мәгълүмат чараларында рус алынмаларының һәм халыкара сүзләрнең (интернационализмнарның) чыганак телдәгечә әйтелеш һәм язылыш формаларын үзгәртергә омтылу – “татарчалаштыру” тенденциясе хөкем сөрә.

Татар телендә күренекле тел галимнәре тарафыннан алынма сүзләрнең әдәби телдә кулланылуына карата төптән уйланылган әһәмиятле принциплар, кагыйдәләр төзелгән. Аларның берсе шуннан гыйбарәт: узган гасырның 20-30 нчы елларына кадәр кабул ителгән рус сүзләре һәм интернационализмнар сөйләм телендә үзләштерелгәнчә әйтелә һәм языла (*эскәтер, камыт, буразна, өстәл* һ.б.), телебезгә соңгырак чорда кергәннәре исә, нигездә, чыганак телдәге әйтелеш һәм язылыш формаларында кулланыла. Бу принцип күп дистә еллар буена сакланып килде, һәм аны ясалма рәвештә үзгәртергә омтылу хәзерге чорның хосусиятенә туры килми.

Хикмәт шунда: икетеллелек шартларында республикабызда яшәүчеләр өчен уртак сүзләрнең татарча әйтелешен һәм язылышын махсус үзгәртү, шул рәвешле рус һәм татар телләрендәге гомуми лексика арасында ясалма рәвештә аерма китереп чыгару практика өчен дә, телләрне өйрәнү һәм алардан файдалану өчен дә уңайсызлык, тотрыксызлык китереп чыгара. Шуңа күрә телебез лексикасында мондый реформа үткәрергә маташуның кирәге юк.

Мәгълүмат чараларындагы бу темага караган кайбер ялгышлар һәм аларның төзәтмәләре:

| **ялгыш** | **дөрес** |
|---|---|
| Бигрәк тә *кампитр* технологиясендә алга китеш. | Бигрәк тә *компьютер* технологиясендә алга китеш. |
| Түбән майлылыктагы эремчек, *йогырт...* | Түбән майлылыктагы эремчек, *йогурт...* |
| Суган салып төнәтелгән аракыны сөзеп *әбәд* алдыннан унар тамчы эчү. | Суган салып төнәтелгән аракыны сөзеп *төшке аш* алдыннан унар тамчы эчү. |
| *Әмрикәдән* килгән ризык. | *Америкадан* килгән ризык. |
| Казанга яңа елга фәлән *ишалун* кар җибәрәчәк, имеш. | Казанга яңа елга фәлән *эшелон* кар җибәрәчәк, имеш. |
| ...кабат *кантрульгә* алдык дигән сүзләр әйтә торган түрәләр... | ...кабат *контрольгә* алдык дигән сүзләр әйтә торган түрәләр... |

| | |
|---|---|
| Бөтен җирдә уйный торган уен ул *кәрт.* | Бөтен җирдә уйный торган уен ул *– карта уены* |
| Калын *пәлтә*, олтанлы итек кидем. | Калын *пальто*, олтанлы итек кидем. |
| Татар *гәзитенә* яздыруга бер меңнән артык тираж җыя алдык. | Татар *газетасына* яздыруга бер меңнән артык тираж җыя алдык. |
| *Гәҗит*-журналларга язылу башлана. | *Газета*-журналларга язылу башлана. |
| Теге башта чуаш *әртисләре* әйттерә, бу башта – *Арчалар.* | Теге башта чуаш *артислары*, бу башта *Арчалылар* әйттерә. |
| Гонорарыннан бер *кәньяк* алган да урамнан һаваланып атлаган. | Гонорарыннан бер (шешә) *коньяк* алган да урамнан һаваланып атлаган. |
| Милләтләрне, укмаштырып, бер *сәвит* халкына әверелдерергә маташтылар. | Милләтләрне, укмаштырып, бер *совет* халкына әверелдерергә маташтылар. |
| Ике республика арасындагы *тауар* әйләнеше. | Ике республика арасындагы *товар* әйләнеше. |
| Биредә вафлилы *кәнфитләр* җитештерелә. | Биредә вафлилы *конфетлар* җитештерелә. |
| Тавык *кәтлите.* | Тавык к*отлеты.* |
| Ул – *мангул* яуларын туктатучы... | Ул – *монгол* яуларын туктатучы... |
| Карсыз декабрь, җылы *гыйнвар.* | Карсыз декабрь, җылы *январь.* |
| *Тупыллар* яктылыкны томалый. | *Топольләр* яктылыкны томалый. |
| Көндез температура *плүс* 18 градуска *кадәр* җитәр, дип көтелә. | Көндез температура *плюс* 18 градуска җитәр, дип фараз ителә. |
| Электр була торып, *керәчен* лампасы кулланучы... | Электр була торып, *керосин* лампасы кулланучы... |
| Анда *җәгърәфия*, хисап, япон теле кебек дәресләр бирелгән. | Анда *география*, хисап, япон теле кебек дәресләр бирелгән. |
| Быел *нимес* телен өйрәнә. | Быел *немец* телен өйрәнә. |
| Пенсия реформасы *тупыйкка* юлыгачак. | Пенсия реформасы *тупикка* юлыгаячак (теръләчәк, эләгәчәк). |
| *Үктәбер инкыйлабы* карак малайлар тудыра. | *Октябрь революциясе* карак малайлар тудыра. |
| Бу исемлекнең башында, әлбәттә, күренекле галим, *фәйләсуф* һәм дин эшлеклесе Шиһабетдин Мәрҗани тора. | Бу исемлекнең башында, әлбәттә, күренекле галим, *философ* һәм дин әһеле Шиһабетдин Мәрҗани тора. |
| Шәйморза *крәстиән* хуҗалыгына җитәкчелек иткән. | Шәйморза *крестьян* хуҗалыгына җитәкчелек иткән. |

# ЯЛГЫШ ЯСАЛГАН СҮЗЛӘР

Соңгы елларда татарча матбугатта һәм радио-телевидение тапшыруларында табигый сүз төзелеше кагыйдәләре бозып ясалган сүзләр шактый күп кулланыла. Бу күренешнең нигезендә каләм ияләренең туган телне тиешле дәрәҗәдә белмәүләре һәм русчадан ялгыш тәрҗемә итүләре ята. Бу ике фактор, мәгълүмат чаралары телендә, гадәттә, бердәм чагылыш таба. Фикеребезне ачыклап китик.

Журналистлар русчадан тәрҗемә иткәндә (аларга бу эш белән күп шөгыльләнергә туры килә), нигездә, оригиналның һәрбер сүзенә тәрҗемә телендә дә аерым сүз туры килергә тиеш дигән фикергә таянып эш итәләр, һәм аларның бу элементар ялгышы еш кына тиешле мәгънәне дә һәм телне дә тупас бозуга китерә. Чөнки алар дөрес тәрҗемә итүнең төп шартын – оригиналның сүзен сүзгә белдерү белән мавыкмыйча, текстның, сөйләмнең эчтәлеген, мәгънәсен икенче тел чаралары белән, ул телнең үзен бозмыйча, төгәл итеп белдерергә кирәк дигән таләпне үтәмиләр. Безнең татар журналистлары исә рус теленең һәр сүзен татарчадагы һәр аерым сүз белән бирү генә түгел, ул сүзнең хәтта морфологик төзелешен дә күчереп куялар.

Ялгыш ясалып, мәгълүмат чараларында аеруча еш кулланыла торган кайбер сүзләрне таблица рәвешендә күрсәтәбез.

| **Ялгыш** | **Дөрес** |
|---|---|
| Милли балетка *дәүләти бәя.* | Милли балетка *дәүләт бәясе.* |
| *Әкияти* образларга әйләнә. | *Әкияттәге* образларга әйләнә. |
| *Һөнәри лицей.* | *Һөнәр лицее.* |
| Яшь буынның *экчечелеккә бирелүе* нидән соң? | Яшь буынның *эчүчелеккә бирелүе* нидән соң? |
| Чөнки бу хуҗалыкларда *дуңгызчылык* белән шөгыльләнүдән бөтенләйгә туктаганнар. | Чөнки бу хуҗалыкларда *дуңгыз асрау (тоту)* белән шөгыльләнүдән *(вар.: дуңгыз асраудан)* бөтенләй туктаганнар. |
| Ул *сөтчелек эшендә ил алдынгы сөт алучы* иде. | Ул *сөт җитештерү эшендә ил күләмендәге алдынгы кеше* иде. |
| Сәләй авылы *сарыкчылык фермасын* бетергәч бушап, тынып калды. | Сәләй авылы, *сарык фермасын* бетергәч, бушап, тынып калды. |

| | |
|---|---|
| Юк, мин әле беренче тапкыр гына *чылтыратам* (телефоннан – *Р.Ю.*). | Юк, мин әле беренче тапкыр гына *шалтыратам.* |
| Югары *бәяләнү алган.* | Югары *бәяләнгән.* |
| “Урожай” колхозының алдынгы савымчысы Нурия Вәлиевага да *мактаулы грамота* бирелде. | “Урожай” колхозының алдынгы сыер савучысы Нурия Вәлиевага да *мактау (почет) грамотасы* бирелде. |
| *Газлаштыру* өлкәсендә башкарган эшләребез сөенерлек. | *Газ кертү* өлкәсендә башкарган эшләребез сөенерлек. |
| Мәскәүдә өч меңләп кеше медицинаның сыйфатсызлыгына каршы *йөрешкә* чыкты. | Мәскәүдә өч меңләп кеше медицинаның сыйфаты начар булуга (сыйфатсызлыгына) каршылык күрсәтеп, *урамга чыккан* (вар.: каршылык йөзеннән урамга чыккан). |
| Кырымтатар халкына бәйле мәсьәләләрне уңышлы хәл итүдә ул *кызыксынулы.* | Кырым татарларына бәйле мәсьәләләрнең уңышлы *хәл ителүен тели* (вар.: уңышлы хәл ителүе яклы, уңышлы хәл ителсен иде дигән караштa тора һ.б.). |
| *Өлкәнәйгәч* тә без *бала.* | *Олыгайгач та* без *балалар кебек.* |
| Әлеге сокны (каен суын – *Р.Ю.*) *иртә язда* гына җыеп калып була. | Каен суын *яз башында* гына җыеп калып була. |
| ...2013 елның июленә кадәр *хезмәт куя.* | ...2013 елның июленә кадәр *эшли.* |
| Черкиләрне, *малярия белән йогышлап*, дошман гаскәрләре өстенә сиптерергә җыенганнар. | Черкиләрне, *малярия (бизгәк) йоктырып*, дошман гаскәрләре өстенә сиптерергә җыенганнар. |
| Клаус Шиллинг әсирләрне бизгәк белән *йогышландырган.* | Клаус Шиллинг әсирләргә бизгәк *йоктырган.* |
| Төрки дөньяда язу, *китапчылык*, күн эшләре буенча *фәнни-гамәли* конференцияләр узды. | Төрки дөньяда язу, *китап (бастырып ) чыгару*, күн эшләре буенча *фәнни-практик* конференцияләр узды. |
| ...медицинадан *педагогиягә* күчтем. | ...медицинадан *педагогика өлкәсенә* күчтем. |
| Карчыкның бер улы, дүрт оныгы, алты *оныкчыгы* бар. | Карчыкның бер улы, дүрт оныгы, *онықларының алты баласы* бар. |

| | |
|---|---|
| Авыл *җирлегенең эшчәнлеге* нидә чагыла? | *Авыл халкының хезмәт сөючән* булуы нәрсәдә күренә? |
| *Авыл җирлеге* яхшы эшли. | *Авыл (халкы)* яхшы эшли. |
| Тимершык *авыл җирлегенә* биш авыл карый. | Тимершык *авылы идарәсенә* биш авыл карый. |
| *Агымдагы елга* килгәндә, ул истәлекле вакыйгаларга шактый бай булыр кебек. | *Бу ел* истәлекле вакыйгаларга шактый бай булыр кебек. |
| 1943 елда әтиемнең *туганнан туган* энесе Гаяз Сименеевны җәзалап *үтерделәр.* | 1943 елда әтиемнең абыйсының (энесенең, апасының, сеңлесенең) улын җәзалап *үтергәннәр.* |
| 41 яшьлек ирнең *кул чуклары* зыян күргән. | 41 яшьлек ирнең *кул бармаклары* зыян күргән (вар.: *бармакларына зыян кил*гән). |
| Казанда һәм республикада инвалидлар өчен 238 ярдәмчел корылма төзиячәкбез. Мәгариф, мәдәният, сәламәтлек саклау, социаль яклау учреждениеләре *колачланачак.* | Казанда һәм республикада инвалидлар өчен 238 ярдәмчел корылма төзиячәкбез. Мәгариф, мәдәният, сәламәтлек саклау, социаль яклау учреждениеләре *җәлеп ителәчәк.* |
| Татарстанда мөмкинлекләре чикле кешеләрне тиешле *шартлар белән тәэмин итү буенча эшчәнлек* дәвам итә. | Татарстанда мөмкинлекләре чикле кешеләргә тиешле *шартлар булдыру эше* дәвам итә. |
| М.Е.Кухарчук *хезмәт эшчәнлеген* колхозда бухгалтер булып башлый. | М.Е.Кухарчук *хезмәт биографиясен* колхоз бухгалтеры булып башлый (...колхозда бухгалтер булып эшли башлый). |
| Халыкны *бернишләтеп* тә булмый аны. | Халыкны *берни дә эшләтеп* булмый аны. |
| М.Госманов – халыкара масштабта да *танылу алган* галим. | М.Госманов – халыкара күләмдә (яки дәрәҗәдә) (чит илләрдә дә) *танылган (мәгълүм)* галим. |
| Ул *чыганакчылык гыйлеме* белән махсус шөгыльләнә башлый. | Ул язма *чыганаклар белән махсус* шөгыльләнә башлый (Ул язма чыганакларны махсус өйрәнә башлый һ.б.). |
| Сорауларыгыз булса, *шылтыратыгыз.* | Сорауларыгыз булса, *шалтыратыгыз.* |

| | |
|---|---|
| Соңрак бу хәл *чыганакчы тарихчының* профессиональ *эшчәнлегенә* уңай тәэсир ясый. | ... *язма чыганаклар белән эшләүче тарихчының* профессиональ *эшенә* уңай тәэсир ясый. |
| Элек Татарстан парламентында даими рәвештә *хезмәт куючы* 20 депутат кына хисап тота иде. | Элек Татарстан парламентында даими рәвештә *эшләүче* 20 депутат кына хисап тота иде. |
| Кыйммәтле ювелир *бизәнгечләрен* урлаганнар. | Кыйммәтле ювелир *бизәнү әйберләрен* урлаганнар. |
| Төзү эшләрен башлап җибәрү өчен, төзелеш *рөхсәтнамәсе* кирәк. | Төзү эшләрен башлап җибәрү өчен, төзелеш *лицензиясе* кирәк. |
| *Кызчыкның* белемне үзләштерү дәрәҗәсе *кимеде.* | *Кызның* белемне үзләштерү дәрәҗәсе *кимеде* (вар.: *түбәнәйде*) |
| Һава ширкәте *сүзчесе* Гөлназ Миңнеханова... | *...пресс-секретаре* Гөлназ Миңнеханова... |
| Бала мәктәптән кайтып төнгә кадәр *санак* каршында утыра. | Бала, мәктәптән кайтып, төнгә кадәр (төн җиткәнче) *компьютер* каршында утыра. |
| Алар арасындагы *иң-иңнәр* 10 мең педагогны укытырга ирешәчәк. | Алар арасындагы *иң яхшылары(?),(иң тәҗрибәлеләре(?); (иң зур белемлеләре?); иң әзерлеклеләре(?) һ.б.)* 10 мең педагогны укытуга ирешәчәк. |
| Татарстанда иҗат ителгән көйләрнең *иң-иңнәрен* бөтен Россиядә ишетәчәкләр. | Татарстанда иҗат ителгән көйләрнең *иң яхшыларын (иң матурларын һ.б.)* бөтен Россиядә ишетәчәкләр. |
| Ул мәгърифәт өлкәсендә дә зур *эшчәнлек күрсәткән.* | Ул мәгърифәт өлкәсендә дә зур *эшләр башкарган (яки күп эшләгән)..* |
| Ферма *эшчәннәре* ... барлык көчләрен куялар. | Ферма *эшчеләре* ... барлык көчләрен салалар (куялар, бирәләр). |
| ...кооператив хуҗалык *хезмәтчелләре* яшь*производствочыларны* армиягә озаттылар. | ...кооператив хуҗалык *кешеләре (халкы) үзләрендә эшләгән егетләрне* армиягә озаттылар. |
| Казандагы әлеге бакчада *шөгыльләр* уздырганда дидактик материаллар... җитми икән. | Казандагы бу бакчада *дәресләр* уздырганда дидактик материаллар... җитми икән. |
| ... дип *җаваплады* хуҗабикә. | ... дип *җавап бирде* хуҗабикә. |

| | |
|---|---|
| *Кырымтатар* халкына бәйле мәсьәләләрне уңышлы хәл итүдә ул *кызыксынулы.* | Ул *Кырым татарларына* бәйле мәсьәләләрне уңышлы *хәл итү яклы (*вариант*: хәл ителүен тели; хәл ителергә тиеш, ди).* |
| Безнең мәгарифтә уңышларыбыз бар, дип *басым ясап әйтте* И.Халиков. | Безнең мәгарифтә уңышларыбыз бар, *диде* (вариант: *дип әйтте*) И.Халиков. |
| Йөзегезгә карагач, *ярымай* күренә. | Йөзегез *ай* кебек балкый (вариант: йөзегездән ай нуры сирпелә...). |
| Бу көннәрдә *һава шартларының* сизелерлек *үзгәрүе көтелә.* | Алдагы *көннәрнең* җитди *үзгәрүе мөмкин..* |
| Температура төнлә 17 градуска кадәр *түбәнгә төшәчәк.* | Температура төнлә 17 градуска кадәр *түбәнәячәк.* |
| ...2013 елның июленә кадәр *хезмәт куя.* | ...2013 елның июленә кадәр *эшли.* |
| ...хезмәттәшлек турында килешүләр *имзалады.* | ...хезмәттәшлек турындагы килешүләргә *имза куйды (вар.: кул куйды).* |
| Исерек килеш йөргән өчен *штраф сукканнар.* | Исерек килеш йөргән өчен *штраф салганнар.* |
| Биюләре *уткабызгычлы...* | Биюләре *дәртле...* |
| “Муса Җәлилнең *ике туган абыйсы* буларак, Таһир Яхъя улы...” | “Муса Җәлилнең *әтиләре (әниләре) бертуган абыйсы буларак*, Таһир Яхъя улы...” |
| “Бу юлы “Рубин” үз кырында “Динамо” белән *җиңешә* алмады”. | “Бу юлы “Рубин” үз кырында “Динамо”ны *җиңә* алмады”. |
| “Филология һәм сәнгать институты каршында *урыс телле* кешеләр өчен... курслары эшли башлады”. | “Филология һәм сәнгать *институтында рус телендә сөйләшүче* кешеләр өчен... курслар эшли башлады”. |
| “*Китапчыкка* шигырьләрең сайлап алып кына кертелдеме?”. | “*Китапка* шигырьләрең сайлап алып кына кертелдеме?”. |
| “Филология, т*әрҗемәчелек* дигән төркем тупланды”. | “Филология, т*әрҗемә белеме (тәрҗемә фәне)* дигән төркем тупланды”. |
| “Пермь якташлыгы оешмасы якташларны *Дәрвишләр бистәсе* аланына очрашуга чакыра”. | “Пермь якташлыгы оешмасы якташларны *Дербышки поселогы* аланына очрашуга чакыра”. |
| “Татарча-русча-инглизчә *сөйләүлек* чыгачак”. | “Татарча-русча-инглизчә *сөйләшү китабы* чыгачак”. |

| | |
|---|---|
| “*Төнгелеккә улакларга туйганчы* силос салабыз”. | “*Төнгә тагаракларга маллар туярлык итеп* силос салабыз”. |
| “Ел ахырына Кәҗә бистәсе станциясен *төзеп тәмамлау* планлаштырыла”. | “Ел ахырына Кәҗә бистәсе станциясен *төзеп бетерү* планлаштырыла”. |
| “Гамәлдәге *закончалыклар* нигезендә...” | “Гамәлдәге *законнар* нигезендә...” |
| *“Мөмкинчелек”* | *“Мөмкинлек”* |
| “...Садриевның язмасы *башисемен* бераз үзгәртеп...” | “...Садриев язмасының *исемен* бераз үзгәртеп...” |
| *“Минем белән бар да яхшы”.* | *“Минем хәлем әйбәт (Минем зарланырлык урыным юк)”.* |
| “*Синең белән* берәр нәрсә булгандыр, дип борчылдым”. | “*Сиңа* берәр нәрсә булгандыр, дип борчылдым”. |
| “Тынычлыкта калдыр!”. | “Бәйләнмә!” һ.б. |
| “*Дәүсовет* утырышларында...” | “*Дәүләт Советы* утырышларында...” |
| “Ник дәүләтсез иттең мине *бүгенгемдә*?”. | “Ник дәүләтсез иттең мине *бүген*?”. |
| “Корбан бәйрәменә сарыклар сатам. *Аяклата* һәм суеп”. | “Корбан бәйрәменә сарыклар сатам. *Тере килеш* һәм суеп”. |
| ...“Татарстан – Яңа гасыр” иҗтимагый хәрәкәтенең җирле *бүлекчәләре* рәисләре белән очрашты. | ... “Татарстан – Яңа гасыр” иҗтимагый хәрәкәтенең җирле *бүлекләренең* рәисләре белән очрашты. |
| Яшьләр хәзер аракыны *шешә тамагыннан* гына эчәләр. | Яшьләр хәзер аракыны *шешә авызыннан* гына эчәләр. |
| ...өченче урынга исә Берләшкән Гарәп Әмирлекләрендәге Бурж-Хәлифә *күктерәр йорты* куелган. | ...өченче урынга исә Берләшкән Гарәп Әмирлекләрендәге Бурж-Хәлифә *небоскребы* (бик биек йорты) куелган. |
| Уйгур әдәбиятын да өйрәнеп, *киң катлау укучыга...* тәкъдим итте. | Уйгур әдәбиятын да өйрәнеп, *күп санлы укучыларга...* тәкъдим итте. |
| Авылыбыз артында *биек булмаган* таулар, калкулыклар бар. | Авылыбыз артында *тәбәнәк* таулар, калкулыклар бар. |
| Безне *зур булмаган* бүлмәгә урнаштырдылар. | Безне *кечерәк кенә бер* бүлмәгә урнаштырдылар. |
| Президент сараеннан *ерак булмаган* бер ашханәнең эшләве мәгълүм булды. | Президент сараена *якын гына бер* ашханәнең эшләве мәгълүм булды. |

| | |
|---|---|
| Авыл хуҗалыгы өчен *зур булмаган* бер мәсьәлә чишү... | Авыл хуҗалыгы өчен *кечерәк кенә* бер мәсьәлә чишү... |
| 2014 ел *эшчәнлегенә* йомгак ясап кына калмыйча, *агымдагы елга* да күп *йөкләмәләр куелды.* | 2014 ел *эшенә* йомгак ясап кына калмыйча, *бу елга* да күп *йөкләмәләр алынды.* |
| Россия күләм турнирда юлларда *тайгыч.* | Россия күләм турнирда юлларда *тайгак.* |
| Шартлау сәүдә үзәгенә һәм мәчеткә *керештә* булды. | Шартлау сәүдә үзәгенә һәм мәчеткә *керә торган урында* булды. |
| Мөхәммәт Мәһдиевнең *истәлекханәсе* ачылуга да 10 ел үтеп киткән. | Мөхәммәт Мәһдиевнең *музее* ачылуга да 10 ел үтеп киткән. |
| ...тынгысыз затлар халкыбыз *туплау яшәгән* башка төбәкләрдә дә театрлар оештыра. | ...тынгысыз затлар халкыбыз *тупланып (оешып) яшәгән* башка төбәкләрдә дә театрлар оештыра. |
| *Дәүләтчелек* булу. | *Дәүләт төзелеше, дәүләтле, дәүләте булу.* |
| Татарстан Республикасында кече һәм урта *эшкуарлыкны* үстерү турында ... | Татарстан Республикасында кече һәм урта *бизнесны* үстерү турында ... |
| ...дип *җаваплады* хуҗабикә. | ...дип *җавап бирде* хуҗабикә. |
| Арцебарскийның тормыш юлын *нечкәләсәң*, аның чыннан да, эзлекле рәвештә үз максатына барганын чамалыйсың. | Арцебарскийның *тормыш юлы белән танышсаң*, аның чыннан да, эзлекле рәвештә үз максатына барганын чамалыйсың. |
| 12 июнь – Россия көне – *эш көне булмаган* бәйрәм санала. | 12 июнь – Россия көне – *яллы* бәйрәм санала. |
| Барыбызның да *эшчәнлеге* белән идарә итә торган координацион үзәк. | Барыбызның да *эше* белән идарә итә торган координацион үзәк. |
| Иң аянычы шул: Россиядә *эчкечелек* яшәрде. | Иң аянычы шул: Россиядә *эчүчелек* яшәрде. |
| Казан *педагогия* көллияте. | Казан *педагогика* көллияте (*колледжы*). |

| | |
|---|---|
| *Һөнәри лицей.* | *Һөнәр лицее.* |
| *Рәсәй, Русия.* | *Россия.* |
| Клаус Шиллинг әсирләрне бизгәк белән *йогышландырган.* | Клаус Шиллинг әсирләргә бизгәк *йоктырган.* |
| Нинель Юлтыева сәнгать җитәкчесе *вазыйфасында хезмәт куйды.* | Нинель Юлтыева сәнгать җитәкчесе *булып эшләде* (*вазыйфасын башкарды).* |
| Элек Татарстан парламентында *даими рәвештә хезмәт куючы* 20 депутат кына хисап тота иде. | Элек Татарстан парламентында *даими рәвештә эшләүче* 20 депутат кына хисап тота иде. |
| Әлеге сокны (каен суын) *иртә язда* гына җыеп калып була. | Әлеге сокны (каен суын) *яз башында гына* җыеп калып була. |

## МОРФОЛОГИК КҮРЕНЕШЛӘРДӘН ДӨРЕС ФАЙЛАНУ ЗАРУРЛЫГЫ

Бүгенге мәгълүмат чаралары һәм башка төрле материаллар телендә морфологик формаларны кулланудагы ялгышларның күбесе, лексика-фразеология өлкәсендәге кебек, тәрҗемә иткәндә рус теленә генә хас үзенчәлекләрне, белмичә, татар теленә күчереп кую нәтиҗәсендә барлыкка килә. Шуны исәпкә алып, морфология өлкәсенә караган хаталарны анализлау күбесенчә рус һәм татар телләрендәге гомуми һәм үзенчәлекле күренешләрнең нисбәтен тасвирлау җирлегендә башкарыла.

Рус һәм татар телләренең морфологик чараларында, телләрнең башка элементларындагы кебек үк, бертөрле һәм охшаш күренешләр белән үзенчәлекле билгеләр үрелеп бара.

Үзара мөнәсәбәттәге телләрнең гомуми һәм үзенчәлекле (специфик) грамматик күренешләреннән тиешенчә хәбәрдар булмау һәм бу телләрнең бертөрле, охшаш морфологик билгеләрен специфик үзенчәлекләреннән аера белмәү тәрҗемәдәге яманаты чыккан формализмга – рус теленең специфик морфологик күренешләрен татар теленә, һәм, киресенчә, татар теленекен рус теленә күчереп куюга сәбәп була. Бу исә оригиналны тулы итеп гәүдәләндерергә мөмкинлек бирми һәм тәрҗемә теленең грамматик нормалары бозылуга китерә.

Бу язмада, рус һәм татар телләрендәге морфологик күренешләр каралып, тәрҗемә процессында рус морфологиясенең кайбер формаларын татар теленә механик рәвештә күчереп кую аркасында, телебезнең әдәби нормалары бозылу хәлләренә анализ ясала һәм рус теленең морфологик формаларын калькалаштыру белән мавыгу нәтиҗәсендә хаксыз рәвештә татар теленең төрле грамматик үзенчәлекләренең тулы файдаланылмавы очраклары күрсәтелә.

Рус теле морфологиясенең татар теленә интерференциясенең кайбер аеруча киң таралган очракларын күздән кичерик.

| **Ялгыш** | **Дөрес** |
|---|---|
| Ул инвалидларны самолетка менгерүгә *көйләнелгән.* | Ул инвалидларны самолетка менгерүгә *көйләнгән.* |
| Кайнар эздән үтерүдә *шикләнелүче* дә табылган. | Кайнар эздән үтерүдә *шикле* кеше дә табылган. |
| Авылны *ямьләгән* гаилә. | Авылны *ямьләндергән* гаилә. |
| ...товар тамгасын рөхсәтсез *файдаланылганы* өчен штрафка тартылган. | ...товар тамгасын рөхсәтсез *файдаланганы* өчен штрафка тартылган. |
| Ләкин ул *ризалашмый.* | Ләкин ул *риза булмый.* |
| “Мин кайсы эштә *эшләмәсәм дә*”... – ди Эльмира Зарипова. | “Мин нинди генә эштә *эшләсәм дә*”... – ди Эльмира Зарипова. |
| Татарстанда хәзер 65180 чит ил *гражданины теркәүдә тора.* | Татарстанда хәзер 65180 чит ил *гражданы теркәлгән.* |
| КФУ студентлары *кайда* гына бармыйлар. | КФУ студентлары *кая* гына бармыйлар. |
| *Юрганга карап...* | *Юрганыңа карап...* |
| *1962 нче елларда* республикада 5 меңнән артык авыл булган. | *1962 нче елда* (яки 1960 нчы елларда) республикада 5 меңнән артык авыл булган. |
| *Бүлекчәдә* хатын-кызлар да күп. | *Бүлектә* хатын-кызлар да күп. |
| Сезнең гаиләдә биш кеше *исәпләнелә.* | Сезнең гаиләдә биш кеше *исәпләнә.* |
| Зөфәр Хәйретдиновның *чәчләре.* | Зөфәр Хәйретдиновның *чәче.* |
| Әлеге илдән *җимешләр* кертүне туктатты. | Бу илдән *җиләк-җимеш* кертүне туктатты. |
| Мин һәр көнне аларның күңел җылысын *тойдым.* | Мин һәр көнне аларның күңел җылысын *тоеп тордым.* |

| | |
|---|---|
| Ике ел буе безне экстремизм, ваһабизм тамыр җәя... дип *куркыттылар.* | Ике ел буе безне экстремизм, ваһабизм тамыр җәя... дип *куркытып килделәр (вар.: куркытып тордылар)..* |
| “Умырзая” ансамбле концертларына халык күп йөри. Залда буш урын *юк.* | “Умырзая” ансамбле концертларына халык күп йөри. Залда буш урын *булмый.* |
| Поездда еланны *онытткан.* | Поездда еланны *онытып калдырган.* |
| Минтимер Шәймиев, чәчкә куйгач, ветераннар янына *утырды.* | Минтимер Шәймиев, чәчәк куйгач, ветераннар янына *килеп утырды.* |
| Азык-төлек пакетлары *илтелде.* | Азык-төлек пакетлары *илттерелде.* |
| Ничек болай *чыкты* соң ул? | Ничек болай *килеп чыкты* соң ул? |
| Эшмәкәр әледән-әле авылына кайтып, якташларының *хәлләрен белешә* һәм ярдәм кирәккән һәркемгә *булыша.* | Эшмәкәр, әледән-әле авылына кайтып, якташларының *хәлләрен белешеп,* ярдәмгә мохтаҗ һәркемгә *булышып тора.* |
| Габдрәшит Ибраһим Тукайдан 30 яшькә өлкәнрәк. 1904 елның ахырында аларның Җаекта *очрашуы да мөмкин.* | Габдрәшит Ибраһим Тукайдан 30 яшькә өлкәнрәк булган. 1904 елның ахырында аларның Җаекта *очрашкан да булуы мөмкин.* |
| Бу арада Балтач көн саен диярлек дәрәҗәле *кунаклар кабул итте.* | Бу арада Балтач көн саен диярлек дәрәҗәле *кунаклар кабул итеп торды.* |
| Бүген... “Татарстан гүзәле” *бәйгесенә* йомгак ясала. Финалга кадәр Татарстан районнарында һәм Казанда матур кызларны *сайладылар.* | Бүген... “Татарстан гүзәле” *конкурсына* йомгак ясала. Финалга кадәр Татарстан районнарында һәм Казанда матур кызларны *сайлап алдылар.* |
| Декабрьнең карлы-буранлы көннәре дә *аз түгел.* | Декабрьнең карлы-буранлы көннәре дә *аз булмый.* |
| Күптән түгел... туганыбыз *үлде.* | Күптән түгел... туганыбыз *үлеп китте.* |

| | |
|---|---|
| *Әгәр* мин авылны ташлап, Казанга барып *урнашсам, аз дигәндә* дә күренекле шагыйрь, яки берәр галим *булыр* идем, чөнки мин укырга, *белем эстәргә* бик һәвәс *зат* булдым. Мәктәпне дә *гел* “бишле”гә генә *тәмамладым.* | *Әгәр дә* мин, авылны ташлап, Казанга барып *урнашкан булсам, һич югында* күренекле шагыйрь яки берәр галим *булган булыр* идем, чөнки мин укырга, *белем алырга* бик һәвәс *кеше* булдым. Мәктәпне дә *гел* “бишле”гә генә *тәмамлаган идем.* |
| “Бердәм Россия” *фиркасе* тарафдарлары *Дәү Думага шикләнелүчеләрне* гарипләндергән өчен полицияне җинаять җаваплылыгыннан азат итү турында *канун өлгесен* тәкъдим иткән. | “Бердәм Россия” *партиясе* тарафдарлары *Дәүләт Думасына шикле кешеләрне* гарипләндергән өчен полицияне җинаять җаваплылыгыннан азат итү турында *закон проекты* тәкъдим иткән. |
| Җитәкчеләр алдына *килеп басучы* проблемаларны аңлыйбыз. | Җитәкчеләр *алдындагы* (вар.: *алдында торган*) проблемаларны аңлыйбыз. |
| Гаҗәеп *операцияләр ясалучы* бүлек ... балалар клиник хастаханәсендә дә ачылачак. | Гаҗәеп *операцияләр ясала торган* бүлек ... балалар клиник хастаханәсендә дә ачылачак. |
| Тагын бер елдан 1000 еллыгын *билгеләп үтүче* шәһәргә теплоход белән килергә туристлык кампаниясе билетлар сата башлаган. | Тагын бер елдан 1000 еллыгын *билгеләп үтәчәк (бәйрәм итәчәк)* шәһәргә теплоход белән килергә туристлык кампаниясе билетлар сата башлаган. |
| *Утыручылар* (самолетта – Р.Ю.) арасында бер “сәвитчә” киенгән картка күзем төште. | *Пассажирлар арасындагы* (самолетта – *Р.Ю.*) бер “сәвитчә” киенгән картка күзем төште. |
| Полиция хезмәткәрләре *тоткарлаганны* ... кыйнаганнар. | Полиция хезмәткәрләре *тоткарлаган кешене* ... кыйнаганнар. |
| Бишенче мәртәбә *узучы чара* “алтын куллар”ны берләштерә. | Бишенче мәртәбә *уздырыла торган чара* “алтын куллар”ны берләштерә. |
| ...матди хәле *авыр булучылар* рәхәтләнеп сорана алачак. | ...матди хәле *авыр кешеләр* рәхәтләнеп сорана алачак. |
| Рузилә Мөхәммәтҗанова түрәләрдән *өметләндерүче сүз* көтә. | Рузилә Мөхәммәтҗанова түрәләрдән *өметләндерерлек (өметле) сүз* көтә. |

| | |
|---|---|
| Авылда иң авыр эш – иң аз *түләнүче* эш. | Авылда иң авыр эш – иң аз *түләүле* эш. |
| Бурычлыларга *күрелүче* чара – мөлкәткә арест салу. | Бурычлыларга күрелә торган (*күрелгән* ) чара – мөлкәткә арест салу. |
| Сабантуйлары алдыннан тәкъдим *ителүче* бу рәсем... | Сабантуйлары алдыннан тәкъдим *ителгән* бу рәсем... |
| Энем Илсурның эшен *дәвам итәм.* | Энем Илсурның эшен *дәвам иттерәм.* |
| Аның ике зур шкафы кием белән *шыплап тулган.* | Аның ике зур шкафы кием белән *шыплап тутырылган.* |
| Әнисе аңа... *дия* торган була. | Әнисе аңа... *ди (дип әйтә*) торган була. |
| ...*диеп* аның адресын бирде. | ...*дип* аның адресын бирде. |
| Татар халкы тарихында уйгур *язуының куллануы* хакында мәгълүмат бирегез. | Татар халкы тарихында уйгур *язуының кулланылуы* хакында мәгълүмат бирегез. |
| Мин һәр көнне аларның күңел җылысын *тойдым.* | Мин һәр көнне аларның күңел җылысын *тоеп тордым.* |
| Ике ел буе ... Татарстанда яшәп булмый дип *куркыттылар.* | Ике ел буе ... Татарстанда яшәп булмый дип *куркытып килделәр.* |
| Бер яшемдә *үлә яздым.* | Бер яшемдә *үлә язганмын.* |
| Мин ничек *тудым*? Яки бала белән бу хакта ничек сөйләшергә? | Мин ничек *туганмын*? Яки бала белән бу хакта ничек сөйләшергә? |
| Элек патшалар, ханнар властьны *улына калдырган.* | Элек патшалар, ханнар властьны *улларына калдыра торган булганнар.* |
| 1958 елның маенда *бала да туа.* Ул бала *мин идем.* | 1958 елның маенда *бала да туа.* Ул бала *мин булганмын*. |
| Лука Канашевич яраннары XVIII гасыр уртасында 500ләп мәчетебезне яндырганнан соң, Аллаһ йортларын яңадан төзергә *кирәк иде.* | Лука Канашевич яраннары XVIII гасыр уртасында 500ләп мәчетебезне яндырганнан соң, Аллаһ йортларын яңадан төзергә *кирәк була.* |

Сөйләм телендә дә, мәгълүмат чаралары телендә дә сорау җөмләләрдәге *икән* сүзенә ялгыш -*мы-ме* кисәкчәсе ялгап куллану күренеше бар: “Нигә аларны эфирга чыгаралар *микән*?” (дөресе – “... чыгаралар *икән*?”.)

Татар телендә рус теле исемнәренең кечерәйтү-иркәләү формасына туры килә торган *-чык/-чек/, -кай/-кәй* кушымчалары бар: *птичка – кошчык, коробочка – тартмачык, кошечка, котёнок – песекәй, мамочка – әнкәй, папочка – әткәй, бабуся – әбекәй, дедуля – бабакай* һ.б. Ләкин рус теле исемнәре белән татар теле исемнәренең иркәләү-кечерәйтү формалары арасында аерма зур: бу форма татар теле сүзләрендә бик сирәк кулланыла, ягъни ул бу тел өчен типик күренеш түгел. Рус телендә исә бу мәсьәләдә хәл бөтенләй башкача: мондагы исемнәрнең бик күбесе иркәләү-кечерәйтү рәвешендә була ала *(столик, домик, деревенька, городок* һ.б.).

Кайбер каләм ияләре, бу ике тел арасындагы шушы җитди аерманы исәпкә алмыйча, татар телендә рус теле үрнәгендә яңа сүзләр ясарга омтылалар.

*Аның 8 баласы, 29 оныгы, 59* ***оныкчыгы*** *бар.* Татар телендә *оныкчык* сүзе юк, бу җөмләдәге *оныкчык* рус телендәге *правнук* сүзеннән калькалаштырып ясалган, ләкин бу уңышсыз сүз булып чыккан. Сәбәбе һаман да шул бер нәрсә: журналист бу очракта да оригиналда төшенчә бер сүз белән генә белдерелгән икән, тәрҗемәдә дә шулай булырга тиеш, дип уйлап эш иткән. *Правнук* сүзен *оныкларының балалары* дип әйтергә мөмкин, һәм шулай эшләргә кирәк тә.

*...Юл һәлакәтендә 10 яшьлек* ***кызчык*** *үлгән* (бу тәрҗемәдәге ***кызчык – девчонка***ның уңышсыз калькасы, һәм ул татарча дөрес сүз булып санала алмый: *10 яшьлек* ***кыз*** гына дияргә кирәк иде).

***Зур булмаган*** *Амштейттен* ***шәһәрчегендә*** *яшәүче электрик Иозеф Фритиль.* Бу фразадагы ***зур булмаган шәһәрчек – небольшой городок***ның калькасы, һәм, әлбәттә, ул табигый түгел: аны ***кечерәк кенә Амштейттен шәһәре*** дияргә кирәк иде.

***Мәскәүләргә*** *күрсәтерлегебез бар.* Мондагы ***Мәскәүләр*** сүзендә татар телендәге табигый сүз ясалыш нормасы бозылган. Гадәттә билгеле бер торак пунктта яшәүчеләрне белдерә торган сүз ул торак исеменә *-лы-ле* кушымчасы ялганып ясала: ***Мәскәүле, Казанлы, Әтнәле (ләр)***.

***Закон*** урынына ялгыш ***закончалык*** сүзен, ***эш*** урынына ***эшчәнлек*** сүзен куллану – киң таралган күренеш: *...****закончалыкта*** *каралган чаралар күрергә таләп җибәрелде* (дөресе – ***закон)***; *Мөлкәт җинаятьләренә каршы көрәш алып бару – ...органнары* ***эшчәнлегендә*** *иң актуаль проблема* (*органнары* ***эшендә*** татарча табигыйрак була).

А.Некрасовның “Кому на Руси жить хорошо” поэмасы тәрҗемәсендә ***исерек төнкәй*** дигән әйтелмә бар. Мондагы ***төнкәй ночька*** (***ночька пьяная***) сүзенең хәрефкә-хәреф тәрҗемәсе, һәм, әлбәттә, бу бик уңышсыз килеп чыккан: татарча ***төнкәй*** дип әйтеп булмый.

*...**диеп** аның адресын бирде* (әдәби форма – ***дип***), *Әнисе аңа ...**дия** торган була* (*...**дип әйтә торган була*** кирәк).

*Татар дәүләт гуманитар-**педагогия** университетының ректораты.* Бу тезмә исемдәге ***педагогия*** сүзе дөрес кулланылмаган: ***педагогия*** дигән сүз юк, *...**педагогика** университеты* булырга тиеш.

Соңгы вакытларда телебездә рус теленнән ялгыш тәрҗемә итү аркасында шактый киң таралып килгән тупас хаталарның берсе – ***телле*** сүзе белән ясалган әйтелмәләр: *Дине, теле, гореф-гадәтләре белән аерылып торучы милләт **рус телле** халыкларга гаҗәп тә, серле дә булып күренә.* Шулай ук, *рус телле укучылар, рус телле мәктәпләр* һ.б. әйтелмәләр бар. Болардагы ***телле*** сүзе дөрес кулланылмый: алар *рус телендә сөйләшүче халык (кеше, укучы* һ.б.ш.), *рус телендә укытыла торган мәктәп* яки *рус мәктәбе рәвешендә* булырга тиеш.

Соңгы елларда матбугат битләрендә *бүлекчә* сүзе бик күп кулланыла башлады. Моның сәбәбе менә нәрсәдә: мөгаен, төрле оешмаларның кечерәк дәрәҗәдәге (яссылыктагы) бүлекләрен атау өчен, *бүлек* сүзе янына *бүлекчә* сүзен өстәү ихтыяҗы тугандыр. Ләкин моның өчен, тел бозып, яңа сүз ясауның кирәге юк *(бүлекчә* татар теле өчен табигый түгел), бәлки телнең булган мөмкинлекләреннән тулырак файдаланырга гына кирәк иде. Мәсәлән, *Россия пенсия фондының **Татарстан буенча бүлекчәсе... (Татарстан бүлеге*** дияргә иде). Әйтик, ниндидер фондның республика, Казан шәһәре, районнар һ.б. бүлекләре булып, аларны аерым-аерым атыйсы булса, *...фондының Казан шәһәре бүлеге, Вахитов районы бүлеге* рәвешендә, ягъни ялгызлык исемен өстәп әйтергә була.

Кечерәйтү мәгънәсендәге *-ча/-чә* кушымчасы белән соңгы елларда күп терминнар ясала (алар төрле сүзлекләрдә һәм фәнни хезмәтләрдә зур урын алып тора, әмма аларның күбесе татар телендәге сүз ясалыш кагыйдәләренә туры килми.

Рус телендәге *не* төшенчәсе белән ясалган тискәре мәгънәле сыйфатларны ялгыш тәрҗемә итү аркасында да гайре табигый сүзләр очрый:

*Безне* ***зур булмаган*** *бүлмәгә урнаштырдылар.* Бу җөмләдәге *зур булмаган* сүзләре – *небольшой* сүзенең калькасы. Саф татарча алай дип әйтмиләр. *Безне кечерәк* ***кенә*** *бер бүлмәгә урнаштырдылар* дияргә кирәк иде.

*Президент сараеннан* ***ерак булмаган*** *бер ашханәнең эшләве мәгълүм булды. Ерак булмаган – недалеко (недалёкий)* сүзенең хәрефкә-хәреф тәрҗемәсе, һәм ул татарча түгел. Дөресе – *Президент сараена* ***якын гына*** *(урнашкан) бер ашханәнең эшләве мәгълүм булды.*

***Төзек булмаган*** *техника белән йөрүнең ун очрагы теркәлгән* (дөресе – ***ватык*** *техника).*

*Авылыбыз артында* ***биек булмаган*** *таулар, калкулыклар бар* (дөресе – ***тәбәнәк кенә*** *таулар).*

*Дом с садом – бакчасы булган йорт* (хәрефкә-хәреф тәрҗемә итү аркасында “өтек” әйтелмә килеп чыккан).

*Сөт әзерләү эше* ***канәгатьләнмәслек*** *оештырылган.* Татарча *канәгатьләнерлек* дип әйтәләр, ләкин *канәгатьләнмәслек* дип әйтеп булмый. Морфологик норма бозылмасын өчен, үзара бәйләнештәге ике сүзнең дә грамматик формаларын үзгәртергә кирәк: *канәгатьләнерлек оештырылмаган.*

*Авылымны* ***ямьлисем*** *килә* (дөресе – ***ямьләндерәсем*** яисә ***матурайтасым*** *килә).*

***Никахта тормаучы*** *ирләр һәм хатын-кызлар (никахта тормаучы* – кытыршы әйтелмә, рус телендәге *не состоящие в браке* сүзтезмәсенең уңышсыз калькасы; дөресе – ***ялгыз*** *ирләр һәм хатын-кызлар).*

*“Прожектор”ны тагын да* ***тәэсирчән*** *һәм кызыклырак итәргә кирәк (тәэсирчән* татарча дөрес сүз түгел. Бу – журналистның сүз ясау новаторлыгы нәтиҗәсе. *Тәэсир* сүзенә *-чә* кушымчасы ялганып, сыйфатны белдерә торган сүз ясалмый. Дөресе – *тәэсирле).*

*“УАЗ-469” маркалы автомобильне “ВАЗ-21093” маркалы автомобильгә* ***килешенү*** *буенча алмаштырабыз* (дөресе – *килешү буенча).*

*Пьянство* мәгънәсендә эчкечелек сүзен куллану да дөрес түгел: бу сүзнең нигезе *эчке* түгел, бәлки *эчү*. Димәк, дөресе *эчүчелек* булырга тиеш.

*Сез безнең белдерүне* ***кая*** *күрдегез?* “*Кая* нәрсә булганын ияр-чен ярдәмендә күзәтү”; “*Кая* гына эшләсә дә, ул музыкадан аерыл-мый”. Бу җөмләләрдә дә урын-вакыт килеше формасындагы *кай-да?* сорау алмашлыгы урынына ялгыш юнәлеш килешендәге *кая?* алмашлыгы кулланылган. ***Кайда*** *мөрәҗәгать итә алам?.* “*Кайда* барсалар да, рәхәтләнеп үз телләрендә сөйләшәләр”. “Безнең бу-лышчыларыбыз *кайда* качты соң?”. Боларында, киресенчә, юнәлеш килешендәге *кая?* сорау алмашлыгы урынына ялгыш урын-вакыт килешендәге *кайда?* алмашлыгы кулланылган. Мондый хаталар шактый еш очрый.

Соңгы вакытларда, шулай ук рус теле формасына ияреп бул-са кирәк, *-ый/-и* кушымчалы нисби сыйфатлар куллану белән ма-выгу күренә: *Милли балетка дәүләти бәя* ; ***...әкияти*** *образларга әйләнә.*

*-ый/-и* кушымчасы ялганып ясалган нисби сыйфатлар татар телендә сирәк кулланыла *(сәяси),* димәк, бу безнең тел өчен типик күренеш түгел. Мисал итеп китерелгән *дәүләти бәя, әкияти образ* кебек сыйфатлы исем сүзтезмәләр урынына татар телендә, гадәттә, исемле исем сүзтезмәләр кулланыла: *дәүләт бәясе, әкияттәге об-раз* яки *әкият образы.*

Кайчак исемле исем сүзтезмәләрдә *-лы/-ле* кушымчасы белән килгән сүз урынына ялгыш *-дагы/-дәге, -тагы/-тәге* кушымчалы исем кулланыла. Бу татар теле өчен табигый түгел. Мәсәлән: *Эмо-циональ булган* ***эчтәлектәге*** *юлламаны җибәрде* (дөресе – *эмоци-ональ* ***эчтәлекле*** *юлламаны); Югары сыйфатлы бодай үстерү дә* ***күтелгән кадәрдәге*** *табышны бирми* (дөресе – *көтелгән* ***кадәрле*** *табышны).*

***Иртәгәге*** *көнгә карап* (дөресе – ***иртәге*** *көнгә).*

Соңгы бер-ике елда журналистлар керткән яңалыкларның та-гын берсе – *телефоннан шалтырату* дигән әйтелмәдәге *шалты-рату* сүзен *чылтыратуга* алмаштыру. Нигә кирәге булгандыр бу яңалыкның?!

Мәгълүмат чаралары телендәге морфологик ялгышлар күбрәк исем һәм фигыль сүз төркемнәренә карый. Шуны истә тотып, без матбугат һәм радио-телевидение тапшырулары ми-салында исемнәрнең килеш, аныклык һәм аныксызлык, тартым категорияләрендәге, хикәя һәм сыйфат фигыль формаларындагы интерференция күренешләрен карап китәрбез.

# ФИГЫЛЬ ФОРМАЛАРЫН КУЛЛАНУ МӘСЬӘЛӘСЕ

Хәзерге телдә фигыль сүз төркеме формаларының ялгыш кулланылуы гадәти күренешкә әверелә бара. Һәм бу хәлнең төп сәбәбе каләм ияләренең рус теле фигыль формаларының татар теленә йогынтысын (интерференциясен) исәпкә алмауларында, икенче төрле әйткәндә, рус һәм татар телләрендәге фигыль сүз төркемнәренең бер-берсеннән зур аермалы булуына төшенмәүләрендә.

Фигыльләрнең сөйләм культурасына турыдан-туры караган формаларыннан аеруча игътибарга лаеклылары – үткән заман хикәя фигыльләре һәм сыйфат фигыльләр.

**Татар теленең үткән заман хикәя фигыльләре,** төп вазыйфаларын (сөйләү вакытына кадәр булган процессны тәгъбир итү) башкарудан тыш, төрле мәгънә төсмерләре белдерәләр. Һәм бу мәгънә төсмерләренең һәркайсының үзенә бер формасы бар. Рус телендәге үткән заман хикәя фигыльләре, татар телендәге кебек мәгънә төсмерләренә ия түгел, һәм шунлыктан алар, нигездә, бер грамматик форма белән генә белдерелә: *ехал, шёл, сделал, принёс, посмотрел.*

Ике телнең дә үзара актив мөнәсәбәттә булуы һәм ике тел белән эш итүчеләрнең һәр телнең үзенчәлекләрен исәпкә алып җиткермәүләре аркасында, еш кына татар теленең бай фигыль формалары тулы файдаланылмый: ике телле каләм ияләре, татарча язганда, нигездә, үткән заман хикәя фигыльләренең бер генә төре *-ды/-де, -ты/-те* кушымчалы билгеле үткән заман дип атала торган формасы белән эш итәләр. Шулай итеп, монда рус теле фигыль формасының татар теле фигыльләренә интерференциясе чагылыш таба: ике тел иясе, татарча сөйләгәндә һәм язганда, рус фигыленең бер генә төрле формасы йогынтысында татар теле фигыльләренең дә бер генә төрен куллана. Нәтиҗәдә татар теленең сөйләм нормалары бозыла, процессның тиешле мәгънә төсмерләре тәгъбир ителми, тыңлаучы һәм укучыга җиткерелми кала.

Тәрҗемә язмаларда һәм оригиналь материалларда да татар телендәге үткән заман хикәя фигыльләренең күп төрле формалары урынында ялгыш ***-ды-де (-ты-те)*** кушымчалы фигыльләр генә кулланылу мисаллары:.

1. **-ган-гән (-кан-кән)** кушымчалы билгесез үткән заман хикәя фигыльләре урынында:

| ялгыш | дөрес |
|---|---|
| Быел Кытай патент гаризаларының саны буенча АКШны да *узып китте.* | Быел Кытай патент гаризаларының саны буенча АКШны да *узып киткән.* |
| Путингә *әләк яздылар* (Игорь Шувалов өстеннән – *Р.Ю.*). | Путингә *әләк язганнар (язып салганнар).* |
| Алла Пугачеваның игезәк *балалары туды.* | Алла Пугачеваның игезәк *балалары туган.* |
| “Дөньяда”(рубрика). Нигериядәге “Боко харам” сугышчылары ... террор оешмасына тугры булачакларына *ант итте.* | “Дөньяда”. Нигериядәге “Боко харам” сугышчылары ... террор оешмасына тугры булачакларына *ант иткән.* |
| Искәртеп үтәбез: “Ислам дәүләте” төркеме сугышчылары йөзләрчә тоткынны *үтерде.* | Искәртеп үтәбез: “Ислам дәүләте” төркеме сугышчылары йөзләрчә тоткынны *үтергән.* |
| Мин Финляндиядә *тудым.* | Мин Финляндиядә *туганмын.* |
| Элек-электән печән базары *урыны иде.* | Элек-электән печән базары *урыны булган.* |
| Инде хәбәр ителгәнчә, бу көннәрдә бездә генә түгел, Кытайда да *ишеп кар яуды.* | Инде хәбәр ителгәнчә, бу көннәрдә бездә генә түгел, Кытайда да *ишелеп кар яуган.* |
| Бердәм форма *сагындырды бугай.* | Бердәм форма *сагындырган бугай.* |
| Билгесез кешеләр ике чиркәүгә *ут төртте.* | Билгесез кешеләр ике чиркәүгә *ут төрткән.* |
| Ахырзаман пәйгамбәре Мөхәммәд инде 1500 елга якын элек үк... *дип белдерде.* | Ахырзаман пәйгамбәре Мөхәммәд инде 1500 елга якын элек үк... *дип белдергән..* |
| “Ватаным Татарстан” газетасының “Чит илләрдә” дигән рубрикасыннан: Забастовка *тәмамланды***.** Агуланган *500 кеше үлде.* | ...Забастовка *тәмамланган***.** Агуланган *500 кеше үлгән***.** |
| Моннан 140 еллар элек Франциядә Лион тукучылары “эшләп яшәргә яки көрәшеп үләргә!” дигән лозунг белән *чыктылар.* | Моннан 140 еллар элек Франциядә Лион тукучылары “эшләп яшәргә яки көрәшеп үләргә!” дигән лозунг белән *чыкканнар.* |

| | |
|---|---|
| 76 нчы мәргәннәр полкының атлы разведкасы йөкчеләренә Вася Курка кайда һәм кайчан *иярде,* моны беркем дә хәтерләми | 76 нчы мәргәннәр полкының атлы разведкасы йөкчеләренә Вася Курка кайда һәм кайчан *ияргәндер,* моны беркем дә хәтерләми. |
| Мин кечкенә чакта еш *авырдым.* Бер яшемдә үлә *яздым.* | Мин кечкенә чакта еш *авырганмын.* Бер яшемдә үлә *язганмын.* |
| “15 сентябрь көнне Иракның 11 шәһәрендә терактлар *булды.* Шартлаткыч куелган машиналар күккә очты”. | “15 сентябрь көнне Иракның 11 шәһәрендә терактлар *булган.* Шартлаткыч куелган машиналар күккә очкан”. |
| “Ольга Шелест әни булды. 36 яшьлек Ольга Нью-Йорктагы клиникаларның берсендә кыз бала тапты”. | “Ольга Шелест әни булган. 36 яшьлек Ольга Нью-Йорктагы клиникаларның берсендә кыз бала тапкан”. |

2. **-ган-гән (-кан-кән)+иде** формалы билгеле күптән үткән заман хикәя фигыльләре урынында:

| **ялгыш** | **дөрес** |
|---|---|
| Радиода эшләүчеләрнең һәрберсе биш елга бер тапкыр Мәскәүдә дикторлык осталыгын күтәрү курсларында *укып кайтты.* | Радиода эшләүчеләрнең һәрберсе биш елга бер тапкыр Мәскәүдә дикторлык осталыгын күтәрү курсларында *укып кайта иде.* |
| Моңа кадәр Владимир Якунин тиз йөрешле тимер юлны салу эше башланмаска да мөмкин икәнен *әйтте.* | Моңа кадәр Владимир Якунин тиз йөрешле тимер юлны салу эше башланмаска да мөмкин *дигән иде.* |
| “Яңа гасыр” оештырылганда тапшыруларны дөньядагы барлык милләттәшләребезгә җиткерү бурычы *куелды*, әмма бүген республикада яшәүчеләрнең дә дүрттән бере аны тыңлый алмый. | “Яңа гасыр” оештырылганда тапшыруларны дөньядагы барлык милләттәшләребезгә җиткерү бурычы *куелган иде*, әмма бүген республикада яшәүчеләрнең дә дүрттән бере аны тыңлый алмый. |
| Мин Вәлиулла хәзрәтне 1998 елдан бирле беләм. Без аның белән берләштерү съезды алдыннан *таныштык.* | Мин Вәлиулла хәзрәтне 1998 елдан бирле беләм. Без аның белән берләштерү съезды алдыннан *танышкан идек.* |

| | |
|---|---|
| 1992-95 елларда ваучерлар *бирделәр.* Заманында кешеләр аны йә сатты, йә товарга алыштырды. | 1992-95 елларда ваучерлар *биргән иделәр.* Заманында кешеләр аны я сатты, я товарга алыштырды. |
| Ярты гасырдан артык кешеләр дөньяның барлык почмакларыннан Болгария күрәзәчесе Ванга янына киңәшкә һәм ярдәм сорап *килделәр.* | Ярты гасырдан артык кешеләр дөньяның барлык почмакларыннан Болгария күрәзәчесе Ванга янына киңәшкә һәм ярдәм сорап *килеп йөрделәр (килә иделәр, килеп тордылар һ.б.).* |
| Хәтерләсәгез, ул закон да шактый бәхәсләрдән соң *кабул ителде.* | Хәтерләсәгез, ул закон да шактый бәхәсләрдән соң *кабул ителгән иде.* |
| Бу мәсьәлә элегрәк тә *күтәрелде.* | Бу мәсьәлә элегрәк тә *күтәрелгән иде.* |
| Безгә хат *яздыгызмы?* | Безгә хат *язган идегезме?* |

3. **-ган-гән(кан-кән) +була(булган**) формалы билгесез күптән үткән заман хикәя фигыльләре урынында:

| **ялгыш** | **дөрес** |
|---|---|
| Идел болгарлары тормышның күп тармакларында югары культурага *ирештеләр.* | Идел болгарлары тормышның күп тармакларында югары культурага *ирешкән булганнар.* |

Менә бу җөмләләрдә фигыльләр дөрес кулланылган: *Элек заманнарда Каратау кешесе, хәрби хезмәткә алынгач, аягына иң зур итек яки иң зур ботинка алырга тырыша торган була*; *Владимир Ильичның әтисе Илья Николаевич шунда (Казанда. – Р.Ю.) укыган була.*

Сөйләү вакытына кадәр булган хәлләрне хикәяләгәндә, үткән заман, шул исәптән билгеле үткән заман төрләре урынында тасвирлаулы хәзерге заман фигыльләрен куллану максатка ярашлы була. Әмма практикада телебезнең бу үзенчәлеге исәпкә алынып бетми, һәм хәзерге заман формасы урынында да еш кына билгеле үткән заман фигыльләре кулланыла. Мисаллар:

*Менә чәчәккә чуар күбәләк килеп **кунды.** Менә кар хәрәкәткә **килде.** Ботак селкенеп **куйды.*** Монда хикәяләү үткәндәге хәлләр турында барса да, табигатьнең даими күренешләре тасвирлана, һәм фигыльләр, һичшиксез, хәзерге заманда булырга тиеш.

*Хәл **кискенләште.** Дошман һөҗүмгә **күчте**.* Бу ике җөмлә Ватан сугышы батыры Сабир Әхмәтов турында, һәм фигыльләрне аларда хәзерге заманда кую максатка ярашлы булыр иде.

*Азинның аты, чокырга туры килеп, сөрлегеп китте, начдив җиргә очып төште һәм дошман кулына эләкте. Пленда ул үзен чын революция солдаты итеп күрсәтте.* Бу текстта *-ды/-де, -ты/-те* формасы һич кенә дә урынлы түгел, фигыльләрне хәзерге заманда кулланырга кирәк иде. Мондый очракларда хәзерге заман формасында язу мәгънә буталчыклыгына китерер, үткәндәге вакыйгалар хәзерге булып аңлашылыр дигән шик булырга тиеш түгел, чөнки сүзнең узган хәлләр турында баруы сөйләмнән (тексттан) аңлашылып тора. Шуның өстенә, текстның беренче җөмләсендәге фигыльләрне үткән заман формасына куеп, калганнарын хәзерге заманга күчерергә мөмкин. Бу сурәтләнә торган вакыйгаларның үткәндә булганлыгын аңларга ярдәм итә. Мәсәлән, *Ленин бик яхшы **укыган,** хәтта искиткеч яхшы **укыган.** Ул гимназияне алтын медаль белән **бетерә*** (М.Зощенко). Татар халык әкиятләрендә дә шулай бит: баштагы җөмләләр үткән заман формасында төзелә дә, анары сөйләм хәзерге заман формасында бара ***(Яшәгән,** ди, **булган,** ди, бер карт белән карчык...* Алга таба әкият *Камыр батыр фәлән **эшли,** төгән **эшли*** дип дәвам итә).

Үткән вакыйгаларны хәзерге заманда сөйләү – күп яктан отышлы алым. Ул сөйләмне табигый, шома итә һәм мәгънәгә дә зыян китерми. Хәзерге заман кешесенең, бигрәк тә яшьләрнең, *М.Җәлил... темаларга мөрәҗәгать **итте...** Сугыш елларында “Алтынчәч” аеруча актуаль булып **яңгырады.** ... Сугыш **башланып китте*** дип язуы туган тел нормаларына туры килми. *Иде* ярдәмче фигыле белән ясалган аналитик үткән заман формалары, сөйләүче (язучы) үзе күргән яки катнашкан процессны белдерә, һәм аларның сөйләүченең (язучының), үзе күрмичә яки катнашмыйча, башка чыганакларга гына таянып хәбәр иткән процессны белдерү өчен куллануы тел нормаларын бозу булып санала. Мондый хәлләр мәгълүмат чаралары телендә шактый еш очрый.

*Иде* ярдәмче фигыле белән ясалган хәбәрләр ялгыш түбәндәге формалар урынында кулланыла:

*1. Бул* ярдәмче фигыленең хәзерге заман формасы белән ясалган хәбәрләр урынында: *М.Кутузов, Суворов һәм Александр Македонский тарихта шундый бөек, данлыклы полководецлар **иде** (полководецлар **була*** кирәк); *Афанасий Никитин Һиндстанга ба-*

*рып кайткан беренче европалы* ***иде*** *(европалы* ***була*** кирәк); *Бруно, Коперник, Галилей өйрәткәннәрне тыярга да, яшерергә дә мөмкин* ***түгел иде,*** *чөнки ул хакыйкатьнең үзе* ***иде!*** *(мөмкин* ***булмый,*** *хакыйкатьнең үзе* ***була*** кирәк); *Болгарлар Х гасырның башыннан ук үз тәңкәләрен гарәпчә монументаль куфи язуы белән* ***сугалар иде*** *(суга торган булалар* яки *булганнар).*

*2. Бул* ярдәмче фигыленең үткән заман формасы белән ясалган хәбәрләр урынында: *Декабристлар нинди кеше* ***иде соң?*** *(нинди кеше* ***булган соң?*** кирәк); *М.Җәлил икенче көнне Мәскәүгә китәргә тиеш* ***иде*** *(китәргә тиеш* ***булган*** кирәк).

3. Тәмамланмаган билгеле үткән заман формасы ярдәмендә белдерелгән процессны кайбер текстларда һәм сөйләмдә тасвирлауны хәзерге заман формасы белән бирү кулайрак була: *Тукайның, үзе әйтмешли, күзе күпне күрә, колагы күпне ишетә* ***иде.*** *Сатирик буларак, ул 10-12 ел буе татар дөньясындагы хисапсыз күп кешеләргә, вакыйга һәм фактларга рәхимсез бәясен бирә* ***иде***. Монда *иде* ярдәмче фигыле урынлы түгел, хикәяләүне хәзерге заман формасында төзү уңышлырак булыр иде (дөресе – *күпне ишетә, бәясен биреп килә).*

Узган вакыйгаларны тасвирлаганда, беренче җөмләнең хәбәрен *була* ярдәмче фигыле ярдәмендә төзеп, калган җөмләләрнең хәбәрләрен хәзерге заман формасында куллану уңай нәтиҗә бирә: *Күл өстендә иртәнге* ***томан тарала башлаган чак иде.*** *Әкрен генә кояш күтәрелде, һәм камышлар арасыннан, балаларын ияртеп, бер үрдәк йөзеп чыкты (башлаган чак була, томан күтәрелә, йөзеп чыга)* дисәк, сөйләм татарча табигыйрак булачак).

Төрле формалар урынында *-ган/-гән, -кан/-кән* формалы билгесез үткән заман фигыльләрен куллану очраклары бар:

1. Билгеле бер вакытта булып узган эш яки хәлне белдерү өчен килгән үткән заман сыйфат фигыль белән *бул* ярдәмче фигыленнән торган конструкция (билгесез күптән үткән заман формасы) урынына: *Махсус чыгарылган язма боерык нигезендә түбән катлау кешеләренең, балаларын гимназиягә алу тыелган* (татар теле нормаларына *тыелган була* яки *тыелган булган* күбрәк туры килә, чөнки *тыелган* формасыннан бу очракта күбрәк процессның нәтиҗәсе аңлашыла).

2. Күптән булган кабатлаулы процессны белдерә торган һәм хәзерге заман сыйфат фигыленең аналитик формасына *бул* ярдәмче фигыле кушылып ясалган билгесез кабатлаулы үткән заман фор-

масы урынына: *Монголларның торак-тирмәләре колгаларга киез* ***каплап ясалган*** *(ясала торган булган* кирәк); *Элек Галиняны авылы аша Львовтан Валахиягә борынгы сәүдә юлы үткән, биредә елына өч тапкыр ярминкә булган. Анда Прикарпатъеда яшәүче кешеләр* ***килгәннәр*** (дөресе – *кешеләре* ***килә торган булган)***.

Икетеллелек шартларында сөйләм культурасын тиешле югарылыкта тоту өчен, татар телендәге фигыль дәрәҗәләре белән рус теле фигыльләрендәге вид категориясен яхшы белү һәм аларның үзара мөнәсәбәтен дөрес билгеләү әһәмиятле. Рус телендә татар телендә булмаган вид категориясе бар һәм, ике тел һәрвакыт тыгыз бәйләнештә торганлыктан, ул категориянең вазыйфасын татар телендә дә тиешле чаралар белән бирү ихтыяҗы чыгып тора. Кайбер очракларда ике тел ияләренең совершенный вид һәм несовершенный вид үзенчәлекләрен белеп бетермәве яки аларга игътибар итмәве аркасында татарча матбугат текстларында һәм радио-телевидение сөйләмендә тиешле мәгънә төгәл бирелми, һәм тел нормалары бозыла.

Шуны исәпкә алып, без хәзер, фигыль кулланылышындагы хаталарны анализлап, совершенный һәм несовершенный видлар белдергән мәгънәләрне татар телендә бирү чараларын карап китәрбез.

Беренчедән, рус теле фигыльләрендәге вид категориясенең кайбер функцияләрен татар телендәге фигыль дәрәҗәләре бирергә мөмкин.

Совершенный вид мәгънәләрен бирү өчен, процессның тәмамлануын, нәтиҗәсен, кинәтлеген белдергән дәрәҗә формаларыннан файдаланып була. Андый дәрәҗәләр *-ып/-еп* кушымчалы хәл фигыль белән *алу, бирү, бетү, бетерү, калу, китү, кую, чыгу, чыгару, үтү, узу, җитү, җибәрү, салу, ташлау* кебек ярдәмче фигыльләр ярдәмендә тәгъбир ителә. Мәсәлән: *язып бетерү – написать, укып чыгу – прочитать, эшләп кую – сделать, тынып калу – стихнуть, карап чыгу – просмотреть, йоклап китү – заснуть, барып җитү – дойти (доехать), күреп алу – увидеть, сискәнеп китү – вздрогнуть* һ.б.

Несовершенный вид мәгънәләрен бирү өчен процессның дәвамлылыгын, кабатлануын, өлешчә башкарылуын белдергән дәрәҗә формаларыннан файдаланырга мөмкин. Андый дәрәҗәләр хәл фигыль белән *яту, тору, йөрү, утыру, бару, килү, чыгу, бирү, карау, багу* ярдәмче фигыльләре, шулай ук *-галә/-гәлә, -калә/-кәлә,*

*-ыштыр/-ештер, -штыр/-штер* кушымчалары һәм башка чаралар ярдәмендә тәгъбир ителә. Мәсәлән: *яшәп яту – жить, сөйләп тору – рассказывать, җыеп йөрү – собирать, җырлап утыру – петь, карап бару – смотреть, әйтә килү – говорить, йөргәләү – похаживать, караштыру – посматривать, эзләп карау – поискать* һ.б.

Икенчедән, совершенный вид һәм несовершенный вид мәгънәләрен татар теленең үткән заман хикәя фигыль төрләре дә шактый дәрәҗәдә белдерә ала, һәм вид мәгънәләрен бирү мәсьәләсендәге ялгышлар күбрәк әнә шул фигыль төрләрен дөрес кулланмау аркасында килеп чыга.

Аналитик үткән заман хикәя фигыльләрдән дүрт төр, кагыйдә буларак, несовершенный вид (дәвамлы, тәмамланмаган, кабатлаулы процесслар) мәгънәләрен белдерә. Алар – тәмамланмаган үткән заман *(бара иде),* кабатлаулы билгеле үткән заман *(бара торган иде),* кабатлаулы билгесез үткән заманның беренче һәм икенче төрләре *(бара торган була, бара торган булган).* Мәсәлән: *Ул алны-ялны белми эшли иде. – Он работал не покладая рук; Безнең әти бервакытта да кешеләрне рәнҗетми торган иде. – Наш отец никогда не обижал людей; Ул сорый торган була. – Он не* ***раз*** *спрашивал.*

Билгеле үткән заман *(барды),* билгесез үткән заман *(барган),* күптән үткән заманның билгеле һәм билгесез формалары *(барган иде, барган була, барган булган),* текстка (сөйләмгә) карап, совершенный вид мәгънәләрендә, несовершенный вид мәгънәләрен дә белдерергә мөмкин. Мәсәлән: *Мин ул киноны карадым. – Я посмотрел* (совершенный вид) *этот фильм; Мин күп тамашалар карадым. – Я смотрел* (несовершенный вид) *много зрелищ; Равил күп эшләр эшләгән иде. – Равиль делал много разных дел; Ул теге вакытта "Күтәрелгән чирәм" романын укыган була (булган). – Он тогда прочитал роман "Поднятая целина"; Ул күп китаплар укыган була (булган). – Он читал много книг.*

Димәк, бу формалар билгеле бер текстта (сөйләмдә) совершенный вид яки несовершенный вид мәгънәсен белдерәләр. Мәсәлән: *Ул кичә трамплиннан сикерде* (совершенный вид). *– Он вчера прыгнул с трамплина; Ул трамплиннан күп тапкырлар сикерде* (несовершенный вид мәгънәсе). *– Он много раз прыгал с трамплина.* Бу җөмләнең татарчасында несовершенный вид мәгънәсе махсус сүзләр *(күп тапкырлар),* русча текстта, махсус сүзләрдән тыш, аерым морфологик категория *(прыгал)* ярдәмендә белдерелгән.

Әгәр вид мәгънәсенә ишарә итәрлек махсус сүзләр булмаса, несовершенный вид функциясен грамматик чаралар ярдәмендә белдерү ихтыяҗы туа, һәм андый очракта, несовершенный вид мәгънәсен тәгаен бирә алырлык махсус чаралар – заман яки дәрәҗә формасы – булганлыктан, вид функциясе билгеләнмәгән форма куллану максатка ярашлы була алмый. Әйтик, безгә татар телендә русча *делал* сүзеннән аңлашылган несовершенный вид мәгънәсен бирергә кирәк, ди. Моның өчен берничә төрле чара – тугыз заман төре һәм фигыль дәрәҗәләре бар. Заман төрләренә килгәндә, алар арасында, карап киткәнебезчә, несовершенный вид мәгънәләрен генә белдерә торганнары да, ике вид мәгънәсен белдерә торганнары да бар. Шундый сайлап алу мөмкинлеге була торып, без күрсәтелгән рус сүзенең несовершенный вид функциясен, конкрет мәгънәле тәмамланмаган үткән заман *(эшли иде)* яки кабатлаулы үткән заман *(эшли торган иде, эшли торган була, эшли торган булган)* төрләре белән бирмичә, ике төрле функция башкара торган заман (билгеле үткән заман) *(эшләде)* һәм билгесез үткән заман *(эшләгән),* күптән үткән заман *(эшләгән иде, эшләгән була, эшләгән булган)* формалары белән бирсәк, дөрес булмас иде. Чөнки *эшли иде, эшли торган иде, эшли торган була (булган)* төрләре *делал* сүзенең мәгънә төсмерләрен – процессның тәмамланмаган, кабатлаулы, дәвамлы булуын тәгаен белдерә, ә *эшләде, эшләгән, эшләгән иде, эшләгән була (булган)* төрләре андый мәгънә төсмерләрен тәгаен белдерә алмый.

*Президент Татарстанның икътисады һәм мәдәнияте белән кызыксынды* дигән җөмләдә *кызыксынды* фигыленә карап кына процессның дәвамлымы, кабатлаулымы, әллә дәвамсыз һәм кабатлаусызмы икәнлеген белеп булмый (оригиналга караганда, ул дәвамлы, кабатлаулы процесс). Әгәр шул ук фигыльне *кызыксына иде* яки *кызыксына торган иде (була, булган)* яки *кызыксынып торды (тора, торган)* формаларында куллансаң, тиешле мәгънә тулы һәм тәгаен белдереләчәк.

*Йөрәкләренә* ***курку төште.*** Бу җөмләдә фигыль формасына карап процессның бер генә тапкыр яки берничә тапкыр булганлыгын белен булмый, асылда исә сүз кабатлаулы процесс турында бара *(Не раз их охватывал трепет).* Шулай булгач, аның фигылен *курку төшә иде* яки *курку төшә торган булды* рәвешендә төзергә кирәк иде.

*Крестьяннар һәрвакыт үзебез эшли торган җир алпавытларныкы түгел, үзебезнеке булса иде дип хыяллардылар.* Бу текстта процессның дәвамлы икәнлеген *һәрвакыт* сүзе күрсәтеп тора. Димәк, җөмләнең фигылен дә дәвамлы процессны белдерерлек формада куярга кирәк иде *(хыялланып килделәр).*

*Халык, авыр изүгә чыдый алмыйча, кулына корал тотып, әледән-әле феодалларга каршы көрәшкә күтәрелгән. Халык... көрәшкә күтәрелә торган булган* яки *...күтәрелеп торган* булса, тиешле мәгънә тулырак белдерелер иде. Менә бу җөмләдә мәсьәлә дөрес хәл ителгән: *Стражниклар төзелешкә коллар һәм крестьяннарны бөтен Мисырдан* ***куып китерә торган булганнар.*** *Стражниклар... куып китерделәр яки куып китергән* булса, мәгънә төсмере (дәвамлы, кабатлаулы процесс) тулы бирелмәс иде.

*Ара-тирә минем янга да килеп, эшләрегез ничек барганлыгын, миннән сезгә нинди ярдәм кирәклеген әйтерсез (әйтеп торырсыз* кирәк, чөнки бу форма дәвамлылыкны *әйтерсез* сүзенә караганда тулырак бирә. Процессның кабатлаулы икәнлегенә *ара-тирә* сүзе дә ишарә итә).

Күргәнебезчә, үткән заман хикәя фигыльләренең төрле формалары бар, һәм алар күптөрле мәгънә төсмерләрен белдерә. Шулай булгач, фигыльләрнең байлыгын, аларның барлык төрләрен һәм мәгънә үзенчәлекләрен белеп эш итү зарур.

Фигыльләрне куллану өлкәсендәге хаталарның күбесе **сыйфат фигыльләргә** туры килә. Сәбәбе – беренчедән, сыйфат фигыль формаларының мәгънә үзенчәлекләрен белеп бетермәү яки аларга тиешле игътибар бирмәү һәм, икенчедән, рус телендәге **причастие** дип аталган **морфологик** категориянең күп формаларының аңа якын торган сыйфат фигыльләргә интерференцион тәэсире.

Рус телендәге **причастие** белән татар телендәге **сыйфат фигыль** – функцияләре буенча үзара охшаш морфологик категорияләр. Рус теленең *-ущ/-ющ, -ащ/-ящ* суффикслары белән ясалган хәзерге заман причастиеләре һәм татар теленең *-учы/-үче* кушымчасыннан, шулай ук *-а/-ә* кушымчасы + *торган* ярдәмче фигыленнән ясалган хәзерге заман сыйфат фигыльләре, *-вш/-ш; -ин/-ен,-н; -т* суффикслары ярдәмендә ясалган үткән заман причастиеләре һәм *-ган/-гән, -кан/-кән* кушымчалары белән төзелгән үткән заман сыйфат фигыль мәгънәләре һәм функцияләре буенча еш кына бер-берсенә туры киләләр: *играющий ребёнок – уйнаучы бала; говорящий человек –*

*сөйләүче кеше; прошедший год – үткән ел; написанная книга – язылган китап.*

Причастие белән сыйфат фигыльләр нисбәте турында сөйләгәндә, алар арасында шактый зур аерма да булуны истән чыгарырга ярамый. Хәлбуки, тәрҗемә практикасында бу категорияләр арасында тулы параллель үткәрергә тырышу күзәтелә, һәм шуның аркасында сыйфат фигыль төрләрен куллануда күп хаталар җибәрелә.

Хаталар күбесенчә *-учы/-үче* кушымчалы хәзерге заман сыйфат фигыльләрен куллануга карый.

Моның сәбәпләренең берсе – үзара тәңгәллекләр булып саналган *-ущ/-ющ, -ащ/-ящ* суффикслы причастиеләр белән *-учы/-үче* кушымчалы сыйфат фигыльләрнең һәр очракта да бертөрле кулланылмавында. Хикмәт шунда: рус телендә причастие төрләре үзләре ачыклап килгән сүзнең зат исеме яки предмет исеме булуына карата битараф, ягъни моңа карап үзгәрмиләр: татар теленең хәзерге заман сыйфат фигыльләре исә, ачыкланып килгән сүзнең җансыз әйбер исеме яки зат исеме булуына карап, төрле формаларда кулланыла. Хикәя фигыль белән *торган* ярдәмче сүзеннән ясалган *(эшли торган)* аналитик формалы хәзерге заман сыйфат фигыле зат исемнәрен дә, предмет исемнәрен дә ачыклап килә алса *(яза торган кеше, яза торган машина), -учы/-үче* кушымчалы сыйфат фигыльләр, гадәттә, зат исемнәренә карата кулланыла. Аны предмет исемнәре белән бәйләнешкә кертү татар теле нормалары буенча дөрес түгел: *череп ятучы такта* диюгә караганда *череп ята торган* яки *череп яткан такта* дип әйтү кулайрак; *безнең авылга йөрүче машина* түгел, *безнең авылга йөри торган машина.* Ике тел белән эш итүчеләрнең күбесе телебезнең бу үзенчәлеген исләрендә тотмый яки белми, һәм нәтиҗәдә *өйрәнүче төшенчәләр, хезмәт итүче идеяләр, ерак торучы шәһәр, сакланучы документ, канга бирүче эчке секреция бизләре* кебек татарча ялгыш тәгъбирләр барлыкка килә. Алардагы *-учы/-үче* кушымчалы сыйфат фигыльләр *-а/-ә + торган* формасында кулланылырга тиеш. Мисаллар:

| **ялгыш** | **дөрес** |
|---|---|
| Елга бер *килүче* ял. | Елга бер *килә торган* ял. |
| Хуҗа Хәсәннән Казанга *йөрүче* автобус сәгать 6 да китәчәк. | Хуҗа Хәсәннән Казанга *йөри торган* автобус сәгать 6 да китәчәк. |

| | |
|---|---|
| Бикбау авылы һәр җирдә күзгә *ташланучы* тәртип-чисталыгы, җыйнаклыгы-пөхтәлеге белән гаҗәпкә калдыра. | Бикбау авылы һәр җирдә күзгә *ташланып торган* тәртип-чисталыгы, җыйнаклыгы-пөхтәлеге белән гаҗәпкә калдыра. |
| Волгоград урамы буенча *үтүче* җылылык үткәргечтә ике тишек-тошык табылган. | Волгоград урамы буенча *үтә торган* җылылык үткәргечтә ике тишек табылган. |
| Шундый ук гаҗәеп операцияләр *ясалучы* бүлек ачылачак. | Шундый ук гаҗәеп операцияләр *ясала торган* бүлек ачылачак. |

Икенче интерференция хатасы, *-ган/-гән, -кан/-кән* кушымчасы белән ясалган үткән заман фигыль формаларының төрле функцияләр башкаруын белмичә, рус телендәге хәзерге заман причастиесенә ияреп, *-ган/-гән, -кан/-кән* формасы урынына ялгыш *-учы/-үче* кушымчалы хәзерге заман сыйфат фигыльләр куллanудан гыйбарәт.

*-ган/-гән, -кан/-кән* кушымчасы белән ясалган сүзләр үткән заман сыйфат фигыльләр дип аталса да, аларның вазыйфасы предметның билгесен сөйләү вакытына кадәр булган эш-хәл аша белдерү генә түгел. Бу фигыльләрнең бер функциясе – үткәндәге процесс билгесенең хәзер дә дәвам иткән нәтиҗәсен белдерү. *Безнең белемнәребезне* ***урап алучы*** *елга шундый сай* фразасында *урап алучы* дөрес түгел, *урап алган* булырга тиеш. *-ган/-гән, -кан/-кән* формалы сыйфат фигыль предметның билгесен сөйләү вакытында барган процесс аша да белдерә ала: *Урамнан мылтык аткан тавышлар ишетелеп тора* **(атучы** *тавышлар* булса, саф татарча булмас иде); *Баренц диңгезеннән алып Ладога күленә кадәр* ***сузылучы*** *йөзләрчә километр арада...* (дөресе – *сузылган арада).*

Предметның билгесен сөйләү вакытына мөнәсәбәтсез, даими булып торган процесс аша белдерү өчен дә *-ган/-гән, -кан/-кән* кушымчалы сыйфат фигыль кулланыла ала: *Авылны тирә-яктан урап алган урман нindидер бер шомлы тавыш белән шаулый иде.*

Ә менә бу җөмләләрдә татар теленең мондый үзенчәлеге исәпкә алынмаган:

*Түбән Кама районының борма-борма* ***агучы*** *Зәй елгасы булган, мәһабәт тауларга* ***орынып торучы*** *Тоба авылында туган...* *(борма-борма (бормаланып-бормаланып)* ***аккан*** *Зәй елгасы булган, мәһабәт тауларга* ***орынып торган*** *Тоба авылында туган* булырга тиеш).

*Елга буенда* ***үсүче*** *тирәкләр бакчага аеруча ямь өстиләр (елга буенда* ***үскән*** *тирәкләр* кирәк).

| **ялгыш** | **дөрес** |
|---|---|
| Яхшы сыйфатларга *ия булучы* хатын-кызларыбыз күп безнең. | Яхшы сыйфатларга *ия булган* хатын-кызларыбыз күп безнең. |
| Икенче ел *уткәрелүче* чараның файдасы ни дәрәҗәдә соң? | Икенче ел *уткәрелә торган (уткәрелгән)* чараның файдасы ни дәрәҗәдә соң? |
| Безнең йортка *терәлеп торучы* бина. | Безнең йортка *терәлеп торган* бина. |
| Республикада бер тапкыр *кулланылучы* шприц производствосын ачу кирәк. | Республикада бер тапкыр *кулланыла торган* шприц производствосын ачу кирәк. |
| Әрмәнстанның Ереван-Сочи маршруты буенча *очучы* самолеты диңгезгә *төшкән.* | Әрмәнстанның Ереван-Сочи маршруты буенча *йөри торган* самолеты диңгезгә *егылып төшкән.* |
| Ул ....Чаллының республикада иң кызу темпларда *үсүче* шәһәр булуын искәрткән. | Ул ....Чаллының республикада иң кызу темпларда *үсә торган* шәһәр булуын искәрткән. |
| Онищенко чит илдән *кертелүче* бөтен зыянлы әйберләрдән *киртәләп* бетерде. | Онищенко чит илдән *кертелә торган* бөтен зыянлы әйберләргә *киртә куеп (корып)* бетерде (чыкты). |
| 14 ел дәвамында *уткәрелүче* “Мисс Татарстан” конкурсының үз катнашучылары барлыкка килде. | 14 ел дәвамында *уткәрелеп килгән* “Мисс Татарстан” конкурсының үз катнашучылары барлыкка килде. |
| Бормаланып *агучы* Сөн буенда үтте безнең яшь чаклар. | Бормаланып *аккан* Сөн буенда үтте безнең яшь чаклар. |
| Татарча *чыгучы* газета-журналлар. | Татарча *чыга торган* газета-журналлар. |
| Рөстәм Миннеханов... уңыш *казанучыларга* дәүләт бүләкләре тапшырды. | Рөстәм Миннеханов... уңыш *казанган кешеләргә* дәүләт бүләкләре тапшырды. |
| Татар операсына нигез *салучылар* арасында... | Татар операсына нигез *салган кешеләр* арасында... |
| Бүген республикада 7 меңгә якын сәяси яктан *зыян күрүче* яши. | Бүген республикада сәяси яктан *зыян күргән* 7 меңгә якын кеше яши. |
| Зыян *күрүчеләрнең* 18,2 проценты агуланган. | Зыян *күргән кешеләрнең* 18,2 проценты агуланган. |

Предметның сөйләү вакытына кадәр булган процесс аша белдерелгән билгесен ***-учы-үче*** кушымчалы сыйфат белән тәгъбир итү – тупас хаталарның берсе. Хәлбуки мондый ялгышлар матбугат телендә еш очрый:

| **ялгыш** | **дөрес** |
|---|---|
| Тукайны соңгы юлга *озатучы* имамнар. | Тукайны соңгы юлга *озаткан* имамнар. |
| ...газетасы кешеләрне элек-электән *борчып килүче* йөз дә бер сорауга җавапларны бастырып чыгарган. | ...газетасы кешеләрне элек-электән *борчып килгән* йөз дә бер сорауга җавапларны бастырып чыгарган. |
| *...сугыш хәрәкәтләрендә һәлак булучылар* саны... | *...сугышларда һәлак булганнарның* саны... |
| Мәскәү шәһәрендә татар театрына *нигез салучы* Газиз Айдарский... | Мәскәү шәһәрендә татар театрына *нигез салган* Газиз Айдарский... |
| Күптән түгел генә *таныклык алучы йөртүчеләрнең* кагыйдә бозуы... | Күптән түгел генә *таныклык алган автомобиль йөртүчеләрнең* кагыйдә бозуы... |
| Һәлак *булучылар* һәм *үлүчеләрнең* барысы да хәрбиләр. | Һәлак *булган* һәм *үлгән кешеләрнең* барысы да хәрбиләр. |
| 1857 елда сөргенгә *җибәрелүчеләр* арасында 5 мөселман була. | 1857 елда сөргенгә *җибәрелгән (сөрелгән) кешеләр* арасында 5 мөселман була. |
| Бөек Ватан сугышында *катнашучы* Андрей Иванов турында яңа мәгълүматлар табылда. | Бөек Ватан сугышында *катнашкан* Андрей Иванов турында яңа мәгълүматлар табылда. |

Сыйфат фигыльләрне, сыйфат һәм рәвешләрне куллануда төгәлсезлекләр булмасын өчен, мондый бер үзенчәлекне дә истә тоту әһәмиятле: татар телендә дә, рус телендә дә, ачыкланып килгән исемнәр төшеп калып, сыйфат фигыль, сыйфат, рәвешләрнең исем функциясендә йөрү очраклары бар. Ләкин моны ике телдәге үзара тәңгәл сүзләр һәр очракта да бертөрле исемләшә ала икән дип аңларга ярамый.

Мәсәлән, "Великая Отечественная" дигән фильм исеме рус телендә исем вазыйфасын башкара, ә татар телендә аңа исем өстәргә туры килә: "Бөек Ватан сугышы". Димәк, татар телендә, рус теленә ияреп, һәр сыйфат фигыль (причастие), сыйфат һәм рәвешне үзләре ачыклап килгән исемнән башка куллану туган тел нормаларын бо-

зуга китерә. Мондый хәлләр язу һәм сөйләм практикасында булып тора. *Тантаналы өлештән соң үзешчәи сәнгатьтә катнашучылар* ***җыелучыларга*** *спектакль күрсәттеләр (җыелучылар* – уңышсыз кулланылган сүз, ***халыкка*** *спектакль күрсәттеләр* кирәк); *Илдус Камалов – авылда* ***хөрмәт ителүче*** *кешеләрнең берсе* **(*хөрмәтле*** яки ***хөрмәткә лаеклы*** *кешеләрнең берсе* кирәк); *... дип киңәш бирә аңа* ***үтеп баручы*** *(советует ему прохожий) (үтеп барган бер кеше* булса, әйбәтрәк булыр иде); *... музыкасында бар яхшыны чагылдыра (...воплотил в своей музыке все лучшее)* (күргәнебезчә, рус теле өчен *лучшее* сүзенең исем вазифасын үтәве – табигый күренеш, ә татарчада бу очракта *яхшы* сүзеннән соң *нәрсә* сүзен куллану таләп ителә; дөресе ***барлык яхшы нәрсәләрне*** *чагылдыра); Кайчандыр ул булдыклы, җитез хәрби булган (Когда-то он был бравым военным).* Күрүебезчә, *хәрби* сүзенә *военный* үрнәгендә исем вазифасы тагылган, ләкин уңышсыз: *военный* рус телендә татар телендәге *хәрби* сүзенә караганда ныграк исемләшкән, шулай булгач, татарчада *хәрби* сыйфатын *кеше* сүзе белән бергә кулланырга кирәк (уңган хәрби кеше булган); *рәссам ясаганнар (изображённое художником) (рәссам ясаган әйберләр* кирәк); *Рәсем сәнгате һәм башка бик* ***күпләр*** *турында сезгә түбәндәге китаплар сөйләр* **(*күп нәрсәләр*** *турында* кирәк).

# СТИЛЬ ЧАРАЛАРЫ
# СТИЛИСТИЧЕСКИЕ СРЕДСТВА

## КУШЫМЧАЛАР ҺӘМ ИНТОНАЦИЯ

Телдә әһәмиятсез, вак нәрсә юк. Бу яктан җөмләләрнең тиңдәш кисәкләрендәге һәм хәбәрләрендәге кушымчалар игътибарга лаек. Алар, мәгълүм булганча, мөстәкыйль лексик мәгънә белдермәсәләр дә, сөйләмнең бөтенлегенә, интонациянең табигыйлыгына ирешүдә әһәмиятле роль уйныйлар, һәм, димәк, бу кушымчаларның дөрес, урынлы кулланылуы сөйләм культурасын саклауда турыдан-туры чагылыш таба.

Телебездә тиңдәш кисәкләр кулланылышындагы стиль кытыршылыкларының сәбәпләре бу грамматик категорияне рус телендәге шундый ук күренеш белән мөнәсәбәттә караганда ачык күренә.

Татар һәм рус телләрендә тиңдәш кисәкләрнең үзенчәлекләре бигрәк тә күплек, килеш, тартым һ.б. кушымчаларның ялгану характерында күренә. Рус теле флектив тел булганлыктан, һәм бер үк кушымча берничә мәгънә белдерә алганлыктан, тиешле кушымчалар тиңдәш кисәкләрнең барысына да ялгана. Агглютинатив үзенчәлекле татар телендә, һәр кушымчаның үз мәгънәсе булганлыктан (чагыштырыйк: *столов – өстәлләрнең)*, тиңдәш кисәкләрнең барысына да кушымчалар ялгану шарт түгел. Бертөрле кушымчаларның янәшә яки якын арада кабатланып килүе бу тел стиле өчен уңай күренеш түгел. Тел кыскалыкка, җыйнаклыкка омтыла, һәм моңа ирешүнең чаралары да бар:

1. Тиңдәш кисәкләр икәү генә булганда, күплек, килеш һәм тартым кушымчалары һ.б. төрле кушымчалар икенче сүзгә генә ялгана: ***университет*** *һәм* ***институтларның*** *материаль-техник базасы;* ***шәһәр*** *һәм* ***поселоклардагы*** *төп торак фонды;* ***завод-фабрикаларыбызның*** *саны өзлексез арта бара.* Мисаллардан күренгәнчә, бу очракта тиңдәш кисәкләр үзара теркәгеч яисә интонация ярдәмендә бәйләнә.

2. Тиңдәш кисәкләр күп булмаганда, кушымчалар соңгы сүзгә генә ялгана. Мәсәлән: ***Промышленность, төзелеш, транспорт*** *һәм* ***элемтәнең*** *барлык тармаклары тагын да зур исеш алды; Механизаторларыбыз,* ***сабан, тырма, культиватор*** *һәм* ***чәчкечләрне*** *көйләп, кышкы саклауга куйдылар.* Бу очракта тиңдәш кисәкләрнең соңгы икесе үзара *һәм* теркәгече, башкалары интонация ярдәмендә бәйләнә.

3. Тиңдәш кисәкләр күп булганда, кушымчалар аларның берничәсеннән соң кабатланып килергә мөмкин. *Аның белән бергә мәктәптә укырга* ***Италия, Франция, Швециядән, Финляндия, Бельгия, Япониядән*** *һ.б. илләрдән вәкилләр килде*; *... илебез халыклары тырыш хезмәтләре белән* ***шәһәр, авыл, завод-фабрикаларны; юллар, каналлар, электр станцияләрен*** *барлыкка китергәннәр.*

4. Тиңдәш кисәкләр күп булганда, кушымчалар аларның беренчесенә һәм соңгысына ялганырга мөмкин: *Быел алар бергәләп* ***Мәскәүгә,*** *узган елда* ***Волгоград, Ростов, Уфа, Астраханьга*** *барганнар.*

Соңгы ике очракта тиңдәш кисәкләр үзара интонация ярдәмендә бәйләнә.

Ләкин еш кына, рус телендәге кушымчаларның бөтенесен дә татарчага механик рәвештә тәрҗемә итү аркасында, бертөрле кушымчалар күп тапкырлар кабатланып килә. Нәтиҗәдә сөйләм ялыктыргыч, ясалма төс ала. Мәсәлән: *районыбыз* ***авылларының*** *һәм* ***поселокларының*** *инженер-техник работниклары... (районыбыз* ***авыл-посёлокларының*** *инженер-техник хезмәткәрләре...* кирәк). *Алар – пропагандистлар, агитаторлар, политинформаторлар, укытучылар, мәктәпкәчә яшьтәге балалар учреждениеләре работниклары, махсус уку йортлары укытучылары, культура учреждениесе работниклары...; Алар арасында бухгалтерлар, аудиторлар, икътисадчылар һәм җитәкчеләр, укытучылар һәм студентлар да бар* . Бу җөмләләрне болайрак төзәтеп булыр, һәм мәгънәләре шул ук сакланыр иде: *Алар – пропагандист, агитатор, политинформатор, укытучылар, мәктәпкәчә яшьтәге балалар учреждениесе хезмәткәрләре, махсус уку йортлары укытучылары, культура учреждениесе хезмәткәрләре...; Алар арасында бухгалтер, аудитор, икътисадчы һәм җитәкчеләр, укытучы һәм студентлар да бар; Белоруссия заводлары һәм фабрикалары шулай ук күпләп мотоцикллар һәм велосипедлар, радиоалгычлар һәм телевизорлар, фотоаппаратлар һәм электр лампалары... җитештерә*

*(Белоруссия завод-фабрикалары... мотоцикл һәм велосипедлар, радиоалгыч һәм телевизорлар, фотоаппарат һәм электр лампалары... җитештерә* дип, күплек кушымчаларын кыскартсаң, сөйләм җыйнаграк, шомарак булыр иде). *Хуҗалыкта атлары, сыерлары, сарыклары, кәҗәләре булган, кош-корт асраганнар (Хуҗалыкта ат, сыер, сарык, кәҗәләре булган...* татарча табигыйрак); *Алар (Советлар. – Р.Ю.) ... Иваново-Вознесенскида, Петербургта, Мәскәүдә, Ростовта, Саратовта, Костромада, Читада, Красноярскида, Иркутскида, Смоленскида һәм башка күп шәһәрләрдә һәм поселокларда төзелде.* Бу җөмләдәге урын-вакыт килеше кушымчаларының да бик күбесеннән котылырга мөмкин һәм кирәк.

Әйтелгәннәрдән тиңдәш кисәкләрдәге кушымчаларның барысын да бетерергә яки киметергә кирәк икән дигән фикер туарга тиеш түгел, әлбәттә. Монда чама хисе белән, кайбер нәрсәләрне исәпкә алып эш итәргә кирәк:

1) тиңдәш кисәкләрдәге кушымчалар, аерым басым ясап әйтелсә, саклана; 2) мәгънәгә зыян килү яки ялгыш аңлашылу ихтималы булганда, шулай ук кушымчаларны төшереп калдырырга ярамый; 3) кайчакта, сөйләм интонациясенә зарар китермәс өчен дә, кушымчаларны сакларга кирәк була.

Татар һәм рус телләрендәге грамматик үзенчәлекләр бу ике тел җөмләләренең мәгънәләре бердәй хәбәрләрендә дә чагылыш таба.

Татар һәм рус телләрендәге ия белән хәбәрнең ярашуында шактый зур аерма бар. Рус телендә ия күплек санда торса, хәбәр һәрвакытта да күплек формасында килә. Бу – рус теленең бер үзенчәлеге. Татар телендә исә, башка төрки телләрдәге кебек үк, ия белән хәбәр ярашуына катгый шарт юк. Ия күплек санда килгәндә, хәбәр күплек формасында да, урынына карап, берлектә дә кулланылырга мөмкин.

Татар телендә ия белән хәбәрнең ярашуы бердәм грамматик кагыйдә белән билгеләнмәсә дә, ия күплек санда булганда да хәбәрнең берлек формада куелуы стиль таләпләре белән аңлатыла. Телнең кыскалыкка, җыйнаклыкка омтылуын, бертөрле сүзләрнең, кушымчаларның кирәксезгә кулланылуыннан котылырга тырышуын без исемнәрдәге, тиңдәш кисәкләрдәге артык кушымчаларның сөйләм төзүдә уңай роль уйнамавында күрдек һәм алда фигыль – хәбәрләрдә һәм гомумән фигыльләрдә бертөрле

кушымчаларның стилистик кытыршылыклар китереп чыгаруында да күрербез.

Кыскасы, ия күплек санда килгәндә дә, хәбәрнең еш кына берлек формасында кулланылуы сөйләмнең җыйнак, шома, табигый агышлы булуына ярдәм итә. Бу – татар теленең рус теленнән аермалы сыйфатларыннан берсе, һәм шушы үзенчәлек икетеллелек практикасында һичшиксез исәпкә алынырга тиеш. Димәк, русча җөмләдә хәбәр күплектә тора дип, татарча җөмләдә дә хәбәрне һәрчак күплек санда куярга ярамый. Моны сөйләмнең көй, яңгыраш таләпләре кушканча, шул ук вакытта мәгънәгә дә зыян китермичә һәм аңлаешлылык дәрәҗәсен дә төшермичә эшләргә кирәк була. Хәлбуки безнең әдәби телдә, бигрәк тә матбугат телендә, тәрҗемә материалларында русча формага ияреп, җөмләнең хәбәрен һәрвакыт күплектә куллану хәлләре бар. Нәтиҗәдә сөйләмнең табигый яңгырашына зыян килә.

Хәзер җөмләнең иясе күплек санда торганда да, хәбәрнең берлектә килүе кулай булган очракларны аерым мисалларда карап китик. Ия белән хәбәр ярашуына карата билгеләнгән төп кагыйдә шул: аерым басым ясап әйтелмәсә һәм ияднән ерак тормаса, ия күплектә килсә дә, хәбәр, нигездә, берлек формасында кулланыла. Мәсәлән: *Коммунарлар һәр урам, һәр йорт, һәр карыш җир өчен* ***сугыша***; *1606 елда Илья Горчаков җитәкчелегендәге казак отрядлары Астраханьнан Идел буйлап югарыга таба күтәрелә* ***башлый.***

Татар теле җөмләләрендә хәбәр, ия күплектә торса да, түбәндәге очракларда берлек санда килә:

1. Ия санлы исем сүзтезмә белән белдерелгәндә: ***20 студент*** *терлекчелек комплексын төзүдә* ***катнашты*** *(20 студентов работали на строительстве животноводческого комплекса)* (рус телендә, ия *бер* саны белән килгән исем сүзтезмә ярдәмендә белдерелсә генә, хәбәр берлектә була: *51 человек пришёл – 51 кеше килде).* Татар телендә саналмыш һәрвакыт берлек формасында килгәнлектән, иясе санлы исем сүзтезмәсеннән торган җөмләләрдә хәбәр һәрвакыт берлектә була.

2. Җөмләнең иясе тартымлы сан белән белдерелгәндә: *100 укучының* ***50се*** *урып-җыю эшендә* ***катнашты.*** Рус телендә, тартым категориясе булмаганлыктан, ия күплек мәгънәсендәге *җыю* (собирательные) һәм *микъдар* (количественные) *саннары* белән белдерелә. Хәбәр андый очракта күплектә, сирәк кенә средний родта берлек санда килә. Ә татар телендә, ия җыю саны белән

белдерелгәндә, хәбәр күплектә дә, берлектә да килә ала: *унау эшлиләр; бишәү бара.*

3. Җөмләнең иясе *барысы, бөтенесе, һәммәсе, күбесе, күпчелеге, байтагы* кебек гомумиләштерүче сүзләр, шулай ук *кайберләре, кайберәүләре, кайсыберләре* кебек билгесезлек алмашлыгы функциясендәге сүзләр белән белдерелгәндә (рус телендә исә хәбәр мондый очракларда, гадәттә, күплек формасында куела, иясе *большинство* сүзе белән белдерелгәндә генә хәбәр средний родта, берлек санда килә ала: *большинство уехало): Механизаторларның **барысы** да катнаша*; *все работали – **бөтенесе дә** эшләде; некоторые отдыхают – **кайберәүләр** ял итә* һ.б.

4. Җөмләнең хәбәре төшем, кайтым юнәлешендәге фигыльләр, *-ар/-әр, -ыр/-ер (-мас/-мәс) -ачак-әчәк* кушымчалы киләчәк заман хикәя фигыльләр, хәзерге заман, берлек сан, өченче затта *-ла/-лә* кушымчасы алган фигыльләр белән, шулай ук сыйфат, рәвеш, модаль сүзләр белән белдерелгәндә: *Биредә фәнни-практик конференцияләр **уздырыла***; *Фәритләр иртәгә циркка **барачак** (барыр); Укучылар җәйге эшләрдә **катнашмый калмас;** Безнең авыл яшьләре бик **тырыш;** Студентлар тырышып **укырга тиеш.*** Рус телендә мондый очракларда хәбәр һәрвакытта да күплектә килә.

*5. Бара, килә, тора* кебек ярдәмче сүзләр белән килгән тезмә фигыль хәбәрләр берлек санда куела: *Аның хатлары укучыларга да **килеп тора;** ...аның мондый күренешләре **кабатлана бара**.*

*6. Була, иде* ярдәмче сүзе белән килгән кушма исемхәбәрнең төп сүзе күплектә булса, ярдәмче сүзнең берлек формасында куелуы кулайрак: ***Алар коммунистлар иде.***

Мәгълүмат чараларында ия белән хәбәр бәйләнешенең үзенчәлекләре еш кына исәпкә алынмый. Нәтиҗәдә шактый тупас стилистик һәм грамматик хаталар китә. Күплек кушымчаларының урынсыз кулланылуы,  күпләп тезелеп килүе сөйләмне авырайта. Мәсәлән:

| **ялгыш** | **дөрес** |
|---|---|
| *Тагылмага өелгән бүрәнәләрне* ике кеше бушаталар**.** | *Тагылмага өелгән бүрәнәләрне* ике кеше бушата**.** |
| *Нәтиҗәдә 10* кеше *фаҗига урынында ук* үлгәннәр. | *Нәтиҗәдә 10* кеше *фаҗига урынында ук* үлгән**.** |
| *Чөнки быел гына да* 12 яшүсмер урлашу кылдылар. | *Чөнки быел гына да* 12 яшүсмер караклык кылган. |

*Дәресләрне* белгечләр үткәрделәр.
*Хәзер исә Омск өлкәсе басуларында бу заводларның да яңа* көндәшләре тудылар.
*Шәһәр мәктәпләре укучыларының* ***өчтән бер өлеше*** *икенче чирекне “4” һәм “5” ле билгеләренә генә* ***тәмамладылар.***
*Нәтиҗәдә* ***терлекләрнең һәр башы*** *тәүлеккә 750 грамм үсеш* ***бирделәр.***
*Менделеевск шәһәрендәге 1 нче урта мәктәпне тәмамлаучылардан* ***6 кеше*** *Бөек Ватан сугышы елларында Советлар Союзы Герое дигән исемгә* ***лаек булдылар.***
1925 *елны 54* ***бала*** *укырга килделәр.*
*Ә аларның* ***җидесе*** *уку елы барышында* ***алышындылар.***
*Шулардан* ***тугызы*** гына *демократлар.*
***Болар барысы да*** *продукция җитештерүгә хәлиткеч* ***йогынтыя сыйлар.***
*Аларның* ***күбесе*** *үз эшләрен чын күңелдән* ***башкаралар.***
***Бөтенесе дә*** *матур күлмәкләрдән* ***булачаклар.***
***Һәркайсы*** *тәртип белән пөхтә итеп* ***урнаштырылганнар.***
*Хезмәт дисциплинасын ныгыту* ***мәсьәләләре*** *бик сирәк* ***тикшереләләр.***
***Сатып алучылар*** *аның эшеннән һәрчак* ***канәгатьләр.***
*Ул чиккән* ***сөлгеләр*** *мәктәп музеенда* ***саклpackages***

*Дәресләрне* белгечләр үткәрде.
*Хәзер исә Омск өлкәсе басуларында бу заводларның да яңа* көндәшләре барлыкка килде.
*Шәһәр мәктәпләре укучыларының* ***өчтән бер өлеше*** *икенче чирекне “4” һәм “5” ле билгеләренә генә* ***тәмамлады.***
*Нәтиҗәдә* ***терлекләрнең һәр башы*** *тәүлеккә 750 грамм үсеш* ***бирде.***
*Менделеевск шәһәрендәге 1 нче урта мәктәпне тәмамлаучылардан* ***6 кеше*** *Бөек Ватан сугышы елларында Советлар Союзы Герое дигән исемгә* ***лаек булды.***
1925 *елны 54* ***бала*** *укырга килде.*
*Ә аларның* ***җидесе*** *уку елы барышында* ***алышынды.***
*Шулардан* ***тугызы*** гына *демократ.*
***Боларның барысы да*** *продукция җитештерүгә хәлиткеч* ***йогынтыясый.***
*Аларның* ***күбесе*** *үз эшләрен чын күңелдән* ***башкара.***
***Бөтенесе дә*** *матур күлмәкләрдән* ***булачак.***
***Һәркайсы*** *тәртип белән пөхтә итеп* ***урнаштырылган.***
*Хезмәт дисциплинасын ныгыту* ***мәсьәләләре*** *бик сирәк* ***тикшерелә.***
***Сатып алучылар*** *аның эшеннән һәрчак* ***канәгать.***
*Ул чиккән* ***сөлгеләр*** *мәктәп музеенда* ***саклана.***

| | |
|---|---|
| ***...документлары*** *дәүләт архивында* ***саклананалар.*** | ***...документлары*** *дәүләт архивында* ***саклана.*** |
| ***... дирекцияләре*** *дә эшне бик нык яхшыртырга* ***бурычлылар.*** | ***... дирекцияләре*** *дә эшне бик нык яхшыртырга* ***бурычлы.*** |
| *Үсә төшкәч, ул* ***бурычлар*** *катлаулана* ***баралар.*** | *Үсә төшкәч, ул* ***бурычлар*** *катлаулана* ***бара.*** |
| *Бу көрәшнең* ***нәтиҗәләре шатландырмый кала алмыйлар.*** | *Бу көрәшнең* ***нәтиҗәләре шатландырмый кала алмый.*** |
| ***Алар*** *революцияне беренче* ***яклаучылар булдылар.*** | ***Алар*** *революцияне беренче* ***яклаучылар булды.*** |
| ***Бу үзгәрешләр...*** *договорларга кул куелу нәтиҗәсендә* ***мөмкин булдылар.*** | ***Бу үзгәрешләр...*** *договорларга кул куелу нәтиҗәсендә* ***мөмкин булды.*** |

## СТИЛЬ ЧАРАЛАРЫ БУЛАРАК ФИГЫЛЬ-ХӘБӘР ФОРМАЛАРЫ

Сөйләмнең табигый агышын, сыгылмалылык сыйфатын булдыруда катнашучы күп төрле фигыль формалары, үзара билгеле бер тәртиптә урнашып, сөйләмнең шомалыгына ярдәм итәләр, аңа үзенә бертөрле бизәк өстиләр, һәм, киресенчә, күп төрле фигыль формаларыннан тулы файдаланмыйча, нигездә, аларның бер-икесе белән генә эш итү сөйләмнең табигый интонациясенә, көенә зыян китерә, телне фәкыйрьләндерә. Бу бигрәк тә үткән заман хикәя фигыльләр кулланылышына карый.

Хәзерге вакытта сөйләмебездә (телдән сөйләмдә дә, язма сөйләмдә дә), шул исәптән мәгълүмат чаралары телендә дә, күбрәк хәтта кагыйдә буларак дияргә була, үткән заман хикәя фигыльләренең *-ды/-де, -ты/-те* кушымчалы билгеле үткән заман төрләре кулланылу һәм нәтиҗәдә ялыктыргыч интонация (монотонлылык) барлыкка килү күпмедер дәрәҗәдә рус теленең үткән заман хикәя фигыльләре йогынтысы белән аңлатыла.

Проза сөйләмендә җөмләләрнең, гадәттә, фигыль-хәбәрләр белән тәмамлануы татар телендәге сүз тәртибе закончалыгына бәйле. Җөмләләрнең хәбәрләре сөйләм вакытына кадәр булган эш-хәлне белдерә торган фигыльләр белән тәгъбир ителгәндә, һәрвакыт *-ды/-де, -ты/-те* кушымчалы билгеле үткән заман хикәя фигыль формасыннан гына файдалану рус телендәге үткән заман

хикәя фигыль формасына иярүдән килеп чыга: рус телендә үткән заман хикәя фигыльнең бер формасы гына кулланыла (анда төрле формалар юк), һәм, шуннан үрнәк алып, татарларның кайберләре татар теленең дә бер генә формасы *(-ды/-де, -ты/-те* формасы) белән эш итәләр, телебездә үткән заман хикәя фигыльнең күп төрле формалары барлыгын һәм алардан да файдаланырга кирәклеген онытalar яки белмиләр. Нәтиҗәдә татар теле бу мәсьәләдә рус теле белән чагыштырганда оттырышлы хәлдә кала.

Чөнки рус теленең үткән заман хикәя фигыльләре бертөрле кушымчага гына тәмамланмый *(ехал, шёл, сходил, нёс, взял).* Рус телендә сүз тәртибе дә ирекләрәк һәм фигыль-хәбәрләр дә җөмлә азагында безнең телдәгегә караганда сирәгрәк урнаша, шулай булгач, анда монотонлылык та барлыкка килми. Татар телендә исә, барлык җөмләләр дә *-ды/-де, -ты/-те* кушымчалы фигыль хәбәрләргә генә тәмамланганга, ялыктыргыч бертөрлелек килеп чыга. Җөмләләр кыска булганда, ялыктыргыч интонация тагын да көчәя.

Фигыльләр дөрес кулланылган табигый сөйләмдә мондый ялыктыргыч бертөрлелек сизелми, чөнки, гадәттә, үткән заман хикәя фигыльләренең төрле формалары кулланыла *(барды, барган, бара иде, барган иде, бара торган иде, барган булган, бара торган була, бара торган булган, барганы бар, барганы юк* һ.б.). Шуның өстенә, халыкның җанлы сөйләмендә фигыль-хәбәр җөмлә азагында гына тормый, ягъни җөмләләр фигыль-хәбәрләр белән генә тәмамланмый.

Фигыль кушымчалары тавтологиясенә карата әйтелгән бу фикер *-ды/-де, -ты/-те* кушымчалы фигыль-хәбәрләргә генә түгел, бәлки башка төрле фигыльләргә дә, тиңдәш фигыль кушымчаларына да карый: бертөрле кушымчаларның янәшә һәм якын арада берничә тапкыр кабатланып килүе сөйләмнең стиль ягыннан камиллегенә зыян китерә.

Димәк, ике тел белән эшләү процессында, бер телдә белдерелгән фикерне икенче тел чаралары белән тәгъбир иткәндә, ике тел фигыльләренең стилистик кулланылышындагы үзенчәлекләрен һич кенә дә истән чыгармыйча, татар телендәге фигыль формаларыннан тулы һәм оста файдаланып, сөйләмнең табигый агышына ирешергә кирәк.

*-ды/-де, -ты/-те* кушымчалы фигыльләр тавтологиясен булдырмауның төрле юллары бар:

1. Мәгънә ягыннан үзара тыгыз бәйләнгән һәм бик үк озын булмаган ике яки берничә җөмләне берләштереп, баштагы һәм уртадагы җөмләләрнең хәбәрләрен *-ып/-еп, -п; -гач/-гәч, -кач/-кәч* кушымчалы хәл фигыль формаларында куярга мөмкин. Мәсәлән: *2005 елда планнан тыш йөзләрчә мең сумлык продукция* ***сатылды.*** *Планнан тыш бер миллион сумнан артык табыш* ***алынды.*** Бу ике җөмлә мәгънә ягыннан бер-берсе белән тыгыз бәйләнгән, алар арасында сәбәп-нәтиҗә мөнәсәбәте бар: планнан тыш продукция сатылу аркасында бер миллион сумнан артык табыш алынган. Шуның өстенә, аларны кабатланып килгән *планнан тыш* сүзе дә берләштерә. Шулай булгач, алардан *...сатылып, ...табыш алынды* дигән бер җөмлә төзергә мөмкин. Мондый җөмләләрне дә берләштерү әйбәт булыр иде: *Алдынгы терлекче елның декабрь аенда аеруча яхшы нәтиҗәләргә иреште, һәр сыерыннан 535 килограмм сөт* ***сауды***, *"Алдынгы терлекче, һәр сыерыннан 535 килограмм сөт* ***савып,*** *үткән елның...* ***иреште" – татарча табигыйрак.***

2. Тиңдәш фигыльләрнең берсен шулай ук *-ып/-еп, -п; -гач/-гәч, -кач/-кәч* кушымчалы хәл фигыль формаларында кулланырга мөмкин. Мәсәлән: *Мин бәлагә юлыктым һәм больницага* ***эләктем.*** *– Мин, бәлагә* ***юлыгып****, больницага* ***эләктем;*** *Елгадан аерылган сулыклар кипкәндә, анда күп санда маймычлар* ***кала*** *һәм* ***үләләр*** (дөресе *– маймычлар* ***калып үләләр); Бу*** *йөкләмәләр завод профсоюз активы җыелышында* ***тикшерелделәр*** *һәм* ***кабул ителделәр*** (дөресе – *тикшерелеп кабул ителде); Бәрәңгене иртә срокларда – май ае башында* ***утыртачакбыз*** *һәм шул ук вакытта рәт араларына берәр центнер исәбеннән ашлама* ***кертәчәкбез*** (дөресе – *Бәрәңгене ...****утыртып ...ашлама кертәчәкбез).***

Бу җөмләләрдәге тиңдәш фигыльләр үзара сәбәп-нәтиҗә, вакыт ягыннан эзлеклелек мөнәсәбәтләрендә торалар, һәм шунлыктан аларның беренчеләрен *-ып/-еп, -п* кушымчалы хәл фигыль формасында куллану үзен аклый: андый мөнәсәбәттәге процессларны белдерә торган фигыльләрнең мондый бәйләнеше татар теленең табигатенә күбрәк туры килә.

3. Күп җөмләләр рәттән *-ды/-де, -ты/-те* кушымчалы фигыльләргә тәмамланганда, ул форманы үткән заманның башка төрләре һәм тасвирлаулы хәзерге заман формасы белән алмаштырырга мөмкин. Монда, урынына, мәгънәсенә карап, ул формаларның төрлесен куллану әһәмиятле.

Монотонлылык башка төр кушымчалы фигыльләрнең тиңдәшләнеп килүе аркасында да була. Мондый бертөрлелектән фигыльнең берсен хәл фигыль формасына куеп котылырга мөмкин: *Россия хөкүмәте барлык илләргә, сугышны* ***туктатырга*** *һәм тынычлык* ***төзергә*** *тәкъдим итте. – Россия хөкүмәте барлык илләргә сугышны* ***туктатып,*** *тынычлык* ***төзергә*** *тәкъдим итте.*

Практикада, бигрәк тә тәрҗемә иткәндә, тиңдәш фигыльләр өлкәсендәге бу мөмкинлек еш кына онытыла, һәм монда рус теле интерференциясе чагылыш таба: ике тел белән эш итүче кеше рус җөмләсендәге фигыльләр йогынтысында татар телендә дә шундый ук чаралардан файдаланырга күнегеп китә. Хәлбуки татар теле өчен тиңдәш процессларны белдерә торган сүзләрнең берсен хәл фигыль формасына кую – табигый күренеш. Аннары шунысы да бар: рус телендә тиңдәш фигыльләр еш кына бертөрле кушымчаларга тәмамланмаганлыктан, аларда бертөрлелек сизелми дә, ә татар телендә тиңдәш фигыльләр бер формада булалар. Чагыштырып карыйк: *Когда Ленин умер и настал срок проводить его последний раз в занесённую снегами Москву... – Ленин* ***үлгәч,*** *һәм кар баскан Мәскәүгә аны соңгы тапкыр озату сәгате* ***җиткәч****...* Бу җөмләне *Ленин* ***үлеп...*** *озату сәгате* ***җиткәч...*** рәвешендә төзесәң, уңышлырак булыр иде. *Анда Россия Президенты Путин* ***да катнашты*** *һәм* ***чыгыш ясады****. ...катнашып чыгыш ясады рәвешендә* булса, интонация шомарак була.

Татар теленең табигый интонациясен төзү чараларының берсе – аналитик фигыльләр. Бу фигыльләр телебезнең үзенчәлеген тәшкил итә. Рус телендә синтетик фигыль кулланылган урында татар телендә күбрәк аналитик фигыль кулланыла.

Матбугатта, радио-телевидение тапшыруларында, рус теле тәэсирендә булса кирәк, күбрәк синтетик фигыльләр белән генә эш итәргә тырышу сизелә. Янәсе, рус телендә *пишет* икән – татар телендә дә *яза, находят* икән – *табалар, слышится* икән – *ишетелә* һ.б. Ә бит *пишет* ул татарча *яза* гына түгел, *язып утыра* да, *язып ята* да; *находят табалар* гына түгел, *табып алалар* да; *слышится ишетелә* генә түгел, *ишетелеп куя* да, *ишетелеп китә* дә һ.б.

Мисалларга игътибар итик:

*Илбашы Минтимер Шәймиев, чәчәкләр куйгач, ветераннар янына* ***утырды*** *(...килеп утырды* булса, саф татарча булыр иде).

*Ярославльлеләр уен башында ук каршы як командасыннан курыктылар.* Монда процессның – *куркуның* – кинәт булуын *калды*

ярдәмче фигыле ярдәмендә белдерергә мөмкин һәм кирәк иде: *...каршы як командасыннан куркып калдылар.* Шулай булганда, җөмләләрнең интонациясе тулырак, шомарак булыр иде. *Тормыш табигый рәвештә яңа проблемаларны да* ***куя***. Монда да процессның даими кабатланып торуын, хәбәргә *тора* ярдәмче фигыле өстәп, аналитик форма белән белдереп була. Нәтиҗәдә җөмләнең интонациясе дә камилләшер иде (... проблемалар да **куеп тора**)..

Бер уңай мисал да китерик. Г.Ибраһимовның "Тирән тамырлар" романы *Фәхрине үтереп ташладылар* дигән җөмлә белән башланып китә. Бу очраклы түгел, әлбәттә. *Фәхрине үтерделәр* генә булса, мәгънә дә тулы булмас, җөмләнең яңгырашы да табигыйлыгын югалтыр иде.

Күргәнебезчә, безнең телдә фигыльләрнең шулай дәрәҗә белдерә торган сүзләр белән килүе, беренчедән, төп мәгънәгә өстәп, билгеле бер мәгънә төсмерләре белдерергә мөмкинлек бирсә, икенчедән, сөйләмнең интонациясен тулырак, сыгылмалырак итә.

Аңлашыла ки, фигыльләрнең бу бай мөмкинлекләре практикада тулы файдаланылырга тиеш. Кыскалыкка омтылу принцибын сылтау итеп, уңайлылыкка омтылып, фигыльләрнең аналитик төрләренә игътибар итмичә, синтетик төрләре белән генә эш итү, шул рәвешчә, янәсе, кәгазь һәм вакыт экономияләү телебезнең табигыйлыгына һәм мәгънәгә зыян китерә. Түбәндәге җөмләләрдә, мәсәлән, калын хәрефләр белән бирелгән синтетик фигыльләрне аналитик итеп төзү мәгънәне тулырак бирергә һәм камил интонациягә ирешергә ярдәм итәр иде: *Оясыннан чыкканчы, ул башта сакланып кына сузылып* ***карый, тыңлый,*** *аз гына шикләнсә дә, яңадан* ***кача*** *(...карап, тыңлап тора, иснәнә... кереп кача* булса, әйбәтрәк булыр иде); *Гаять куәтле тизлек белән бик зур кара болыт килә, нәрсәгәдер* ***суккан кебек,*** *беренче көчле җил улавы ишетелә (...китереп суккан кебек* кирәк).

Җөмләнең фигыль-хәбәре арта, көчәя барган процессны белдергәндә, мәгънә белән интонация тулырак булсын өчен, гадәттә, хәбәргә *бара* сүзе өстәлә. Андый җөмләләрдә *елдан-ел, көннән-көн, торган саен* кебек сүзләр дә кулланылучан яки хәбәрләре кабатланып килүчән була: *Бу тармак хәзер елдан-ел киңәя бара; Татарстан башкаласы Казан көннән-көн матурлана, ямьләнә бара; Хезмәт алдынгыларының саны ишәйгәннән-ишәя бара.*

Татар телендә фигыль-хәбәрләрнең бу үзенчәлеге тел практикасында һәрвакытта да исәпкә алынмый. Мәсәлән: *Укучыларны*

*чит телләргә өйрәтү елдан-ел яхшыра*; *Кимчелекләрне бетерүгә игътибар көчәйгәннән-көчәя.* Бу җөмләләрнең хәбәрләренә *бара* сүзе өстәлсә, интонация тулырак булыр иде.

Татар телендә сөйләм вакытыннан элек булган процессны белдерә торган тартымлы үткән заман сыйфат фигыль белән *бар* сүзеннән ясалган яисә кабатлау юлы белән төзелгән үзенчәлекле хәбәр конструкцияләре кулланыла. Алардан файдалану шулай ук интонациядәге монотонлылыктан котылырга ярдәм итә: *Минем Африкада булганым бар; Свидригайловны ул берничә мәртәбә очраткан иде очратуын; Чыгырыннан ычкынды егет, такылдапмы-такылдый.*

Элегрәк, рус телендәгедән аермалы буларак, даими процесс белдергәндә, татар теленә аналитик исем-хәбәрләр куллану хас, ягъни рус телендә синтетик исем хәбәрләр кулланылган очракта, татар телендә күбрәк аналитик исем-хәбәр кулланыла, диелгән иде. Бу үзенчәлек тә интонация камиллеге белән бәйләнештә тора. Рус теле формаларына ияреп, исем-хәбәрләрне ярдәмче сүзләрдән башка гына куллану сөйләмнең табигый агышына комачаулый, аны вакытсыз туктатып, кисеп калдыра. Мәсәлән: *Иң соңыннан **душ керергә,** ярты сәгать чамасы **ял итәргә** кирәк. Шуның белән **процедура тәмам** (...душ кереп, ...ял итәргә (ял итеп алырга) кирәк. Шуның белән процедура тәмам була*).

Рус теленә ияреп, ике составлы җөмлә кулланыласы урында бер составлы (атау) җөмләләр куллану да интонациягә зыян китерә: *Ә тегендә, кырыйда, түгәрәк башня (...башня тора* кирәк); *Бу көйдә – чишмәләр чылтыравы, әллә каян килеп чыккан күк күкрәве, көтүче быргысының моңы (...моңы бар* кирәк); *Лондонның Көнбатыш як дип йөртелә торган Вест Энд районында – иң әйбәт музейлар, театрлар, гостиницалар, магазиннар (...магазиннар урнашкан* булса, интонация тулы булыр иде).

Хәбәр составында килеп, аңа мәгънә төсмере өсти, кисәкчә функциясен башкара торган сүзләр дә җөмләнең интонацион яктан бөтен, камил булуына ярдәм итә, һәм аларның тиешле урында булмавы сөйләм агышына күпмедер дәрәҗәдә зыян китерә. Хәзер шундый сүзләрнең кайберләрен карап китик:

*1. Инде* сүзе җөмләдә:

а) төп процессны белдерә торган сүзгә тәмамлану, чикләнү төсмере өсти: *Йә, ярар, **җитәр инде** (Ну ладно, хватит);*

б) процессның дәвамлылыгын белдерә: *Ул монда егерме ел **эшли инде** (Здесь она работает двадцать лет)*;

в) сорау җөмләләрдә *инде,* хәбәр янында килеп, сорауны көчәйтеп, эмоциональ төс бирә: *Минем сине ничә ел* ***күргәнем юк инде?!***

Кайбер очракларда *инде* үтенечне көчәйтү өчен кулланыла: *Син* ***ачуланма инде*** *(Ты уж извини).* Барлык очракларда да *инде* сөйләмнең дөрес көйле булуына ярдәм итә.

*2. Икән* ярдәмче сүзе шулай ук төрле мәгънә төсмерләре белдерә

а) сөйләүче, үзе күрмичә генә, башка чыганакларга таянып хәбәр итә торган күренешләрнең көтелмәгән яңалык булуына ишарә ясый: *АКШ галимнәре исбат иткәнчә, яңа чыккан күгәрчен балалары 3-4 атнага кадәр яктылыкны күзләреннән башка сизәләр икән;*

б) сорауны көчәйтеп, аңа эмоциональ төс бирә: ***Кайда икән*** *аларның барысы да, ни булган икән аларга? (Где они все, что с ними?*).

3. *Әле* сүзе дә процессның тәмамланмаган булуына ишарә итә һәм сорауга эмоциональлек өсти: *Швеция белән сугышны бетерү өчен, аны диңгездә* ***җиңәргә кирәк иде.*** *...аны диңгездә* ***җиңәргә кирәк була әле*** формасында бирелсә, мәгънә дә төгәлрәк, интонация дә тулырак булыр иде. Чагыштырыйк: *Ничә көннән бирле укып* ***бетермәдеңме?*** *– Ничә көннән бирле укып* ***бетермәдеңме әле?*** Икенче җөмләдә интонация тулырак.

*4. Әллә* кисәкчәсе, хәбәр янында килеп, сорауны көчәйтә. Чагыштырып карыйк: *Тукта әле... Мине күрми дип уйлыйсызмы? – Погоди... Что же вы думаете, я не вижу? Тукта әле... Мине күрми дип уйлыйсызмы* ***әллә?*** дигәндә, сорау тойгы белән әйтелә.

5. Хәбәр янында килгән *шул* сүзе сөйләмгә өздереп әйтү мәгънәсен өсти. Мәсәлән: *Да, забыл* мәгънәсен *Әйе, онытьтым* фразасы тулы интонация белән белдерми. *Онытканмын шул* булса, мәгънә уңай якка үзгәрер иде.

6. Тойгыны көчәйтү чарасы буларак, хәбәр составында кисәкчә функциясендә *ул* сүзе килә. *Уку елының бөтен борчылуларыннан соң иркенлеккә чыгу нинди рәхәт!* Бу җөмләдә фикерне хис белән әйтү өчен киң итеп алган сулыш киселеп калган кебек була. *Рәхәт* янына *ул* дип өстәгәндә, хәл уңай якка үзгәрә.

7. Сорау җөмләнең хәбәре составында, сөйләмгә эмоциональ һәм интонацион бөтенлек бирү өчен, *соң* кисәкчәсе килә: *Бу бурычларны ничек* ***утиләр соң?*** Ләкин бу чарага җитәрлек игътибар ителми: *Иҗтимагый шәхестә культура тәрбияләү белән җенси*

*тәрбия мәсьәләләре арасында нинди бәйләнешләр* ***бар?*** *(нинди бәйләнешләр* ***бар соң?*** кирәк).

8. Җөмләнең интонациясе тулы булсын өчен, гадәттә, исем хәбәргә куелуы шарт булмаган хәбәрлек кушымчасы өстәлә: *Чагыштырып карарга, кат-кат тикшерергә тиешбез; Әйе, бүген-иртәгә килеп җитәргә* ***тиешләр.***

9. Риторик сорау җөмләләрдә, рус теленнән аермалы буларак, татар телендә хәбәрнең юклык формасында торуы әһәмиятле. Бу мәсьәләдә рус теленә ияреп, сөйләмнең табигыйлыгына зарар китерү очраклары бар: *Күпме модельләр* ***ясады*** *ул! (Сколько моделей он сделал!) (Күпме генә модельләр* ***ясамады*** *ул!* кирәк); *Бу чорда ничә буын савучылар гына* ***әзерләде*** *ул! (Сколько поколений доярок она за этот период подготовила!) (Ничә генә буын сыер савучылар* ***әзерләмәде*** *ул чорда!* кирәк).

## ЯРДӘМЛЕК СҮЗЛӘРНЕҢ ИНТОНАЦИЯ ТӨЗҮДӘГЕ РОЛЕ

Без кайбер сүзләрнең, хәбәр составында килеп, сөйләмнең шомалыгына, табигый агышына ярдәм итүе турында сөйләп киткән идек. Шундый ук вазыйфаны, хәбәр янында гына түгел, җөмләнең төрле урыннарында килеп, башка ярдәмлек сүзләр дә башкара.

Андый сүзләрне тикшерә башлаганчы, шуны искәртеп куйыйк: интонация бөтенлегенә хезмәт итә торган сүзләр еш кына хаксыз төшереп калдырыла, дөресрәге, кирәк була торып та куелмый, бу, нигездә, рус телендәге җөмлә төзелешенең татар теленә йогынтысы аркасында килеп чыга. Бу күренешнең технологиясе болай: ике телдә язучы яки, гомумән, ике телдә сөйләүче кеше, бер телдәге фикерне икенче тел чаралары ярдәмендә тәгъбир иткәндә, чыганак телнең һәр сүзенә икенче телдә аерым тәңгәллек табу юлы белән эш итә, һәм, димәк, бу эш сүзгә-сүз принцибы белән генә эшләнгәнлектән, икенче телдәге сөйләм (җөмлә) интонациясе өчен кирәкле өстәмә сүз кулланылышка кертелми, телнең стилистик камиллегенә ирешелми кала. Шуңа күрә дә, бер телдәге фикерне икенче телгә күчергәндә, ике тел чаралары арасында тәңгәллекләр урнаштырылуга иҗади карарга, икенче телдәге сөйләмнең табигый яңгырашлы, стиль ягыннан камил булуына ирешергә кирәк.

Интонация тулылыгы өчен хезмәт иткән сүзләрнең аеруча киң кулланыла торганнарыннан берсе – *менә* күрсәтү алмашлыгы.

Сөйләмебезгә игътибар итсәк, без анда бу сүзнең бик еш кулланылганын күрербез. Ул, гадәттә, җөмлә башында килеп, сөйләм көенең бөтенлегенә, шома агышына хезмәт итә. Әйтерсең, ул, кеше сөйли башлаганда, җөмләдәге бушлыкны тутырып кую өчен кирәк була: ***Менә*** *сизелмичә генә биш ел вакыт үтеп тә китте; ...цехында* ***менә*** *егерме елдан артык инде Камил Гарипов та ярышның алгы сафында бара.* Рус телендә мондый очракларда *вот* сүзе кулланыла.

*Бер* сүзе дә еш кына кисәкчә вазыйфасында интонация тулылыгы өчен кулланыла: *Измә чәчрәп беткән тәрәзәдән чуар косынкалы, көләч йөзле бер кыз күренә.* Монда *бер* санны белдерми (кызның берәү генә икәнлеге аннан башка да аңлашыла), бәлки сөйләмнең табигый интонациясенә ирешү чарасы буларак килә. *Кинәттән аңа яңа дөнья ачылган төсле булып китте; Ниндидер эчке тавыш аңарга әйтә килде.* Бу җөмләләргә *бер* сүзен өстәү таләп ителә: *яңа бер дөнья, ниндидер бер эчке тавыш.*

*-гына/-генә, -кына/-кенә* кисәкчәләре сөйләмгә төрле мәгънә төсмерләре бирә һәм мәгънә көчәйтү, чик билгеләү, төшенчәне конкретлаштыру һ.б. өчен кулланыла. Бу кисәкчәләр тагын бер мөһим вазыйфа үтиләр – сөйләм көенең камиллегенә ярдәм итәләр. *Иртәгесен Оленин соң* ***гына*** *уянды. – На другое утро Оленин проснулся поздно.* Бу җөмләдәге *гына* кисәкчәсенең мәгънә өчен әллә ни әһәмияте юк: ул *соң* мәгънәсен көчәйтү өчен дә бердәнбер чара түгел, моның өчен *бик* сүзеннән дә файдаланып булыр иде. Бу очракта *гына* фразаның табигый, салмак яңгыравына ярдәм итә. Ләкин интонациянең камиллегенә ирешүдә, башка күптөрле чаралар кебек, бу чара да тиешенчә файдаланылмый: *Кыска вакыт эчендә илебез тоташ грамоталы илгә әверелде*; *Аларның эшләре һич бетмәс кебек тоелды миңа.* Бу җөмләләрдәге *кыска, һич* сүзләрен тиешле кисәкчәләр белән бергә куллану әйбәтрәк булыр иде *(кыска* ***гына вакытта,*** *һич* ***кенә дә*** *бетмәс кебек). А.В.Тарасовны кайсы малай белми икән?* Бу җөмләдә *гына* кисәкчәсе куелмау аркасында риторик сорау югалган. Бу – тупас хата ***(кайсы гына*** *малай белми икән?* кирәк иде).

*Да-дә, та-та* кисәкчәләре дә сөйләмгә төрле мәгънә төсмерләре өсти: процессның моңарчы да булганлыгын, башкалары да барлыгын белдерә, мәгънәне көчәйтә һәм сөйләм интонациясен төзүдә дә әһәмиятле роль уйный. Тиешле урында алар куелмаса, сөйләм агышы өзелеп, тоткарланып тора. *Да-дә, та-тә* кисәкчәләре, гадәттә, билгеле бер сүзләр янында кулланыла.

1. Юклык алмашлыклары *(бернинди, берничек, беркем, һичкем, берни* һ.б.) янында: *Димәк, Урта Идел һәм Урал буе татарларының Көнчыгыш Европа җирләренә басып кергән монгол-татарлар белән **бернинди дә** уртаклыгы юк.* Кайчагында, кирәк була торып та, кисәкчәләр куелмый: *Аның ни әйтергә теләгәнен **беркем** аңламаячак* (дөресе – *... **беркем дә** аңламаячак); ...**беркайчан** оныт-мам* (*...**беркайчан** да оныттмам* кирәк); ***Әле** ярый сез бар...* ***(әле дә** ярый сез бар* кирәк); *Мине, хореограф буларак, **барыннан биг-рәк** халык биюләре кызыксындырды **(барыннан да** бигрәк* кирәк); ***Тырышларның** тырышы **(тырышларның да** тырышы* кирәк); *Менә көтелгән көн **18 гыйнвар** килеп җитте **(18 январьда** килеп җитте* кирәк).

2. Билгеләү алмашлыклары *(һәркем, һәрнәрсә, һәммәсе, ба-рысы, бөтенесе* һ.б.) янында: *полицейскийларның һәммәсе дә диярлек китеп бетте.* Бу җөмләләрдә кисәкчәләр куелмаган: *Менә, Елена Александровна, **барысы** шунда (**барысы да** шунда* кирәк); *Бу гаиләнең нинди тату, бәхетле булуын хәзер **һәркем белә** инде **(...һәркем дә белә** инде* кирәк).

*3. Бик, утә* кебек рәвешләр янында: *Бу эш мине **бик** тә дул-кынландырды.*

*4. Гына-генә, кына-кенә* кисәкчәләре белән килгән сүзләр янын-да: *Йортның бер катында **гына да** 46 квартира бар.* Бу җөмләләрдә *гына-генә, кына-кенә* кисәкчәләренә *да-дә* кисәкчәләрен өстәргә кирәк иде: *Кайбер бригадирлар (алар **гына түгел)** уңышка ирешәчәксең дип уйлыйлар (алар **гына да** түгел* кирәк иде); *Район эчке эшләр бүлегендә **генә** 18 махсус урта белемле сотрудник бар.* Соңгы җөмләдә *дә* кисәкчәсенең төшеп калуы мәгънә ялгышына китерә: *махсус урта белемле сотрудник башка оешмада юк* дип уйларга нигез кала. Әгәр *дә* кисәкчәсе булса, *башка оешмалар белән беррәттән район эчке эшләр билегендә дә бар* дигән мәгънә аңлашылыр иде. Димәк, бу очракта җөмләне *бүлегендә **генә дә...** хезмәткәр бар* формасында төзергә кирәк.

*5. Хәтта* кисәкчәсе белән килгән сүзләр янында: *Ул хакта сүз кузгатырга аның хәтта **теле** әйләнмәде* дигән җөмләне ... ***хәтта теле** дә әйләнмәде* рәвешендә бирү интонацион яктан уңышлырак булыр иде. Исебезгә төшерик: *хәтта шуны да эшли алмагансың, ичмаса,* дип сөйли халык.

*6. Әле дә булса* конструкциясе составында килә: *Чүпрәк кисәкләре* ***әле булса*** *идән уртасында аунап ята* дигән җөмләне *әле дә булса аунап ята* дип бирергә кирәк.

7. Елдан айга, айдан көнгә кимеп барган вакыт исемнәренең компонентлары үзара *да-дә* кисәкчәләре белән бәйләнә: *бер ел да ике ай* (русларның *два года, шесть месяцев* формасына ияреп, *ике ел, алты ай* дип сөйләү һәм язу дөрес түгел.

*8. Гына түгел, ...да* конструкциясе составында *(не только, но и* үрнәгендә) килә. Бу конструкция телдә инде үзләштерелгән, һәм аның составыннан *да-дә, та-тә* кисәкчәләрен төшереп калдыру тел нормаларын бозу булып санала: *Механизатор Ишим ага Арслановны авылда* ***гына түгел, районда*** *яхшы беләләр* ***(районда да*** *яхшы беләләр* кирәк). Кайчак *да-дә, та-тә* кисәкчәләре әдәби телдә кирәк булган башка очракларда да кулланылмый. Мәсәлән: *Гыйнвар үтте. Февраль җитте, ә эшләр һаман бетми әле (Январь* ***да*** *үтеп китте, февраль* ***дә килеп*** *җитте, ә эшләр һаман* ***да*** *бетми әле* кирәк); *Бөтенесе өйләренә кайталар, автобуста бер генә буш урын юк (автобуста бер генә буш* ***урын да*** *юк* кирәк); *Сыерларның савылмыйча калган вакытлары була (савылмыйча калган* ***вакытлары да*** *була* кирәк).

Интонация тулылыгы өчен кайбер башка сүзләрдән дә файдаланырга мөмкин:

*1) Моннан фәлән ел (ай, көн) элек* конструкциясе составында *моннан* сүзен.

2) Җөмлә азагында *анысы, үзе, аның, шунда* сүзләрен. *Танышлар мәсьәләсендә дөрес әйтәсез* ***анысы.***

3) Тартымлы исем янында, интонация төзү чарасы буларак, алмашлыкларны: *Минем әтием колхозчы,* ***аның*** *әтисе җирсез була*; ***Безнең*** *өметебез шунда, бары шунда гына булачак; Ә* ***сезнең*** *карашыгыз икенче төрле идеме?* Чагыштырып карыйк: *Исемең ничек? (Как тебя зовут?) – Исемең ничек синең?* Алмашлык белән килгәндә, интонация уңышлырак.

Интонация тулылыгы өчен кисәкчә функциясендәге *ул* сүзе җөмләнең төрле кисәкләре янында килә ала. Чагыштырып карыйк: *"Нигә кылыч?" диде ("Зачем же меч?" – сказал). – "Нигә ул кылыч?" – диде.* Ул сүзе өстәлгән вариант табигыйрак яңгырый.

*Әлбәттә, билгеле* кебек модаль сүзләр дә интонация камиллегенә ярдәм итә. Алар, җөмлә азагында килгәндә, сөйләм агышын тәмамлап куя.

Сөйләм төзү процессында (сөйләгәндә дә, язганда да) җөмләнең, фразаның интонацион тулылыгы, камиллеге өчен, алдан күреп бетереп булмый торган, мөстәкыйль мәгънәгә ия булмаган башка бик күп төрле сүзләрдән дә файдаланырга мөмкин, әмма алар интонация таләбен тоеп кулланылырга тиеш.

Интонация камиллелегенең табигый сөйләм төзүдәге әһәмияте, бер тел формаларын, сүзләрен икенче телгә механик рәвештә күчерүнең икенче тел табигатенә никадәр зыянлы булуы тәрҗемәләрдә ачык күренә. Кайчагында, оригинал мәгънәсе бирелсә дә, текст татарча яңгырамый. *Мин әйттем – утырыгыз! Бу – приказ! (Я сказал – садитесь! Это приказ! Әйттем бит мин сезгә утырыгыз дип! Приказ бу!* рәвешендә булса, интонация үзгәрә. Беренче *гыйнвар – бәйрәм көн. Тик бөтен кеше дә ял итмәде* (1 *январь – праздник. Но не все отдыхали).* Монда икенче җөмлә алдыннан сулыш киселеп калгандай була. Җөмләне 1 *гыйнвар – бәйрәм. Әмма бу көнне бөтен кеше дә ял итмәде* дип үзгәртсәң, сөйләм агышы шомарак булыр иде. *Мылтыгын элә, бикләнә, йокламый (Ружьё повесит, закроется кругом, лежит и не спит).* Русчада интонация табигый. Татарча җөмләдә табигыйлык югала: *Мылтыгын элеп куя да бикләнеп ятып, ә үзе йокламый* дисәң, әйбәтрәк булыр иде.

Сөйләмнең (текстның) табигый яңгыравына ирешү өчен, халыкның җанлы сөйләм чараларыннан (аерым сүзләр, әйләнмәләрдән, җөмләдә сүзләрнең үзенчәлекле тәртибеннән, кабатлаулар, инверсиядән һ.б.) тулы файдаланырга кирәк.

Моңарчы без, күплек кушымчалары еш кына кирәксезгә кулланыла, дигән идек. Кайбер очракта, интонация тулылыгы өчен, күплек кушымчаларын грамматика кагыйдәләре таләп итмәгәндә дә куярга туры килә, берлек санда гына йөри торган исемнәргә күплек кушымчасы өстәлә:

*Кайбер төннәрне хәтта сине уйлап* ***күзләремә*** *йокылар кермәде.* Моңа мисаллар сөйләм телендә һәм халык авыз иҗатында да бар: ***Ага сулар,*** *ага* ***сулар,*** *ага* ***сулар, ташулар.*** Кешенең исемен, фамилиясен, атасының исемен күплектә кую (бу алым рус телендә дә бар): *Пульхерия* ***Александровналарда*** *ифрат кыңгелсез сөйләшүдән соң...*; *Без кичә* ***Фәритләргә*** *бардык.*

Тиңдәш ялгызлык исемнәрен санап барганда, аларның соңгысы күплектә куела (бу үзенчәлек татар теленә генә хас). *Күргәзмәдә Татарстан рәссамнарыннан Әнвәр Шәрипов... һәм Ил-*

*дар Зарипов* ***катнашалар***. Тыңдаш кисәкләрнең соңгысын күплек санда, хәбәрне берлектә куйсаң, интонация шомарак булыр иде: *Күргәзмәдә...* ***Илдар Зариповлар катнаша.***

Телебездә парлы сүзләрнең рус телендәгегә караганда күбрәк кулланылуы да сөйләм көенең сыгылмалылык хосусияте белән аңлатыла булса кирәк. Әйтик, рус телендә *дети* диелә икән, татар телендә аны *бала-чага(лар)* дип тә *(балалар* гына дию шарт түгел), рус телендә *посуда* икән, татарча *савыт-саба (савыт* кына түгел) дип тә әйтергә мөмкин һәм урыны белән кирәк тә.

Интонация шомалыгы өчен аерым сүзләр, кушымчалар өстәгәндә, үтә саклык таләп ителә. Мавыгып китеп, кирәксә-кирәкмәсә дә андый элементлар куллану дөрес булмас иде. Монда сөйләмнең агышын тоеп, чама белән эш итәргә кирәк. Бу таләп, гомумән, стиль чаралары куллану мәсьәләсенә карый. Тик, мисаллардан күргәнебезчә, кайбер каләм ияләренең өстәмә сүз, кушымча мәсьәләсенә дә, стиль чараларының башка төрләренә дә (без аларны алга таба да күрербез) игътибарлары җитми, алар моны вак нәрсә дип саныйлар булса кирәк.

Артык сүзләр, кушымчаларны бетерү белән урынсыз мавыгу бигрәк тә кайбер журналистларга хас. Алар вакытлы матбугат материалларының теле мөмкин кадәр кыска, җыйнак булырга, мәгънә, эчтәлек өчен мөһим сүзләрдән генә торырга тиеш, дип уйлыйлар булса кирәк. Мондый караш кайчак фәнни-популяр китаплар, дәреслекләр, политик әдәбият чыгаручыларда да сизелә. Вакытлы матбугат теле дә, фәнни-популяр, публицистик әдәбият һәм хәтта дәреслекләр теле дә җанлы, ятышлы, табигый тел булырга тиеш. Бары шул чагында гына эчтәлек, тиешле мәгънә укучыга тулысынча барып ирешә. Хәлбуки телнең табигый яңгырашлы булуында стиль чаралары, шул исәптән мәгънә өчен әллә ни әһәмиятле булмаган сүзләр һәм кисәкчәләр дә роль уйный.

Сөйләмнең табигый яңгырашына ирешүдә ярдәмлек сүзләрдән теркәгечләрне, бигрәк тә *һәм* теркәгечен, дөрес куллануның әһәмияте бар. Бу мәсьәләдә ялгышмас өчен, интонациягә кагылышлы чаралар буларак, татар телендәге кайбер теркәгечләрнең рус теле союзлары белән мөнәсәбәтләрен ачыклап китү мөһим.

Мәгълүм булганча, рус телендәге союзларга төп функцияләре буенча татар теленең билгеле бер теркәгечләре туры килә: *и – һәм, да – дә, та – тә; но, однако – ләкин, әмма; а – ә; или – яки, яисә; то – әле; то ли – әллә* һ.б. Ләкин бу гомумилек якынча гына. Чөнки

1) рус телендәге союзлар белән татар телендәге теркәгечләр сан ягыннан бертигез түгел; 2) гомумән алганда тәңгәл дип саналган кайбер союз һәм теркәгечләр барлык очракларда да үзара туры килми; 3) рус телендәге союз функциясе татар телендә интонация ярдәмендә белдерелә ала һәм киресенчә дә була; 4) рус телендәге тиңдәш кисәкләр татар телендә тиңдәшлек үзенчәлекләрен югалтырга да мөмкин.

Союз һәм теркәгечләрнең бер-берсеннән аермасы, специфик үзенчәлекләре икетеллелек практикасында һичшиксез исәпкә алынырга тиеш. Хәлбуки кайбер ике телдә язучы каләм ияләренең төрле тел сүзләре арасында һәр очракка да яраклы әзер тәңгәллекләр бар дигән ялгыш карашка, шактый нык тамыр җәйгән хәрефкә-хәреф тәрҗемә итү принцибына таянып эш итүләре аркасында, *союз – теркәгеч* тәңгәллекләрен ялгыш файдалану, икенче төрле әйткәндә, союзлар белән теркәгечләр арасында тәңгәллекләрне дөрес билгеләмәү очраклары шактый күп әле. Нәтиҗәдә телебезнең стиль нормалары бозыла, сөйләмебезнең камиллегенә зыян килә.

Татар теленең тезүче теркәгечләрен кулланудагы ялгышларның күбесе *һәм* сүзенә туры килә. Моның нигезендә һәрвакытта да *и – һәм* тәңгәллеге белән генә эш итү ята.

Вазыйфалары һәм стилистик кулланылыш үзенчәлекләре белән рус телендәге *и* союзы татар телендәге *һәм* теркәгеченнән шактый нык аерыла.

Рус телендәге *и* союзы бик еш кулланыла, һәм бу телнең табигатенә туры килә. Аның вазыйфалары күп төрле, бу союз чыганагы буенча рус теленең үз сүзе һәм авазлар составы буенча бик җыйнак (бер генә аваздан тора).

*Һәм* теркәгече – алынма сүз, аның вазыйфалары да кимрәк: ул татар теленә, нигездә, китап теле аша кергән, хәзер дә, башлыча, әдәби телгә, бигрәк тә фәнни стильгә хас, сөйләм телендә исә аз кулланыла. Авазлар саны буенча да *и* союзыннан аерыла (өч аваздан тора), *һәм* теркәгече *и* союзы кебек үк кулланылмый, ул башкарган вазыйфаларның барысын да үти алмый. Кайбер урыннарда, аеруча теле халыкның җанлы сөйләменә якын торган публицистика материалларында, бу теркәгеч сөйләм агышына өзеклек кертә, аны тоткарлап тора кебек, кыскасы, интонациягә ниндидер бер ясалма төс бирә. Чагыштырып карыйк: *кибеткә кердем һәм китап алдым – кибеткә кердем дә китап алдым – кибеткә кереп, китап алдым.* Мәгънәви һәм грамматик яктан бу очракта *һәм, дә*

теркәгечләре, хәл фигыль кушымчасы *-еп* – бер дәрәҗәдәге, тигез кыйммәтле чаралар, ә интонация ягыннан алар бертигез түгел: *дә* теркәгече һәм *-еп* кушымчасы ярдәмендә төзелгән әйтелмәләр *һәм* теркәгеченә караганда табигыйрак яңгырый.

*И* союзының вазыйфаларын татар телендә, урынына карап, мондый чаралар белән биреп була:

1. Тиңдәш ике исем үзара теркәгеч функциясендәге *белән* бәйлеге ярдәмендә бәйләнә: *Мәскәүдәге Кызыл мәйданда Минин белән Пожарскийга салынган һәйкәлне кем генә белми икән! Белән* бәйлеге – тиңдәш кисәкләр зат исемнәре булганда, бигрәк тә уңышлы чара. Ләкин телдә мондый очракларда еш кына *һәм* теркәгече кулланыла: *Тракторчылар Садретдин Фәсәхов һәм Зәет Хамматов көнлек норманы 150-200 процентка җиткереп үтиләр*; *Виктор Савиных һәм Александр Волковның космик вахтасы.* Бу җөмләләрдә *һәм* теркәгече урынына *белән* бәйлеген куллану уңышлырак булыр иде. *Арасында* сүзе тиңдәш исемнәрнең икесенә дә караган очракта алар һичшиксез *белән* ярдәмендә бәйләнергә тиеш: *Кеше куллана торган тоз күләме һәм кан басымы арасында турыдан-туры бәйләнеш бар (тоз күләме белән кан басымы арасында* кирәк).

2. Тиңдәш кисәкләр үзара санау интонациясе ярдәмендә бәйләнә: *Фәрит, Мансур, Камил өчесе дә "бишле"гә генә укыйлар.* Андый интонация белән бәйләнгән тиңдәш кисәкләрнең соңгысына күплек сан кушымчасы ялганып килә, бу – интонация тулылыгы өчен кулланыла торган үзенчәлекле алым: *Быел укучылар... халыкара хәрәкәт эшлеклеләре Эрнст Тельман, Долорес Ибарруриларның тормыш юлын өйрәнүне билгеләделәр.*

Рус телендәге тиңдәш кисәкләр кайчак татар телендә парлы сүзгә әверелә: *сетования отдельных матерей и отцов – кайбер ата-аналарның сукранулары.*

Каршы кую мөнәсәбәтендәге тиңдәш кисәкләр дә бер-берсенә интонация ярдәмендә бәйләнергә мөмкин. Мәсәлән: *"Не они, а мы тут каторжные", – сказал с раздражением командир. – "Алар түгел, без монда каторжниклар", – диде ачу белән командир.* Интонация, тиңдәш кисәкләрне бәйләүче чара буларак, бик күптәннән кулланылып килгән, сөйләм телендә ул әле дә киң кулланыла. Рус телендә дә шундый ук хәл. Димәк, сөйләм теле үзенчәлекләре зур урын алып торган мәгълүмат чаралары телендә дә бу чара киң файдаланылырга тиеш.

Интонация, – бер җөмләдә берничә тиңдәш кисәк булганда, бертөрле теркәгечләрнең ялыктыргыч кабатлануыннан котылу өчен дә уңышлы чара: *Завод җитәкчелеге һәм эшчеләр бу инициативалы һәм өметле егетне бригадир итеп тәкъдим итәләр.* Бу җөмләдә ике пар тиңдәш кисәкләрнең беренчесен интонация ярдәмендә бәйләп, ике *һәм* сүзенең берсеннән котылып була. Менә бу җөмләдә дә ике *һәм*нең берсен интонация (өтер) белән алмаштырырга иде: *Башкортстан Президенты Мортаза Рәхимов һәм аның бердәнбер улы Урал арасында озакка сузылган һәм каты "сугыш бара" (Рәхимов белән... Урал арасында* кирәк).

3. Ике тиңдәш фигыльне бәйләү өчен һәм, тиңдәш фигыльләр икедән артык булып, бәйләүче чара аларның һәркайсы янында кабатланып килсә, *да-дә, та-тә* теркәгечләре кулланыла: *Ул эшләпәсен эләктерде дә атылып урамга чыкты.* Ләкин телдә мондый тиңдәш кисәкләр янында да күбрәк **һәм** теркәгече кулланыла: *Лена... утны сүндерә* ***һәм,*** *чишенмичә, караватына утыра. Лена... утны сүндерә дә, чишенмичә генә, караватына барып утыра* рәвешендә булса, интонация табигыйрак булыр иде. *Сергей... кызны эләктереп алды* ***һәм*** *чигәсеннән, битеннән үпте (эләктереп алды да чигәсеннән, битеннән үпте* булганда, сөйләм көйлерәк).

4. Рус телендәге ике тиңдәш фигыльнең берсен татарча *-ып/-еп* кушымчалы хәл фигыль белән бирү дә – сөйләмнең табигый яңгырашына ирешүдә нәтиҗәле чара: *Д.И.Лещенко, килеп, аны фоторәсемгә төшерде (Приехал Д.И.Лещенко и сфотографировал его).* Ләкин бу алым да тиешле кулланылыш тапмый, мондый очракларда да *һәм* теркәгеченә өстенлек бирелә: *Алар иртә культуралар чәчүне тәгәлләделәр* ***һәм*** *югары уңыш өчен көрәшне дәвам иттерделәр (чәчүне тәгәлләп... көрәшне дәвам иттерделәр* уңышлырак булыр иде). Кайбер тиңдәш кисәкләрне бәйләү өчен *һәм* теркәгече уңай чара була ала. Мәсәлән, тиңдәш кисәкләр сыйфат яки рәвеш булса, алар арасында *һәм* сүзен куллану урынлы: *Хат бик озын* ***һәм*** *тыгыз итеп язылган.*

*Һәм* теркәгечен куллану белән мавыгу, аңа барлык стильләрдә дә, бигрәк тә матбугатта, кирәгеннән артык урын бирү, мөмкин булган чаралардан тиешенчә файдаланмау сөйләм интонациясенең камиллегенә ирешергә комачаулый, шулай ук сүзләрнең стилистик кулланылышына буталчыклык кертә, *һәм, нигездә,* фәнни стильгә хас, димәк, аның фәнни хезмәтләрдә күбрәк урын алуы зарур. Матур әдәбиятта, матбугат материалларында исә халыкның сөйләм

теленә хас чараларга *(белән* бәйлегенә, *да-дә, та-тә* теркәгечләренә, интонациягә һәм *-ып/-еп* кушымчалы хәл фигыль формасына) күбрәк урын бирелергә тиеш.

*А* союзына күбесенчә *ә* теркәгече һәм *исә* теркәгеч сүзе туры килә. *Ты сиди здесь, а я разделаюсь с этими. – Син шунда утырып тор, **ә** мин алар белән эшемне бетерим. Исә* сүзе, *ә* теркәгеченнән аермалы буларак, икенче тиңдәш кисәктән соң килә: *Школьные фотографы должны распространять его снимки, а школьным поэтам неплохо и стихи сложить про него. – Мәктәп фотографлары аның рәсемнәрен таратырга, укучы шагыйрьләр **исә** аның турында шигырьләр язарга тиешләр. Исә* теркәгеч сүзе күбрәк язма телгә хас, сөйләм телендә *ә* ешрак очрый. *А* союзының функциясе татар телендә каршы кую интонациясе, шулай ук *ләкин, һәм, бәлки* теркәгечләре ярдәмендә дә белдерелергә мөмкин. Интонация күбрәк сөйләм теленә (персонаж теленә) хас: *Умрём, а не выдадим. – Үлсәк үләрбез, сине бирмәбез.*

Бездә, рус телендәге *а* союзына ияреп булса кирәк, *ә* теркәгечен куллану белән мавыгу күренеше бар. Мәсәлән, радио-телевидение дикторлары еш кына сүзләрен *ә хәзер...* дип башлап китәләр. Баксаң, монда *ә* теркәгеченең бөтенләй кирәге булмый. Газета-журиалларда да очрый мондый хәлләр: *Районнардагы хәлләрне җирдән генә түгел, **ә** һавадан да күзәтеп баралар* (бу җөмләдә *ә* теркәгече ни өчен куелгандыр, аңлашылмый).

*Но* союзы да бертөрле генә тәрҗемә ителми. Аның вазыйфасы, интонацияне, мәгънә төсмерләрен бирү таләбенә карап, *ләкин, бәлки, ә* теркәгечләре белән генә дә, каршы кую интонациясе ярдәмендә дә белдерелә. Мәсәлән: *Он встал и пошёл искать дорогу домой, но ещё долго блуждал по незнакомому лесу. – Ул урыныннан торды да өйгә кайтырга юл эзләп китте, **ләкин** таныш түгел урманда бик озак адашып йөрде әле; Им насыщены не только плоды этого кустарника, но и листья. – Витамин аның җимешләрендә генә түгел, яфракларында да күп.*

*Или, либо* союзлары *я, яисә* теркәгечләре белән тәрҗемә ителә. Мәсәлән: *"Дайте сюда сена или соломы", – сказал Дубровский. – "Монда печән йә салам китерегез", – диде Дубровский.*

Нигездә китап теле аша кергән *әмма, ләкин, бәлки, яисә, яки* кебек каршы куючы һәм бүлүче теркәгечләр күбрәк фәнни стильгә, публицистикага, ә *я, ни-ни, әллә-әллә* теркәгечләре һәм бүлүче

теркәгеч функциясендә килгән *-мы/-ме* сорау кисәкчәсе җанлы сөйләм үзенчәлекләренә ия матур әдәбият стиленә һәм матбугат теленә хас.

| **Мәгълүмат чараларында табигый интонациягә зыян килү мисаллары** | **Тәкъдим ителә** |
|---|---|
| *Әле ярый* сез бар. | *Әле дә ярый* сез бар. |
| *Тырышларның тырышы.* | *Тырышларның да тырышы.* |
| Мине... *барыннан бигрәк* халык биюләре кызыксындырды. | Мине... *барыннан да бигрәк* халык биюләре кызыксындырды. |
| ...бүлмәләр тезмәсе йортның борынгы рухи мохитен *әле булса* саклыйлар кебек. | ...бүлмәләр тезмәсе йортның борынгы рухи мохитен *әле дә булса* саклыйлар кебек. |
| Минем кебекләр АКШта 40 мең чамасы, *Нью-Йоркта гына* без 25 мең. | Минем кебекләр АКШта 40 мең чамасы, *Нью-Йоркта гына да* без 25 мең. |
| Татарстанның *үзеннән генә* 250 галим катнашыр дип көтелә. | Татарстанның *үзеннән генә дә* 250 галим катнашыр дип көтелә. |
| Юк, мин каннан курыкмыйм. Мин *бернәрсәдән* курыкмыйм. | Юк, мин каннан курыкмыйм. Мин *бернәрсәдән дә* курыкмыйм. |
| Эшлисең икән, *бернидән* курыкма. | Эшлисең икән, *бернидән дә* курыкма. |
| Казан федераль университеты – Татарстанның горурлыгы гына түгел, ә Россиядә *әйдәп баручы* уку йортларының берсе. | Казан федераль университеты – Татарстанның горурлыгы гына түгел, Россиядә *төп* уку йортларының *берсе дә.* |
| Быел җәй фатир базарында кайнашучыларны... читен хәлдә *калдырмасмы?* | Быел җәй фатир базарында кайнашучыларны... читен хәлдә *калдырмасмы икән?* |
| Соңгы вакытта хуҗалыклардан мал-туарны алып чыгып китү фактлары *арткаsuccessfullyннан-арта.* | Соңгы вакытта хуҗалыклардан мал-туарны алып чыгып китү фактлары *арткаsuccessfullyннан-арта бара.* |
| Сәяси шахмат тактасында көрәш *кызганнан-кыза.* | Сәяси шахмат тактасында көрәш *кызганнан-кыза бара.* |
| Кышкы *каникуллар* вакытында... | Кышкы *каникул* вакытында... |
| Матур гына яшәп ятканда, ул кинәт кенә *арабыздан китте.* | Матур гына яшәп ятканда, ул кинәт кенә *арабыздан китеп барды.* |

| | |
|---|---|
| К.Тинчурин *һәм* С.Сәйдәшевнең иҗади дуслыгы. | К.Тинчурин *белән* С.Сәйдәшевнең иҗади дуслыгы. |
| Казан федераль университеты *һәм* Бельгия университеты арасында хезмәттәшлекне *үстерү.* | Казан федераль университеты *белән* Бельгия университеты арасында хезмәттәшлекне *җәелдерү.* |
| Россия *һәм* Украина арасында яңа низаг чыгарга тора. | Россия *белән* Украина арасында яңа низаг чыгарга тора. |
| ...Рөстәм Миңнеханов *һәм* Даниал Әхмәтовның очрашуы булды. | ...Рөстәм Миңнеханов *белән* Даниал Әхмәтовның очрашуы булды. |
| Бер хатын автосервиска *килә һәм* механикларга ялына. | Бер хатын, автосервиска *килеп,* механикларга ялына. |
| Анда Россия Президенты Путин да *катнашты һәм чыгыш ясады.* | Анда Россия Президенты Путин да *катнашып чыгыш ясады.* |

## **“БАЛЛАСТ” СҮЗЛӘР**

Телдә гомумән алганда артык сүз булмый. Әмма кайчакта кайбер сүзләр кирәксезгә кулланыла, икенче төрле әйткәндә, артык була. Артыклык шуның белән аңлатыла: теге яки бу сүзнең (сүзләрнең) билгеле бер урында сөйләмнең эчтәлеге өчен әһәмияте аз була яки бөтенләй булмый, шул ук вакытта аның табигый агышына комачаулый, интонациягә ясалма төс бирә һәм, димәк, телнең стилистик нормаларын боза.

Татарча сөйләмдәге “артык” сүзләрнең күбесе русча текстлардагы сүзләрне хәрефкә-хәреф тәрҗемә итү, оригиналның һәр сүзенә ябышып яту аркасында барлыкка килә.

“Артык” сүзләрнең аеруча күп таралганнарыннан берсе – *булып тора.* Ул, рус телендәге *является* сүзен турыдан-туры тәрҗемә итү нәтиҗәсендә кереп, бигрәк тә мәгълүмат чаралары телендә шактый зур урын алган, әкренләп сөйләм телендә дә тарала бара. Бу сүзне, мәгънәгә бернинди дә зыян китермичә, күп урында төшереп калдырырга мөмкин. Моннан сөйләм җыйнакланыр, һәм интонация дә шомарак булыр иде. Мәсәлән: *Съезд партиянең югары органы булып тора. Булып тора* сүзен төшереп калдырганда, җөмләнең иясе һәм ияргә караган сүзләре белән хәбәре һәм хәбәргә караган сүзләре арасында пауза ясала, язуда ул пауза сызык белән

белдерелә: *Съезд – партиянең югары органы. Хат аша аралашу арзанлы бер чара **булып тора*** (*аралашу – арзанлы бер чара* кирәк).

Күп таралган “артык” сүзләрнең тагын берсе – *булган.* Ул күбрәк түбәндәге сүзләр янында кулланыла:

*1) хас* сүзеннән соң: *Гомум кешелеккә **хас булган** иң яхшы сыйфатларны тәрбияләү ата-аналарның изге бурычы **булып** тора*;

*2) әһәмиятле* сүзеннән соң: ***Әһәмиятле булган** мәсьәләләр турында фикер алышачаклар (әһәмиятле мәсьәләләр* кирәк); *Җыелышта **әһәмиятле булган** сораулар каралды (әһәмиятле сораулар* кирәк).

3) гадәттә, сыйфат һәм исем сүз төркеме янында: *Кубада иң зур **булган** текстиль комбинаты төзелеп килә, (иң зур текстиль комбинаты* кирәк) *Дөньяның иң бай иле **булган** Америкада ил байлыгының сиксән проценты алар кулында* (дөресе – *...иң бай иле Америкада); гап-гади **булган** эшләрне алардан эшләтеп... (гап-гади эшләрне алардан эшләтеп* кирәк); *300 дән артык хуҗалыгы **булган** Шушмабаш якын-тирә 17 авылны берләштерүче үзәк **булып тора** (хуҗалыклы Шушмабаш – берләштерүче үзәк* кирәк); *Магадан өлкәсеннән булган вәкиле Вячеслав Калинин (Магадан өлкәсе вәкиле* кирәк).

*Булып санала* һәм *санала* сүзләре: *Комбинат... иң зур комбинатларның берсе **булып санала**; Бу илебезнең аерым бер нефть районы өчен рекордлы казаныштан санала.*

*Буенча, турында, карата* сүзләре: *...ремонт базасын тагын да **үстерү буенча** булган чараларны тормышка ашыру (үстерү чараларын* кирәк); *Россия пенсия фондының **Татарстан буенча** бүлекчәсе Айрат Шәфигуллин... (Татарстан **бүлеге*** кирәк); ***туу турындагы** таныклык; **үзгәртү турындагы** мәсьәлә; **түләү турындагы** эшләр* (дөресе – *туу таныклыгы, үзгәртү мәсьәләсе, түләү эшләре); **фәнгә карата** мәхәббәт тәрбияләү **(фәнгә мәхәббәт** тәрбияләү* кирәк).

*Биш көннән соң (ун елдан соң* һ.б.) кебек вакытны белдергән конструкцияләрне һәрвакыт *соң* сүзе белән язу һәм сөйләү шарт түгел, татарча *биш көннән, ун елдан* дип тә әйтеп була: мәгънә саклана, сөйләм җыйнаклана. Тәрҗемәләрдә *через пять дней, через десятъ лет* һ.б.ш. үрнәгендә *соң* сүзен төшереп калдырмаска тырышу сизелә: *через* сүзе хәрефкә-хәреф тәрҗемә ителә.

Кайбер очракларда телдә *через некоторое время* рәвешендәге *бераз вакыттан соң* дигән әйләнмә дә кулланыла. Моны *бераздан* дип тә әйтеп булыр иде.

Вакытны белдерә торган конструкцияләрдәге *в течение* сүзен еш кына *эчендә* дип тәрҗемә итәләр: *10 ел эчендә (в течение 10 лет) (10 елда* гына дияргә мөмкин һәм кирәк тә); *ике көн срок эчендә (ике көнлек срокта* яки *ике көндә* генә дияргә була); *сыналу вакыты эчендә (в течение испытательного срока) (сынау вакытында); кыска гына вакыт эчендә (аз гына вакытта); бу еллар эчендә (бу елларда* татарчарак); *Шушы 30 ел эчендә мәктәпне 1068 кеше тәмамлаган (30 елда* кирәк).

Русча *становится всё более...* конструкциясендәге *всё более* сүзен *һаман* дип тәрҗемә итү нәтиҗәсендә бу сүз дә кайчак *артык* сүзгә әйләнә: *Инглизләр өчен тавыш һаман куркынычрак була бара.* Бу җөмләдә *һаман* урынсыз кулланылган, мәгънә аннан башка да төгәл бирелә.

Әдәби һәм сөйләм теле практикасында башка төрле сүзләрнең дә кирәксезгә кулланылу очраклары бар. Шундыйлардан *күләмендә, кадрлар, туры килә, төп, тәшкил итә, тәшкил иткән, бергә, менә, гәрчә, эчкә, бер төркем* һ.б. сүзләрне күрсәтергә була. Мәсәлән: *Амбарларга 90 центнер **күләмендә** язгы бодай салынды. Кооперативны механизатор **кадрлар** белән тәэмин итү (90 центнер язгы бодай, механизаторлар белән тәэмин итү* кирәк); *Ә бездә һәр терлектән бер айда үсеш 28-29 килограмм **туры килә***; *Шатлыкларын, кайгыларын **бергә** уртаклашалар. Уртаклашу* сүзе, уртаклык юнәлешендәге фигыль булганлыктан, бергәлекне аңлата, шулай булгач, монда *бергә* сүзенең кирәге юк. *Депоның механика цехында менә 45 ел эшли инде ул; ...һөҗүмнәрнең саны 600 кешегә **кадәр җиткән** булырга да мөмкин* (монда *кадәр* сүзе артык: *600 кешегә җиткән* кирәк); *яшен **эчкә** йотып (йотып* дигәч, *эчкә* сүзе кирәкми). *Бу көннәрдә Казанда Польша Халык Республикасыннан бер төркем туристлар булып китте (туристлар булып китте* дисәң дә җитә); *Әңгәмәбезне **алга таба** дәвам итәбез (дәвам иттерәбез* кирәк: *алга таба* сүзе артык).

Тискәре мисаллар һәм аларның уңай вариантлары:

| **стиль кытыршылыклары** | **тәкъдимнәр** |
|---|---|
| “*Туу турында* таныклык” татарча бирелә икән. | “*Туу таныклыгы*” (*балага исем кушу таныклыгы*) татарча бирелә икән. |
| *Безнең көннәргә кадәр килеп җиткән* язма истәлекләр. | *Безнең көннәргә килеп җиткән* язма истәлекләр. |

| | |
|---|---|
| Кайбер урыннарда ул (җир тетрәү – *Р.Ю.*) *8 баллга кадәр җиткән.* | Кайбер урыннарда ул (җир тетрәү– *Р.Ю.*) *8 баллга җиткән.* |
| Гыйлемле булу һәр мөселманга *фарыз булып тора.* | Гыйлемле булу – һәр мөселманга *фарыз.* |
| *Иң кискен торган* мәсьәләләрнең берсе. | *Иң кискен* мәсьәләләрнең берсе. |
| Җыелышта *әһәмиятле булган сораулар* каралды. | Җыелышта *әһәмиятле сораулар* каралды. |
| Халкыбызга *хас булган сабыр холык*, түземлек, рәхим-шәфкать якты моң булып сузылып бара. | Халкыбызга *хас сабыр холык*, түземлек, рәхим-шәфкать якты моң булып сузылып бара. |
| Кичәге очрашу барышында әлеге проектны гамәлгә *ашыру буенча алга таба* планнар...каралды. | Кичәге очрашуда бу проектны гамәлгә *ашыру планнары...* каралды (яки *тикшерелде).* |
| *Кызганычка каршы*, аларда татарлар турында бай экспонатлар юк. | *Аяныч хәл:* аларда татарлар турында бай экспонатлар юк. |
| ...үлемсез әсәрләр тудыру – зур батырлык, *әйтергә яраса*, феноменаль күренеш. | ...үлемсез әсәрләр тудыру – зур батырлык, *хәтта*, феноменаль күренеш дип әйтергә мөмкин. |
| Районнардагы хәлләрне җирдән генә түгел, *ә* һавадан да күзәтеп *баралар.* | Районнардагы хәлләрне җирдән генә түгел, һавадан да күзәтеп *торалар.* |
| Заман журналист *һөнәренә карата* югары таләпләр куя. | Заман журналист *һөнәренә* югары таләпләр куя. |
| Ярымфиналда исә бу шикләр *эреп юкка чыкты.* | Ярымфиналда исә бу шикләр *юкка чыкты.* |
| Безнең төп эшебез *булып* авыл халкына хезмәт күрсәтү *тора.* | Безнең төп эшебез – авыл халкына хезмәт күрсәтү. |
| Хезмәт хакын күтәрү *бары тик* 3,3 миллион кешегә генә кагылган. | Хезмәт хакын күтәрү 3,3 миллион кешегә генә кагылган. |
| Хезмәт хакын *нибары* 5 процентка гына күтәрүне планлаштыралар. | Хезмәт хакын 5 процентка гына күтәрүне планлаштыралар. |
| Без *сугыш вакыты елларында* нинди генә эшләр башкармадык. | Без *сугыш елларында* (вар.: *сугыш вакытында*) нинди генә эшләр башкармадык. |
| Мөһим вакыйгалар турында хәбәрләр санаулы *минутлар эчендә* редакциягә барып ирешә. | Мөһим вакыйгалар турында хәбәрләр санаулы *минутларда* редакциягә барып ирешә. |

| | |
|---|---|
| Капиталь ремонтка *мохтаҗ булган* барлык йортларны төзекләндереп бетерергә вәгъдә итә. | Капиталь ремонтка *мохтаҗ* барлык йортларны төзекләндереп бетерергә вәгъдә итә. |
| Киләсе ярты еллыкның 27 декабренә кадәрге *вакыт аралыгында* түләнеп бетәргә тиеш. | Киләсе ярты еллыкның 27 декабренә кадәр түләнеп бетәргә тиеш. |
| ...юл-транспорт фаҗигасендә Федерация Советының Магадан *өлкәсеннән булган* вәкиле Вячеслав Каликян һәлак булган. | ...юл-транспорт фаҗигасендә Федерация Советының Магадан *өлкәсе* вәкиле Вячеслав Каликян һәлак булган. |
| Лайнер *бортында булган* 113 кешенең 26сы Россия гражданнары. | Лайнер *бортындагы* 113 кешенең 26сы Россия гражданнары. |
| ...мәсьәләне *шәхси үз күзәтчелеге астына* алачагын әйтте. | ...мәсьәләне *үзе тикшереп (вар.: күзәтеп) торачагын* әйтте. |
| Шушы көннәрдә мәктәпне нәкъ шул елны *тәмамлаган чыгарылыш* укучылары очрашырга җыена. | Шушы көннәрдә мәктәпне шул елны *тәмамлаган* укучылар очрашырга җыена. |
| ...*рус милләтеннән булган кызга* өйләнә. | ...*рус кызына* өйләнә. |
| Соңгы елларда *әти-әниләр*, укытучылар, укучыларның хезмәт тәрбиясенә *карата карашы* тискәре якка үзгәрде. | Соңгы елларда *ата-аналар*, укытучылар, укучыларның хезмәт тәрбиясенә *карашы* тискәре якка үзгәрде. |
| Татарстан Президенты ... үзара хезмәттәшлекне *алга таба үстерүгә* ышаныч белдерде. | Татарстан Президенты ... үзара хезмәттәшлекне *үстерүгә* ышаныч белдерде. |
| ...147се *хезмәт хакы түләнелми торган* ялга җибәрелгән. | ...147се *түләүсез* ялга җибәрелгән. |
| Экстремистик *юнәлештә булган* негатив кешеләр бар. | Экстремистик *юнәлештәге (юнәлешле)* негатив кешеләр бар. |
| Иң *кискен торган* мәсьәләләрнең берсе. | Иң *кискен* мәсьәләләрнең берсе. |
| Сугышка кушылган *һөҗүмчеләрнең* саны 600 *кешегә кадәр җиткән* булырга да мөмкин. | Сугышка кушылган *кешеләрнең* саны 600 *гә җиткән* булырга мөмкин. |
| *Безнең авылыбызның* иң гүзәл почмагы. | *Авылыбызның* иң(?) гүзәл почмагы. |

| | |
|---|---|
| *Безнең шәһәребезнең* көннән-көн матурая баруын барыбыз да күрәбез. | *Шәһәребезнең* көннән-көн матурая баруын барыбыз да күрәбез (күреп торабыз). |
| *Кагыйдә буларак*, бар авылларда күп эчәләр. | Барлык авылларда да күп эчәләр. |
| Татарстанда июль башыннан 11 кешене елан чаккан. *Аерым алганда*, шундый очраклар Әлмәт, Сарман, Биектау, Зәй, Арча һәм Югары Осланда *теркәлгән.* | Татарстанда июль башыннан 11 кешене елан чаккан. Мондый хәлләр Әлмәт, Сарман, Биектау, Зәй, Арча һәм Югары Осланда *булган.* |
| Закон кысаларында *эшләгәнлектән, кызганычка каршы*, кайчак бик җентекләп эшләргә туры килә шул. | Закон кысаларында *эш иткәнлектән,* кайчак бик җентекләп эшләргә туры килә шул. |
| Татарстан Президенты, чыгыш ясап, *аерым алганда*, республикабыз инновация юлын сайлады, *дип билгеләп үтте.* | Татарстан Президенты, чыгыш ясап, республикабыз инновация юлын сайлады, *диде.* |
| “Җырлый торган Казан” исеме *астында узучы* бу чарада...хор катнашачак. | “Җырлый торган Казан” *исемле (дигән)* бу чарада...хор катнашачак. |
| *Үз эшләренең* осталары *булган* белгечләр ... китеп барды. | *Оста* белгечләр ... китеп барды. |
| Хәтер – вакытның бердәнбер үлчәме *булып тора.* | Хәтер – вакытның бердәнбер үлчәме. |
| Алар безгә иң популяр *булган* җырларын башкарачак. | Алар безгә иң популяр җырларын башкарачак. |
| Дөньяда иң бай кеше, милләте *буенча* гарәп *булган* мексикалы Карлос Слим фикеренчә... | Дөньяда иң бай гарәп (кешесе) мексикалы Карлос Слим фикеренчә... |
| Татарстан сәламәтлек саклау министрлыгының Казан *буенча* идарәсе... | Татарстан сәламәтлек саклау министрлыгының Казан идарәсе... |
| Сезгә таныш *булган* Азат Тимершәех... | Сезгә таныш Азат Тимершәех... |
| Исәнмесез, *безнең өчен* кадерле *булган* тамашачылар! | Исәнмесез, кадерле тамашачыларыбыз! |
| Кырык ел *эчендә.* | Кырык елда**.** |
| Өч эре заводны үз *эченә алган* нефть эшкәртү комплексы... | Өч эре заводтан **торган** нефть эшкәртү комплексы... |

| | |
|---|---|
| *Температура* Казанда 25 градус җылы. | Казанда 25 градус җылы. |
| Ул заманнардан соң, *кем әйтмешли*, күпме сулар акты. | Ул заманнардан бирле күпме сулар аккан. |
| 1917 елдан 1990 елга кадәр *вакыт эчендә* республиканың хөкем органнары... | 1917 елдан 1990 елга кадәр республиканың хөкем органнары... |
| ...диде Гөлфирә, күз яшьләрен *эчкә* йота-йота. | ...диде Гөлфирә, күз яшьләрен йота-йота. |
| ...туган теленә *карата мәхәббәте* көннән-көн *үсә* бара аның. | ...туган телен яратуы көннән-көн *арта* бара аның. |
| ...күп еллар төзелеш *өлкәсендә* эшли. | ...күп еллар төзелештә эшли. |
| Илнең атом энергетикасы *буенча* оешмасы... | Илнең атом энергетикасы оешмасы... |
| Бер парта *артында* утырган малай... | Бер партада утырган малай... |
| Шушы *сәбәп аркасында* йөзәрләгән мең ятим балалар... | Шушы *сәбәпле (шуның аркасында)* йөзәрләгән мең (йөз меңнәрчә) ятим балалар... |
| Татарстан Президенты, *аерым алганда,* республикабыз инновация юлын сайлады, диде. | Татарстан Президенты республикабыз инновация юлын сайлады, диде. |
| Укучылар уку *буенча* да калышмый. | Укучылар (балалар) укуда да калышмый. |

## ДӨРЕС СӨЙЛӘМ ТӨЗҮДӘ СҮЗ ТӘРТИБЕНЕҢ РОЛЕ

Сөйләмдә (текстта) сүзләр урнашуның катгый тәртибе, нигездә, прозага карый. Монда телдә гомум кабул ителгән сүз тәртибен бозу синтаксик нормалардан читкә тайпылу булып исәпләнә. Поэзия сөйләмендә проза өчен мәҗбүри саналган сүз тәртибе (туры сүз тәртибе) аңлы рәвештә (рифма, ритм һ.б. өчен) еш кына бозыла, һәм бу ялгыш эш дип саналмый. Халыкның җанлы сөйләмендә дә сүз тәртибе, әдәби прозадагы һәм публицистикадагы белән чагыштырганда, күпкә ирекле рәк.

Ләкин проза сөйләмендә дә билгеле бер максатларда берникадәр дәрәҗәдә кире сүз тәртибе (инверсия) кулланыла. Бу күренеш публицистика материалларында да була.

Инверсия төп ике максатны – сөйләмне тәэсирлерәк (эмоциональрәк) итү һәм күп җөмләләрнең рәттән бер төрле фигыль формаларына тәмамлануыннан килеп чыккан монотонлылыкны (ялыктыргыч бер төрле яңгырашны) киметү максатларын күздә тота.

Инверсиянең төрләре шактый күп. Шуларның кайберләрен күрсәтеп китик.

1. Ия җөмлә азагында килә: *Шулай хезмәтне яратып, хезмәттән тәм табып укый һәм яши безнең* ***мәктәп балалары****; Япь-яшь көе тол калып, балаларын кеше иткән аналар ул бүгенге* ***әбиләр****.*

Сорау җөмләләрдә иянең хәбәрдән соң куелуы эмоциональлекне көчәйтә. Чагыштырыйк: *Син ни өчен китап күтәреп бара дип уйлыйсың? – Ни өчен китап күтәреп бара дип уйлыйсың* ***син?*** *Син нәрсә сөйлисең? – Нәрсә сөйлисең соң* ***син?***

*2.* Тәмамлык җөмлә азагында куела: *Үз эшенең остасы диләр цех җитәкчеләре аның* ***турында;*** *Мин дә бик тырышып өйрәнә башладым* ***эшне.***

Тәмамлыкның җөмлә азагында килүе сорау җөмләләрдә дә эмоциональлекне көчәйтә. Мәсәлән: *Телисеңме, әкият сөйлим?* ***Әкият*** *сөйлимме үзеңә?* рәвешендә булса, интонация татарчарак була.

3. Җөмлә хәл белән тәмамлана: *Уйлап карасаң, эшләрдәй эшләр күп бит алар* ***классында****; Хезмәт биографиясенең иң гүзәл сәхифәләрен яза* ***быел****.*

Эндәш сүзле җөмләләрдә ул сүзнең җөмлә азагында торуы сөйләм агышын шомарак итә. Чагыштырыйк: *Син, Гөлназ,* ***нәрсә*** *уйлыйсың? –* ***Нәрсә*** *уйлыйсың син, Гөлназ?*

Ләкин инверсия мәсьәләсендә сак булырга кирәк. Гадәти сүз тәртибен үзгәртү белән мавыгырга ярамый. Инверсияне артык күп куллану ясалма интонация китереп чыгара. Проза сөйләме өчен гомумән алганда инверсия хас түгел, шулай булгач, кире сүз тәртибеннән чама хисен югалтмыйча гына файдаланырга мөмкин.

Хәзерге кайбер материалларда, рус теленә ияреп, инверсия белән мавыгу күренешләре очрый. Монда ике телнең сүз тәртибендә аерма барлыгы исәпкә алынмый. Рус телендә сүз тәртибе татар телендәгегә караганда ирекләрәк, анда инверсиянең вазыйфалары татар телендәгегә туры килеп бетми. Шулай булгач, рус текс-

тында хәбәр җөмлә башында килә икән, татар җөмләсе дә шулай төзелергә тиеш дигән сүз түгел. Мәсәлән, бу җөмләдәге концерт исеме рус телендәге сүз тәртибе буенча төзелгән: *Алар арасында... "Җырлый Рафаэль Ильясов" исемле фильм-концерт бар.* Хәлбуки аны чын татарча итеп әйтүнең бер дә авырлыгы юк: *"Рафаэль Ильясов җырлый" исемле...*

Бу җөмләләрдә дә хәбәр инверсиясен куллану уңышлы килеп чыкмаган: янәшә яки бер-берсенә якын торган җөмләләрнең гел хәбәрдән башлануы җитди эчтәлекле проза сөйләмен әкият стиленә охшата башлый. *Чыгып китәләр өйдән әтисе белән Ерёмка. – Вышли отец и Ерёмка на улицу..,; Басуга карап тора Ерёмканың әтисе, ә күзләре мөлдерәмә яшь. – Смотрит Ерёмкин отец на поле, слёзой глаза наполняются; "Бар әнә Путилов заводына", – дип киңәш бирә аңа үтеп баручы. – "Иди на Путиловский завод", – советует ему прохожий. "Әнә Путилов заводына бар...* яки *"Путилов заводына бар әнә..."* рәвешендә булса, интонация ятышлырак булыр иде.

Гомумкабул ителгән сүз тәртибе бозылу сөйләмнең табигыйлыгына кайбер башка очракларда да зыян китерә.

Ниндидер вакыйгалар, яңалыкларны хәбәр итә торган матбугат, радио-телевидение материалларында җөмлә кисәкләренең мондый тәртиптә урнашуы гадәти санала: башта вакыт хәле, аннан соң рәвеш хәле, аннары ия үзе генә яки аны ачыклап килгән сүзләр белән, аннары хәбәр һ.б. Мәсәлән: *Кичә Казанда тантаналы шартларда республиканың профсоюз активы киңәшмәсе булды.* Җөмләне шушы күнегелгән тәртибен үзгәртеп төзесәң, ул сәеррәк, кытыршырак килеп чыга, нәрсәдер үз урынына куелмаганда була торган канәгатьсезлек хисе туа.

Рус телендәге *аныкланмыш – аныклагыч* сүз тәртибен татарчага шул килеш күчерү телебездә сәер яңгырашлы әйләнмәләр китереп чыгара: *Вася – итекче, Накоряков – публицист, инструктор – кием тегүче, мастер – каючы; мәктәп – интернат, эшче – машина төзүче, кооператив – миллионер.* Болар татар телендәге сүз тәртибе буенча *итекче Вася, публицист Накоряков, кием тегүче инструктор, каючы мастер, интернат мәктәп, машина төзүче эшче, миллионер кооператив* формасында булырга тиеш.

Исемне төрле яктан ачыклап килгән берничә аергычның гадәти урыннарын бутау татар теле өчен ят бәйләнеш тәртибе кертә: *Ватаныбызның югары бу бүләге... (Ватаныбызның бу югары*

*бүләге* кирәк); *озын кышкы кичләрдә (в долгие зимние вечера)* (саф татарча – *кышкы озын кичләрдә).*

Мәгълүмат чараларында инверсиягә караган иң күп таралган ялгышларның берсе – сәгать буенча вакыт исәбен әйтү. Монда да рус теле интерференциясе чагылыш таба. Русча вакыт исәбен әйткәндә, башта – тиешле сан, аннары *сәгать* сүзе әйтелә *(шесть часов).* Татарча, киресенчә, башта – *сәгать* сүзе, аннары тиешле сан әйтелә *(сәгать алты).* Матбугат материалларында, радио-телевидение тапшыруларында, хәтта китапларда һәм кайбер кешеләр сөйләмендә дә сәгать исәбен рус телендәгечә итеп язу һәм әйтү очраклары күп. Мәсәлән: *9 сәгатьтә Мәскәү тапшыруларын трансляцияләү* (саф татарча – *сәгать 9 да); кич 11 сәгатьтә (төнге сәгать 11 дә* кирәк); *төнге 2 сәгать 10 минутта* (дөресе – *төнге сәгать 3 нче 10 минутта); Концерт 11.00 сәгатьтә башлана (Концерт сәгать 11 дә башлана* кирәк); *14.00-16.00 сәгатьтә үзләрен кызыксындырган сораулар белән Разил Исмәгыйль улы Вәлиевкә мөрәҗәгать итә аласыз (сәгать 2 дән 4 кә кадәр* булырга тиеш).

Дөрес, монда, көндезге уникедән соңгы вакытны әйткәндә, берникадәр кыенлык туа. Рус телендә көндезге сәгать бердән башлап *тринадцать часов* дип санау гадәткә кергән. Моны татарча тәртиптә әйтү кыенрак тоела: *сәгать унөч, сәгать егерме* һ.б. Шуңа күрә *унбиш сәгать* формасында сөйләү һәм язу гадәткә кереп бара. Әмма монда халыкчан әйтү мөмкинлеге дә бар: *иртәнге сәгать биш, кичке сәгать алты, сәгать төнге унбер* һ.б. Сөйләм теленең бай мөмкинлекләре тулы файдаланылырга тиеш. Аларны, онытып, кулланылыштан чыгарып, икенче телгә хас сүз тәртибеннән файдалану туган телебезне бозуга китерә.

| **Ялгыш** | **Дөрес** |
|---|---|
| Йокысызлыктан интеккән баш мие арыганлык өчен компенсация *таләп итә – тәмле һәм зыянлы ризык ашап куюны.* | Йокысызлыктан интеккән баш мие арыганлык өчен компенсация *– тәмле һәм зыянлы ризык* ашап куюны таләп итә. |
| РТ Президенты *“Эфир” җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте коллективын* ...котлады. | РТ Президенты *җаваплылыгы чикләнгән җәмгыять “Эфир” коллективын* ...котлады. |

| | |
|---|---|
| “Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика клиник онкология диспансеры” дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе баш табибы...белән бүләкләнде. | Дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе “Татарстан республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика клиник онкология диспансеры”ның баш табибы ...белән бүләкләнде. |
| “Алабуга мәдәният һәм сәнгать көллияте” һөнәри белем бирү дәүләт автоном учреждениесе коллективы... | Һөнәри белем бирү дәүләт автоном учреждениесе “Алабуга мәдәният һәм сәнгать көллияте” коллективы... |
| ...яшерен оешмадагы 11 каһарманның фаҗигале язмышы безгә мәгълүм инде: Муса Җәлил һәм аның көрәштәшләре. | ... 11 каһарманның – Муса Җәлил һәм аның көрәштәшләренең фаҗигале язмышы... |
| Шәхси хезмәткәрләр дә сәүдәне үз мөмкинлекләреннән түбән дәрәҗәдә оештырдылар, *аеруча җәмәгать туклануы хезмәткәрләре.* | Шәхси хезмәткәрләр, аеруча *җәмәгать туклануы хезмәткәрләре*, сәүдәне ... оештырдылар. |
| Купербаев җитәкчелегендә өлкә делегациясе *Татарстанга ике көнлек визит белән килде.* | *Татарстанга ике көнлек визит белән* Купербаев җитәкчелегендә өлкә делегациясе *килде.* |
| Газ кулланган автомобиль *бензин ягулыгында йөрүче тимер атка караганда* агулы матдәләрне табигатькә биш тапкыр кимрәк тарата. | Газ кулланган автомобиль агулы матдәләрне табигатькә *бензин ягулыгында йөрүче тимер атка караганда* биш тапкыр кимрәк тарата. |
| Русиядә 2015 елның беренче яртысында узган елның шул вакыты белән чагыштырганда 24,4% кимрәк *җиңел машина* җитештерелгән. | Россиядә 2015 елның беренче яртысында *җиңел машина* узган елның шул вакыты белән чагыштырганда 24,4 %ка кимрәк җитештерелгән. |
| Донецк халык республикасы вәкилләре *40 тапкыр* ут ачмау килешүен бозды дип белдерә. | Донецк халык республикасы вәкилләре ут ачмау килешүен *40 тапкыр* бозды дип белдерә. |
| Мин хатын-кыз *иң элек.* | Мин *барыннан да бигрәк* (яки *беренче чиратта*) хатын-кыз. |
| Меморандумга *кул куйдылар*: Татарстан ягыннан Р.Моратов, Иран ягыннан М.Яхъя Әл-Исхак. | Меморандумга Татарстан ягыннан Р.Моратов, Иран ягыннан М.Яхъя Әл-Исхак *кул куйдылар*:. |

| | |
|---|---|
| Бишме, әллә сигез катлымы, *кечерәк кыя өстенә утырган* гаҗәеп гүзәл йортта безнең хирургия взводы урнашты. | *Кечерәк кенә кыя өстенә утырган* биш катлымы, әллә сигез катлымы гаҗәеп гүзәл йортта безнең хирургия взводы урнашты. |
| *Зәп-зәңгәр, озын кара керфекләр белән каймаланган* нур чәчеп торган күзләр дисеңме... – бар да килешле. | *Озын кара керфекләр белән каймаланган,* нур чәчеп торган *зәп-зәңгәр,* күзләр дисеңме... – бар да килешле. |
| Кичә республикабыз башкаласына Ингушетия башлыгы Юныс бәк Евкуров *эшлекле визит белән* килде. | Кичә республикабыз башкаласына *эшлекле визит белән* Ингушетия башлыгы Юныс бәк Евкуров килде. |
| Россиядә яшәүче *һәр бишенче кеше* эшен югалтудан курка. | Россиядә яшәүче *һәр биш кешенең берсе (*яки *яшәүчеләрнең биштән бере)* эшен югалтудан курка. |
| Мин *галим-тюрколог* Әхмәт Зәки Вәлиди хезмәтләре белән танышып чыктым. | Мин *тюрколог-галим (*яки *тюркология галиме)* Әхмәт Зәки Вәлиди хезмәтләре белән танышып чыктым. |
| *Бишенче чакырылыш Дәүләт Советының* тугызынчы утырышы 8 июль көнне *10.00 сәгатьтә* Дәүләт Советы утырышлар залында була. Дәүләт Советы депутатларын *теркәү* Дәүләт Советы бинасында 7 июль көнне *13.00дән 18.00 сәгатькәчә* һәм 8 июльдә *8.00 сәгатьтән* башлап хәл ителә. | *Татарстан республикасының бишенче чакырылыш Дәүләт Советының* тугызынчы утырышы 8 июль көнне *сәгать 10да* парламентның утырышлар залында була. Дәүләт Советы депутатларын теркәү парламент бинасында 7 июль көнне *сәгать 1дән 6га кадәр* һәм 8 июльдә *сәгать 8дән* башлап уздырыла (үткәрелә). |
| Утырыш *12.00 сәгатьтә* башлана. | Утырыш *сәгать 12дә* башлана. |
| ...комитеты 9 май көнне 10.00 *сәгатьтә* ... митингка чакыра. | ...комитеты 9 май көнне *сәгать* 10да... митингка чакыра. |
| *Дәүләт Советы* депутатларын *теркәү Дәүләт Советы* бинасында 21апрелдә 8.00 *сәгатьтән* башлап *хәл ителә.* | *Дәүләт Советы* депутатларын *теркәү парламент* бинасында 21 апрелдә *сәгать* 8дән башлана. |
| ...трансляциясе 8 август көнне иртәнге *6 сәгать 30 минутта* башланачак. | ...трансляциясе 8 август көнне иртәнге *сәгать 7нче яртыда (ва.: 6 тулып 30 минутта)* башланачак. |

| | |
|---|---|
| Фаяз Шабаев 1 ноябрьдә *10.00 дән 12.00 сәгатькәчә* ... гражданнарны кабул итәчәк. | Фаяз Шабаев 1 ноябрьдә *сәгать 10нан 12гә кадәр* ... гражданнарны кабул итәчәк. |
| *Унөч сәгать 10 минут* (радио). | *Сәгать 2нче 10 минут (сәгать бер тулып 10 минут).* |
| Гаетне *4 сәгать 50 минутта* башлап, *5 сәгать 35 минутта* тәмамлау планлаштырыла. | Гаетне, *сәгать 5тулырга 10 минутта (10 минут кала)* башлап, *5 тулып 35 минутта* тәмамлау планлаштырыла. |
| Бүген кояш *7 сәгать 33 минутта* чыкты, һәм ул *17 сәгать 23 минутта* офык артына күмеләчәк. | Бүген кояш *сәгать 8нче 33 минутта* чыкты, *5 тулып 23 минутта* батачак. |

## СТИЛЬ НОРМАЛАРЫ ҺӘМ ТАВТОЛОГИЯ

Телебезнең, шул исәптән матбугат һәм эфир теленең, стилистик нормаларын бозган, сөйләмнең табигый агышына зыян китергән күренешләрнең берсе – тавтология – бертөрле, тамырдаш һәм охшаш яңгырашлы сүзләр яисә әйләнмәләрнең бер үк яки янәшә җөмләләрдә кабатлануы, шулай ук җөмләдә бертөрле кушымчаларның күп булуы аркасында барлыкка килә. Моңа ритм, эмоция, тәэсирлелек, ягъни сурәтлелек-бизәклелек чарасы буларак махсус кулланылган кабатлаулар керми. Тавтология, киресенчә, сөйләмдә ялыктыргыч бертөрлелек, табигый булмаган яңгыраш тудыра торган һәм шактый киң таралган стиль хаталарыннан санала. Тәрҗемә иткәндә кирәксез кабатлаулар кайчак төрле тел сүзләре арасында тәңгәллекләрне дөрес билгели алмау аркасында килеп чыга. Әйтик, рус теленең *творительный падеждагы* сүзен дә, *с* предлогын да татарча *белән* бәйлеге ярдәмендә бирү тавтологиягә китерә: *друг с другом соединены тёплым корпусом – бер-берсе **белән** җылы корпус **белән** тоташтырылган; родственники космических братьев* сүзтезмәсендәге *родственники* һәм *братьев* сүзләренең икесен дә *туганнар* дип тәрҗемә итү аркасында тавтология барлыкка килгән: *космик **туганнарыбызның** якыннары һәм **туганнары*** (аннан, *туганнар* сүзенең икенчесен *кардәшләр* белән алыштырып, җиңел генә котылып була); *беренчеләрдән берсе* дигән тавтология дә – *один из первых* тезмәсенең компонентларын тамырдаш сүзләр белән **тәрҗемә** итү нәтиҗәсе (контекстта аннан котылырга мөмкин, әлбәттә).

Тавтология төрле характерда була:

1. Бер үк җөмләдә яки янәшә җөмләләрдә нәкъ бертөрле сүз (яки сүзләр) берничә тапкыр кабатланып килә. Тавтологиянең бу төре мәгълүмат чараларында күп очрый. Мисаллар: *Минераль* ***ашламалар*** *алып кайту, саклау һәм куллану аерым игътибарга лаек.* ***Ашламалар куллану*** *планын төзү, бөртеклеләрнең һәр гектарына бары тик катлаулы ашламалар кертеп кенә чәчү турында сөйләшү булды* (ике җөмләгә өч *ашлама,* ике *куллану* сүзе кергән); *Алар бу мемуарлардан оста рәссам кулы белән* ***төшерелгән*** *портрет-****сурәтләр*** *табарлар, тиз-тиз генә* ***төшерелгән*** *бу* ***сурәтләр*** *кубесенчә казарма ишекләренә һәм чәйханә стеналарына ясалган булса да, укучылар* ***сурәтләрен*** *күреп таныйрлар* (бер җөмләдә *төшерелгән* сүзе – ике тапкыр, *сурәтләр* сүзе өч тапкыр кабатланган; синонимнардан файдаланып, һәм, кирәк булса, җөмлә төзелешен үзгәртеп, бу тавтологияне булдырмаска мөмкин иде); *Мәчеттә барысын да күзәткәннән соң, без* ***мәчеткә*** *йөрүче бабайларның үзләрен дә җомга көнне кунакка чакырдык* (кабатланган *мәчет* сүзен *монда* сүзе белән алмаштырырга иде).

*Шәһәрнең Авиатөзелеш районында экологик мониторинг үзәге 36 нчы мәктәп* ***базасында,*** *Вахитов районында 51 нче мәктәп* ***базасында,*** *Киров районында 81 нче мәктәп* ***базасында,*** *Мәскәү районында 102 нче мәктәп* ***базасында*** *оештырылачак*; ***Кунаклар*** *икәү дигән идем бит. Икенче* ***кунагыбыз*** *үзе белән тагын бер* ***кунак*** *алып килгән. Әйдәгез, башта икенче* ***кунагыбызга*** *сүз бирик тә аннары* ***кунагыбызның кунагын*** *тыңларбыз. Икенче* ***кунагыбыз*** *дигәне – Нияз Акмал. Иң авыр хәл Россиянең төньяк-көнбатыш төбәгендә күзәтелә.* ***Биредә*** *154 йортта җылылык юк. Соңгы көннәрдә* ***биредә*** *бары тик 3 йорт җылылык белән тәэмин ителә башлады* (икенче җөмләдә *биредә* сүзенең синонимы *монда* сүзен кулланырга мөмкин иде).

Кабатланып килгән бертөрле сүзләр арасында җөмләнең тиңдәш кисәкләрен яки алар составындагы ярдәмче сүзләрне тәшкил итә торганнары да бар: *Әмма Рөстәм әфәнде* ***янына керергә*** *кирәк, булган хәлләрне аңа* ***сөйләп бирергә кирәк*** (җөмләне *янына кереп, ...сөйләп бирергә кирәк* рәвешендә төзесәң, тавтология булмас иде); *Хәзерге Севастополь шәһәре тирәсендә борынгы грек шәһәре һәм дәүләте Херсонеска* ***нигез салына,*** *хәзерге Керчь урынына Пантикапей шәһәренә* ***нигез салына*** (беренче *нигез салына* сүзенең бөтенләй кирәге юк).

2. Бер үк җөмләдә яки янәшә җөмләләрдә бер тамырдан булган берничә мөстәкыйль лексик берәмлек яки бер үк сүзнең төрле грамматик формалары кулланыла. Мәсәлән: *Аларның юл **башы** шулай **башланып** киткән.* Юл башы ничек башлансын инде?! *Аларның юллары шулай башланып киткән* кирәк; *Бөтенесе **очраклы** бер **очрак** аркасында килеп чыкты (очраклы бер хәл* дияргә яки башкача әйтергә мөмкин); *Партизаннар төн җитүен **көтәләр** дә **көтмәгәндә** һөҗүм итәләр*; *55 **еллыгы елында;** газ **кертүгә** зур өлеш **керткән;** иптәшнең лекциясен **тыңларга** күп **тыңлаучылар** килде; Производство базасын **планлы** төзүнең башлангычы булып ГОЭЛРО **планы** булды; Бу **бурычларны** уңышлы үтәп чыгуга идеология работниклары **бурычлылар;** Бередә ял итү **өчен** һәм уку **өчен** барлык мөмкинлекләр дә бар*; *Рәхим итеп **тыңлагыз,** мөхтәрәм **тыңлаучылар***; *Моннан тыш "Татнефтепродукты"ның республика күләмендә 40 ягулык станциясе **исәпләнә;** Татарстанда шәхси кулларда 226 ягулык станциясе **исәпләнгән***; *Матбугат **күзәтүен** бүгенге материалны күзәтү белән башлыйбыз*; *Башка шундый **төзелешләрне төзегән** кебек ук, шушы гаскәри частьны **төзеп...***; *Бу зурларның үзара сөйләшүеи күзәтеп-ишетеп **торуларыннан тора***; *Колхозның ярдәм итеп **торуы** стимул булып **тора** инде*; *Сергей Успенский, Радик Шәймиев белән бертигез очко **бүлешеп,** 4-5 урыннарны **бүлеште***; *бергә берләшеп...*; *халыкка хезмәт **итүен** дәвам **итә.***

3. Бер үк җөмләдә охшаш яңгырашлы сүзләр кулланыла: *актык вакытта **артык** үртәлүчән* дигән әйләнмәне *соңгы вакытта артык үртәлүчән* рәвешендә төзү хәерлерәк булыр иде; ***йөкләр йөртү** планы **(йөк ташу** планы* кирәк).

4. Бертөрле яки охшаш яңгырашлы сүзләр янәшә торган ике җөмләдә – беренчесенең азагында, икенчесенең башында кулланыла. Мәсәлән: *Ә шагыйрь А.Твардовский, бу солдатка багышлап, бөтен бер **поэма** яза. **Поэма** "Василий Тёркин" дип атала; Республикабызның музыкаль культурасы үсешендә сугыштан соңгы елларда яңа **этап** башланды. Бу этап татар совет музыкасынын барлык жанрларында да зур күтәрелеш этабы булды.*

5. Бертөрле яки охшаш яңгырашлы сүзләр яки сүзтезмәләр янәшә ике җөмләнең дә башларында, азакларында һ.б. урыннарында торырга мөмкин: *Пәрәүдә пенсионерларны талаган Казан ПТУсында укучы **тоткарланды.** Караишевода урлауда шикләнелгән тагын бер кеше **тоткарланды.*** Бу ике җөмләне кушып, бер *тот-*

*карланды*дан котылырга мөмкин иде; *Казан ПТУсында укучы һәм тагын бер кеше торкарланды; Шуңа күрә аның бу тәртипләрне үзгәртәсе* ***кирә.*** *Эшчеләрнең тормышларын яхшыртасы* ***килә;*** *Сезнең экраннарыгызда – иң эре комплекс* ***төзелеше.*** *Ул Владимир өлкәсендә* ***төзелә.***

6. Бер-берсенә бик якын урнашкан җөмләләрнең бер үк сүзгә башлануы яки тәмамлануы, бер үк сүзнең, бер җөмләнең азагында, икенчесенең башында кулланылуы да тавтология күренеше һәм стиль җитешсезлеге санала: *Бангладеш күрше илләр белән бәйләнеш тота. Һиндстан белән тынычлык, дуслык һәм үзара ярдәмләшү договоры төзелгән. Бангладеш Россия һәм башка илләр белән элемтә тота* (соңгы җөмләне *элемтәдә тора* дип тәмамласаң, стиль шомарак булыр иде).

7. Семантик тавтология, ягъни бертөрле, якын мәгънәле сүзләр тавтологиясе дә очрый: *Бай турәләр* ***үзара бер-берсе*** *белән тәпәләшкәннәр (үзара* белән *бер-берсе* – бер мәгънәле сүзләр, димәк, аларның берсе кирәкми); *...кереш* ***сүз белән чыгыш ясады*** *(сүз белән чыгыш ясау* дип әйтү дөрес түгел, чөнки чыгыш ясау үзе үк *сөйләү* мәгънәсен бирә. Бу очракта *кереш сүз сөйләде* диярgә кирәк); *Тамырдан яңадан кору (тамырдан* һәм *яңадан* – якын мәгънәле сүзләр, һәм аларның бергә килүе уңышсыз); *сугыш вакыты елларында (сугыш вакытында* яки *сугыш елларында* кирәк); *Хезмәт хакын күтәрү* ***бары тик*** *3,3 миллион кешегә* ***генә*** *кагылган; хезмәт хакын* ***нибары*** *5 процентка* ***гына*** *күтәрүне планлаштыралар* (бу җөмләләрдәге *бары тик, генә, нибары, гына* бертөрле мәгънә аңлата, шунлыктан аларның берсен генә калдыру да җитә).

8. Шактый киң таралган тавтологияләрнең берсе – рәттән килгән күп җөмләләрнең *иде* сүзе ярдәмендә төзелгән аналитик хәбәрләр белән тәмамлануы. Кайбер текстларда җидешәр-сигезәр җөмлә рәттән *иде* сүзенә бетә. Бу хәлне телгә, аның стилистик кануннарына битараф караш белән генә аңлатырга мөмкин. Бераз гына көч салганда, “иделәр өемен” шактый кечерәйтергә була. Мисал өчен менә бу өзекне карап китик: *Әгәр дә башындагы уйлары да янчыктагы папиростай ятса, унөч-ундурт сәгать эчендә бер генә фикернең дә кымшанып карамаганлыгы ап-ачык күренер* ***иде.*** *Өенә ул рухи яктан сафланып, физик яктан ныгып, бәхете ташып кайтыр* ***иде.*** *Шул вакыт эчендә ул үзенең нәрсә уйлаганын әйтә алмас* ***иде.*** *Әллә уйлар, әллә истәлекләр, әллә хыяллар йөзә* ***иде*** *аның башында – барысы да өзек-төтек булыр* ***иде.*** *Исенә-акылына килеп, нәрсә уйлыйм соң әле мин, дип сорап куяр да шулчак үзен йә*

*кәләше белән бергә-бергә бакчада эшләп йөрүче казак итеп, йә тау илендә яшәүче абрек итеп, йә үзеннән качып баручы кабан дуңгызы итеп күрер* ***иде.*** *Кайчан карама, сагаеп кына йә фазан, йә кабан, йә болан килеп чыкканын көтәр* ***иде.*** Рәттән тезелеп килгән бу җиде *иде* сүзенең һичьюгында берничәсеннән котылырга мөмкин.

Тезмә кушма җөмләдәге һәр компонентның *иде* сүзенә тәмамлануы шулай ук стиль кытыршылыгы булып санала: *Директор янына керергә теләүчеләр гадәттәгечә күп* ***иде,*** *секретарь көч-хәл белән генә тәртип саклап тора* ***иде.*** Бу җөмләдәге беренче *иде*дән җиңел котылып була.

*Иде* тавтологиясен булдырмауның торле чаралары бар: күләме белән кыска, мәгънәләре буенча якын җөмләләрне берләштерергә, берничә *иде* сүзенең кайберләрең төшереп калдырырга, кайберләрең исә төрле фигыль кушымчалары белән алмаштырырга, җөмләнең фигыль хәбәрен хәзерге заман хикәя фигыль формаларында кулланырга, инверсия алымыннан файдаланырга һ.б. чаралар күрергә мөмкин.

Без тиңдәш кисәкләрдә бертөрле кушымчаларның кулланылыш үзенчәлекләрен караган идек инде. Хәзер бер үк җөмләдә гомумән бертөрле кушымчаларның кабатланып килүе аркасында сөйләмнең ямьсезләнүе хакында әйтеп китәрбез.

Бер җөмләдә гел бертөрле сүзләр кулланылмасын өчен, синонимик аффикслардан файдаланырга, кушымчаларның кайберләрең төшереп калдырырга һәм җөмләне үзгәртеп корырга була:

а) бер үк җөмләдә берничә күплек кушымчалы сүз килгәндә, аларның санын киметергә мөмкин. Болай эшләү сөйләмне матуррак яңгырашлы итә: ***Авылларда крестьяннарның*** *да* ***тормышлары*** *авыр иде* (җөмләне *авылда крестьяннарның да* яки *крестьянның да тормышы авыр иде* дип төзергә мөмкин); *Чәршәмбе булгач,* ***дәресләр әзерләргә*** *кирәк* ***(дәрес әзерләргә*** кирәк);

*Күпмилләтле* ***илебезнең*** *барлык* ***халыкларының*** *уллары һәм кызлары* (иялек килеше кушымчаларының берсен *-дәге* кушымчасы белән алмаштырырга мөмкин: *Кцпмилләтле* ***илебездәге*** *барлык* ***халыкларның*** *уллары һәм кызлары);* ***Россиянең*** *җәмгыять* ***төзелешенең*** *әһәмиятле ягы* (иялек килеше кушымчаларының беренчесен урын-вакыт килеше кушымчасы белән алмаштырырга мөмкин: ***Россиядә*** *җәмгыять төзелешенең әһәмиятле ягы);*

б) юнәлеш килеше кушымчалары: *Ленин* ***Себердә*** *тайга* ***уртасына*** *Шушь елгасы буена урнашкан ташландык, караңгы бер авылда өч ел яши (тайга* ***уртасындагы*** *Шушь елгасы буена урнашкан* дип

үзгәртсәк, ягъни *уртасы* сүзенең юнәлеш килеше кушымчасын -*дагы* аффиксы белән алмаштырсак, кабатлаудан котылырбыз);

в) төшем килеше кушымчалары: *үз өстегезгә билгеле бер **йөкләмәләрне үтәүне** аласыз (йөкләмәләр **үтәүне** аласыз* кирәк);

г) урын-вакыт килеше кушымчалары: *Ванюгиа Шувалов **Питер янында** кәгазь **фабрикасында** эшли (Питер **янындагы** кәгазь **фабрикасында** эшли* кирәк);

д) *-дагы/-дәге, -тагы/-тәге* кушымчасы: *Матрослар **пароходтагы** сатлык җаннар **кулындагы** компосны ала алырлармы? (**кулыннан** компосны ала алырлармы?* Кирәк);

е) тартым кушымчалары: *Уфа **губернасы** Минзәлә **өязе** Зәй **шәһәре чите** крестьян **депутатлары Советы члены** (Уфа губернасы Минзәлә өязенең Зәй шәһәре **тирәсендәге** крестьян депутатлары Советы члены* кирәк).

| Стиль нормалары бозылу | Төзәтмәләр |
|---|---|
| Рейслар атнасына ике тапкыр *башкарылачак. Татарстан башкаласыннан очкычлар* дүшәмбе көннәрендә – 00 сәгать 50 минутта һәм чәршәмбе көннәрендә – 23 сәгать 20 минутта *очачак.* | Рейслар атнасына ике тапкыр *башкарылачак. Татарстан башкаласыннан самолетлар* дүшәмбе көннәрендә – төнге 1 тулырга 10 минутта һәм чәршәмбе көннәрендә – төнге 12 нче 20 минутта *китәчәк.* |
| Бу төркемдә Фирдәвес Гарипова, Шамил Маннапов кебек *зыялыларыбыз* укыганын да искә төшерсәк, татарның рухи дөньясына өлеш керткән *зыялылар* җыелган булган икән дип сокланмый мөмкин түгел. | Бу төркемдә Фирдәвес Гарипова, Шамил Маннапов кебек *зыялыларыбыз* укыганын да искә төшерсәк, татарның рухи дөньясына өлеш керткән *шәхесләр* җыелган булган икән дип сокланмый мөмкин түгел. |
| Башка шундый *төзелмәләрне төзегән* кебек үк, шушы гаскәри частьне төзеп... | Башка шундый *биналарны (корылмаларны) салган* кебек үк, шушы гаскәри частьне төзеп... |
| Колхозның ярдәм *итеп торуы* да стимул *булып тора* инде. | Колхозның ярдәм *итеп торуы* да стимул инде. |
| Матбугат *күзәтүен* бүгенге материалларны *күзәтү* белән башлыйбыз. | Матбугат *күзәтүен* бүгенге материаллар белән таныштырудан башлыйбыз. |

| | |
|---|---|
| Бу... зурларның үзара сөйләшүен күзәтеп-ишетеп *торуыннан тора.* | Бу... зурларның үзара сөйләшүен күзәтеп-ишетеп торулары *дигән сүз.* |
| Тәртип белән *баштан башлыйм* әле. | Тәртип белән *башлыйм* әле. |
| Беркем дә *онытылмады*, бернәрсә дә *онытылмады.* | Беркем дә, бернәрсә дә *онытылмады.* |
| Мәктәпләрдә *сәламәтлек буенча төркем* мәсьәләсен укучылар файдасына хәл итү *буенча* ни эшләп була соң? | Мәктәпләрдә *сәламәтлек төркемнәре* мәсьәләсен укучылар файдасына хәл итү *буенча* ни эшләп була соң? |
| Чишмә *башы* Оренбургтан *башлана.* | (?) Оренбургтан *башлана.* |
| Әти-әниләре белән күрешү шатлыгын *кичергән* малайларның *кичерешләрен* аңларга була. | Әти-әниләре белән күрешү шатлыгын *кичергән* малайларның *хисләрен* аңларга була. |
| *Ветераннар* (?) белән бергә *хезмәт ветераннары* да бар иде митингта. | *Сугыш ветераннары* белән бергә... |
| ...“Алексеевск *чыңнары” кыңгырау чыңы* фестивален ачу тантанасында катнашты. | ...“Алексеевск *чыңнары”* фестивален ачу тантанасында катнашты. |
| Әгәр авылда *калган* булса, алар күп кенә мөмкинлекләрдән мәхрүм *калырга* мөмкин. | Әгәр авылда *калган* булса, алар күп кенә мөмкинлекләрдән мәхрүм *булырга* мөмкин. |
| Гамәлдәге яки *урнаштырыла* (?) торган корылмалар *урнашкан* җир кишәрлекләре. | Гамәлдәге яки *төзелә* (?) (куела) торган корылмалар *урнашкан* җир кишәрлекләре. |
| Иң авыр хәл ... төбәгендә *күзәтелә. Биредә* 154 йортта җылылык юк. Соңгы көннәрдә *биредә* бары тик өч йорт җылылык белән *тәэмин ителә башлады.* | Иң авыр хәл ... төбәгендә. *Анда* 154 йортта җылылык юк. Соңгы көннәрдә ул бары тик өч йортка *бирелә башлаган.* |
| *Мәчеттә* барысын да күзәткәннән соң, без *мәчеткә* йөрүче бабайларның үзләрен дә җомга көнне кунакка чакырдык. | *Мәчеттә* барысын да күзәткәннән соң, без *анда* йөрүче бабайларның үзләрен дә җомга көнне кунакка чакырдык. |
| Бер ел эшләүгә, аны Иске Комазан мәктәбенә завуч итеп *күчерәләр.* Анда дүрт ел эшләгәннән соң, Шәдче мәктәбенә директор итеп *күчерелә.* | Бер ел эшләүгә, аны Иске Комазан мәктәбенә завуч итеп *билгеләләр (куялар).* Анда дүрт ел эшләгәннән соң, ул Шәдче мәктәбенә директор итеп *күчерелә.* |

| | |
|---|---|
| Яз башында *комбайнчылар комбайнчы* ярдәмчеләре таба алмыйча иза чиктеләр. | Яз башында *комбайнчылар үзләренә* ярдәмчеләр таба алмыйча иза чиктеләр. |
| Аида Гарифуллинаның тавышы ... опера сәнгате *бәйгесендә* иң яхшы сопрано дип табылган. *Бәйгедә* катнашу өчен меңнәрчә яшь башкаручы гариза биргән булган. | Аида Гарифуллинаның тавышы ... опера сәнгате *конкурсында* иң яхшы сопрано дип табылган. *Анда* катнашу өчен меңнәрчә яшь башкаручы гариза биргән булган. |
| “Юбилей туган яктан башлана” дип аталган бәйрәмдә *катнашкан* җырчылар да биредә *катнашачак.* | “Юбилей туган яктан башлана” дип аталган бәйрәмдә *катнашкан* җырчылар да биредә (монда) булачак. |
| “Бәрәкәт” керәшен *оешмасы оешты.* | “Бәрәкәт” керәшен *оешмасы төзелде.* |
| Алар зур фәнни *казанышлары* белән абруй *казанган* шәхесләр. | Алар зур фәнни *хезмәтләре* белән абруй *казанган* шәхесләр. |
| Патриотик тәрбия *буенча* эш планы нигезендә традиция *буенча* хәрби-патриотик смена үткәрелә. | Патриотик тәрбия эше планы нигезендә традиция *буенча* хәрби-патриотик смена үткәрелә. |
| Барлык җиңүчеләргә ял итү мөмкинлекләре *бирүче* сертификатлар *бирелде.* | Барлык җиңүчеләргә ял итү мөмкинлекләре *бирә торган* сертификатлар *тапшырылды.* |
| Дүртенче *чакырылыш...* Дәүләт Советының унберенче утырышын... утырышлар залында *чакырырга*. | Дүртенче *чакырылыш...* Дәүләт Советының унберенче сессиясен... утырышлар залында *үткәрергә.* |
| *Россиядә* быел *урманнарда янгынга* каршы көрәш чараларын үткәрү... *башланды.* Гадәттә урманда янгын апрель *башларында* күзәтелә *башлый.* Әмма *Россиядә* 2 апрельгә *янгынның* 500 *очрагы теркәлгән* дә инде. Әлегә Татарстанда янгын *очрагы теркәлмәгән.* | ...Гадәттә андый хәлләр апрельнең беренче көннәрендә була. Әмма безнең илдә... 500 янгын *очрагы теркәлгән* инде. Әлегә Татарстанда мондый бәла-казаның булганы юк. |

| | |
|---|---|
| ... коры мәгълүмат *белән* канәгатьләнүче җитәкчеләр *белән* еш очрашырга туры килә безгә. | ... коры мәгълүматтан канәгать булган җитәкчеләр *белән* еш очрашырга туры килә безгә. |
| ...“Автомобильсез бер көн” *акцияләре* оештырылган. Әлеге *акцияләр* халыкны җәяү яки велосипедта йөрергә *чакыру астында уза***.** | ...“Автомобильсез бер көн” *акцияләре* оештырылган. Бу чара халыкны җәяү яки велосипедта йөрергә *өндәү белән уздырыла.* |
| Нефть кризисы *булган* 1970 елларда оештырыла торган *булган.* | Нефть кризисы *булган* 1970 елларда оештырылган**.** |
| Чәчүгә *чыгар* алдыннан, авылның мөхтәрәм бабайлары, басуга *чыгып,* азан, тәгъбир әйтәләр. | Чәчү (башланыр) алдыннан, авылның мөхтәрәм бабайлары, басуга *чыгып,* азан, тәгъбир әйтәләр. |
| Гаҗәпләнүләрем Мәскәүдән Нью-Йоркка *очасы очкычка* утырганда ук башланды. | Гаҗәпләнүләрем Мәскәүдән Нью-Йоркка *барасы самолетка* утырганда ук башланды. |
| Тулы *айдан айның* 3нче чирегенә кадәр организм кысылуга бара. | Тулы *айдан (ай туганнан соң) аның* 3нче чирегенә кадәр организм кысылуга бара. |
| Татарстанда *узачак дөньякүләм* чаралар югары дәрәҗәдә *узар.* | Татарстанда *үтәчәк дөньякүләмендәге* чаралар югары дәрәҗәдә *узар.* |
| *Кызым* Фаизә Нурфәиз *кызын* 18 яшьлеге белән... котлыйм. | *Кызым* Фаизәне 18 яшьлеге белән... котлыйм. |
| *Бар* булган белән ярдәм иткән *бар* кешегә рәхмәтләрнең чиге юк. | *Булганы белән (хәзинәдә бары белән)* ярдәм иткән *бөтен* кешегә рәхмәтләребез бик зур (бик зур рәхмәт һ.б.). |
| Татарлар сәүдә өлкәсендә *эшмәкәрлек эшчәнлегенә* нигез сала. | Татарлар сәүдә өлкәсендәге *эшмәкәрлеккә* нигез сала. |
| Мин тагын яңа *ачышлар ачам.* | Мин тагын яңа *ачышлар ясыйм.* |
| М.Е.Кухарчук *хезмәт эшчәнлеген* бухгалтер булып башлый. | М.Е.Кухарчук *хезмәт юлын (хезмәтен)* бухгалтер булып башлый. |

# СҮЗЛӘРНЕҢ СТИЛИСТИК КУЛЛАНЫЛЫШЫ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

Мәгълүм ки, һәр телнең дә сүзләре, төп лексик мәгънәләреннән тыш, стилистик мәгънәләргә дә ия. Сүзнең стилистик мәгънәләрен, мәгънә төсмерләрен сиземләү, аларны тиешле урында куллана белү тел әһелләреннән зур осталык таләп итә. Даими рәвештә ике телдән файдаланганда исә, сүзләрнең стилистик кулланылышы – аеруча җитди мәсьәләләрнең берсе. Бу ике телдәге төп мәгънәләре бердәй сүзләрнең стиль үзенчәлекләрен исәпкә алырга кирәклек белән аңлатыла. Хәлбуки, төп мәгънәләре буенча тәңгәл саналган сүзләр стилистик кулланылышлары белән берберсеннән шактый нык аерыла. Ике тел сүзләренең шушы хосусиятен белмәү яки истә тотмау сөйләмебезнең стилистик нормаларын бозуга китерә.

Телдәге стильләр һәм аларда сүзләрнең, грамматик формаларның кулланылыш үзенчәлекләре – катлаулы мәсьәлә, һәм аны монда җентекләп тикшерү безнең бурычка керми (татар теле стилистикасы мәсьәләләре Х.Курбатов, В.Хаков һ.б. тел галимнәренең хезмәтләрендә тулы яктыртылган). Без татар сүзләренең стилистик кулланылышын рус сүзләренә мөнәсәбәттә генә карап китәчәкбез.

Һәр телнең дә күп меңләгән сүзләре арасында кулланылыш ягыннан тулы иреклеләре дә, берникадәр чикләнгәннәре дә бар. Тулы ирекле яки нейтраль сүзләр сүзлек составының иң зур күпчелеген тәшкил итә, һәм алар телнең барлык стильләрендә дә кулланыла ала (мәсәлән: *кеше, баш, кул, аяк, йорт, китап, дәфтәр, бару, кайту, ашау, эчү, күрү, якты, матур, биек, тәбәнәк* һ.б.). Кулланылышлары чикләнгән сүзләрдән исә һәрбер стильдә файдаланып булмый. Әйтик, гади сөйләмгә караган лексик чаралар публицистик, фәнни стильләрдә кулланылмый.

Сүзләрнең стилистик кулланылышы синонимнар (мәгънәдәш сүзләр) белән бәйләнештә тора. Якынча мәгънәле сүзләрнең берсе – бер стильдә, икенчесе икенче стильдә иркен кулланыла, һәм, димәк, бер стиль өчен яраклы сүз икенчесе өчен ярамаска мөмкин. *Кечкенә* сүзе барлык стильләрдә дә тулы хокуклы булса, аның синонимы *бәләкәйне* иҗтимагый-политик эчтәлекле һәм фәнни әдәбият телендә куллану дөрес саналмый.

Аңлашыла ки, сөйләм культурасы югары дәрәҗәдә булсын өчен, сүзләрне стиль ягыннан дөрес куллану әһәмиятле.

Телебездә, шул исәптән матбугат чаралары телендә дә, шактый еш очрый торган стиль хаталарының берсе – рус теленнән калькалаштырып алынган мөрәҗәгать сүзләре. Русларда күптәннән үк килгән сөйләм этикасы нормалары буенча кешеләргә хөрмәтләп, зурлап эндәшә торган *батя* сүзе бар. Элекке телдә аның *батенька, батюшка* дигән вариантлары булган. Хәзер *батя* яшь ягыннан үзеннән олы кешегә карата кулланылса, революциягә кадәрге руслар тормышында *батенька, батюшка* үзеннән яшьрәк кешеләргә дә зурлап дәшү формасы булган. Элеккерәк чорлардагы вакыйгалар сурәтләнгән рус әдәбияты әсәрләрен татарчага тәрҗемә иткәндә, бу сүзләрне безнең телгә *атакай* сүзе белән алмаштыралар. Нәтиҗәдә, мәсәлән, Л.Толстойның "Казаклар" повестенда олы яшьтәге абзый үзеннән күп яшь егеткә дә, кызлар үзләре белән бер яшьтәге егеткә дә *атакай* дип эндәшә. Шулай ук Ф.Достоевскийның "Җинаять һәм җәза" романында карчык кеше егеткә *атакаем* дип мөрәҗәгать итә. Андый мисалларны башка китаплардан да табып була. Болай эндәшү формасы татарларга хас түгел. Мондый очракларда оригинал сүзенә функциональ һәм стилистик яктан тиң сүз эзләп табарга кирәк.

Бу уңайдан хәзерге вакытта рус һәм татар сөйләмендәге эндәшү үзенчәлекләрен искә төшереп китү урынлы булыр. Русларда таныш булмаган өлкән яшьтәге хатын-кызга *мамаша* дип, ир кешегә *папаша (батя)* дип эндәшү гадәте бар. Татарларда мондый очракларда *папаша (батя)* һәм *мамаша*ның төп мәгънәләрендәге тәңгәллекләре *әти, әни* сүзләре түгел, бәлки чыганак сүзләргә функциональ һәм стиль ягыннан туры килә торган *абый* һәм *апа* сүзләре кулланыла.

Шулай ук таныш булмаган кыз кешегә русча *девушка,* кечкенә кызга *девочка* дип, егет яки яшь ир кешегә *молодой человек,* малай кешегә *мальчик* дип эндәшәләр. Татарча мондый очракларда ул сүзләрнең номинатив мәгънәләрендәге тәңгәллекләре кулланылмый. Бездә үзеннән яшьрәк хатын-кызга (кызларга, яшь хатыннарга) *сеңелем* дип, үзеннән яшьрәк ир-атка (малайларга, егетләргә һәм яшь ирләргә) *энем* дип эндәшү гадәткә кергән. Руслар өчен малайларга *мальчик (мальчики)* дип эндәшү табигый күренеш булып саналса, татарча *малай* дип эндәшү тупасрак булып тоела. Шулай ук хатын-кызга русча *женщина* дип, ир-атка *мужчина* дип эндәшеп була икән, татарча *хатын-кыз, хатын, кыз, ир-ат, ир (ир кеше)* дип эндәшеп булмый.

Безнең телдә *кыз* сүзенең кечерәйтелгән формалары *кызый, кызыкай,* гадәттә, тәкәллефсезлек, кимсетү, түбәнсетү төсмере белән кулланыла. Шунлыктан бу сүзләрне җитди урында куллану стиль ягыннан хата булып санала. Мәсәлән: *Апаның йөзе* ***кызыкай-га*** *бик тә таныш кебек тоелды. – Лицо посетительницы вдруг показалось* ***девушке*** *очень знакомым.*

Сөйләм телендә, матур әдәбият стилендә кулланыла торган кечерәйтелгән мәгънәдәге *бәләкәй, нәни* сүзләренең иҗтимагый-политик текстта кулланылуы дөрес түгел: *...экономик нәтиҗәсе бәләкәй; Аны характерлау өчен нәни генә сызык та җитә.* Мондагы *бәләкәй, нәни* сүзләре урынына *кечкенә* сүзе кулланылырга тиеш.

Русларда яшь һәм урта яшьтәге ир-атка *мальчики* дип эндәшү бар. Ләкин моны татарчага О.Горчаковның “Утны үзебезгә юнәлдерәбез” киносценариендагы кебек *малайлар* дип тәрҗемә итү дөрес булмый: *Җитәр сезгә, малайлар! Тукта, Эрих! – Полно вам,* ***мальчики!*** *Хватит, Эрих!* Мондый очракларда татарларда *егетләр* дип дәшәләр.

“Совет дәүләте һәм хокукы нигезләре” дигән китапта хулиганның иптәше *дускай* дип бирелгән. Бу – *дружок* сүзенең тәрҗемәсе. Ләкин алар стиль ягыннан бер-берсенә туры килми: русларда *дружок (дружки)* сүзенең *начар иптәш* дигән мәгънәсе дә бар. Татарча *дускай* дус кешегә иркәләп эндәшү мәгънәсендә йөри. Шулай булгач, анда *дускай* урынына *иптәш* яки *дус* сүзләрен куллану дөресрәк булыр иде.

*Ты бы его видела в танце. Гений. – Син аны биегән вакытта күрсәң иде. Даһи.* Бу тәрҗемәдә дә гомумән алгандагы эквивалент сүзләр *гений* һәм *даһи* тәңгәл түгел: татарлар биючегә *даһи* дип әйтмиләр; *очып кына йөри, останың да остасы, җилдән җитез бии, искиткеч шәп бии* һ.б. дияргә кирәк.

Гражданнар сугышы героеның һәлак булуы турында *эшен бетерәләр* дип язу кайбер очракта эквивалент сүзләрнең стиль ягыннан тәңгәл килмәвен күрсәтә. *Эшен бетеру* дип юньсезләргә, дошманнарга әйтергә мөмкин, гражданнар сугышы геройларына карата ярамый.

*“Судан Эйруэйс” авиакомпаниясенең “Боинг-737” самолеты* ***мәтәлеп төште.*** *Әлеге фаҗигадә 15 кеше үлде.* (Фаҗига турында сөйләгәндә, *мәтәлеп төшү* сүзен куллану стиль ягыннан дөрес түгел. (Текстны *...самолеты* ***ватылып төшкән.*** *Бу фаҗигадә 15 кеше һәлак булган* рәвешендә төзергә кирәк иде).

*Какая глыба, а? Какой матёрый человечище! – Нинди олы тау, ә? Нинди зур кеше! Олы тау* оригиналдагы *глыба* сүзенең эмоциональ-экспрессив көчен бирми, әлбәттә. *Алып батыр бит ул! Нинди көчле кеше!* дип әйтергә кирәк иде,

*Утро было совершенно ясное. – Инде дә аяз иртә иде. Совершенно* – әдәби сүз, *инде дә* – гади сөйләм формасы. Димәк, алар стиль ягыннан тәңгәл түгел. Бу очракта тәрҗемәдә әдәби сүз кулланылырга тиеш: *Чалт аяз иртә иде.*

Ике телнең грамматик формалары да бер-берсенә стиль ягыннан тәңгәл булырга, ягъни морфологик форма, синтаксик конструкция әсәрдәге персонажларның теленә туры килергә тиеш. “Көтәбез сине, егет!” фильмында бер кечкенә малай болай ди: *Ул* (әтәч – *Р.Ю.) шундый акыллы. Тик сугыша гына. Шундый сугыша ки, хәтта апаның күзен чукыды.* Бу сөйләм малайларга хас түгел: *ки* теркәгечен, гадәттә, олы яшьтәге кешеләр куллана, малайлар алай сөйләшми. Җөмлә *Ул бик акыллы әтәч, тик сугышырга гына ярата. Беркөнне әле апаның күзен дә чукып алды* булырга тиеш.

| **Стилистик ялгышлар** | **Төзәтмәләр** |
|---|---|
| Бу саклану корылмасы – *республикабыз тарихында* иң үзенчәлекле, фаҗигале *битләрнең* берсе. | Бу саклану корылмасы – *республикабыз тарихында* иң үзенчәлекле, фаҗигале *сәхифәләрнең* берсе. |
| Юлларда бик тайгак: *зинһар өчен* игътибарлы булыгыз! | Игътибарлы була күрегез: юлларда бик тайгак. |
| *Чирне* китереп чыгаручы сәбәпләр. | *Авыруны* китереп чыгарган сәбәпләр. |
| 30 августта ил *күләм әти-әниләр* җыелышы узды. | 30 августта ил *күләмендә ата-аналар* җыелышы узды. |
| ...мәктәп укучыларының сәламәтлеге начараю хакында *әти-әниләрдән дә, укытучылар авызыннан* да күп ишетергә туры килә. | ...мәктәп укучыларының сәламәтлеге начараю хакында *ата-аналардан да, укытучылардан* да күп ишетергә туры килә. |
| ...сак бүлекчәләре хезмәткәрләре арасында һөнәри осталык *бәйгесе* булды. | ...сак бүлекчәләре хезмәткәрләре арасында һөнәри осталык *ярышы* булды. |
| *Әүвәл* дөньяның унбиш иленнән... килгән вәкилләр катнашында халыкара форум узды. | *Элек* дөньяның унбиш иленнән... килгән вәкилләр катнашында халыкара форум узды. |

| | |
|---|---|
| *Тәгәрмәчләрне* вакытында алмаштырса, машина йөртүче уңайсыз һава шартларында да юлда курыкмыйча хәрәкәт итә алачак, – диелә хәбәрдә. | *Көпчәкләрне* вакытында алмаштырса, машина йөртүче уңайсыз һава шартларында да юлда курыкмыйча хәрәкәт итә алачак, – диелә хәбәрдә. |
| Әмма танклар саны буенча өстенлек булуга карамастан, *орыш* совет гаскәрләренең җиңелүе белән тәмамлана. | Әмма танклар саны буенча өстенлек булуга карамастан, *сугыш* совет гаскәрләренең җиңелүе белән тәмамлана. |
| Бөек Ватан сугышы тарихына “Умань казаны” исеме белән кереп калган *орыш* вакытында 100 меңнән артык совет хәрбие әсир төшә. | Бөек Ватан сугышы тарихына “Умань казаны” исеме белән кереп калган *сугыш* вакытында 100 меңнән артык совет хәрбие әсир төшә. |
| Минем дүрт *малаем*, ике кызым бар. | Минем дүрт *улым*, ике кызым бар. |
| Кызыл диңгез буендагы Судан шәһәре тирәсендә “Судан-Эйруэйс авиакампания”сенең “Боинг-737” самолеты *мәтәлеп төште.* | Кызыл диңгез буендагы Судан шәһәре тирәсендә “Судан-Эйруэйс авиакампания”сенең “Боинг-737” самолеты *егылып төшкән.* |
| Казан *чәчкәләргә* күмелә. Казан урамнарында *чәчкә* савытлары саны арта. | Казан *чәчәкләргә* күмелә. Казан урамнарында *чәчәк* савытлары саны арта. |
| ...эчәк таякчыгы әлегә Россия кешеләре *корсакларын* әйләнеп уза. | ...эчәк таякчыгы әлегә Россия кешеләренә (*кешеләренең эчәкләренә*) кагылмый тора. |
| Алар *бәләкәй* көймәдә... Мальта аша Парижга чыгалар. | Алар *кечкенә* көймәдә... Мальта аша Парижга чыгалар (киләләр). |
| Депутатлар *салган килеш руль артына утыручыларга* штраф күләмен дә арттырырга җыенмыйлар. | Депутатлар *эчкән килеш машина (автомобиль) йөртүчеләргә* штраф күләмен дә арттырырга җыенмыйлар. |
| Студентлар Әхмәт әфәндегә (Төркия консулына – *Р.Ю.*) *чиксез рәхмәтләрен* җиткерделәр. | Студентлар Әхмәт әфәндегә *рәхмәтләрен* белдерделәр. |
| *Искитмәле* биек үрләр яулаган Фәрит әфәнденең сүзләренә ышанмый мөмкин түгел. | (Бик?) биек үрләр яулаган Фәрит әфәнденең сүзләренә ышанмый мөмкин түгел. |
| Сак *бүлекчәләре* хезмәткәрләре арасында һөнәри осталык *бәйгесе* булды. | Сак ***(бүлекләре)*** хезмәткәрләре арасында һөнәри осталык *ярышы (конкурсы)* булды. |

| | |
|---|---|
| Татарстаныбызга барысы *да мач килеп...* без җырлап яшәп киткәндә дә җир мае *эчебезне төртеп тишмәячәк.* | Татарстаныбызда барысы *да әйбәт булып..* без җырлап яшәп киткәндә дә *җир мае артык булмас.* |
| Бер яшьлек баланы өч эт *тешләп* үтергән. | Бер яшьлек баланы өч эт *талап* үтергән. |
| Казанның төрле уку йортларында *белем алучылар* инглиз теле *буенча тирәнтен белем эстәде.* | Казан шәһәре укучылары инглиз теленнән нык (яхшы) *белем алды*. |
| *Чирне китереп чыгаручы* сәбәпләр... | *Авыруны китереп чыгарган* сәбәпләр... |
| *Ни кызганыч*, күп очракта берәү дә үзен гаепле дип санамый. | *Шунысы үкенечле*: күп очракта берәү дә үзен гаепле дип санамый. |
| 4 декабрьгә кадәр *җылы һава торышы сакланачак.* | 4 декабрьгә кадәр *көннәр җылы булачак.* |
| Ул да минем *китмәвемне тели.* | Ул да минем *китүемне теләми.* |
| Эшсезлектән *куркасызмы?* | Эшсезлектән *курыкмыйсызмы?* |

## ОРФОГРАФИЯ<br>ҺӘМ ПУНКТУАЦИЯ ПРОБЛЕМАЛАРЫ

Мәгълүмат чараларындагы тел ялгышлары күп төрле. Без бу мәкаләдә бары тик кайбер сүзләрнең хаксыз рәвештә кушып язылуы, кечкенә хәрефләр урынына баш хәрефләр язу кебек орфография хаталары һәм тыныш билгеләрен куюдагы аеруча күп очрый торган ялгышлар турында сөйләрбез.

Кайбер каләм ияләре сөйләмдәге (җөмләдәге) үзара ачыклаулы мөнәсәбәттә торган ике сүзне, бер сүз итеп, кушып язу белән мавыгалар. Нәтиҗәдә телебезнең дөрес язу кагыйдәләре, тәгаенләп әйткәндә, кушма сүзләр ясалу тәртибе тупас бозыла.

Телебездә янәшә торган ике сүз, мөстәкыйль мәгънәләрен югалтып, гомуми яңа бер мәгънә белдерә башлаган очракта гына кушма сүзгә әверелә. Мәсәлән, *көнбагыш, атланмай, ишегалды, өйалды, аккош* (аккошларның барысы да ак булмый), *өчпочмак (ашамлык), суүсем, өскорма* һ.б. Кайбер каләм ияләренең исә, теге яки бу янәшә торган ике сүзне бернинди нигезсез кушып язып, алардан белдеклеләнеп кушма сүз ясап куюларын һич кенә дә яраклы гамәл дип әйтеп булмый.

Хәзер мисал итеп китереләчәк уйдырма кушма сүзләрнең барлык кисәкләренең дә мөстәкыйль мәгънәләре аермачык аңлашылып тора, һәм, димәк, алар бернинди дә кушма сүзләр түгел, бәлки үзара ачыклагыч мөнәсәбәтендәге аерым-аерым сүзләр. Шулай булгач, аларны кушып язу телебезнең дөрес язылыш кагыйдәләрен тупас бозу итеп санала.

"Фидель Кастроның элеккеге *тәнсакчысы* Хуан Санчес...". Бу җөмләдәге *тәнсакчысы*, беренчедән, русчадагы *телохранитель*нең ялгыш калькасы (хәрефкә-хәреф тәрҗемәсе), аны *шәхси сакчысы* дип куллану кулайрак булыр иде; икенчедән, *тән сакчысы* берничек тә кушып язылырга тиеш түгел: ул безнең телгә рус теленнән механик рәвештә күчереп кую аркасында килеп кергән.

"Алар *сатлыкҗан* булып санала" (мондагы сатлыкҗан аерым язылырга тиеш: сатлык җан).

"*Канкойгыч* бәрелешләрдә ул ике тапкыр контузия ала". Мондагы *канкойгыч*ны кушып язу өчен дә бернинди нигез юк. Ул да рус телендәге *кровопролитные* (столкновения) сүзен калькалаштыру нәтиҗәсендә барлыкка килгән. Дөресе – *кан койгыч (кан коюлы, канлы).*

*Илкүләм* халык фикерен өйрәнү үзәге. (Ил күләмендә халык...).

Әлегә *тулыканлы* мәхәллә Тукайда гына (дөресе – *тулы канлы*).

Моңа кадәр Владимир Якунин *тизйөрешл*е тимер юлны салу эше башланмаска да мөмкин *икәнен* әйткән иде (... тиз *йөрешле тимер* юлны салу эшенең башланмаска да мөмкин *икәнлеген* әйткән иде кирәк).

Украина Югары радасы 12нче ноябрьдә *кырымтатар халкына* каршы геноцид кылынганлыгын таныды (дөресе – ... *Кырым татарларына* каршы геноцид...).

Кырымның Яңа Конституциясе *кырымтатар* файдасына *булмаска ошый* (*...Кырым татарлары* файдасыны *булырга ошамый*).

Улым, синнән башка *берялгызым* нәрсә эшлим, кайт (*бер ялгызым* булырга тиеш).

170тән артык милләтнең *бербөтен* булып яшәве – күп төбәкләргә үрнәк (... бер бөтен булып яшәве...).

*Бөтентатар* иҗтимагый үзәге... халык җыены уздыра (дөресе – *Бөтен татар* иҗтимагый үзәге...).

Очасавара архипелагы янында *суасты* вулканы атылгач.. ...Бу җөмләдәге *суасты* русчадагы *подводный* (вулкан) сүзеннән калькалаштырып алынган. Дөресе – *су асты* вулканы.

Русиядә бишенче буын *суасты* көймәсе эшләнәчәк (...*су асты* көймәсе...).

Хуҗалыкта җәйге лагерьлар юк, маллар *ярымбәйләп* асрала. (... *ярым бәйләп*... кирәк).

Йөзегезгә карагач *ярымай* күренә. Монда ике хата бар: беренчедән, *карагач* сүзеннән соң өтер куелырга тиеш; икенчедән, *ярымай*, дигән сүз юк, *ярым ай* сүзләре генә булырга мөмкин. Җөмлә стиль ягыннан да бик тупас төзелгән. Ул *Йөзегездән ай нуры сирпелә* яки *Йөзегез ай кебек балкый* кебегрәк төзелергә тиеш.

Халкыбызның якты киләчәге өчен җан атып йөрүче *бертөркем* депутатларның... (*бер төркем* депутатларның...).

*Бертөркем* галим яман шешнең барлык төрләрен дә... җиңү ысулын уйлап тапкан (*Бер төркем галимнәр*... кирәк).

*Бертөркем* авыл яшьләре кичке уенга бара (*Бер төркем* авыл...).

Кеше тормышының иминлеген саклау – республикада алып барыла торган *киңкырлы* юнәлешләрнең берсе (дөресе – ... *күп кырлы* яки *күп төрле* юнәлешләрнең берсе).

*Беряклы* ялгыш нәтиҗәгә китерүләре (дөресе – *бер яклы* нәтиҗә...).

*Ара* сүзе белән бергә килгән сүзләрне кушып язу да дөрес түгел: *Милләтара* һәм *конфессияара* татулыкны саклап калу өчен...; *динара* элемтәләр булдыру да дөрес булыр иде.

Яңа образларны гадәттә, *йокыаралаш* күрәм (дөресе – *йокы аралаш*...).

Сүзләрне ялгыш кушып язу очраклары аеруча *күп* сүзе белән бергә килгән әйтелмәләргә карый. Бу мәсьәләдә соңгы вакытларда сәер күренеш хөкем сөрә: *күп* сүзе белән янәшә торган барлык сүзләрне дә кушып язу гадәткә кереп бара. Мисаллар:

*Күптавышлы* моңлану могҗизасы.

...христианлыкны мәҗүси *күпаллалыкка* кайту дип кабул итә.

*Күпмәдәниятле* дөньяда ислам дине дип аталучы халыкара форум.

*Күпмилләтле, күпдинле* илебездә тыныч-тату яшәү аеруча әһәмиятле.

Гүя, аның *күпсанлы* пассажирлары ...тугайларга таралышкан.

Этник гармония *күптеллелек* аша гына мөмкин (...*күп теллелек* аша...).

Быел *күптөрле* эшләр эшләнде (Быел *күп төрле* эшләр эшләнде).

Ана телебездә – *күптомлы* энциклопедия (дөресе – *күп томлы* ...).

*Күпьеллык* нәтиҗәле *эшчәнлеге* өчен...(*Күп еллык* нәтиҗәле *эше* өчен...)

*Күпкатлы* йортлар төзеп куйдылар (*Күп катлы* йортлар...).

Н.Я.Бичурин *күртөрле* чыганакларны өйрәнеп... (...*күп төрле* чыганаклар...).

*Күпфатирлы* йортлар белән идарә итү (*Күп фатирлы* йорт...)..

*Күпбалалы* гаиләләргә бүлеп бирелгән җирләр (*Күп балалы* гаиләләр...).

Бу җөмләләрдәге *күп* сүзе белән кушып язылган сүзләр – рус телендәге *многонациональный, многочисленный, многоквартирный* кебек рус кушма сүзләренең ялгыш калькалары. Аларның берсе дә кушма сүзләр түгел һәм, димәк, аларны кушып язарга да нигез юк.

Такташ әсәрләренең *өчтомлыгы* чыгып өлгергән иде (...*өч томлыгы*...).

“Уйдырма” кушма исемнәргә мисалларны күп күрсәтергә мөмкин.

Телебездә күп таралган ялгыш язу очракларының бер төрен тезмә ялгызлык исемнәрен яза белмәү тәшкил итә. Моның төп ике сәбәбе бар: берсе – рус телендәге шундый исемнәрне ялгыш тәрҗемә итү, икенчесе – тезмә ялгызлык исемнәрен язу кагыйдәләрен белмәү.

Рус телендә дә, татар телендә дә тезмә ялгызлык исемнәрен язу кагыйдәсе, нигездә, бер төрле: тезмә ялгызлык исемнәренең беренче сүзе генә баш хәрефтән языла, калганнары кечкенә хәреф белән башлап языла. Хәер, тезмә исем составында ялгызлык исеме булса, ул зур хәреф белән башлап язылырга тиеш, әлбәттә. Әмма бу мәсьәләдә рус теле белән татар телләренең бер үзенчәлеге бар. Рус телендә тезмә ялгызлык исеме эченә кергән беренче уртаклык исеме баш хәрефтән язылса, аны татарчага тәрҗемә иткәндә, рус әйтелмәсе эчендәге сүзләрнең урнашу тәртибе үзгәргәнлектән, рус тезмәсендә баш хәреф белән язылган беренче сүз татарчада, кайчакта, беренчелеген югалтып, кечкенә хәрефтән башлап язылырга тиеш була.

Ләкин бу үзенчәлек ике тел белән эш итүчеләр практикасында еш кына исәпкә алынмый. Нәтиҗәдә тезмә ялгызлык исемнәренең дөрес язылышы кагыйдәсе бозыла. Мәсәлән, *Министерство образования и науки Республики Татарстан* дигән русча тезмә ялгызлык исемдә *Министерство* сүзе, әйтелмәдә беренче булып торганлыктан, баш хәрефтән язылса, татарчасында *мәгариф* сүзе, беренче урында булмаганлыктан, кечкенә хәреф белән башлап язылырга тиеш. Әмма безнең мәгълүмат чаралары авторлары бу кагыйдәне бервакытта да исәпкә алмыйлар һәм *Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы* формасында – *Мәгариф* сүзен баш хәреф белән язалар (дөресе – *Татарстан республикасының мәгариф һәм фән министрлыгы*).

*Аппарат Кабинета Министров Татарстана* әйтелмәсендә *Аппарат*, тезмә ялгызлык исемнең беренче компоненты буларак, баш хәрефтән языла. Аны татарча әйткәндә исә, *аппарат*, сүзтезмәнең башында тормаганлыктан, кечкенә хәрефтән башлап язылырга тиеш. Әмма бөтен газеталарда һәм башка чыганакларда *Татарстан Министрлар Кабинеты Аппараты* дип, ягъни *аппарат*ны хаксыз рәвештә баш хәрефтән язалар.

Татарстан Язучылар берлегенең *корылтае...* (дөресе – *Татарстанның язучылар союзы съезды...*).

*Татарстан Республикасы хөкүмәте"* дигәндә дә кайберәүләр ялгыш *хөкүмәт* сүзен баш хәреф белән язалар.

РФ *Хөкүмәте Рәисе* урынбасары ... очрашуында катнашты. Бу җөмләдә дә *хөкүмәт* һәм *рәис* сүзләре ялгыш баш хәрефләр белән язылган.

Татнефть *Директорлар* советының чираттагы утырышы булып узды. *Директорлар* сүзен зур хәрефтән башлап язуны һич кенә дә нигезләп булмый: ул бернинди дә ялгызлык исеме түгел.

Татарстан Үзәк сайлау комиссиясе рәисе... (*Татарстанның үзәк сайлау комиссиясе рәисе...* кирәк).

Бу турыда РФ *Вице-премьеры* Ольга Голодец белдерде. Монда *Вице-премьерны* баш хәрефтән язу шулай ук дөрес түгел.

Бу җөмләдәге *Гадәттән тыш илчесе* әйтелмәсенең *гадәттән* сүзен баш хәреф белән язылуын шулай ук берничек тә аңлап булмый:

Япониянең Гадәттән тыш һәм вәкаләтле илчесе Тикохито Харада... утырышында катнашты. *Гадәттән тыш илче* (гадәтие дә, гадәттән тышы да) һич кенә дә ялгызлык исеме була алмый.

Казандагы мәгълүм бер концерт залын газеталар менә болай яза: *С.Сәйдәшев исемендәге Дәүләт Зур концертлар залы. Дәүләт* һәм *зур* сүзләрен зур хәреф белән башлап язуны ничек нигезләп була? Берничек тә булмый. Бу тезмә исемне ялгызлык исеме дип атарга телибез икән, моның өчен әйтелмәнең беренче сүзен (С.Сәйдәшев) зур хәреф белән башлап язу җитә.

Кайбер каләм ияләре язганда гомумән аны-моны уйлап тормыйча гына эш итәләр, күрәсең. Менә бу җөмлә авторы *мәгариф* сүзен ни өчен баш хәреф белән язды икән?! Бу көннәрдә *Мәгариф* хезмәтләреннән файдаланучылар хокукын яклау җәмгыяте башлыгы.... Шушы ук фикерне бу җөмләгә карата да әйтергә була: Рөстәм Миңнеханов Дәүләт Советына *Юлламасында* ... кагылып үтте. *Юллама* ни өчен баш хәрефтән язылган? Ул ялгызлык исеме түгел бит!

Россия Президенты *Рәхмәте* игълан ителде (...*рәхмәте* игълан ителде кирәк).

Мәкаләбезнең башында тезмә ялгызлык исемнәрен язуда ялгышлар күбесенчә тәрҗемә иткәндә рус һәм татар телләренең үзенчәлекләрен исәпкә алмау аркасында килеп чыга дигән идек. Шушы фикерне расларлык тагын бер-ике гыйбрәтле мисал китерәбез.

Республикабызның язмышын хәл итүдә гаять әһәмиятле бер документ исемендәге беренче сүз *Декларация* пунктуация кагыйдәсе буенча баш хәрефтән языла:

*Декларация о государственном суверенитете Республики Татарстан”*. Моны татарчага тәрҗемә иткәч, *декларация* сүзе, беренче урынын югалтып, кечкенә хәреф белән язылырга тиеш, чөнки ул үзе генә ялгызлык исеме түгел. Ләкин безнең каләм әһелләре, бу документ исеменең русчасына карап, механик рәвештә *декларация*не зур хәрефтән башлап язалар. Дөресе – Татарстан Республикасының дәүләт суверенитеты турында *декларация*!

Татарская государственная филармония имени Габдуллы Тукая. Татарчасы – Габдулла Тукай исемендәге Татар Дәүләт филармониясе (*Татар* һәм *дәүләт* сүзләре баш хәреф белән язылырга тиеш түгел).

Олимпия *Уеннарында* уңышка ирешүчеләр арасында милләттәшләребез дә бар (дөресе – Олимпия *уеннарында*...).

Монда билбаулы көрәш буенча *Дөнья Беренчелеге* узды (...*дөнья беренчелеге узды* кирәк).

Татарча матбугат материалларында сүзләрнең дөрес язылышы бозылуның башка төрле очраклары да бар. Кайберләрен генә күрсәтеп китик.

Соңгы вакытларда кайберәүләрнең ишетелгәнчә генә язу чире йоктырулары аркасында *микән* дигән сүзне куллану гадәте кереп китте. Мәсәлән: Пенсиямне дөрес исәплиләр *микән*?; Хет берәрсе уйлый *микән* минем хакта? Балам мәктәпкә китте *микән*? Татар телендә **микән** дигән сүз юк. Бу җөмләләрдән күренгәнчә, **икән** ярдәмче сүзенә аның алдыннан килгән сүзнең *мы-ме* сорау кисәкчәсен ул сүздән хаксыз аерып алып кушып кую аркасында килеп чыга. Чын татарча булсын дисәң, *...исәплиләрме икән?; ...уйлыймы икән?; ...киттеме икән?* рәвешендә булырга тиеш. Кайбер төбәкләрдә яшәүчеләр телендә *микән* диалекталь форма буларак, *икән* сүзе урынында кулланыла. Бу ялгыш кайчакта газеталар теленә дә кереп китә: *Нindирәк үрдәк микән ул?* Әдәби дөресе – *Ниндирәк үрдәк икән ул?*

Кайбер сүзләрнең морфологик төзелешен исәпкә алмыйча, аларның ишетелүенә генә таянып, тиешле сузык аваз хәрефен ялгыш төшереп калдырып язу очраклары бар. Мәсәлән, *...барсы* да бар татар моңында дигән шигырь юлы җөмләсендә *барсы* сүзе ялгыш язылган. Дөресе – *барысы да бар* татар моңында. Бездә *сеңел* сүзенең беренче һәм икенче зат кушымчалары белән килгән очракларында аның икенче *е* авазын төшереп калдырып язу гадәткә кергән: *сеңлем, сеңлең*, диләр. Бу дөрес түгел: *сеңелем, сеңелең*, дип язылырга тиеш: бу сүзнең төп мәгънәле кисәге – *сеңел* һәм аның зат-сан, килеш белән төрләнгәндә үзгәрешсез саклануы зарур.

Бездә алынма сүзләрнең кушымчаларын, фамилияләрнең соңгы сузыкларын *(-ов-ев)* язуда төрлелек хөкем сөрә: яңа орфография сүзлекләре юк, элеккегеләре – күптән тузып, таралып беткән, һәм журналистлар да, башка каләм ияләре дә һәркайсы үзенчә эш итә. Мәсәлән, *мәдәният, әдәбият, нәшрия*т кебек сүзләргә, соңгы иҗектәге сузыкның калын яки нечкә әйтелешенә карап (ә бу мәсьәлә тәгаен хәл ителмәгән) калын кушымча да, нечкә кушымча да ялгап әйтергә һәм язарга мөмкин: *әдәбиятны-әдәбиятне, мәдәниятка-мәдәниятка, нәшрияттан-нәшрияттән.* Соңгы иҗеге **и** сузык авазы белән ясалган ялгызлык исемнәренә нинди кушымча ялгау мәсьәләсе ачык түгел. Мәсәлән, безнең журналистлар, Рим сүзендәге **и** нечкә сузык дип уйлап, аңа нечкә кушымча ялгап язалар: “Иң популяр урыннар исемлегенә *Римдәге*

Колизей кертелгән”. Ләкин Римдагы **и***рек* сүзендәге **и** кебек нечкә әйтелми, **ы** авазына якынрак итеп, калынрак әйтелә, шуңа күрә *Римгә, Римдәге* һ.б.ш. түгел, бәлки *Римда, Римдагы* һ.б.ш. рәвештә булырга тиеш.

Кайбер сүзләрне язудагы ялгышларның сәбәбе, әле әйтелгәнчә, орфография кагыйдәләренең билгеләнеп бетмәвендә булса, хаталарның күбесе каләм иясенең игътибарсызлыгы яки татар телен җитәрлек белмәве аркасында була. Мәсәлән, *зәвык* – бик мәгълүм һәм язылышы, әйтелеше дә бәхәссез сүз, ләкин кайсыдыр журналистлар аны ялгыш язалар: “Сәнгать кешесенең *зәвеге* югары булырга тиеш”. *Вазгыять* тә сүзлекләрдә шушы рәвештә теркәлгән, ләкин аны безнең иң өлкән республика газетасы *вәзгыять* дип яза. “Татарстан милли музее бу *мәрәсимне* Мостафа авылында билгеләп үтте” (дөресе – *мәрасим*). Бер газета хәтта академик Зәкиевнең исемен *Мирфатих* дип яза, хәлбуки аның чын татарчасы – *Мирфатыйх.*

Яки менә тагын гади генә сүзләрне дә хата белән язу: “...хезмәт хаклары 10 процентка *кимеячәк*” (дөресе – *кимиячәк*); “...бәхетле тормыш *төзеячәкләренә* ышана” (*...төзиячәкләренә* ышана кирәк).

Һәм инде кайбер журналистларның, хәзерге телдә гомум кабул ителгән орфография кагыйдәләрен бозып, *конфет*ны *кәнфит* дип, *пальто*ны *пәлтә, скрипка*ны *эскрипкә, товар*ны *тауар, немец*ны *нимес*, *йогурт*ны *йогыр*т дип язуларын берничек тә аңлап булмый.

Республика газеталарының берсендә “**Көндә бәйрәм, көндә туй**” (дөресе – *көн дә бәйрәм, көн дә туй*) дигән җөмләгә тап булгач, телебезнең мондый элементар кагыйдәләрен белмәгән каләм ияләре шундый җитди матбугат органында ничек эшлиләр икән дип шаккатып каласың.

Сүзләрнең дөрес язылышы мәсьәләсендәге фикерләребезне шуның белән тәмамлап, татарча язуда тыныш билгеләре кую турында әйтеп китик.

Хакыйкать шул: татарча язмаларда тыныш билгеләрен куюда хаталар күп, хәтта бик күп. Алар пунктуация кагыйдәләренең төрле өлкәләренә карыйлар, ягъни эчтәлекләре буенча күп төрле. Без аеруча күзгә ташланып торганнарының кайберләрен генә бәян итәрбез.

Тыныш билгеләренең тиешле урында куелмавына караган ялгышларның бигрәк тә киң таралган төре ул – җөмләнең ае-

рымланган хәл дигән кисәкләрен өтерләр белән аерып күрсәтә белмәү. Мондый хаталар үзләре ике төрле: җөенке хәл кисәкләрен яки бөтенләй аермыйлар яки өтерне күбесенчә бер яктан – соңгы сүзеннән соң гына куялар. Бу хәл исә, бердән, сөйләмнең интонациясен дөрес куярга комачаулый, икенчедән, мәгънәне, эчтәлекне дөрес аңларга мөмкинлек бирми. Мисалларга игътибар итик.

*...бәрәңге уңышы гектарыннан 200 ц чиген узып, уртача 235 центнер тәшкил итә.* Бу җөмләдә *гектарыннан 200 ц чиген узып* дигән җәенке хәл аерымлана һәм, димәк, *уңышы* сүзеннән соң өтер куелырга тиеш, әмма ул куелмаган.

*Буа суы җибәрелгәч, бик саеккан* (буа суы сүзеннән соң өтер куелырга тиеш).

*Бәрәңгеләрне мөмкин кадәр җентекле итеп аралап, чирле яки черегәннәреннән арындыру мөһим.* Мода *мөмкин кадәр җентекле итеп аралап* дигән җәенке хәлнең беренче сүзе (*мөмкин*) алдыннан өтер куелырга тиеш.

*Булдыра алганча үзе тырмаша* (*алганча* сүзеннән соң өтер куелырга тиеш)

*Черү ихтималын алдан белү өчен кайберәүләр полиэтилен пакетка 10-20 бәрәңге салып, ике атна тота. Өчен* сүзеннән соң өтер куярга кирәк, чөнки *черү ихтималын алдан белү өчен,* җәенке максат хәле буларак, аерымланырга тиеш. Бу җөмләдә дә шундый ук күренеш:

*Балалар яхшы белем алсын өчен әти-әниләр ... ашкынып торырга тиеш* (*өчен* сүзеннән соң өтер кирәк).

*Әтнә районы мәктәпләре бүген белем биреп кенә калмыйча, авыл халкын ... җиләк-җимеш белән дә сөендерә.* Бу җөмләдә *белем биреп кенә калмыйча* – аерымланган хәл һәм, димәк, ике ягыннан да өтер белән аерылырга тиеш. Әмма монда, гадәттәгечә, автор пунктуация кагыйдәсен белми яки аңа игътибар итми: *белем* сүзе алдыннан өтер куймый.

Кушма җөмләнең *Эш шунда, Шунысы әһәмиятле, Шуңа игътибар итик* кебек баш җөмлә кисәкләреннән соң ике нокта куелырга тиеш. Әмма бу кагыйдә дә сирәк авторлар тарафыннан гына үтәлә: гадәттә күп кеше андый җөмлә кисәкләреннән соң өтер яки сызык куя. Мәсәлән: *Эш шунда – Люксембургта фирманың төп офисы урнашкан.... Шунысы мөһим, ул Лондон университетында... лекцияләр укый* (*шунда, мөһим* сүзләреннән соң ике нокта куелырга тиеш). *Исегезгә төшерәбез, 17 июль Татарстанда ял көне буларак*

*игълан ителде* (*төшерәбез* сүзеннән соң шулай ук ике нокта куелырга тиеш). *Чынбарлык шуны күрсәтә – шәхесне формалаштыруда мәктәпкәчә тәрбиянең роле үзгәрде* (*күрсәтә* сүзеннән соң сызык түгел, ике нокта куелырга тиеш).

Тыныш билгеләрен бер дә кирәкмәгән, һич кенә дә тиеш булмаган урыннарда куеп язучылар да аз түгел. Мәсәлән: *Гомер буе эшләп, арымаган. Иртәгә – кандидат өчен тынлык көне* (*иртәгә* сүзеннән соң сызыкның һич кенә дә кирәге юк). *Мөнир Абдуллович, минем кулда – Сезнең.... Журналистлар берлеге әгъзасы булуыгыз турында таныклык; Авыл буенча, күрше салалардан кеше эзләп чакырып йөрим; Газета, чын-чынлап, Татарстанның дәүләтчелеген торгызу трибунасына әверелде; Гөлнур Айзатуллова кызы, бәйгенең иң яшь конкурсанты Назлыгөл белән* (*кызы* сүзеннән соң бернинди дә тыныш билгесе булырга тиеш түгел).

*Яисә, яки* сүзләре янында ялгыш өтер кую очраклары бар: *Хикмәт тормыш хәленең авырлыгында, яисә икътисади вә социаль вәзгыятьнең катлаулы булып калуында гына да түгел (яисә* алдыннан өтер кирәкми); *...эшне ташларга, яки караучы ялларга туры килә (яки* сүзе алдыннан өтер булырга тиеш түгел).

Кайбер җөмләләрдә аныклагычларны дөрес билгели белмиләр. Мәсәлән, бу җөмләдә *Лаеш районында* сүзтезмәсен сызык белән аерымлау дөрес түгел: *Шагыйрьнең туып үскән төбәге – Лаеш районында халыкара конференция уздырылды.* (*Лаеш* сүзе алдыннан сызык кирәкми).

Тезмә кушма җөмләләрнең компонентлары *һәм* теркәгече ярдәмендә бәйләнсә дә, алар арасында өтер куела дигән кагыйдәне белмәүче каләм ияләре дә бар. Мәсәлән: *Путин тарафдарлары – күпчелек һәм алар арта бара* җөмләсендә *күпчелек* сүзеннән соң өтер куелырга тиеш.

Мәгълүмат чараларында тыныш билгеләрен куя белмәү очраклары бик күп, һәм бу күренеш журналистларны әзерли торган уку йортында әлеге әһәмиятле белгечләрне сыйфатлы итеп укытуга игътибар җитми, журналистлар үзләре дә эш дәверендә белемнәрен күтәрү белән шөгыльләнмиләр, ахрысы, дигән фикер туа.

# ЭФИР ТЕЛЕ ТУРЫНДА

Телдән дөрес файдалану, аның сүзләрен, әйтелмә-тәгъбирләрен төгәл мәгънәдә һәм урынлы куллану, туган телнең чыганагы буенча үз сүзләре белән чит телләрдән кергән алынмалар нисбәтен билгели белү, сүзтезмәләр һәм җөмләләрне дөрес төзү һәм сөйләмебездә туган телнең табигыйлыгын саклауга караган башка таләпләр матбугат һәм радио-телевидение телләре өчен, нигездә, бердәй. Һәм телебезне кулланудагы күренешләр, проблемалар гомумән алганда мәгълүмат чараларының барысы өчен дә уртак.

Шуның белән бергә радио һәм телевидение теленә, аның үзенчәлекле табигатьле булуы аркасында, берникадәр өстәмә һәм катлаулырак таләпләр дә куела. Радио һәм телевидение тапшыруларын гамәлгә ашыручылар, сөйләгәндә телнең чын татарча төзелешен (лексик, грамматик һәм стилистик нормаларын) саклап кына калмыйча, сөйләмнең табигый интонациясенә, сүзләрнең, авазларның дөрес әйтелешенә дә ирешергә тиеш. Радио һәм телевидение теленең бурычы – һәръяктан да үрнәк тел булу: бу куәтле мәгълүмат чараларын миллионнарча кешеләр тыңлый һәм карый, димәк, ул, дөрес, камил булса, балаларга, яшьләргә әдәби телне үзләштерергә ярдәм итә, әгәр дә ялгыш, начар булса, аларның телләрен бозуга этәргеч ясый. Хәлбуки, хәзерге татар-рус икетеллелеге шартларында мәгълүм сәбәпләр аркасында рус теленең татар теленә йогынтысы көчәя, һәм гаиләләрдә, мәктәпләрдә балаларга татар телен өйрәтү проблемалары арта барганда, радио һәм телевидение тапшыруларында катнашучыларны саф, матур татар телендә сөйләтү шактый катлаулы гамәлгә әверелә. Сер түгел: бүгенге көндә татарча радио һәм телевидение тапшыруларының теле күп очракта дөрес әдәби сөйләм таләпләренә җавап бирә алмый.

Бүгенге эфир теленең үзенә генә хас тел җитешсезлекләре дә шактый күп.

Беренчедән, радио һәм телевидение тапшыруларында катнашучыларның күбесе татарча авыр сөйли, кирәксезгә, татар теленең үз сүзләре булганда да, рус алынмаларын куллана.

Икенчедән, сөйләүчеләр татар теленең үзенә генә хас авазларны бозып әйтәләр. Мондыйлар арасында иң күп бозып сөйләү **һ** авазына туры килә. Бу авазны әйтә белмәү татар телендә сөйләүчеләр өчен бер яман чиргә, хурлыклы күренешкә әверелә бара. Аны бик күп кешеләр, хәтта радио-телевидение тапшыруларын алып ба-

ручылар һәм дикторларның үзләренең дә күбесе бозып әйтә. Алар телендә **һәм-хәм(хам), шәһәр-шәхәр, һәр-хәр, һәрбер-хәрбер, һөнәр-хөнәр, әһәмиятле-әхәмиятле, мөһим-мөхим, һәрвакыт-хәрвакыт, һава-хава, җиһаз-җихаз, ниһаять-нихаять, һәйкәл-хәйкәл** һәм башка шулай.

Радиодан сөйләүчеләр, бигрәк тә дини вәгазь сөйләүчеләр, арасында кайбер сүзләрдә әдәби тел нормалары буенча әйтелергә тиешле **h** авазын бөтенләй төшереп калдыручылар да бар. Мәсәлән, **аллаһы тәгалә** дип әйтәсе урында **алла тәәлә**, диләр.

Кайберәүләр татар теленең язуда **э** хәрефе белән белдерелә торган авазын бозып әйтәләр. Мәсәлән, **тәэмин** сүзен **тәймин**, диләр.

Рус мәктәбендә укып, үз телләрен начар белгән милләттәшләр татар теленең үзенчәлекле авазлары калын **к, г** авазларын, русчадагы кебек, нечкәртеп әйтәләр. Бу күренеш күп кенә мишәр татарларына да хас: аларның күбесенең телендә калын **к** һәм **г** авазлары, алар өчен, табигый хәл буларак, нечкәртелеп әйтелә, һәм кайберәүләр аларны гомере буена татар әдәби телендәгечә итеп әйтергә өйрәнмиләр һәм өйрәнергә бик теләмиләр дә булса кирәк.

Безнең татарларда, кайсы төбәктә яшәүләренә карап, кайбер сүзләрдә әдәби тел кагыйдәсе буенча әйтелергә тиешле **е(йэ-йы)** авазын **җ** белән алмаштырып, шул ук вакытта кайбер сүзләрдәге әдәби норма булып саналган **җ** авазы урынына **е(йэ-йы)** кулланылу күренеше бар. Мәсәлән, **егерме, егет, ефәк, елау, егылу, ел, елан, елга, ерак, ертык** сүзләрен **җегерме, җегет, җефәк, җылау, җыгылу, җыл, җылан, җылга, җырак, җыртык** һәм, киресенчә, **җыр, җылы, җир, җил, җимеш** кебек сүзләрне **йыр, йылы, ийр, йыл иймеш** рәвешендә әйтеп сөйләүчеләр бар. Һәм бу күренеш радио-телевидение тапшыруларында катнашучылар телендә дә чагылыш таба. Мәсәлән, ТНВ каналындагы "Татарлар" тапшыруында бер күренекле режиссер әдәби телдә *е (йэ-йы)* белән кулланыла торган сүзләрне *җ*ләштереп сөйли (мәсәлән, *егет*не *җегет*, дип).

Бер бер үк сүзләрне төрле төбәк татарларында *җ*ләштереп яки *ел*әштереп әйтүнең мондый аңлатмасы бар.

Безнең татар халкы борынгы төп ике бер-берсенә бик якын телле болгар һәм кыпчак кабиләләре кушылмасыннан барлыкка килгән, дип исәпләнә. Һәм менә шушы ике төрки кабилә телләренең кайбер үзенчәлекләре хәзерге төрле урыннарда яшәүче татарларның сөйләмнәрендә чагылыш таба. Төгәлрәк итеп әйткәндә, Казан та-

тарлары дип йөртелә торганнар билгеле бер сүзләрне **җ** авазы белән әйтәләр, мишәр татарлары дип йөртелгәннәр шул ук сүзләрдәге җ урынына **е(йэ)** кулланалар. Һәр ике төркемгә караганнарның барысы да түгел, әлбәттә: әдәби телне яхшы үзләштергән татарларның бөтенесе дә гомумән алганда бертөрле сөйлиләр. Билгеле сәбәпләр аркасында тиешле белем ала алмаганнарның, кайсы җирдә яшәүләренә карап, телләрендәге үзенчәлекләр (аерма) шактый була.

Әдәби тел татарларның барысы өчен дә уртак, димәк, безнең милләтнең төрле урыннарында яшәгән вәкилләре, үзара телләрендәге диалекталь (җирле) үзенчәлекләреннән файдаланып сөйләшсәләр дә, гомуми аудиторияләрдә, әдәби тел буларак, аның кабул ителгән үзенчәлекләрен, кагыйдә-нормаларын саклап сөйләргә һәм сөйләшергә тиеш.

Радио һәм телевидение тапшыруларында катнашучылар арасында кайбер сүзләрнең басымнарын дөрес куймыйча сөйләүчеләр дә очрый. Бу телнең орфоэпик кагыйдәләрен (нормаларын) бозу дип санала. Мәсәлән, “Яшь ТНВ”да күрсәтелгән мультфильмда бер кыз бала “Минем энекәшемне күрмәдеңме?” дип кат-кат соравында *күрмәдеңме* сүзендәге азактан икенче иҗеккә төшәргә тиешле басымны ялгыш сүзнең беренче иҗегенә куеп әйтә. Шул ук “Яшь ТНВ”дагы бер тапшыруда алып баручы кыз, *икенче, бишенче* дигәндә һәм башка шундый тәртип саннарын әйткәндә, сүзнең азагында торырга тиешле басымны беренче иҗегенә куеп сөйли.

Эфир тапшыруларына хас тел кытыршылыкларыннан аларда катнашучыларның, шул исәптән алып баручыларның да, күбесенең кирәксә-кирәкмәсә, җөмлә саен диярлек *инде* сүзен кушып сөйләүләрен искәртү зарур.

Эфир телендә тагын бер еш ишетелә торган нәрсә – кайбер сүзләргә урынсыз -*дагын -дәген* кушымчасын ялгып әйтү: *бездәген, алардагын, балалардагын* һ.б. Бу Казан тирәсендә яшәүче татарларның җирле сөйләменә хас үзенчәлекләрнең берсе.

Бу мәкаләдә радио һәм телевидение тапшыруларында катнашучыларның сөйләмендәге чатаклыкларның барысын да күрсәтү бурычы куелмады. Чынлыкта алар бик күп.

Бу мәсьәләдә шунысы бәхәссез: эфир теле һичшиксез әдәби дөрес, матур, тәэсирле тел булырга тиеш. Бу өлкәдә эшләүче журналистларга каләмнәрен бик нык чарлыйсы, телләрен шомартасы бар әле.

# ТЕЛ СӘЯСӘТЕ
# ЯЗЫКОВАЯ ПОЛИТИКА

## МӘГЪЛҮМАТ ЧАРАЛАРЫНА ИГЪТИБАР КИРӘК

Җәмгыять тормышында мәгълүмат чараларының (матбугат, радио-телевидениенең) роле ифрат зур. Алар кешеләргә илдә, дөньяда булып торган яңалык, үзгәрешләрне, вакыйгаларны хәбәр итәләр, халыкка сәясәт, икътисад, мәдәният, сәнгать, фән, спорт өлкәләреннән һәм башка тармаклардан мөһим мәгълүмат бирәләр, газета-журнал укучыларына, радио-телевидение тыңлаучыларына һәм караучыларына мәгърифәт нуры тарата, аларны тәрбияли һәм ял иттерә. Шуңа күрә, табигый ки, бу гаять әһәмиятле чаралар дәүләтнең, хакимият ияләренең һәрвакыт игътибар үзәгендә булырга һәм аларның кайгыртучанлыгын даими рәвештә тоеп торырга тиеш.

Мәгълүмат чаралары, нәтиҗәле һәм сыйфатлы булса, җәмгыятьнең уңышлы алга баруына ярдәм итә һәм халыкның мәдәниятле, тәрбияле, актив булуына уңай йогынты ясый.

Матбугат, радио-телевидениенең шулай югары бәяләнүе җирлегендә республикабызда татар телендәге мәгълүмат чараларының торышы, аларны тиешле дәрәҗәдә тоту өчен зарури чаралар турында, бу мәсьәләгә караган проблемалар хакында әңгәмә кору мәгъкуль.

Проблемаларның үзәгендә белгеч кадрлар мәсьәләсе тора. Бу мәсьәләдә мәгълүмат чараларының барысы өчен дә уртак кыенлык – югары әзерлекле, киң эрудицияле һәм татарча яхшы белгән хезмәткәрләр кытлыгы. Мондый күренеш берничә нәрсәдә чагыла. Беренчедән, матбугат материалларында да, радио-телевидение тапшыруларында да темаларның тар булуында. Газета-журналларда укучыны шаккатырырлык сенсацион язмалар белән, радио-телевидениедә шулай ук барыннан да бигрәк тыңлаучы һәм караучыга җиңел, мавыктыргыч, кызыклы тапшырулар, шоу күрсәтү белән мавыгу өстенлек ала. Мәгълүмат чараларының бу ике тармагында да халыкның фикерен уятырлык, уйландырырлык, сәяси ак-

тивлыгын күтәрүгә ярдәм итәрлек, җитди эчтәлекле материаллар аз, хәтта бик аз.

Мәгълүмат чараларының төп бурычы исә – укучыны һәм тыңлаучы-караучыны арзанлы, кызык нәрсәләр белән генә тукландыру түгел, бәлки аның зиһенен баетырлык, аны иҗтимагый тормыштагы җитди вакыйгаларны аңларга, аларга анализ ясарга өйрәтерлек материаллар белән дә тәэмин итү. Әлбәттә, кызык, җиңел, күңелне күтәрерлек нәрсәләрдән дә ваз кичәргә кирәкми. Монда бу ике максатның да тиешле балансын булдыру зарур. Һәрхәлдә шуңа омтылу мәгълүмат чараларын иҗат итүчеләрнең төп бурычы булырга тиеш.

Радио-телевидениедә кызык ишеттерү һәм күрсәтү белән мавыгу күренеше соңгы вакытларда аеруча көчәйде. “Татарстан радио”сыннан һәм “Тәртип”тән (аларга бирелгән вакыт бик аз) башка барлык каналларда да диярлек, ничә тыңласаң да, җыр, җитмәсә, музыкасы да арзанлы, зәгыйфь. Җитди темалы, идеяле эчтәлекле тапшырулар сирәк ишетелә. Хәтта дәүләт телевидениесе саналган ТНВ каналында да иҗтимагый-сәяси темаларга, республикадагы, илдәге һәм дөньядагы халыкны дулкынландырган, борчыган, хәлиткеч вакыйгаларга анализ ясап, объектив бәя бирелә торган тапшырулар, политолог, социологлар һәм башка өлкәләргә караган белгечләр белән акыллы әңгәмәләр юк диярлек. Башка каналлар турында әйтерлек тә түгел. Аның каравы концерт, фестивальләр, башка төрле күңел ачу тапшыруларына бер дә кытлык юк, эфир вакытының иң зур өлеше шуларга бирелә.

Радиода сөйли, телевидениедә күрсәтелә торган кешеләрнең, аудиториянең берьяклырак булуын искәртеп китү кирәктер. Эфирда без күбесенчә дәүләт җитәкчеләрен, хакимият ияләрен, сәнгать һәм әдәбият әһелләрен күрәбез. Әмма дөнья алар белән генә чикләнми бит. Башка төрле хезмәт халкын да онытып бетерергә кирәк түгелдер. Игелекле һөнәр ияләре – медицина хезмәткәрләре, укытучы-тәрбиячеләр, галимнәр, шәһәрдә дә, авылда да җитештерү өлкәсендә хезмәт итүче күркәм, хөрмәткә лаеклы һәм кызыклы биографияле кешеләр күп. Аларны да, җәмгыятьнең бик кирәкле кешеләре буларак, матур, калку итеп күрсәтү кирәк. Моның тәрбияви, идеологик әһәмияте дә бар. Ни өчен хәзер җитештерү, фән, мәгариф өлкәләрендә эшләргә теләүче яшьләр кими, җырлап-биеп көн күрергә омтылучылар арта бара. Экранда күбрәк сәхнә күрсәтү белән мавыгуның йогынтысы юкмы икән монда?

Мәгълүмат чараларының тематикасы, эчтәлеге мәсьәләсендә гомумән саграк эш итәргә һәм объективрак булырга кирәктер. Бу мәсьәләдә Мәскәүгә охшарга тырышу үзен акламас. Мәгълүм ки, үзәк матбугатта һәм радио-телевидениедә безнең хәрби коралны, казанышларны артык күп рекламалау, яшьләрне һәм балаларны тулаем хәрби-патриотик рухта тәрбияләргә, көнбатыш илләрен һәм Американы тискәре яктан гына күрсәтергә омтылу белән мавыгу ахыргы исәптә файдага китерерме икән? Безнең республика мәгълүмат чараларына һәрвакытта да Мәскәүгә ияреп бару кирәкмәстер, кайсыдыр гамәлләр кылганда, үз башыбыз белән уйлап, мөстәкыйльрәк эш итү зарурдыр.

Мәгълүмат чараларындагы шулай ук кадрлар белән бәйләнешле бик җитди проблемаларның берсе татарча матбугат материалларының һәм радио-телевидение тапшыруларының теле мәсьәләсенә карый. Татарча газета-журналларның һәм эфир тапшыруларының теле күп очракта югары таләпләргә җавап бирерлек түгел. Каләм һәм сүз ияләре телебезне нык бозып кулланалар, һәм бу күренеш елдан-ел, көннән-көн кискенләшә генә бара. Туган телебез мәгълүмат чараларында һәм кайбер башка материалларда да, шулай ук шактый дәрәҗәдә телдән һәм язма сөйләмебездә дә ниндидер бер игелексез, кадерсез хәлгә төшә бара.

Телебезне саклау, куллану, өйрәнү-өйрәтү – бүгенге көндә иң актуаль мәсьәләләрнең берсе. Ул кичектермичә дәүләт күләмендә хәл ителүне көтә. Бу мәсьәләдә ваемсызланып, тынычланып йөрү зур югалтуларга китерергә һәм милләтебезнең яшәешенә, алга баруына җитди зыян салырга мөмкин. Бу үзе бер махсус сөйләшү темасы. Без башлаган сүзебезне – мәгълүмат чараларының теле мәсьәләсенә әйләнеп кайтыйк.

Телевидение тапшыруларында дөрес, саф татар телендә сөйләүчеләр аз. Тапшыруда чакырылган катнашучыларның сөйләме турында әйткән дә юк инде, хәтта телевидениенең үзендә даими эшләүче хезмәткәрләрнең дә телендә тупас хаталар күп. Газеталардагы язмаларда да телебезне тупас бозып куллану күренешләре зур урын били. Мин бу язмамда ул гаять күп санлы тел ялгышларын тасвирлап тормыйм. Минем дистәләрчә китапларымда, йөзләрчә мәкаләләремдә тәфсилләп язылган. Әмма журналистлар аларны укуны кирәк санамый, телне үзебез дә яхшы беләбез, дип уйлыйлар, күрәсең. Чынлыкта татар телен, җиренә җиткереп, бөтен хасиятләре белән белгән журналистлар бармак

белән генә санарлык. Әмма минем бу мәкаләмнең максаты аларны яманлау түгел. Бу урында русларның бер гыйбрәтле әйтелмәсен тәрҗемәсез генә искә төшерер идем: “Это не столько их вина, сколько наша общая беда”. Мин, мәгълүмат чаралары теленең зәгыйфь хәлдә булуының сәбәпләрен әйтеп, мондый хилафлыктан котылу юлларын күрсәтергә телим.

Күп ялгышлар җибәреп, телне бозып сөйләү һәм язуның төп сәбәбе – аны кулланучыларның үзләренең төп эш коралын, ягъни телләрен җитәрлек дәрәҗәдә белмәве. Ә белмәүләренең сәбәбе аларга мәктәптә һәм югары уку йортларында тел фәнен яхшы өйрәтмәүләре һәм журналистларның аны мөстәкыйль рәвештә үзләштерергә теләкләре булмавы.

Соңгы чирек гасырда өзлексз үзгәртеп корулар аркасында укытуның сыйфаты түбәнәйде. Туган телне укытуга килгәндә, хакимиятнең татар мәктәпләренә игътибары күптәннән үк инде җитми килә. Татар теленә өйрәтүнең торышы белән кызыксыну, бу предметтан укучыларның белемнәре тиешле дәрәҗәдә булсын өчен югары таләпләр кую җитәрлек түгел. Туган телне укытуның методикасы да тиешле булмагандыр, күрәсең: балаларны күбрәк дөрес, матур итеп сөйләргә, сүз байлыгына күбрәк өйрәтәсе урында кагыйдәләр, билгеләмәр ятлату, күнегүләр эшләтү методы өстенлек алып торган (бу хәзер дә шулай түгелме икән дигән шик бар). Нәтиҗәдә укучылар мәктәптән туган телләренең дөрес әйтелеш һәм язылыш нормаларын (тәртибен) тиешенчә үзләштермәгән килеш, фәкыйрь сүзлек запасы белән китеп баралар. Моның нәтиҗәсе хәзерге мәгълүмат чараларының телендә күренә дә инде.

Журналистларның күбесенең татар әдәби телен камил белмәвенең тагын бер сәбәбе шул: аларны Казан федераль университетында Россия мәгариф министрлыгының уку планы буенча әзерлиләр, ә ул планда татар телен укыту күздә тотылмый: Мәскәүгә безнең татар телебез кирәкми. Ләкин университет җитәкчеләре, тырышсалар, җаен табып, уку планына татар телен дә кертә алырлар иде, теләкләре юк, күрәсең. Казан педагогика университеты да, заманында Мәскәүдән җибәрелгән уку планнары буенча эшләде, һәм анда да татарча укыту дигән нәрсә каралмаган иде. Ләкин без, университет җитәкчеләре, татар мәктәпләрен тәмамлап килгән егет һәм кызларны күп белгечлекләр буенча төрле фәннәрне түбән курсларда татарча, ә югары курсларда русча укыттык. Шулай итеп, татар мәктәпләрендә дә, рус мәктәпләрендә дә эшли алырлык педагоглар әзерләдек.

Мәгълүмат чаралары журналистларының татарча телләре проблемалы булуының тагын бер сәбәбе, минем белүемчә, аларның язмаларының һәм тапшыруларының сыйфаты белән кызыксынып, аңа югары таләпләр куеп һәм кирәк чакта ярдәм итеп торучы оешма булмауда. Бу вазыйфаларны башкарырга тиешле орган Татмедианың җитәкчеләре үзләренә мондый җаваплылык алып мәшәкатьләнмиләр булса кирәк. Гомумән, матбугат һәм радио-телевидение хезмәткәрләренең проблемаларын күреп, аларны хәл итәргә теләгән җаваплы кешеләр күренми. Баксаң, журналистларның проблемалары шактый күп. Мин үзем белгәннәремнең кайберләрен генә искәртеп китәм.

Беренчедән, безнең журналистларның хезмәт хаклары бик түбән.

Икенчедән, яхшы авторлар җәлеп итү өчен, гонорар фонды юк дәрәҗәсендә: кайбер газеталарда бик аз гына, сирәк-мирәк кенә түлиләр, кайберләрендә бөтенләй юк. Командировкаларга йөрү өчен дә финанс такы-токы гына дип беләм. Түләүсез яки бик аз акча тотып кына югары сыйфатлы мәгълүмат чараларына ирешеп буламы икән.

Татар телендәге газета-журналларга үги бала итеп карау төрле мәсьәләләрдә күренә. Мәсәлән, биналар мәсьәләсендә. Бауман урамындагы искиткеч әйбәт мәдәният үзәге Матбугат йортыннан барлык газета-журналлар редакцияләрен куып тарату үзе генә дә халыкның рухи азыгы булдыручыларның кадерен белмәүнең гыйбрәтле мисалы. Шул вакытлардан бирле әлегә кадәр кайбер газета-журнал редакцияләрен шәһәрнең бер почмагыннан икенче почмагына, бер бинадан икенче бинага күчереп йөртәләр.

Татарча мәгълүмат чараларын кадрлар белән тәэмин итү һәм журналистларның белемнәрен күтәрү, һөнәри осталыкларын камилләштерү мәсьәләләре белән шөгыльләнүчеләр дә күренми. Казан федераль университетында татар журналистларын бюджет исәбенә әзерләүне, нигездә, туктату, бу белгечлек буенча студентлар кабул итүнең гомумән бетеп баруын ничек аңларга була? Татар журналистикасын юкка чыгару максаты куелганмы икән әллә? Татарстан дәүләтенең тиешле җитәкчеләре бу хакта нәрсә уйлыйлар икән, гомумән уйлыйлармы икән?

Соңгы берничә дистә елда Татарстан журналистлар союзының мәгълүмат чаралары хезмәткәрләренең эше белән кызыксыну, аларның иҗат осталыкларын күтәрүгә юнәлтелгән гамәлләре күренми.

Республика мәгълүмат чараларында эшләүчеләрнең проблемаларына багышланган җыелыш, утырышлар, матбугат һәм эфир журналистларының иҗат осталыкларын, яңа методларын уртаклашу, тәҗрибә алышу максатында киңәшмә-семинарлар үткәреләме икән? Бу турыда бер дә хәбәр-хәтер юк.

Моннан 30-40 еллар элек Татарстан журналистлар союзының ниндидер эшләре күренә иде. Мәсәлән, республикадагы һәм хәтта чит өлкәләрдәге татар газеталарының журналистларын җыеп семинарлар уздыруларына үзем шаһит.

Ул елларда безнең журналистлар союзында тәрҗемәчеләр секциясе эшләп килде. Аның җаваплы кешеләре, тәрҗемә итүнең катлаулы эш икәнлеген һәм матбугат телендәге күп ялгышларның дөрес тәрҗемә итә белмәү аркасында килеп чыкканлыгын истә тотып, газета-журнал тәрҗемәчеләренең һөнәри осталыгын камилләштерү мәсьәләләре буенча төрле дәрәҗәдәге сөйләшүләр, киңәшмәләр, конференцияләр уздыралар иде. Тәрҗемә теориясе буенча диссертация яклаган яшь галим буларак, миңа да матбугаттагы тәрҗемәнең торышына багышланган чыгышлар ясарга туры килде. Хәзерге журналистлар союзында мондый эшләр белән мәшәкатьләнеп тормыйлар. Аяныч хәл бу. Хәлбуки, татар журналистлары теоретик һәм методик ярдәмгә мохтаҗ. Мин бу фикерне газета, радио-телевидение хезмәткәрләре белән булган әңгәмәләремә таянып әйтәм. Мине белгән кайбер журналистларның, телефоннан шалтыратып, теге яки бу сүзне, тәгъбирне ничек кулланырга, ничек тәрҗемә итәргә, ничек язарга дип киңәш сораулары да шуны күрсәтә. Язу димәктән, татар теленең орфографиясе һәм пунктуациясе мәсьәләсендә дә төрлелек, башбаштаклык зур, ялгышлар да күп. Димәк, көн тәртибендә журналистларның язу һәм сөйләү культурасын күтәрү мәсьәләсе дә тора.

Шуны да искәртеп кую кирәктер: кайбер хосусый газеталарны, мәсәлән “Юлдаш”, “Мәхәббәт...”, “Гаилә” газеталарын чыгаручылар анархия методы белән эшлиләр. Аларның язмаларын укыгач, нинди телдә язалар соң болар, дип уйлап торасың. “Ералаш”, башваткыч. Татар теле гыйлеменең нормага салынган кагыйдәләрен, тәртибен санга сугу дигән нәрсә юк ул газеталарда. Нинди кылану, нинди мөгез чыгарулардыр бу – берничек тә аңларлык түгел. Матбугат теле дөрес әдәби тел, үрнәк тел булырга тиеш дигән хакыйкатьне танырга теләмиләр бу ультра новатор матбугат әһелләре. Бәлки, югарыдан берәр зур җитәкченең саллы сүзен көтәләрдер алар.

Татар матбугатына караган тагын бер ифрат мөһим проблема ул – татарча газеталарны яздырып алдыру, сатып алу һәм шуңа бәйле тираж саны мәсьәләсе.

Татар телендәге газеталарны укучылар саны соңгы елларда шул дәрәҗәдә кимеде һәм туктаусыз кими: бу процесска ничектер бер чик куелмаса, милли рухыбызны – телебезне, мәдәниятебезне саклау мөмкинлекләре тагын да зуррак тизлек белән югала барачак. Бу мәсьәләдә уңай якка борылыш аны дәүләт күләмендә һәм иң җитди дәрәҗәдә хәл иткәндә генә ясалырга мөмкин.

Милли матбугатны савыктыру мәсьәләсе ул – глобаль милли проблемаларның аерылгысыз бер кисәге. Соңгы елларда бөтен Россиядә милләтләрнең саклануы һәм алга барышындагы хәлләрнең кискенләшүе, кыенлыкларның арта баруы милли мәгарифтә дә, милли матбугатта да ачык чагылыш таба. Мәктәпләрдә татарча укучыларның һәм, димәк, татар әдәби телен белгән кешеләрнең саны кимүгә параллель рәвештә татар матбугаты белән кызыксынучыларның сафлары да сирәгәя бара. Шуның өстенә, башка бөтен нәрсәләрнеке кебек, газета-журналларның бәяләре арта, ә хезмәт хакы күтәрелми, кайбер урыннарда хәтта түбәнәя дә. Җитмәсә әле, почтаның эшләвендә еш кына өзеклекләр булу аркасында, газета-журналларны алдыру кыенлыклары килеп чыгып тора.

Кыскасы, дәүләт, бу мәсьәләләрне ачыклап, татар матбугатын тернәкләндерүнең комплекслы чараларын күрмәсә, тора-бара туган телебездәге газета-журналларны чыгаручылар да, укучылар да калмаска мөмкин.

Тиешле дәүләт органнары татар телендәге радио-телевидение эше белән даими рәвештә кызыксынып торсыннар, тапшыруларның темаларына, сыйфатына игътибарны арттырсыннар иде. Бу мөһим максатка ирешүнең төп шартлары – лаеклы журналистика кадрлары әзерләү, аларга матди һәм рухи ярдәм итү, эшләренең югары сыйфатлы булуына ирешү өчен, таләпләрне арттыру, җаваплылыкны көчәйтү.

Журналистларның вазыйфалары – катлаулы, җаваплы һәм мактаулы, халыкка бик кирәкле. Безнең журналистларның зур белемлеләре, сәләтлеләре, матур, мәгънәле радио-телевидение тапшырулары әзерләүчеләре дә, халыкның күңеленә хуш килерлек газета-журнал материаллары иҗат итүчеләре дә бар. Әмма хәл итәсе проблемалар да аз түгел. Алар бу мәкаләдә күрсәтелгәннәрдән

күбрәк. Ләкин алма пешәр, авызыма төшәр дип көтеп утыра торган вакыт түгел. Җитезрәк, кыюрак эш итсәк, вакыт безнең файдага узачак, киресенчә, тынычланып, ваемсызланып йөрсәк, рухи тормышыбызны баетырлык, алга җибәрерлек хәлиткеч нәрсәләр кулдан ычкынырга мөмкин. Бу искәртү һәм теләк дәүләтнең җаваплы кешеләренә дә, хөрмәтле һөнәр ияләре журналистларга да һәм халкыбыз язмышына битараф булмаган, милләтебезнең алга баруын кайгырткан һәркемгә карый.

## ЧЕМ ГРОЗИТ “ПУСКАНИЕ НА САМОТЕК” ТАТАРСКИХ СМИ

В жизни общества  исключительно большую роль играют средства массовой информации в жизни общества. Они несут людям сообщения о новостях, важнейших событиях в стране и мире, информацию о достижениях в экономике, культуре, науке, спорте и других областях, содействуют в обогащении читателей газет и журналов, слушателей и зрителей радио-телевидения знаниями, в воспитании и проведении их культурного досуга. И поэтому, естественно, состояние этих ценных средств должно быть всегда в центре внимания государства, соответствующих органов власти, испытывая их постоянную заботу.

Несомненно, если средства массовой информации функционируют успешно и действенно, то они способствуют развитию общества, благотворно влияют на прогресс в культуре, духовное обогащение народа.

В свете такой  высокой оценки роли печати и радио-телевидения целесообразно вести  разговор о положении татароязычных средств информации в республике, о мерах, необходимых для поддержания их высокого уровня, а также о проблемах, имеющихся в этой сфере деятельности.

В центре этих проблем находится вопрос о кадровых специалистах. В этом вопросе общая для всех средств массовой информации сложность – дефицит работников с хорошей подготовкой, широкой эрудицией и достаточным уровнем знаний  языка. Недостаток в таких кадрах проявляется во многом. Во-первых, в узости тематики как материалов печати, так и радио-телевизионных передач. Газетам и журналам свойственна увлечение сенсационными

публикациями, на радио и телевидении превалируют передачи, первостепенной целью которых является привлечение внимания слушателя и зрителя информациями прежде всего увлекательного, шокирующего характера. Обеим этим ветвям средств массовой информации свойственна малочисленность материалов, направленных на развитие мыслительных способностей читателя, слушателей и зрителей, их политической пассивности, характерен недостаток информации серьезного, глубокого содержания.

Основная задача же средств массовой информации заключается в том, чтобы обеспечивать читателя, слушателя и зрителя не только интересными и дешевыми, но и материалами, позволяющими обогатить их умственно, развить способность осмыслить серьезные события в общественной жизни, научить анализировать их. Разумеется, это не значит, что следует совсем отказываться от интересного, приятного, призванного поднимать и поддерживать хорошее настроение. Здесь важно обеспечивать баланс между этими двумя целями. Во всяком случае, стремление к созданию такого баланса должно составлять главную задачу работников средств массовой информации.

Увлечение передачами на радио и телевидении легковесного содержания в последнее время приобретает все более широкий размах. По всем каналам радио, кроме "Татарстан" и "Тәртип" ("Порядок)" (им отводится очень небольшое время), постоянно звучат песни в основном с несовершенной музыкой на несерьезные стихи. Передач же на актуальные, деловые темы, с идейным содержанием редко можно услышать. Даже на государственном телевидении ТНВ почти нет передач, выступлений и бесед политологов, социологов и специалистов по другим областям, в которых анализировались бы волнующие народ события в республике, стране и в мире. Зато в передачах с концертами, фестивалями и другими увеселительными мероприятиями недостатка нет. Самая большая часть эфирного времени отводится на них.

Следует отметить односторонний, однобокий характер участников радио и телевизионных передач. По эфиру выступают обычно государственные чиновники, представители власти, деятели литературы и искусства. Почему нет представителей других категорий общества? Очень мало появляются на экранах телевизоров и выступают по радио достойные уважения простые труженики – работники промышленности и сельского хозяйства, люди самых

гуманных профессий – врачи, учителя. Ведь так много у нас граждан с богатой и интересной биографией. И их надо показывать выпукло, красиво. В этом имеется большой прок – воспитательное, идеологическое значение. Почему молодежи все меньше и меньше в сферах производства, науки и образования? Желающих же связать свою судьбу со сценой становится все больше и больше. Нет ли в этом непосредственной связи с тенденциями интенсивно демонстрировать на телеэкранах бесконечные концертно-фестивальные шоу.

Относительно тематики и содержания средств массовой информации следовало бы быть поразборчивее и объективнее. В данном вопросе не надо всегда действовать по лекалам центра. Как известно, центральная печать и российское радио и телевидение в последнее время, кажется, слишком усердствует в рекламе достижений наших вооруженных сил и вооружения, в воспитании детей и молодежи в военно-патриотическом духе, а также в пропаганде Запада и США лишь в отрицательном плане. На пользу ли такое увлечение? Нашим республиканским средствам массовой информации не надо, наверное, во всем подражать Москве, а следует некоторые вопросы, придерживаясь своей позиции, решать самостоятельно, с учетом региональных и национальных особенностей.

Одна из проблем в средствах массовой информации, обусловленных обеспечением специалистами кадров, касается вопросов языка татарской печати и татарских радио и телевизионных передач. Не секрет, что язык татарских газет и журналов, а также эфирных передач далеко не всегда соответствует высоким требованиям. Мастера пера и слова нередко серьезно искажают родной язык, допускают грубые нарушения норм литературного языка. При этом такое явление из года в год усиливается. Таким образом, татарский язык в средствах массовой информации, а также и в некоторых других материалах становится чем-то лишенным ценности, своего рода изгоем.

Сохранение родного языка, употребление и обучение его в настоящее время являются одной их самых актуальных задач. Она требует своего неотложного решения в государственном масштабе, Равнодушие, успокоение в данном вопросе могут нанести непоправимый урон выживанию и развитию нашей нации. Впрочем, это большая тема для особого разговора. Однако, мы вернемся к начатому разговору о языке средств массовой информации. Гово-

рящих на правильном татарском языке в телевизионных передачах немного. Среди приглашенных участников тем более. Особенно удивляет то, что даже постоянные, штатные работники телевидения допускают немало искажений татарской речи.

Много грубых нарушений норм родного языка имеется в языке печати. Мы сознательно не станем останавливаться на подробном описании многочисленных языковых ошибок в татарской печати. Об этом подробно сказано в многочисленных книгах и статьях автора этих строк. Но журналисты, кажется, недосуживаются ознакомиться с этими работами, видимо, считая, что они и без того владеют языком в достаточной степени. Но практика начисто отвергает эту версию. По сути журналистов, знающих татарский язык в совершенстве, немного. Однако, цель данной заметки не осуждение их. В этой связи уместно вспомнить известный афоризм: "Это не столько их вина, сколько наша общая беда". Мы ставим целью, называя причины такого досадного положения с языком, указать пути выхода из этой ситуации.

Основная причина многих ошибок в письменном и устном языке средств массовой информации не в совершенном владении журналистами своим главным орудием производства – языком. Корень зла – в некачественном обучении их в школах и высших учебных заведениях татарскому языку, а также в отсутствии практики дальнейшего самостоятельного изучения его.

В последнюю четверть века в результате многочисленных реорганизаций в системе образования уровень обучения упал. Что касается преподавания родного языка, внимания властей к татарским школам недоставало всегда. Не было и нет заинтересованного отношения, высоких требований органов образования к качеству обучения татарскому языку. Преподавание этого предмета осуществлялось не по правильной методике – методике заучивания правил, выполнения упражнений и так далее. Обучению же их свободному правильному общению на этом языке, усвоению его лексического богатства не придавалось должного внимания. В результате учащиеся, проучившись одиннадцать лет, покидали школы, так и не овладевая татарским языком в совершенстве. Плоды такого неадекватного отношения к обучению родному языку пожинаем сейчас и в средствах массовой информации.

Другая причина несовершенного владения большинством журналистом татарским языком заключается в том, что их гото-

вят в Казанском федеральном университете по учебным планам Министерства образования России, в которых преподавание татарского языка не предусмотрено: Москве он не нужен. Однако, если руководство университета посчитало бы необходимым, то сумело бы найти возможность ввести в учебные планы данный предмет. Видимо, у них нет такого желания. К примеру, Казанский педагогический университет в свое время также работал по московским планам, и там не предполагались ни преподавание татарского языка, ни обучение на этом языке. Тем не менее, мы, руководители университета, находили возможность студентов, окончивших татарские школы, обучать на младших курсах на родном языке, а на старших курсах – на русском языке. Таким образом, нам удавалось готовить педагогические кадры, способные работать и в татарских, и в русских школах.

Еще одна причина проблемы журналистов в знаниях по татарскому языку, как нам кажется, в отсутствии официального органа, который бы интересовался качеством их продукции и ставил бы перед ними высокие требования в этом отношении. Похоже, что Агентство Татмедиа – орган, ответственный за деятельность средств массовой коммуникации, не считает обязательным заниматься этим. В целом же, кажется, что журналисты со своими проблемами остаются одни. Между тем, их у них немало. О некоторых из них, известных нам, мы и поговорим.

Во-первых, заработная плата наших журналистов очень низкая.

Во-вторых, не позволяет привлечь хороших авторов гонорарный фонд, который настолько мал, что во многих газетах его нет совсем, а в нескольких – в мизерных размерах. Ездить по командировкам весьма проблематично из-за отсутствия финансов. Имея небольшие средства или совсем не имея их, невозможно выдавать хорошую продукцию, то есть качественный журналистский материал.

Не признание высокой ценности, высокого назначения средств массовой информации, равнодушное отношение к их положению наблюдаются во многом. Безразличие к этим важнейшим средствам идеологической работы началось с разгона всех редакций газет и журналов из замечательного медийно-культурного центра – Дома печати по улице Баумана, после чего редакции вынуждены ютиться в разных уголках большого города без необходимого комфорта.

Никому нет дела и до деятельности, связанной с обеспечением средств массовой информации на татарском языке квалифицированными кадрами, повышением знаний и творческого мастерства журналистов. Не поддается воображению, как можно было прекратить прием студентов на отделение татарской журналистики на бюджетной основе. Видимо, поставлена цель поставить точку на функционировании татарской журналистики. Что думают по этому поводу руководители Татарстана? Думают ли?!

В последние десятилетия не замечается заинтересованного отношения и Союза журналистов Татарстана к деятельности печатных органов, не наблюдается их действий, направленных на повышение эффективности работы редакций газет и журналов на татарском языке. Нет признаков того, чтобы проводились собрания, заседания, посвященные проблемам работников средств массовой информации, а также научно-практические конференции, совещания-семинары в целях обмена опытом, творческим мастерством, современными методами работы.

30-40 лет тому назад Союзом журналистов Татарстана предпринимались определенные полезные начинания. Так, мне довелось участвовать в работе семинара журналистов газет, выходящих в республике и других регионах России.

В те же годы при нашем Союзе журналистов функционировала секция переводчиков. Ответственные лица этой секции, осознавая сложность переводческой деятельности, и учитывая, что многие нарушения в языке печати происходят вследствие неумения правильно переводить, в целях совершенствования умений и навыков переводческой деятельности журналистов проводили круглые столы, совещания, конференции. Как молодому ученому, защитившему диссертацию по теории перевода, мне приходилось выступать на таких форумах. Сейчас в Союзе журналистов не обременяют себя такими заботами. Между тем татарские журналисты нуждаются в теоретической и методической помощи. В этом мне приходится убеждаться по телефонным звонкам отдельных работников редакций газет с просьбой проконсультировать их по тем или иным языковым вопросам. На повестке дня остро стоит вопрос о необходимости повышения культуры родной речи журналистов.

Следует в этой связи заметить, что издатели некоторых частных газет, таких как “Юлдаш”, Мәхәббәт”, “Гаилә”, работают, придерживаясь анархических методов. Они так искажают язык, в такой

степени нарушают литературные нормы татарского языка, что порой бывает трудно понять их газеты. Они совершенно не считаются с положением о том, что язык печати должен быть литературно правильным, доступным. Возможно, потребуется, чтобы кто-то из высоких чинов свои грозным окриком привел их в чувство.

Жизненно важная для татароязычной печати проблема – это вопрос об их тираже, связанном с подпиской и приобретением газет.

Количество читателей татарских газет в последние годы сократилось настолько, что, если каким-то образом не суметь прекратить этот процесс, то возможностей для сохранения национальной сущности – языка, культуры будет оставаться все меньше и меньше. Положительные изменения в данном вопросе, вероятно, могут произойти лишь при решении его в государственном масштабе и при серьезной поддержке правительства Татарстана.

Вопрос об оздоровлении национальной печати – составная часть национальных проблем. Обострение в последние годы во всей России ситуации, связанной с сохранением и развитием наций, их языков и культур, четко отражается на положений национального образования и национальной печати. Резкое сокращение количества обучающихся в школах на татарском языке и численности изучающих татарский язык, а также параллельно этому – количества владеющих родным языком неизбежно приводит к уменьшению читателей газет и журналов на татарском языке. К тому же, как во всем другом, увеличивается стоимость печатной продукции, а повышения заработной платы особо не наблюдается. Вдобавок ко всему этому, вследствие перебоев в работе почты, возникают дополнительные сложности с приобретением газет и журналов.

Таким образом, если государство, разобравшись во всех этих перепетиях, не предпримет комплексные меры по оздоровлению и поддержанию татарской печати, то со временем может не стать как создателей газет и журналов на родном языке, так и их читателей.

Пусть соответствующие органы власти постоянно интересуются деятельностью радио и телевидения, печати, усилят внимание тематике и качеству передач, газетно-журнальных материалов. Главное условие обеспечения высокого уровня средств массовой информации – подготовка достойных журналистских кадров, оказание им материальной и духовной поддержки, повышение требовательности и ответственности за результаты их работы.

Журналисты выполняют сложные, ответственные и почетные обязанности. Среди наших журналистов имеются такие, которые будучи высокопрофессиональными, эрудированными, создают интересные и содержательные радио-телевизионные передачи, готовят трогающие души читателей идейно-художественные газетно-журнальные материалы. Но в деятельности журналистов нашей республики немало проблем. Их гораздо больше, чем указывалось в данной заметке. Однако ждать, когда с неба посыпится манка, времени нет. Если действовать смелее, оперативнее, время будет работать в нашу пользу. И, наоборот, если, самоуспокаиваясь, занимать выжидательную позицию, можно упустить то, что призвано служить обогащению и развитию нашей духовной жизни. Эти замечания и пожелания мы адресуем и соответствующим ответственным лицам государственной службы, и людям почтенной профессии – журналистам, а также всем тем, кому не безразлична судьба своего народа, кто заинтересован в прогрессе нации.

## МИЛЛИ МӘГАРИФ ҺӘМ СТРАТЕГИЯ

Хәзерге шартларда Россиядә яшәүче халыкларның, шул исәптән татарларның да, тулы мәгънәсендә милли мәгарифләре була алмый.. Чөнки укыту-тәрбия тәртибен, мәктәп предметларының барысын да диярлек Россия мәгариф министрлыгы билгели, дәреслекләр дә шушы ведомство күзәтүендә, аның рөхсәте белән генә чыгарыла. Чын-чынлап милли мәгариф мөстәкыйль дәүләтле халыкларда гына булырга мөмкин.

Хәер, демократик принципларга корылган дәүләтләрдә яшәүче халыкларның мәгарифләрендәге милләт үзенчәлекләр шактый күп булырга мөмкин. Әмма хәзерге Россия дәүләтендә демократия элементлары бик аз булганлыктан, монда яшәүче халыкларның мәгариф системаларында милли үзенчәлекләр бик кечкенә генә урын алып тора. Бу күренеш безнең татар мәгарифенә дә хас.

Шулай да гомумән алганда телләре, мәдәниятләре, гореф-гадәтләре төрле халыкларның уку-укыту, тәрбия кылу системалары бер үк төрле була алмый. Аларның һәркайсының күпмедер дәрәҗәдә үзләренә генә хас үзенчәлекләре, аермалы яклары була. Шунлыктан без, шартлы рәвештә генә булса да, милли мәгариф турында сөйли алабыз.

Цивилизацияле халыклар тормышында, аерым алганда татар халкының яшәешендә, мәгарифнең гаять зур әһәмияткә ия булуын һәм татарларның алга баруы стратегиясендә аның иң зур урын алып торырга тиешлеген исәпкә алып, без милли мәгарифебезнең нинди булырга тиешлеге хакында кайбер фикерләребезне белдереп китәргә булдык.

Мәгълүм булганча, мәгариф ул – уку-укыту, аң-белем бирү мәгънәсендәге сүз. Укыту исә бездә гадәттә тәрбия бирүне дә күздә тота. Димәк, алга барыш, прогресс мәгарифкә нигезләнгән. Татарлар гомер-гомергә үзләренең укымышлы, белемле, ягъни мәгърифәтле халык булулары белән аерылып торганнар. Идел буе болгарлары дәүләте чорында ук инде безнең борынгы бабаларыбыз арасында дөнья күләмендәге гыйлем ияләре, мәдәният әһелләре булган. Татарлар, мөстәкыйль дәүләтләреннән мәхрүм калып, патша изүендә яшәгән дәверләрдә дә югары аң-белем ияләре булуларыннан туктамаганнар. Хәзерге заманда да безнең бөтен дөньяда дан-шөһрәт казанган акыл ияләребез, күркәм шәхесләребез күп. Шулай булгач, гасырлар буена татар халкын алга илткән, төрле өлкәләрдә зур уңышларга алып барган мәгърифәт учагының ялкынын сүлпәндерергә яки сүндерергә хакыбыз бармы безнең? Һич кенә дә юк, әлбәттә. Киресенчә, бу ялкынны ныграк дөрләтеп, элекке уңышларыбызны тагын да арттыру, халкыбызны тагын да биегрәк үрләр яулап алырлык зур белемле итү – барыбызны да, беренче чиратта мәгариф органнары хезмәткәрләренең, укытучыларның изге бурычы.

Шушы көннәрдә фикер алышу объектына әверелгән татар халкының алгарышы (прогрессы) стратегиясендә иң беренче урында торырга тиешле милли мәгарифнең перспективасы шундый югары таләпләр җирлегендә билгеләнер дип ышанасы килә.

Татар милли мәгарифенең алдагы еллардагы изге бурычы – халкыбызның данын күтәрерлек, димәк, белемнәре буенча яхшы әзерлекле, югары культуралы, тәрбияле яшьләр әзерләү. Бу ифрат җаваплы, катлаулы бурычны Татарстан мәктәпләрен әйбәт материаль база һәм нык белемле укытучы-педагоглар белән тәэмин итеп, аларның заман таләпләренә җавап бирерлек дәрәҗәдә нәтиҗәле эшләүләренә ирешкәндә генә уңышлы гамәлгә ашырырга мөмкин. Бу шартларның үтәлүе Татарстан мәгариф органнарының җитәкчеләре һәм хезмәткәрләренең, укытучыларның халкыбызны, республикабызны алга җибәрү өчен зур җаваплылык хисе тоеп, фидакарьләрчә хезмәт итүен таләп итә.

Милли мәгариф төшенчәсенең үзәгендә милли телдә, димәк, безнеңчә, белем бирүне татар теле нигезендә оештыру тора. Бу исә, татарча укырга теләгән балаларга җитәрлек санда бик яхшы татар мәктәпләре булдырып, аларда төп фәннәрне татарча укытып, тәрбия һәм оештыру эшләрен шулай ук татар телендә башкарып, уку программасындагы барлык предметларны да нык үзләштерү белән бергә, туган телләрен дә, татар әдәбиятын, татарлар тарихын яхшы өйрәнгән татар яшьләрен әзерләүне күздә тота. Татар мәгарифен үзләштергәндә туган телдә уку һәм аны яхшы итеп өйрәнү бурычы шуның белән аңлатыла: тел ул аралашу чарасы гына түгел, анда аның иясе булган халыкның асылы, эчке дөньясы, табигате, культурасы һәм философиясе чагылыш таба.

Безнең милли мәгариф төшенчәсенә татар халкының үзенә генә хас матур традицияләре, күркәм гореф-гадәтләре, матур сыйфатлары, игелекле әхлак кагыйдәләре (нормалары) керә. Димәк, Татарстанның мәгариф министрлыгына, татар балалары милли мәгарифебезнең бу кыйммәтле компонентларын да үзләштерсен өчен, уку планнарына болар белән бәйләнешле предметларны кертү чараларын да табарга туры киләчәк.

Татарларның милли мәгарифен алга җибәрүнең нигезе татар мәктәпләрендәге укыту-тәрбия бирү системасына салынган булганлыктан, Стратегиядә билгеләнгән татар мәгарифен үстерү бурычын уңышлы гамәлгә ашыру мәктәпләрнең эше югары дәрәҗәдә нәтиҗәле оештырылган һәм башкарылган очракта гына мөмкин булачак.

Мәктәпнең югары дәрәҗәдә сыйфатлы, заманча эшләве мәгариф җитәкчеләренә дә, укытучы-тәрбиячеләргә дә катлаулы һәм җаваплы бурычлар йөкли. Боларның кайберләрен генә булса да искәртеп китү зыянлы булмас.

Беренчедән, гамәлдәге уку планнарын һәм программаларын тәнкыйтьчә күздән үткәреп, җентекләп тикшереп чыгарга һәм аларга милли мәгарифне үстерү бурычлары таләп иткән яңа предметлар һәм материал-мәгълүматларны кертергә кирәк. Бу бурычны уңышлы үтәү безнең җитәкчеләргә аерым очракларда Россия мәгариф министрлыгының күрсәтмәләрендәге кайбер мәсьәләләргә принципиаль караштa торып, милли мәгариф ихтыяҗлары таләп иткән үзгәрешләр кертергә дә туры килергә мөмкин. Чөнки, мәгълүм ки, Мәскәү тәкъдим иткән документлар милли мәгариф мәнфәгатьләрен һәрвакытта да исәпкә алып бетермиләр.

Икенчедән, татар теле, әдәбияты, татар халкы тарихы һәм милли мәдәнияткә караган башка предметлар дәреслекләрен яңарту, стратегия таләп иткән материаллар өстәү эше белән дә шөгыльләнү зарур.

Өченчедән, алда торган катлаулы бурычларны исәпкә алып, укыту-тәрбия методикаларын, эш алымнарын камилләштерергә кирәк булачак. Бигрәк тә соңгы елларда милли телләрне өйрәтү мәсьәләсендә үзәктән килгән директиваларның туган телләрне укытуда зур кыенлыклар китереп чыгаруы шартларында, балаларга татар телен уңышлы өйрәтү өчен, укытуның тагын да нәтиҗәлерәк алымнарын кулланырга туры киләчәк.

Кыскасы, татар халкының үсеш стратегиясендә хәлиткеч рольне үтәргә тиешле милли мәгариф программасын булдырып, тормышка ашыру тиешле җаваплы кешеләрдән фидакарь эш таләп итәчәк. Стратегияне төзү белән иң тәҗрибәле, зур әзерлекле белгечләр шөгыльләнергә тиеш. Бу стратегияне 2050 елга үтәлергә тиешле шулкадәр озак вакытка исәп тотып төзү үзен акламас кебек. Ул дәвердә аны гамәлгә ашыру өчен җаваплы кешеләр калырмы икән инде. Аны тормышка ашыруга бу кадәр күп вакыт кую аның әкренләп онытылуына исәп тота дип уйларга була. Стратегия дип аталган хәлиткеч олы документны җәмәгать оешмасы түгел, республика хөкүмәте кабул итәргә һәм аның үтәлүе өчен җавап бирергә тиеш. Югыйсә ул халыкны өметләндереп, ымсындырып кына калдырган кәгазь генә булып чыгарга мөмкин.

## ЫМСЫНДЫРУ ГЫНА БУЛМАСЫН ИДЕ

Соңгы вакытларда матбугатта һәм Татар конгрессы үткәргән зона конференцияләрендә татар халкының алгарышы (үсеше) стратегиясе хакында фикер алышулар бара. Республикабыз Президенты тәкъдим иткән мондый документ булдыру игътибарга лаеклы һәм, һичшиксез, бик әһәмиятле. Мин, татар милләтенең бер вәкиле буларак, бу җанга якын һәм бик мавыктыргыч мәсьәләгә карата битараф булып кала алмадым, Стратегия турында Татар конгрессының сайтында урнаштырылган “Кем мин – татар булмагач” дигән исемдәге өзек-өзек мәгълүмат (эскизлар) белән танышып, шушы уңайдан кайбер фикерләремне газета укучылар белән уртаклашырга булдым.

“Стратегия” күчерелмә мәгънәдә иҗтимагый, сәяси максатларга ирешүдәге бик әһәмиятле, хәлиткеч нәрсәне белдерә. Димәк, татар халкының алга баруы перспективаларын билгели торган документ җәмәгать оешмасы тарафыннан түгел, республиканың хөкүмәте тарафыннан төзелеп, халык тикшерүенә чыгарылырга тиеш, чөнки соңыннан, ул кабул ителгәч, аның гамәлгә ашырылуы өчен дәүләт органы гына җаваплы була ала.

Бу үзара бик үк бәйләнеп җитмәгән кыска-кыска гына өзекләрдән Стратегиянең тулы килеш нинди булачагын күзаллау кыен.

Җәмәгатьчелек игътибарына тиешле тармакларның бик зур белемле, бай тәҗрибәле белгечләре эшләгән проектын тәкъдим итү максатка ярашлырак булыр иде. Шулай да сайттагы эскизлар буенча гына булса да, бу документка карашыбызны белдереп, татар милләте алгарышының беренче дәрәҗәдә әһәмиятле бурычлары турындагы фикерләребезне кыскача гына бәян итәргә кирәктер дип таптык.

Соңгы елларда татарларның туган телләренең яшәешенә җитди куркыныч тудырган проблемалар чыгып торганлыгын исәпкә алып, татар халкының алга баруы бурычлары бу хәлдә төп проблемага – татар телен саклау һәм үстерү проблемасына нигезләнгән булыр дип фараз итәргә кирәк. Шул ук вакытта “Стратегия”дә Татарстан дәүләтенең тиз арада хәл ителергә тиешле иң мөһим чаралары билгеләнгән булырга тиеш.

Һәркемгә мәгълүм булганча, соңгы чорда татарларның туган телләрен өйрәнү мөмкинлекләре күзгә күренеп кими бара. Үзәк хакимиятнең күрсәтмәләре буенча, берничә елда йөзләрчә татар мәктәпләре һәм класслары бетерелде, сакланып калганнарында исә рус телендә укытуга күчә баралар. Бу хәлгә чик куелмаса, татар халкының туган теле, бигрәк тә әдәби теленең саклануы озакка сузылмастыр. Әдәби тел сакланмый икән, татар халкының алга баруы турында сөйләүнең мәгънәсе дә калмый.

Аңлашыла ки, хәлләр шулай булып торганда, татар милләтенең алгарышы Стратегиясендәге (Програмасындагы) иң беренче дәрәҗәдәге мөһим бурыч итеп, Татарстан хөкүмәтенең республикада бик яхшы татар мәктәпләре булдыруы күздә тотылырга тиеш. Ул мәктәпләрдә укучылар, барлык фәннәрдән дә яхшы белем алудан тыш, рус, татар, инглиз телләрен дә камил үзләштерерләр, туган телләреннән, татарлар һәм Татарстан тарихыннан да ныклы белемгә ия булырлар дип фараз ителә.

Ихтимал, милли мәгарифне үстерү һәм камилләштерү бурычларын гамәлгә ашыру шома гына, каршылыкларсыз гына бармас. Республика җитәкчеләренә татар халкының прогрессына комачаулык итәргә омтылыш ясау күренешләренә дә әзер булып торырга кирәк. Россия халыкларының үзләренең мәдәниятләрен һәм мәгарифләрен үстерүгә хокуклары барлыгы ачык язылган Россия һәм Татарстан законнарына таянып, принципиаль караштә торып эш итәргә туры киләчәк.

"Стратегия"дә татарларның кайберләренең психологиясендә чагылыш тапкан шундый бер күңелсез күренеш турында – аларның татар халкының телләренә, мәдәниятләренә һәм башка миллилек сыйфатларын тәшкил иткән башка нәрсәләргә илтифатсыз, кайчакта хәтта тискәре караштә торулары хакында әйтми мөмкин түгел. Мондый караш шактый күп ата-аналарның балаларын татар телен өйрәтүгә риза булмауларында, мөмкин булганда да татар мәктәпләренә укырга бирергә теләмәүләрендә, күп милләттәшләрнең татарча радио-телевидение тапшыруларын тыңламау һәм карамауларында, татар театрларына йөрмәүләрендә, татар телендәге газета-журналларны, китапларны бик аз укуларында, шәһәрләрдә иҗтимагый урыннарда татарча сөйләшүчеләрнең аз булуында һәм башка шундый нәрсәләрдә күренә. Шулай итеп, татар теле кухня теленә әверелә барамы икән инде дигән шик килә күңелгә.

Борынгы бай әдәбият теле, күп гасырлар буена формалашып килгән, нык үскән, камил тел бит югыйсә безнең тел. Татар теленә, татар мәдәниятенә, телнең иясе булган халыкка яный торган төп куркыныч менә кайда ул! "Стратегия"не төзүчеләр менә шушы хәлнең бөтен хәвефен аңлап эш итәргә, телебезнең, югары культуралы, борынгы бай тарихлы, дәүләтле халыкның сүнә баруына юл куймыйча, киресенчә, аның алга баруына яңа көч, дәрт бирүгә исәп тоткан документ иҗат итәргә тиешләр.

Монда шуны искәртеп китү мөһим. Татарларның бер өлешенең милли хасиятләренә тискәре караштә булуын күпмедер дәрәҗәдә аңларга да була. Ул аларның гына гаебе дә түгел. Бу руслардан башка барлык халыклар өстенә төшкән бәла, патша Россиясенең колониаль сәясәте китергән чир, рус булмаган халыкларның аларны Россия хакимнәре гасырлар буена кимсетеп тотуларыннан барлыкка килгән психологиясе, үзләрен руслар алдында алардан түбән итеп тоярга күнеккән кешеләрнең хисләре чагылышы. Каршыла-

рында һәрвакыт “өлкән агай”лары барлыгын тоеп яшәү гадәте совет чорында да сакланды, ул үзен әле дә сиздерә. “***Россия руслар өчен***”, “***Дәүләтне руслар төзегән***” дигән һәм башка лозунгларның ишетелгәләп торуы – руслардан башка халыкларга карата җиңел уйлап яки уйламыйча үткәрелә торган сәясәтнең чагылышы.

Мондый шартларда Татарстан республикасы җитәкчеләренең әһәмиятле бурычларыннан берсе  татарларда милли горурлык, үзләрен лаеклы кешеләр итеп тою, хөр фикерлелек хисләре тәрбияләүгә юнәлтелгән идеологик эш башкарудан гыйбарәт. Һәм бу бурыч татар халкының алгарышы стратегиясендә ачык күренергә тиеш. Бу документта милли рух булдыру һәм аны үстерү өчен барлык чараларны (мәгариф учреждениеләрен, матбугат, радио-телевидение һ.б.) туплау механизмын сурәтләү зарур.

“Стратегия”дәге татар телен саклауга һәм үстерүгә юнәлтелгән бурычларны бәян иткәндә, татар телен укытуның нәтиҗәлелегенә ирешү юлларын билгеләгәндә, уку йортларында татар теле белеменең югары сыйфаты өчен укытучыларның да, укучыларның да җаваплылыгын күтәрүгә зур ихтыяҗ булуын катгый итеп күрсәтергә кирәк. Бу уңайдан шуны да искәртү мөһим: хәзерге вакытта татарларның телдән һәм язма сөйләмнәрендә туган телнең әдәби нормаларын (кагыйдәләрен) тупас бозу күренешләре күп.

Татар Конгрессының сайтында урнаштырылган “Стратегия” тезислары белән танышканда, шундый бер үкенечле хәл күзгә ташлана: документны төзүчеләрнең әйтергә теләгән төп фикерләрен, еш кына өстән-өстән генә, ашыгып белдерелгәнлектән, аңлап бетерү кыен.

Мәсәлән, “Информация киңлеге” дигән бүлектә “Татар журналистларын әзерләү системасын формалаштыру” диелгән. Бу пунктны берникадәр аңлатып, конкретлаштырып, мәсәлән, Казан федераль университетында татар журналистларын әзерләүдәге төп проблема аларга яхшы итеп татарча өйрәтмәү дип язарга кирәк иде.

“Культура” бүлегендә (ни өчен бу бүлектәдер?) “Татар халкының үзаңын дини институтлар ярдәмендә ныгыту: дини учреждениеләргә бергәләшеп (бабалары, аталары, оныклары) йөрүне традициягә кертергә” диелгән. Бу бик әһәмиятле документта һәр җөмлә, һәр сүз бик уйлап язылган булырга тиеш. Бездә диннең дәүләттән аерылган икәнлеген онытырга ярамый һәм ата-аналарга мәчетләргә балаларын алып барырга кушу (“традициягә кертергә”) законга сыямы икән? Дин әһелләре үзләренең

вәгазьләрендә мәхәллә халкына балаларының туган телләрен уңышлы өйрәнүдә ярдәм итсеннәр, балаларын мәктәптә татар теле дәресләренә йөртсеннәр һәм аларны мөмкин булганда укырга татар мәктәпләренә бирсеннәр дип тәкъдим итсеннәр иде. Мәктәпләрдә балаларга татар телен укытуда проблемалар булуын исәпкә алып, мәчетләрдә балаларга (һәм олыларга да) туган телләрен өйрәтү буенча якшәмбе мәктәпләрен ачу әйбәт булыр иде. Дин әһелләренә мәчетләрдә татар телен өйрәнү курсларын оештырырга тәкъдим итү мәгъкуль. Ата-аналарның күбесе туган телләрен начар беләләр яки бөтенләй белмиләр бит.

Татарстан башкаласы Казанда яшәүче татарлар туган телләрен начар белгәнлектән яки бөтенләй белмәгәнлектән, мәчеткә йөргәндә имамнарның аларга вәгазьләрләрен русча сөйләүләрен күз алдына да китерү кыен. Әмма, кайбер мәчетләрдә хәл нәкъ шундый. Монда уйландырырлык нәрсәләр күп.

“Культура” бүлегендәге “Халык мәдәнияте нигезендә югары культураның заманча формаларын үстерү”, “Татар мәдәниятенең бердәм мәйданнарын оештыру”, “Татар көнкүрешен һәм тормышын дини йолалар белән бәйләү” дигән параграфларның мәгънәләрен аңлап бетереп булмый: төптән уйлап язылмаган алар.

Стратегиянең эскизларындагы “Милли тәрбия системасы: гаилә, балалар бакчасы, белем бирү учреждениеләре” дигән бүлек игътибарны җәлеп итә. Мәгарифнең бу өлкәләренең татарлар алгарышы өчен зур әһәмияткә ия булуын истә тотып, “Стратегия”дә аларны гамәлгә ашыруның конкрет юллары күрсәтелер дигән өмет баглыйбыз.

Хәзерге Россия шартларында, гуманитар өлкәне дәүләт финансы белән тәэмин итү кими барган чорда татар халкының рухи тормышын алга җибәрүдә иганәчәлекнең, меценатлыкның роле арта барачак. Алдагы елларда татарларның тәрбия һәм белем бирү учреждениеләренә хосусый эшмәкәрләрнең инвестицияләре өчен мәйдан киңәер дип фараз ителә. Бу уңайдан татар халкы тормышында мәгариф үсеше тарихын искә төшерү гыйбрәтле: Октябрь революциясенә кадәр татарларның мәгарифе, кагыйдә буларак, үз халкының прогрессын кайгыrткан хәлле кешеләрнең иганәчелеге, меценатлыгы нигезендә үсеш алган, алга барган. Хәзер бу игелекле традицияләрне яңартырга вакыт бик җитте. Бу мәсьәләдә дәүләтнең роле мондый инициативаларны пропагандалаудан, аларга ярдәм итеп торудан гыйбарәт. Татар халкының тормышында меценатлык

гамәлләренә өндәү һәм аларны милли мәгариф өлкәсендә гамәлгә ашыруның юллары “Стратегия”дә чагылыш табарга тиеш.

Стратегиянең эскизларыннан күренгәнчә, татар халкының алгарышы (прогресска баруы) бик озакка – 2050 елга кадәр дип исәпләнә. Безнеңчә, бу бик күп вакыт. Татар халкының рухи тормышы хәзер шундый хәлдә: яхшы вакытлар килүен озак көтеп торуның азагы хәерле булмаска мөмкин. Вакыйгалар шуны күрсәтә: Татарстанның җитәкчеләре яки татарларның рухи тормышын савыктыру һәм алга җибәрү өчен, бигрәк тә аларның туган телләрен саклау, куллану һәм укыту өлкәсендә тиз арада кардиналь чаралар күрәләр, яки татар телен, мәдәниятен һәм цивилизацияле милләт буларак халыкның үзен прогресска илтү мөмкинлеге кулдан ычкыначак.

Республикабызның һәм Татар конгрессының җитәкчеләре, вакыйгалар барышын дөрес аңлап, хәзерге хәлне объектив бәялиләрдер һәм, димәк, тиешле нәтиҗәләр ясарлар дигән ышаныч белдерәсе килә.

## СТРАТЕГИЯ ИЛИ УСПОКОЕНИЕ НАРОДА?

В последнее время в средствах массовой информации, а также на зональных совещаниях, проводимых Конгрессом татар, предметом обсуждений становится вопрос о Стратегии развития татарского народа. Сама идея, выдвинутая Президентом нашей республики, заслуживает внимания и одобрения. Я, как и любой представитель татарской нации, не мог оставаться равнодушным к этому животрепещущему и архи злободневному вопросу. И ознакомился с так называемыми эскизами этой Стратегии на сайте Конгресса татар. С мыслями, возникшими у меня в результате ознакомления с этим документом, решил поделиться с читателями газеты.

“**Стратегия**” в переносном смысле означает “*важный, существенный для достижения главных целей общественной, политической деятельности*” и нам, видимо, под “Стратегией развития татарского народа” следует понимать важнейшие задачи руководства республики, направленные на достижение прогресса татарской нации. Ежели так, то и документ, определяющий перспективы развития татарского народа должен быть разработан и представлен правительством республики, а не общественной организацией.

По отрывочным небольшим кусочкам эскизов (точнее было бы их назвать набросками) Стратегии, не всегда удачно взаимосвязанным между собой, трудно получить полное представление об этом документе. Было бы целесообразно представить вниманию общественности проект Стратегии, а еще лучше Программы, разработанный компетентными специалистами соответствующих сфер. Тем не менее по представленным на сайте наброскам мы решили высказать свое суждение о данном документе и вкратце изложить свое видение первостепенных, важнейших задач развития татарской нации.

Учитывая возникновение сложных серьезных проблем в последние годы в духовной жизни татар, которые представляют серьезную угрозу сохранению и развитию татарского языка и его носителей, все задачи прогресса татарского народа в данной ситуации должны базироваться на главной задаче сохранения и развития родного языка татар. При этом в “Стратегии” должны быть четко обозначены наиболее существенные меры государства Татарстана, которые требуют своего безотлагательного решения.

Всем известно, что в последние годы значительно сокращены возможности изучения татарами своего родного языка. В результате ряда “действенных” мер, проведенных по инициативе центральных властей, за несколько лет намного сократилось количество татарских школ, а в ныне функционирующих происходит интенсивный процесс перехода к обучению на русском языке. Ясно, что, если этот процесс не будет остановлен, перспективы сохранения и развития родного языка татарского народа будут оставаться все более мрачными. А при потере родного литературного языка бессмысленно вести речь о развитии татарского народа, его богатой культуры, добрых традиций и т.д.

Разумеется, в такой ситуации наиважнейшей и первостепенной задачей в Стратегии (Программе) развития татарской нации должна быть определена деятельность правительства Республики, направленная на создание в Татарстане системы элитных учебных заведений, в которых обучающиеся приобретали бы хорошие знания по всем дисциплинам, в том числе по русскому, татарскому и английскому языкам, а дети татар овладевали бы в совершенстве своим родным языком, а также обогатились бы необходимым уровнем знаний по татарской литературе и истории Татарстана и татарского народа.

Вполне возможно, что реализация задачи развития и совершенствования системы национального образования не будет происходить очень гладко и безболезненно. Руководителям республики надо быть готовым к попыткам определенных сил помешать успешному ходу прогресса татарского народа. Потребуется, проявляя принципиальность, строго руководствоваться законодательными актами Российской Федерации и Республики Татарстан, в которых четко прописано право народов России на развитие своих национальных культур и образования.

В “Стратегии” обязательно должно найти отражение такое болезненное явление, проявляющееся в психологии определенной части татар, как неодобрительное, а порою даже отрицательное отношение ко всему своему национальному – к языку, культуре и к другим составляющим сущность татарского народа. Это проявляется в том, что значительная часть родителей-татар отказывается обучать своих детей татарскому языку, многие не смотрят и не слушают телевизионные и радиопередачи на татарском языке, не посещают татарские театры, мало читают литературу на татарском языке, в городах редко услышишь в общественных местах татарскую речь… Похоже, что татарский язык все более становится кухонным языком. А ведь это язык древней богатой литературы, язык развитый, совершенный, формировавшийся в течение многих столетий. Вот где она сегодня главная угроза татарскому языку, татарской культуре и самому татарскому народу. Вот что должны глубоко осознавать составители “Стратегии”, главное предназначение которой – не дать угаснуть языку, высокоразвитой культуре многомиллионного татарского народа с древней историей, некогда имевшего свою государственность, наоборот, придать свежие силы для его процветания. Реализации этой благородной задачи и призван, в нашем представлении, интерпретируемый нами документ (“Стратегия”).

Тут следует оговориться. Негативное отношение определенной части татар к своему родному, о чем мы только что упомянули, это не вина их, а беда, которую привнесла в них, как и во все другие нерусские народы, царская колониальная политика. Это результат политики Российских правителей, которая в течение ряда веков насаждала в умах нерусских народов чувство униженного положения, приниженного состояния перед русскими. Настроение всегда чувствовать перед собой “старшего брата” поддерживалось и в

советском периоде, к сожалению, оно проявляется и в настоящее время. Такие лозунги, как "Россия для русских", "Государствообразующий народ – это русские" и т.д., которые можно услышать и сегодня – это проявление непродуманной политики, которая проводится по отношению к нерусским народам.

В этой ситуации одна из важнейших задач соответствующих органов Республики Татарстан заключается в проведении идеологической работы, направленной на воспитание у татар национальной гордости, привитие им чувств достоинства, свободомыслия. И эта задача также должна быть четко обозначена в Стратегии развития татарского народа. В данном документе должен быть прописан механизм мобилизации всевозможных средств для воспитания и повышения у татар национального духа (образовательные учреждения, средства массовой информации и т.д.).

Хочется надеяться, что при дальнейшей работе над "Стратегией" будет указано на необходимость использования потенциальных возможностей для развития различных сфер татарской культуры. При этом акцент должен быть сделан на развитии народного творчества, в особенности музыкального. Учитывая, что в последнее время наблюдается увлечение интегрированием татарской эстрады во всемирное музыкальное искусство, следует иметь в виду, что, стремясь выводить татарскую эстраду на всероссийскую или всемирную сцену, нельзя нивелировать народную музыку: она хороша в естественной форме.

При изложении в "Стратегии" задач, направленных на развитие татарского языка, в частности при определении путей обеспечения эффективности обучения татарскому языку, следует особо указать на острую необходимость в учебных заведениях повысить ответственность как преподавателей, так и обучающихся за качество знаний татарского языка, учитывая при этом, что в устной и письменной речи татар в настоящее время допускается немало серьезных нарушений литературных норм родного языка.

Вызывает сожаление при ознакомлении с набросками "Стратегии", помещенными на сайте Конгресса татар то, что намерения составителей документа нередко выражены не четко, некоторые формулировки изложены наскоро, поверхностно, вследствие чего в них трудно уловить главную мысль, или суть дела. Так, в разделе "Информационное пространство" обозначено "Формирование системы подготовки татарских журналистов". Надо бы этот пункт

хотя бы несколько расшифровать, называя, например, основную проблему, которая заключается в том, что подготовка татарских журналистов в Казанском федеральном университете осуществлялась и осуществляется без серьезного обучения их татарскому языку.

В разделе "Культура" (почему в этом разделе?!) написано "Укрепление национального самосознания татарского народа при помощи религиозных институтов: ввести в традицию ходить сообща (дед, отец, внук) в культовые учреждения". Формулировки в таком важном документе, как "Стратегия" должны быть очень серьезно продуманы, взвешены. Нельзя забывать, что у нас религия отделена от государства и диктовать родителям ("ввести в практику") ходить в культовые учреждения вместе с детьми вряд ли правомерно. В своих выражениях надо быть очень осторожно. Здесь следовало бы говорить о необходимости рекомендовать служителям культа в своих проповедях призывать прихожан содействовать успешному обучению детей родному языку, в частности проводить разъяснительные беседы с родителями о необходимости разрешать и рекомендовать детям посещать уроки татарского языка и по возможности отдавать детей учиться в татарские школы. Учитывая имеющиеся в некоторых школах проблемы с организацией обучения детей татарскому языку, целесообразно открывать при мечетях так называемые воскресные школы по обучению детей родному языку. Следует рекомендовать служителям культа создавать при мечетях курсы по изучению татарского языка. Ведь не секрет, что многие родители-татары плохо знают или совсем не знают своего родного языка.

Трудно представить, чтобы жители Казани – татары, посещая мечети, совершенно не владели или плохо владели родным языком, и имамы вынуждены читать им свои проповеди на русском языке. Но именно так и происходит в настоящее время в некоторых мечетях. Тут имеется пища для серьезного размышления.

Не совсем понятны в разделе "Культура" формулировки "Развитие на основе народной культуры современных форм высокой культуры" , "Организация единых площадок, представляющих татарскую культуру", "Увязание татарского быта и жизнедеятельности с религиозными обрядами".

Заслуживает внимания в Эскизах стратегии раздел "Система национального воспитания: семья, детский сад, образовательные

учреждения”. Учитывая большую важность этой сферы деятельности для прогресса татар, будем надеяться, что она в “Стратегии” найдет свое развернутое изложение с указанием конкретных путей ее реализации.

В современных условиях России, когда государственное финансирование всей гуманитарной сферы все более сокращается, в развитии духовной жизни татарского народа будет возрастать роль благотворительности, меценатства. Предполагается, что в перспективе откроется широкое поле для инвестиций частных предпринимателей в развитие сети татарских воспитательных и образовательных учреждений. Тут уместно вспомнить историю развития просветительства у татар, в частности тот факт, что просвещение среди татар до революции осуществлялось, как правило, на основе благотворительности, меценатства отдельных состоятельных лиц, заботящихся о прогрессе своего народа. Сейчас впору возродить эти добрые традиции. Здесь роль государства будет заключаться в пропаганде, поощрении и стимулировании таких начинаний. Призыв к меценатскому движению в жизни татар и пути его реализации в сфере их национального образования должны найти отражение в “Стратегии”.

Как видно из “Эскизов стратегии” на сайте, развитие татарского народа рассчитано на довольно долгий период – аж до 2050 года. По нашему мнению, это очень большой срок. Теперешнее состояние духовной жизни татарского народа таково, что долгое ожидание лучших перемен смерти подобно. Сейчас складывается такая ситуация: или руководство Татарстана сумеет незамедлительно предпринять кардинальные меры по оздоровлению и развитию духовной жизни татар, особенно в сфере сохранения, употребления, обучения их родного языка, или будет упущен шанс на развитие языка, культуры и самого народа как цивилизованной нации.

Хочется надеяться, что руководители республики Татарстан и Татарский конгресс осознают ситуацию, объективно оценят современное положение и сделают соответствующие выводы.

# ТӨПТӘН УЙЛАП ЭШЛӘРГӘ ИДЕ

"Ватаным Татарстан" газетасының 2 апрель санында Сәрия Мифтахованың "Бәхетне читтән эзләмик" дигән мәкаләсе басылган.

Игътибарга лаеклы, уйландыра торган мәкалә. Һәрхәлдә, ул мәкаләне укыгач, минем башымда төрле уйлар, бәхәсле фикерләр, шик-шөбһәләр барлыкка килде.

Сүз полилингваль (күп телле) белем бирү комплекслары төзү турында бара. Мәкалә авторы шушы көннәрдә генә Хөкүмәт йортында уздырылган брифингта Татарстанның дәүләт киңәшчесе Минтимер Шәймиев сөйләгән сүзләргә таянып яза, аларга аңлатма бирә.

Полилингваль белем бирү комплекслары оештыру идеясе Россиядә, шул исәптән Татарстанда, инде чирек гасыр буена мәгариф өлкәсендә барган бетмәс-төкәнмәс, нык уйлап эшләнмәгән реформаларның безнең республикада чираттагы бер чагылышы гына булмасмы икән? Бу идеянең авторлары мәсьәләне, белгечләр белән киңәшләшеп, һәръяклап уйлап эш итәләрме, ашыгыч адымнар ясарга җыенмыйлармы икән? Газетадан комплекс проекты белән танышкач, шушы һәм башка төрле сораулар туа.

Газетадан аңлашылганча, полилингваль белем бирү комплексында укыту өч телдә – татар, рус, инглиз телләрендә гамәлгә ашырылачак. "Башлангыч сыйныфта (сыйныфларда дип аңларга кирәктер – *Р.Ю.*) укыту татарча алып барылачак, – дип яза Сәрия Мифтахова, полилингваль комплексның база мәктәбе директоры Айдар Шәмсетдинов сүзләренә таянып, 3нче сыйныфтан сынлы сәнгать, технология дәресләре, ә 7нче сыйныфтан математика, география һәм биология чит телдә укытылачак. Фәнни юнәлешләрдән белем инглизчә биреләчәк".

Бу изге теләкләр татлы хыял гына булып калмасмы?

Башлангыч сыйныфларда татар балалары гына укыячакмы, рус балалары дамы? Рус балалары да булса, аларны татарча укыту барып чыгармы?

3нче сыйныфтан сынлы сәнгать, технология дәресләрен, 7нче сыйныфтан математика, география һәм биология чит телдә укытылачак, диелә, ә кайсы тел ул? Нинди телдә булса да, бу реаль, ягъни мөмкин эшме?

Фәнни юнәлешләрдән белем инглизчә биреләчәк, диелгән. Нәрсәләр алар фәнни юнәлешләр? Укыту предметларымы? Алай булса, инглиз телендә укытылырлыкмы?

Бу комплекста татар теле күпме вакыт һәм ни рәвешле укытылачак?

Мәскәү кушканча, татар телен атнасына ике сәгать кенә укытып, балаларны (бигрәк тә алар арасында рус балалары һәм башка милләт балалары да булса) татарчага яхшы итеп өйрәтеп булырмы?

“Полилингваль комплекслар өч телне, башка халыкларның мәдәниятләрен беләчәк укучылар тәрбияләүне күздә тота”, – дип яза журналист. Ни өчен Татарстан уку йортларында беренче чиратта татар мәдәниятен өйрәтү бурычын кую күздә тотылмый? Башка халыкларның мәдәниятләрен өйрәтү турында гына әйтелә.

Газетада язылганча, “яңа төр уку йортын өч этапта тормышка ашырмакчылар. Беренчесе – 2019-2020 елларда башкалада “Белемгә һәм аңлашуга адымнар” дигән проект булдыру күздә тотыла. Икенче этапта – Казан, Алабуга, ә өченчесендә башка шәһәрләрдә пәйда булачак мондый яңа төр уку йортлары”.

“Белемгә һәм аңлашуга адымнар”ны ничек аңларга? Тексттан күренгәнчә, комплексның беренче этабы бер урында, икенче этабы икенче урында, өченчесе өченче урында гамәлгә ашырылырга тиеш була? Ничек алай булырга мөмкин икән? Аңлашылмый. Икенче һәм өченче этапларның сроклары да күрсәтелмәгән. “Татар халкы стратегиясе”нең эскизларындагы кебек, соңгы этабы 2050 елларга калмасмы икән? Бик озакка китмәсме бу комплексларның төзелүе?

Полилингваль комплекс, имеш, балалар бакчаларын, мәктәпләр, өстәмә белем бирү оешмаларын үз эченә ала. “Күп телле үзәкләр төзү бик отышлы, – дигән Минтимер Шәрипович. – Алар буш урында төзелми, кайдадыр бакча, кайдадыр мәктәпләр сафка басачак”. Ул кайдадыр урнашкан мәктәпләр һәм бакчалар ни рәвешле бер комплекс тәшкил итә алыр икән?

“Билгеле, өч телле мәктәпләргә теләсә кем эләгә алмый, бәйге аша узарга туры киләчәк”, ди дәүләт киңәшчесе, сүзен дәвам итеп.

Ул проект кайчан да булса гамәлгә ашырылса да, республикадагы берничә генә комплекс бүгенге көндә гаять әһәмиятле мәсьәләне – гомумән татарча укыту эшен алга җибәрү проблемасын хәл итә алмаячак бит.

Татар телен өйрәнү, белү, куллану бүген һәлакәт алдында тора. Хәзер әле кайчан буласы билгесез ниндидер аморф комплекслар оештырылуны көтеп торып, кыйммәтле вакытны кулдан ычкындырырга ярамый.

Бөтен көчне туплап, вакытны сузмыйча, мөмкин булганча күбрәк алдынгы, заманча татар мәктәпләре булдырырга, булганнарында укытуның югары сыйфатына, беренче чиратта укучыларга татар теле һәм әдәбиятыннан, татар халкының тарихыннан, мәдәниятеннән ныклы белем бирүгә ирешергә кирәк.

Татарстанда, нигездә, ике телдә – татар һәм рус телләрендә укытыла торган мәктәпләр булырга тиеш. Фараз ителгән комплекслар барып чыкса да, республикада берничә генә булырга ошаган.

Рус мәктәпләрендә укучыларны, бигрәк тә татар балаларын, иркен аралаша, сөйли алырлык дәрәҗәдә татар теленә өйрәтсеннәр.

Татар мәктәпләренең башлангыч сыйныфларында, әлбәттә, укыту балаларның туган телендә, ә башка сыйныфларда гуманитар фәннәрне укыту, тәрбия һәм оештыру эшләре һичшиксез шулай ук татар телендә гамәлгә ашырылырга тиеш. Физика, математика кебек төгәл фәннәр предметлары һәм табигать фәннәрен, хәзерге вәзгыятьне исәпкә алып, укытучылар һәм укучыларның ата-аналары кирәк дип тапсалар, белем бирерлек яхшы укытучылар булса, рус телендә дә укытылырга мөмкиндер. Әмма бу мәҗбүри түгел. Идеаль вариант – барлык предметларны да татарча укыту.

Шуның өстенә, татар мәктәпләрендә рус теле дә һәм инглиз теле дә рус мәктәпләреннән калышмаслык дәрәҗәдә яхшы итеп укытылырга тиеш. Гомумән, татар мәктәпләренең барысы да (сайлап алынган, элиталы мәктәпләр генә түгел) алдынгы һәм абруйлы булсын. Татарстан хөкүмәтенең бүгенге иң әһәмиятле бурычы – шушы.

Барлык мәктәпләрдә дә өч телдә укытуга ирешү – бүгенге көндә тормышка ашмаслык хыял. Татар һәм рус мәктәпләрендә укытып, бу ике телне яхшы итеп үзләштерүгә ирешү өстенә берәр чит тел өйрәтү – кулдан килерлек эш.

Үзгәрешләр, яңалыклар төптән уйланылган, реаль тормышка нигезләнгән булсын, кемнәрнеңдер хыялында гына барлыкка килгән нәрсәләр булырга тиеш түгел.

# ПОЛИЛИНГВАЛЬНЫЕ ОБРАЗОВАТЕЛЬНЫЕ КОМПЛЕКСЫ

Многострадальное образование в России уже четверть века не перестает лихорадить бесконечными, нередко нецелесообразными, реформами и нововведениями. Вот снова в Татарстане возникла идея создания так называемых полилингвальных, то есть многоязычных общеобразовательных комплексов. По этому поводу Государственный советник республики М.Ш.Шаймиев провел брифинг для журналистов.

Вкратце, как явствует из выступления М.Ш.Шаймиева, суть этих комплексов заключается в том, что в Казани, Н.Челнах, Нижнекамске, Елабуге и Альметьевске намереваются создавать трехъязычные школьные комплексы, в которых преподавание будет вестись на русском, татарском и английском языках. Первую такую школу планируют открыть со следующего учебного года на базе 165 школы Казани. Считается, что в этой школе уже имеется образец многоязычного образовательного учреждения.

Следует оговориться, что судя по выступлениям участников брифинга и заявлению директора 165 школы Айдара Шайхутдинова, четкой концепции создания этих полилингвальных комплексов пока еще не имеется. Высказываются отдельные мысли по тем или иным деталям предстоящего образовательного построения. Но зато много вопросов и неясностей относительно содержания и структуры этих комплексов. На некоторых из них мы и остановимся сейчас.

Как предполагается, обучение в начальных классах будет вестись на татарском языке. Следует полагать, что это будет осуществляться, прежде всего, по отношению к детям татар. А как будет с желанием их родителей, а также их уровня элементарных знаний татарского языка? Ведь, как известно, сегодня, к сожалению, не все татары изъявляют желание обучать детей родному языку и далеко не все из городских детей-татар владеют своим родным языком в той степени, чтобы могли обучаться на татарском языке.

По заявлению того же директора 165-ой предполагаемой базовой школы, занятия по искусству и технологии, начиная с 3 класса, а уроки по математике, географии и биологии, начиная с 7 класса будут вестись на иностранном, надо полагать, английском языке. Смелая мысль, но осуществлима ли она на сегодня?

Вопрос же, как будут изучать и будут ли изучать в этих комплексах татарский язык, остается открытым. На этот вопрос журналистов на брифинге Государственный советник ограничился общими рассуждениями о том, что учащиеся будут знать все три языка. Таким образом, самый насущный вопрос остается в тени.

По мысли авторов идеи создания многоязычных комплексов, они должны охватывать детские дошкольные учреждения, а также организации дополнительного образования. Как деятельность этих организаций будет скоординирована, как будут распределены между ними обязанности? Об этом также ничего неизвестно. Государственный советник по поводу этого высказался так: "Организация многоязычных центров – дело очень выигрышное. Они не будут создаваться на пустом месте, где-то будут появляться детские сады, где-то школы". Каким образом будут объединены под одной крышей эти находящиеся где-то садики и школы?

Есть вопрос о так называемых этапах создания полилингвальных комплексов. По выступлениям на брифинге, организация этих комплексов будет осуществляться в три этапа. Реализация первого этапа будет проходить в 2019-2020 годах в Казани и Елабуге по проекту "шаги к знаниям и пониманию". Что подразумевается под этими шагами, нам пока об этом неведомо. Содержание и сроки второго и третьего этапов не раскрываются. Имеется опасение, что эти сроки как бы не оказались очень далекими, как, например, в Стратегии развития татарского народа, где сроки осуществления их определены аж до 2050 года.

Многоязычные образовательные комплексы, если и будет суждено им стать, то, похоже, они будут обслуживать очень ограниченное число детей. Ибо они задуманы как элитные, поступление в которые будет доступно очень немногим. "Разумеется, – говорит Государственный советник по этому поводу, – в трехъязычные школы сможет поступить далеко не каждый, придется проходить через конкурс".

Таким образом, хотя идея создания полилингвальных комплексов еще далеко не прозрачная, однако уже сейчас становится понятным одно: она не призвана решать архиважную на сегодняшний день задачу – задачу не дать зачахнуть национальному образованию, некогда высокоразвитому, древнему литературному татарскому языку, а также совершенствовать систему образования в Татарстане таким образом, чтобы изучение татарского языка для

всех татар, разумеется, особенно для молодого поколения, стало гражданским долгом, духовной потребностью и чтобы для этого были открыты все возможности.

Согласившись с тем, что в республике, возможно, будут созданы многоязычные учебные заведения, тем не менее мы считаем необходимым заявить о том, что, по нашему убеждению, не следовало бы, увлекаясь этой идеей, прилагать особые усилия по созданию этих так называемых полилингвальных образовательных комплексов.

В настоящее время прежде всего исключительно важно добиваться развития татарских школ, создания как можно большего количества лучших современных образовательных учреждений, в которых обучение и воспитание учащихся осуществлялось бы в основном на татарском языке и, в виде исключения, с учетом сегодняшних реалий и желания родителей учеников, предметы физико-математического цикла, а также возможно, некоторые предметы естественно-научного направления преподавались бы на русском языке. При этом одной из важнейших задач правительства Татарстана является обеспечение татарских школ высококвалифицированными учительскими кадрами, создание в них хорошей материальной базы и совершенствование методики преподавания, учебных планов и учебных программ таким образом, чтобы выпускники татарских школ, наряду с отличным знанием своего родного языка, в совершенстве овладевали бы русским языком и хорошо знали один из иностранных языков, в основном английский.

Пусть будут лучшими в нашей республике и во всей России и русскоязычные и все другие школы. Обучение молодого поколения в современных наилучших школах – залог успешного развития здорового, цивилизованного общества.

## ӨЧ ТЕЛДӘ УКЫТУМЫ, ӨЧ ТЕЛНЕ УКУМЫ?

Хәзер күп һәм тиз үзгәрешләр заманы. Узган гасырның 90 нчы еллары башыннан бирле Россияне үзгәртеп кору омтылыш чорын кичердек. Ләкин уңай якка үзгәрешләр бик күренми әле. Мәгарифкә килсәк, бу өлкәдәге реформалар, укыту системасын үзгәртеп торулар аеруча күп. Әмма кирәклеләре, мәгънәлеләре күпме икән? Бу мәсьәләдә шунысы мәгълүм: еш үзгәртеп корулар,

реформалар үткәреп тору һәрвакытта да файдага булмый. Эшләү тәртибен, күнегелгән, сыналган системаны, берөзлексез үзгәртеп, яңартып тору белән мавыкмыйча, камилләштерү, яхшырту белән шөгыльләнү кулайрактыр. Югыйсә, хәзер гадәткә кереп бара: эш аксый башласа, төптән уйлап тормыйча, берәр төрле үзгәреш кертеп куялар. Шуның белән эш яхшырыр дип ышанып йөриләр. Өмет акланмый, һәм, тырышыбрак, сыйфатлырак итеп эшлисе урында, яңадан үзгәреш кертү белән шөгыльләнә башлыйлар. Мәгарифтә дә шундыйрак хәл хөкем сөрә.

Менә соңгы көннәрдә полилингваль белем бирү комплекслары оештыру идеясе килеп чыкты. Матбугаттагы хәбәрләргә караганда, бу идеянең авторлары аны гамәлгә ашыруның конкрет ысулларын, чараларын төптән уйлап бетермәгәннәр әле булса кирәк. Күп телле уку йорты нинди булачак – рус, татар, инглиз телләрендә укыта торган мәктәпме, әллә предметларны рус яки татар телләрендә укытып, татар, рус, инглиз телләрен предметлар буларак өйрәтә торган мәктәпме (комплексмы) икәнлеге ачык түгел.

Булачак күп телле комплексның бүгенге үрнәге саналган Казанның 165 нче мәктәбе директоры әйтүенчә, бу яңа төр мәктәпнең башлангыч сыйныфларында укыту татар телендә булачак. 9 нчы сыйныфка кадәр тарих, җәмгыять белеме, табигать белеме дәресләре шулай ук татар телендә башкарылачак. Бу фикер реаль нигезгә корылганмы? Андагы предметларны татар телендә уку өчен балалар бу телне тиешле дәрәҗәдә белергә тиеш бит. Монда Мәскәү кушуы буенча татар телен укытуга атнага 2 сәгать бирелергә һәм, ата-аналарның теләге булырга тиешлеге исәпкә алынамы?

165 нче мәктәп директоры Айдар Шәмсетдиновның сүзләренә караганда, бу мәктәптә укучы татар балалары 30 процент кына тәшкил итә. Шулай булгач, әлеге предметларны татарча укыту татар балаларына гына карыймы яки рус балаларына дамы? Икесенә дә караса, аларның барысына да татарча укыту идеясенең реаль булуына ышану бик кыен.

Аннан килеп, Айдар Шәмсетдинов, 3 нче сыйныфтан сынлы сәнгать, технология дәресләре, ә 7 нче сыйныфтан математика, география һәм биология чит телдә (инглиз телендә дип уйларга кирәктер – *Р.Ю.*) укыталачак, ди. Фәнни юнәлешләрдә белем инглизчә биреләчәк. Фәнни юнәлешләр дигәне нинди предметларны күздә тота торгандыр. Ничек кенә булса да, мондый предмет-

ларны мәктәптә инглиз телендә уку һәм укыту бик проблемалы күренеш.

Күздә тотылган полилингваль (күп телле) комплекска балалар бакчалары да, өстәмә белем бирү оешмалары да керәчәк, дип уйланыла икән. “Күп телле үзәкләр төзү бик отышлы, ди Татарстанның дәүләт киңәшчесе Минтимер Шәрипович Шәймиев. – Алар буш урында төзелми, кайдадыр бакча, кайдадыр мәктәпләр сафка басачак”. Бу кайдадыр бакча, кайдадыр мәктәп, кайдадыр өстәмә белем бирү оешмалары бер түбә астында ничек укытырлар, аларның эше ничек координацияләнер икән? Сораулар күп әле монда.

Минтимер Шәрипович әйткәнчә, белем бирү өлкәсе бик катлаулы... Ныклап уйлап, дөньядагы белем бирү системаларын өйрәнеп эшләргә кирәк.

Бу полилингваль комплекслар хәзерге иң мөһим мәсьәләне – бөтен көчне туплап, бар акылны җыеп, бөтен татар балаларына да туган телләрен яхшы итеп өйрәтү бурычын хәл итүне күздә тотмый кебек.

Хәзер татар телен өйрәтү, куллану һәм саклау вәзгыяте шуны таләп итә: хөкүмәтнең иң беренче, иң әһәмиятле проблемасы – мөмкин булганча күбрәк яңа, заманча татар мәктәпләре ачу һәм булганнарының нәтиҗәле эшләвенә ирешү.

Татар мәктәпләрендә укыту, тәрбия һәм оештыру эшләре, нигездә, туган телдә булырга тиеш. Хәзерге хәлне һәм ата-аналар теләген исәпкә алып, математика, физика кебек төгәл фәннәрне рус телендә укытырга мөмкин. Татар мәктәпләрендә рус теле дә, чит телләр (беренче чиратта инглиз теле) дә бик яхшы укытылсын. Бу мәктәпләрдә тиешле югары белемле, әзерлекле укытучылар эшләсен. Татар мәктәпләренең материаль базасы да заманча булырга тиеш. Шушы шартлар үтәлгәндә милли мәктәпләрнең абруе артачак, ата-аналар балаларын анда укырга теләп бирәчәк.

Рус мәктәпләре дә яхшы булырга тиеш, әлбәттә. Укыту сыйфаты аларда да тиешле дәрәҗәдә булсын. Аларда укучы татар балалары да туган телләрен иркен аралашырлык итеп өйрәнергә тиеш. Бу безнең телебезне саклап калу өчен зур резерв.

Кыскасы, бүгенге көндә татар телен, аның иясе булган халкын, мәдәниятен алга җибәрүнең төп шарты ул – балаларга, яшь буынга туган телләрен яхшы итеп өйрәтүгә ирешү, мәктәпләрнең эше белән даими кызыксынып, аларга тиешенчә ярдәм итеп тору.

## КОМУ МЕШАЮТ НАЦИОНАЛЬНЫЕ ЯЗЫКИ?

В последние годы в нашей стране происходит всемерное ущемление прав нерусских народов на развитие, употребление и обучение их родных языков. Лет десять тому назад, как известно, по решению центральных властей из школьных программ был исключен национальный компонент, затем введено положение о сдаче единых государственных экзаменов в национальных школах на русском языке и зачислении в вузы, в том числе на специальности "родной язык и литература", по результатам этих экзаменов. Вскоре было дано драконовское указание о преподавании в общеобразовательных школах национальных языков в объеме не более двух часов в неделю, национальных же литератур – не более одного часа. К тому же изучение родных языков государственными стандартами предусмотрено лишь до 10 класса.

В результате таких антидемократических мер по отношению к обучению учащихся на родном языке и изучению родного языка в Татарстане за последние годы были сокращены сотни национальных школ, лишились работы по своей специальности полторы тысячи преподавателей татарского языка и литературы. К тому же многие тысячи детей татар, обучающихся в русскоязычных школах республики, не имеют возможности овладевать своим родным языком хотя бы в объеме, достаточном для свободного общения на этом языке.

Положение с изучением и употреблением родного языка усугубляется еще в связи с тем, что во многих татарских школах происходит процесс перехода к обучению на русском языке. Главная причина – парадоксальная система сдачи в национальных школах выпускных экзаменов на русском языке и зачисление в вузы на основании баллов, полученных на этих экзаменах. Ущемленность выпускников национальных школ очевидна: оценки государственных экзаменов, сданных на русском языке, у выпускников школ с родным языком обучения естественным образом будут ниже, чем у обучавшихся на русском языке и, следовательно, возможностей у тех для зачисления в вузы будет меньше. Учитывая этот фактор, в татарских школах и начался переход к обучению на русском языке, а также родители-татары все больше отдают своих детей в русскоязычные школы. Таким образом, подрывается основа употребления, изучения и развития татарского литературного языка, на

котором создавалась богатейшая литература, языка народа с древней историей, некогда имевшего свою государственность, народа с высокоразвитой культурой – коренного народа донорской республики, которая 80-85% (более 800 миллиардов рублей) своих поступлений ежегодно перечисляет Москве.

Подобного ущемления прав народов на развитие национального образования, своего родного языка не было даже в лихие сталинские годы. Тогда в Татарстане успешно функционировали во всех татарских селах и городах республики национальные школы, татарский язык изучали даже в профессиональных учебных заведениях, в которых обучались представители разных национальностей.

Сейчас процесс централизации в сфере образования в регионах России доходит до неимоверных масштабов: все учебные планы и программы по всем предметам, в том числе по национальным языкам и литературе, утверждаются в обязательном порядке в Москве, учебники же по родным языкам, литературе и истории народов Российской Федерации можно издавать и пользоваться ими лишь после лицензирования и утверждения их в Министерстве образования России. Следовательно, роль министерств просвещения национальных республик и областей по сути сведена на нет.

Все эти противоестественные реорганизации в национальном образовании осуществляются вопреки основным законам (конституциям) Российской Федерации и республик, российскому закону об образовании, а также другим законодательным актам, в которых четко прописаны права народов на образование на родных языках, свободное пользование ими, изучение и развитие их. Никак не соотносятся утверждения и деяния российских властей, когда они пекутся о правах русскоязычных жителей за рубежом и в то же время грубо нарушают законные права народов своей страны на сохранение, развитие их родных языков и получение образования на своих языках.

Вызывает чувства глубокого разочарования и досады проводимая руководством страны политика, направленная на все более ущемление национальных интересов народов России. Не перестаешь удивляться тому, как можно не понимать истину, заключающуюся в том, что многонациональное государство может быть сильным прежде всего благодаря сплоченности, единению народов, проживающих в нем. Сплоченность же их, дружба меж-

ду ними может базироваться лишь на их равноправии и строгом соблюдении национальных интересов. Здесь впору упомянуть о том, что одним  из основных факторов победы СССР в Великой Отечественной войне была солидарность народов. Известно также, что обещание большевиков учитывать национальные интересы народов России сыграло главную роль в их победе в Октябрьской революции и Гражданской войне. Нынешним руководителям государства, благодаря усилиям которых сейчас в школах на изучение родных языков нерусских отводится лишь два часа в неделю, тогда как на изучение русского языка отводится время в несколько раз больше, следовало бы обратиться к указаниям и трудам В.И.Ленина по национальным вопросам.

Как известно, первый руководитель советского правительства большое внимание уделял установлению равноправных отношений между народами и созданию условий для развития национальных культур и языков. Особенно примечательны его высказывания по языковому  строительству в молодой советской стране. В.И.Ленин, отмечая исключительно большую роль русского языка как важного межнационального средства общения разных народов и государственного устройства, строго предупреждал о недопустимости превосходящего статуса этого языка и принудительного изучения его, страстно выступал при решении национальных вопросов, в том числе языковых, против проявлений “великорусского шовинизма”.

Сейчас в учебных заведениях, в том числе в национальных школах, Татарстана нет проблемы с изучением русского языка. По результатам ЕГЭ по русскому языку эта республика занимает одно их первых мест среди регионов. Тем более совершенно не понятно негативное отношение руководителей из Москвы  к татарскому языку. Ведь изучение татарского языка учащимися и обучение в школах на этом языке не наносит ни малейшего ущерба знаниям татарских детей и молодежи по русскому языку. Наоборот, владение несколькими языками расширяет горизонты познания полиглота, создает возможность для него общаться с представителями разных национальностей. Вместе с тем изучение разных языков благотворно сказывается на работе головного мозга носителя языков, на развитии его умственных способностей.

Из сказанного становится ясно, что ориентиром в организации учебного процесса в национальных республиках и областях России должно быть качественное обучение учащихся родному языку де-

тей коренного населения и русскому языку, а также в дополнение – английскому языку и, возможно, еще какому-нибудь иностранному языку в зависимости от потребностей и желания родителей и детей. При этом руководителям как федеральных, так и региональных органов образования следует пересмотреть свое отношение к несправедливой пропорции времени, отводимого на изучение русского и родного для коренного населения языков, прекратить практику увеличения часов на обучение русскому языку за счет неоправданного уменьшения времени на изучение родных языков, доводя его до мизерного количества, как это делается сейчас в Татарстане.

Одна из первостепенных задач руководителей органов образования сегодня заключается в организации учебного процесса таким образом, чтобы дети, как русские, так и нерусские, обучаясь в школе, овладевали своим родным языком. Азбука для цивилизованного педагога – понимание того, что родной язык это святое для каждого, а также осознание той истины, что без родного языка нет в конечном счете и самого народа, этноса, и самой нации.

Государственные деятели, ответственные работники образования обязаны руководствоваться в своих поступках сознанием того, что потеря языка, даже самого малочисленного народа – это ущерб мировой культуре, гуманитарной экологии. Следовало бы помнить каждому, кто имеет отношение к образованию, о том, что прогрессивное мировое сообщество не зря бьет тревогу в связи с интенсивным исчезновением ряда языков малочисленных народов и принимает меры для предотвращения или хотя бы для замедления этого процесса.

## ТАТАР ХАЛКЫНЫҢ ГЫЙБРӘТЛЕ ТАРИХЫ

Бу язма күренекле язучы, журналист, Тукай премиясе лауреаты Вахит Имамовның 1993, 1994 елларда татар һәм рус телләрендә басылып чыккан, аннары тагын күп телләрдә бастырылган “Яшерелгән тарих” (“Запрятанная история татар”) исемле китабы хакында. Күптән түгел республиканың тикшерү органнары, бу китап экстремизм рухында язылган дип, аның авторын хөкемгә тарттылар. Бу күңелсез хәбәргә бик гаҗәпләнеп, мин ул китапны

игътибар белән укып чыктым һәм тәэсирләремне укучылар белән уртаклашырга булдым.

Китапның эчтәлеге белән танышкач, башыма килгән беренче сораулы фикерем шул: татар халкы өчен җан атып йөргән, зур абруйлы бу кешегә карата шундый мәрхәмәтсезлек, гаделсезлек кылу кемгә һәм ни өчен кирәк булды икән? Мин аның китабында бернинди да экстремизм рухын, экстремистлык чагылышын тоймадым, вәләкин патша колонизаторларының татарларны рәхимсез җәберләүләренә күңелем сыкранды, борынгы бабаларыбызның азатлык өчен көрәшләрдәге батырлыкларына горурлык хисләре кичердем.

“Яшерелгән тарих” китабында Вахит Имамов изге максатын гамәлгә ашыра: үзе әйткәнчә, тарихларын бик аз гына белгән кешеләрне татар халкының үткән тормышындагы вакыйгалар белән таныштыру бурычын үти. Тарихыбызны без, татарлар, чыннан да тиешле дәрәҗәдә белмибез. Безгә мәктәптә һәм югары уку йортларында өйрәткән тарихта чынбарлык, бигрәк тә аның аз санлы халыкларга, шул исәптән татарларга, караган өлешләрендә шактый нык бозып күрсәтелгән. Тарих бозып язылган дәреслекләр аз санлы халыкларның казанышларын кечерәйтү яки бөтенләй юкка чыгару исәбенә күп санлы русларның тарихын күпертеп, бизәп тасвирланган. Россиядә һәрвакыт шулай булган: тарихчы галимнәр, хакимият әһелләренең ихтыярын үтәп, русларның барлык гамәлләрен һәм сыйфатларын уңай, яхшы итеп күрсәтү, җитешсез, кимчелекле, ямьсез күренешләрен яшерү белән шөгыльләнгәннәр. Димәк, Россия тарихын М.Худяков һәм Л.Гумилевтан башка рус галимнәре татарлар тормышына караган мәгълүматны бозып, аларны гомергомергә русларга каршы торган кешеләр буларак күрсәтеп язганнар. Татарлар тарихындагы күп кенә якты сәхифәләр, игелекле гамәлләр тарихчыларның игътибарыннан читтә калган, шулай ук татар халкының тормышында XVI-XVIII гасырларда булган рус колонизаторлары белән бәйләнешле дәһшәтле, кайгылы вакыйгалар күрсәтелмәгән. Мәктәп укучыларына һәм югары уку йортлары студентларына татар халкы тормышы турында мәгълүмат тулы итеп бирелмәгән, Казан ханлыгы вакытындагы һәм Казанны Иван Грозный яулап алганнан соңгы вакыйгалар бик өстән-өстән генә сурәтләнгән.Чөнки Рус дәүләте өчен татарлар тарихының бу зур мәгънәле чорларын яшереп калдыру хәерлерәк булган.

Менә шушыларны исәпкә алып һәм татар тарихы фәнендәге хилафлыкны төзәтү нияте белән, язучы Вахит Имамов татар халкының чыннан да яшерелгән тарихының бик мөһим өлешен тасвирлау эшенә алынган. Узган гасырның 90-нчы елларында Россиядә татарларның һәм башка халыкларның милли аңы үсеше хөкем сөргән шартларда аларның икътисади һәм сәяси мөстәкыйльлеккә омтылышы рухы белән сугарылып, Вахит Имамов әлеге китабында төп игътибарын татар халкының милли-азатлык көрәшен тасвирлауга юнәлтә. Бу китапның аеруча әһәмияте шуннан гыйбарәт: ул безнең көннәргә кадәр сакланып калган архив документларында һәм намуслы тарихчыларның ышанычлы гыйльми басмаларында, барыннан да бигрәк М.Худяковның "Очерки по истории Казанского ханства" дигән китабында сурәтләнгән дөрес мәгълүматларга нигезләнгән.

Вахит Имамов үзенең китабында, татарларның беренче дәүләте Идел Болгары, аннары Казан ханлыгы халкының тормышындагы, мәдәни-ятендәге, фәнендәге казанышларны искә алып киткәннән соң, чын, конкрет фактлар белән патша залимнәренең татар, башкорт, чуваш, мари, мордва, удмурт халыкларына карата гасырлар буена кылып килгән явызлыклары турында сөйли. Патша дәүләтенең рәхимсез колониаль сәясәте максатлы рәвештә берничә йөз ел үткәрелә. Бу хәл 1552 нче елның октябрендә Иван Грозный гаскәрләре Казанны алганда башлана. "*Казан алынгач, шәһәрдә исән калган халыкны тоташтан сую башлана. Урыс командованиесе ир җенесеннән булган барлык кешене баштанаяк кылычтан кичерергә боерык бирә:* ***"В полон имати жен и дети малые, а ратных избивати всех"*** *(Царственная книга. – Пг., 1769, стр.308). Ир-ат бөтенләй суела, ләкин шактый гына хатын-кызның да гомере өзелә:* ***"Сечаху нащадно нечистивых мужей и жен"*** (шунда ук, 306 б.). *Шәһәрнең күренеше кот очарлык була. Бөтен җирдә янгын котырына, өйләр таланып бетә, урамнар үле гәүдәләр белән тула, кан гөрләвекләр булып ага* ***("по долием крови течаху").*** *Бөтен шәһәр эчендә мәетләр саны шулкадәр күп була ки, аяк басар урын калмый. Соңгы фидаилар сугышкан Хан сарае артындагы урамнарда үле гәүдәләр тау-тау өелеп, диварлар белән тигезләшә. Шәһәрнең көнбатыш ягындагы чокырлар мәетләр белән тула, Казансуның аръягындагы болынның буеннан-буена шәһидләрнең үле гәүдәләре ята. Елганың үзендә өелешеп үлекләр ага. Мөдһиш Иван*

*шәһәргә керсен өчен озынлыгы 200 метрдан артмаган бер кечкенә урамны (Нургали капкасыннан Хан сараена кадәр) үлекләрдән көчхәл белән чистарталар.*

*Урыс "божра"сын өзеп, Казансуның аръягына чыккан сугышчыларның да һәммәсе диярлек яңа бәрелешләрдә һәлак була. Ә хатын-кызлар мәсхәрәгә дучар ителә. Явыз Иван аларны сугышчыларның тулы карамагына тапшыра. Әсир ителеп мәсхәрәләнгән мөслимәләрнең исәбә-хисабы булмый (****"толь множество взяша полону татарского, яко же всем полком русским наполнитесь; у всякого человека полон татарский бысть"**- Царственная книга, 308 б.). *Гаҗәеп бай шәһәрнең барлык малы таланып, "җинүчеләр" арасында бүленә.*

*Казан алынуның нәтиҗәләре турында М.Г.Худяков болай дип яза:* ***"Чудовищное избиение жителей взятой Казани составляет одну из самых тяжелых страниц русской истории. Такою колоссальную гекатомбию человеческих жертв закончился "крестовый поход" христолюбивого воинства против казанцев, первое выступление русского государства на путь территориальных завоеваний. Кроме огромного количества человеческих жизней, насильственно унесенных в могилу, кроме бесчисленных слез, страданий и горя, пережитых казанским народом, печальный день 2 октября знаменовал собою гибель материального благосостояния, накопленного целыми поколениями, и утрату культурно-бытовых ценностей, которые теперь были безжалостно извлечены из укромных уголков, где они бережно сохранялись, без сожаления были изломаны, изуродованы, потеряны, уничтожены. Тысячи драгоценностей, ювелирных украшений, тканей, произведений высокого мастерства и искусства безвозвратно погибли. Богатству народа был нанесен страшный удар, от которого он едва ли мог оправиться. Громадный город сделался жертвою солдатского грабежа"*** *(*Худяков М. Очерки по истории Казанского ханства. – Казань, 1990 г., 153-154 б.).

Казан җирендә, Чулман (Кама) белән Урал арасындагы территориядә хөкем сөргән колониаль изүнең рәхимсезлеге, әшәкелеге таң калдырырлык. Халыкны мыскыл итүнең чиге булмаган. Ул мәхшәр заманнардагы бер-ике генә хәлне булса да әйтеп китү зарур.

1718 елда Петр I нең махсус әмере белән Казанда корабльләр төзү верфе оештырылган. Бу төзелешкә урманнардан агач кисеп әзерләү өчен, Казан адмиралтействосына татар крестьяннарыннан 65 мең кеше беркетелгән. Н.Калинин бу хәлләр турында менә ниләр язган: "***Агач материалы әзерләүчеләр (алар тарихка лашманчылар исеме белән кереп калган), үзләренә ризыкны, атлары өчен фуражны үзләре алып килеп, айлар буенча кайтмыйча, урманнарда эшләргә мәҗбүр ителгәннәр. Шуның өстенә, җан башына акчалата еллык салым түләргә тиеш булганнар***.

***Лашман эшләре вакытында бик күп татарлар гарип булып калганнар. Ун кешенең сигезе инвалидка әверелгән. Алар урманда агач әзерләүгә, бу эш өчен казнадан алганга караганда, өч тапкыр күбрәк түләгәннәр***".

XVIII гасырда татар һәм башкорт крестьяннары дистәләрчә төрле газаплар һәм йөкләмәләр белән бергә, завод-фабрика җәфаларына да дучар ителә. Россиядә Петр I нигез салган промышленность һәм икътисад үсеше аеруча нык гамәлгә ашырыла башлый.

Демидовлар заводларында уннарча мең крестьяннар каторга шартларында эшлиләр. Аларны айлар буена шахта һәм забойлардан чыгармыйлар, чылбырлар белән бәйләп тоталар. Гаепсез һәм хуҗаларга ошамаган кешеләрне төрмәләрдә, базларда яки кеше яшәми торган утрауларда атналар буенча, агачларга бәйләп куеп, ашарга-эчәргә бирмичә тотканнар. Завод эшчеләре караңгы, дымлы һәм салкын баракларда яки землянкаларда яшәгәннәр. Кечкенә генә гаепләр өчен аларга штрафлар салганнар, чыбыркы һәм камчылар белән суктырганнар. Заводларда иң элементар саклану чаралары да күрелмәгән. Шахталарда, забойларда, металл эретү мичләре янында йөзләрчә крестьяннар гарипләнгән һәм һәлак булган.

Татар халкы җирле башлыклар һәм воеводаларның исәпсез күп санлы салымнарыннан һәм түләүләреннән җәфа чиккән. Кайбер төбәкләрдә салым җыю акылсызлык дәрәҗәсенә җитә торган булган. "***Табышчы"лар (салым җыючылар) Андрей Жихарев белән Михальков Казан һәм Минзәлә воеводстволарында патша указы белән беркетелгән салым системасының гамәлдәге пунктларына өстәп дистәләгән яңа төрләрен керткәннәр: "һәр мич морҗасы өчен, яңа өйләнешкәннәргә һәм аларга никах укыган муллаларга, көтүдәге малларның һәр башы, вафат булган кешеләргә укыган***

***дога өчен өстәмә салым... Умартадагы бал кортлары, күннәргә, камытларга, дугаларга, су бәкеләренә, тәрәзәләргә, капкаларга... салым түләү тәртибе кертелә. Патша вәкилләренең фантазияләре һәм комсызлыклары шул дәрәҗәгә җитә, хәтта алар күзләрнең төрле төсләре өчен салым: коңгырт күзлеләргә унар тиен, кара күзлеләргә сигезәр тиен түләтү турындагы пункт кертергә дигән карарга киләләр!”***

Идел һәм Урал буйларында яшәгән руслардан бүтән халыклар, күп төрле хурлаулар һәм мыскыл итүләрдән тыш, дин тотуга кагылышлы (конфессиональ) җәбер-золымларга да дучар ителәләр: патша хөкүмәте һәм миссионерлары гасырлар буена, Казан алынганнан бирле, әшәке һәм мәкерле сәясәт – татар, башкортларны һәм христиан динендә булмаган башка халыкларны көчләп чукындыру сәясәте үткәреп килгәннәр. Миссионер җәлладлар, татар һәм башкортларны чукындыруда зур уңышларга ирешә алмагач, мөселманнарны җәберләү юллары кулланып максатларына ирешергә маташканнар. Бу көчләү гамәлләрен башкаруда Лука Конашевич дигән бәндә аеруча зур тырышлык күрсәтеп килгән. Бу шашкан кеше әмере буенча миссионер руханилар солдатлар белән берлектә Татар бистәсендә яшәүчеләрне кыйнау һәм газаплау тамашасы оештыралар, йортларны, мәчет, мәдрәсәләрне җимерәләр, яндыралар, кешеләрне бозлы суга куып кертәләр. Мондый тәре походларын якын тирәдәге авылларга да оештыралар.

1742 нче елның 19 ноябрендә императрица Казан губернасындагы барлык мәчетләрне җимерергә һәм яңаларын салдырмаска дигән указга кул куя. Ике елда Казан өязендәге 536 мәчетнең 418 җимертелә.

Ләкин патша мөритләренең бернинди корткычлыклары һәм җәберләүләре дә татар халкының азатлыкка омтылышын бетерә алмый. Ул, Казан ханлыгы җирендә яшәгән башка халыклар кебек үк, коллык хәленә бервакытта да риза булып тормый. Татарлар 1552 елда ук башкортлар, чирмеш, мордва, удмуртлар белән бергә азатлык өчен көрәш башлап җибәрәләр. Руслардан бүтән халыкларның баш күтәрүләре, 10ар-15әр ел саен кабатланып, өч гасырдан артык дәвам итеп тора. Бу көрәш Иделдән алып Уралга кадәр таралган була.

“Татарларның яшерелгән тарихы” китабында Идел һәм Урал буе халыкларының азатлык көрәше, аларның җитәкчеләренең ба-

тырлык һәм фидакарьлекләре турында тулы мәгълүмат бирелгән. Бу халыкларның үзләрен җәберләүчеләргә каршы чыгышлары патшаның җәза бирүче отрядлары тарафыннан рәхимсез рәвештә бастырылып килә. Ул җәзалау төркемнәренең кансызлык гамәлләре, баш күтәрүчеләрне җәзага тартуның иң рәхимсез формаларын кулланганлыклары турында язылганнарны тетрәнмичә укып булмый. Идел буендагы һәм Урал тирәләрендәге җәза гаскәрләренең канэчкеч бригадиры М.Хрущев Минзәләдәге воевода Ф.Волконский ярдәме белән экзекуция гамәленә үзе керешкән: баш күтәрүчеләрнең 13 җитәкчесен газаплы җәзага тартканнар: махсус әйләнеп торган көпчәктә җәзалаганнар (“көпчәкләгәннәр”), кабыргаларыннан асып куйганнар, казыкка утыртканнар (И.Акманов). “***Төбәкнең җирле халкын куркыту өчен, җәза бирүчеләр газаплауның башка төрләрен дә кулланганнар. Җәлладлар, 40 крестьянның берсен генә исән калдырып, 39ын бәкедә батырып үтергәннәр. Баш күтәргәннәрнең икенче бер төркемен, Казанга куып алып киткәннәр. Кышкы юлда ачлыктан, яраларыннан, өшүдән уннарча кешеләр һәлак булган. Бер төркемен зур бинага бикләп, терелəй яндырганнар”*** (“История Татарии...”).

Тарихчы П.Рычковның мәгълүматларына караганда, Акай-Килмәк баш күтәрүчеләре чорында – *1735-1737нче елларда – Казан губернасында җәлладлар тарафыннан 696 авыл яндырылган, 16893 кеше сугышларда яки җәзалап үтерелгән, 3406 кеше сөргенгә сөрелгән, 9194 хатын-кыз һәм ятим калдырылган балалар русларга коллыкка бирелгән, баш күтәрүдә катнашкан волостьлардан, штраф итеп, 17154 баш терлек, 9223 сум акча тартып алынган. Баш күтәрүнең дистәләрчә җитәкчеләре Рогервикка каторгага җибәрелгән* (С.Алишев, В.Витебский).

Әлбәттә, Вахит Имамов үзенең китабында Идел буе һәм Урал тирәсендәге халыкның патша золымына каршы батырларча көрәшен һәм патша мөридләренең баш күтәрүчеләргә карата кулланылган күп санлы коточкыч җәзалар бирүен тасвирлавы хәзерге татарларда русларга нәфрәт, алардан үч алу хисләрен кабызу һәм аларны үзара ызгыштыру нияте белән эшләнмәгән. Һич кенә дә алай түгел. Кемдер шулай уйлый икән, бу зур сафсата. Әгәр дә йөзләрчә, меңнәрчә еллар элек булган вакыйгалар, гамәлләр өчен, хәзер бер-береңнән үч алу юлына басасың икән, төрле милләт

кешеләре, төрле халыклар бер-берсе белән берөзлексез сугышып торырлар иде.

В.Ш.Имамовның “Татарларның яшерелгән тарихы” китабы хәзерге буын кешеләре үзләренең тарихларын яхшырак белсеннәр, андагы яхшы, игелекле гамәлләр һәм вакыйгалардан да, ямьсез күренешләрдән дә хәбәрдар булсыннар дигән максат белән язылган. Үткәннәрне белү, мәгълүм булганча, элекке кешеләрнең уңай һәм тискәре якларын исәпкә алып, алардан сабак алып, хәзер дөрес яшәү һәм киләчәктә бәхетле гомер кичерү өчен кирәк. Бу бөтен кешелекнең, барлык халыкларның хаклык һәм гаделлек белән яшәве өчен мөһим шарт, аксиома, һәм моны һәркем белеп торырга тиеш.

Вахит Имамовның бу китабы бик актуаль темага язылган, ул бигрәк тә бүгенге көн өчен әһәмиятле. Сәбәбе шул: татар халкының киләчәге торган саен өметсезрәк була бара, аның әдәби теле үзәк хакимиятнең төптән уйланылмаган чаралары һәм җирле органнарның югарыдан килгән күрсәтмәләргә сүзсез генә риза булып торулары, шулай ук татарларның шактый зур өлешенең ана телен өйрәнү-өйрәтү, белү, куллану проблемаларына битараф һәм хәтта тискәре карашта булуы аркасында, үзенең вазифаларын үтәүдән туктауга һәм, димәк, үзе дә бетүгә йөз тота. Хәлбуки, халык, милләт, теле, аеруча әдәби теле югалса, үзе дә бетүгә дучар була.

Мин, телебезне саклауны, аның дөреслеген, сафлыгын кайгыртучы кеше буларак, татар әдәби телен югалтмас өчен, безнең кешеләрдә милли горурлык тәрбияләү аша туган телләренә уңай мөнәсәбәт, аны өйрәнергә һәм белергә теләк булдыруга ирешергә кирәк дигән карашта торам. Халыкның милли горурлыкка ия булган лаеклы улларын һәм кызларын тәрбияләүдә яшьләрнең һәм урта буын кешеләренең, хәтта өлкәннәрнең дә халкының үткәндәге лаеклы тормышын, аның бай традицияләрен, тарихының матур сәхифәләрен, данлыклы кешеләренең биографияләрен белү бик әһәмиятле роль уйный.

Татар халкының якты киләчәге өчен борчылып, көрәшеп яшәгән, нәтиҗәле иҗат иткән күренекле Вахит Шәех улы Имамовның “Татар халкының яшерелгән тарихы” дигән китабы – үз халкыңның язмышына битараф булган кешеләрдә элгәреләренең фидакарь гамәлләре, киләчәк буыннарның бәхетле яшәве өчен

үзләрен корбан итүләре мисалында шанлы тарихларына зур хөрмәт һәм халкын, аның мәдәниятен, телен, уңай традицияләрен, гореф-гадәтләрен саклап үстерү өчен җаваплылык хисләре уяту бурычын үтәүгә багышланган кыйммәтле хезмәт.

## ЭЧТӘЛЕК – ОГЛАВЛЕНИЕ


**ТЕЛНЕ САКЛАУ ҺӘМ ҮСТЕРҮ**
**СОХРАНЕНИЕ И РАЗВИТИЕ ЯЗЫКА**

Тел өлкәсендәге мөһим бурычлар ........................................... 3
Телебезне саклап кала алырбызмы икән? ........................... 11
Сумеем ли сохранить свой родной язык? ............................ 15
Международный день родного языка ................................. 24
Сохранение родного языка – долг каждого .......................... 35

**СӨЙЛӘМ КУЛЬТУРАСЫ**
**КУЛЬТУРА РЕЧИ**

Матбугат һәм туган тел ........................................................ 42
Матбугат теленең лексикасындагы проблемалар ................ 54
Телебез үзебезчә булсын ...................................................... 80
Төгәлсезлекләр күңелне һаман да борчый ............................ 88
Туган тел сафлыгы ................................................................ 99
Сүзебезне уйлап сөйлик! ...................................................... 109
Тәрҗемә һәм сөйләм культурасы ......................................... 115
Ничек язсаң да ярыймы? ....................................................... 122
Алынма сүзләрне куллану ..................................................... 126
Ялгыш ясалган сүзләр ........................................................... 128
Морфологик күренешләрдән дөрес файдалану зарурлыгы 135
Фигыль формаларын куллану мәсьәләсе .............................. 144

**СТИЛЬ ЧАРАЛАРЫ**
**СТИЛИСТИЧЕСКИЕ СРЕДСТВА**

Кушымчалар һәм интонация ................................................. 159
Стиль чаралары буларак фигыль-хәбәр формалары ............ 165
Ярдәмлек сүзләрнең интонация төзүдәге роле ..................... 172
“Балласт” сүзләр .................................................................... 183
Дөрес сөйләм төзүдә сүз тәртибенең роле ............................ 189
Стиль нормалары һәм тавтология ......................................... 195
Сүзләрнең стилистик кулланылышы үзенчәлекләре .......... 204
Орфография һәм пунктация проблемалары ......................... 209
Эфир теле турында ................................................................. 219

**ТЕЛ СӘЯСӘТЕ**
**ЯЗЫКОВАЯ ПОЛИТИКА**

Мәгълүмат чараларына игътибар кирәк ................................. 222
Чем грозит “пускание на самотек” татарских СМИ ......... 229
Милли мәгариф һәм стратегия .................................................. 236
Ымсындыру гына булмасын иде ............................................... 239
Стратегия или успокоение народа? ......................................... 244
Төптән уйлап эшләргә иде ........................................................ 250
Полилингвальные образовательные комплексы ........... 253
Өч телдә укытумы, өч телне укумы? ...................................... 255
Кому мешают национальные языки? ......................... 258
Татар халкының гыйбрәтле тарихы ......................................... 261

12+

9 785983 563698

Юсупов Рузаль Абдуллазянович

ТУГАН ТЕЛ ҺӘМ МӘГЪРИФӘТ

РОДНОЙ ЯЗЫК И ОБРАЗОВАНИЕ

*(На русском и татарском языках)*

Редактор *Д.М. Юсупова*
Технический редактор *Н.Ф. Гимадеева*
Дизайн обложки *И.И. Ибрагимов*
Корректор *Л.З. Салахутдинова*

Подписано в печать 10.01.2020. Формат 60×90 $^{1}/_{16}$.
Гарнитура “Times New Roman”. Бумага офсетная. Усл. печ. л. 17.
Тираж 200 экз. Заказ № 268.

Издательство “Слово”.
420066, г. Казань, ул. Декабристов, 2.
Тел. 89033875914.
E-mail: Slovopress-s@yandex.ru

Отпечатано в полном соответствии с качеством предоставленного
электронного оригинал-макета
в ООО “Марийское рекламно-издательское
полиграфическое предприятие”.
424020, г. Йошкар-Ола, ул. Машиностроителей, 8г.
E-mail: marketing@mripp.net